# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ-1973

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1973


## БУ САНДА


С. ХӘКИМ. Кырларда давыл... Шигырьләр . . . 3
Х. ХӘЙРУЛЛИН. Канатлар талмасын. Повесть. Ахыры . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Ә. ГАДЕЛ. Каска. Шигырьләр . . . . . . . . . 94
Э. КАСЫЙМОВ. Һаваларда тургай. Роман. Дәвамы. 97
Ф. САФИН. Чулман. Шигырьләр . . . . . . . 119
Я. МОСТАФИН. Үземнән дә артык яратам. Хикәя 123
Ү. САТТАРОВ. Кызым хикәяләре . . . . . . 131


ОЧЕРКЛАР


С. ЗАКИРОВ. Тормышка ашкан хыял . . . . . 137


СӘНГАТЬ


Г. АХУНОВ. Сәхнәдә — Айрат Арсланов . . . 142
С. ЧЕРВОННАЯ. Туганнарча дуслык шартларында. 147
Я. НУРЛЫГАЯНОВ. Моңнар чишмәсе . . . . . 155


ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


З. МӘҖИТОВ. Тимерче сугышта. . . . . . . 160


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Ф. ХӨСНИ. Без китмәскә килдек! . . . . . 172



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Әйдә киттек сәфәргә . . . 180
М. ВӘЛИЕВ. Карлыгач күктә очсын . . . . . 182

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

В. СЕМЕНОВА. Зур дуслыкның бер истәлеге . . 185

## ЮМОР-САТИРА

З. НУРИ. Ут ник сүнде! Шигырьләр . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 10/XI-1972 ел. Басарга кул куелды 16/I-1973 ел. ПФ 04007. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84346 экз.
Заказ Г-729. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

## Сибгат Хәким

* * *

Кырларда давыл, кырларга
Бер генә кара, дустым;
Арышлар уйный җилләрдә,
Дулкыннар кара-кучкыл.
Әйтерсең үткән сугышның
Калган көле кушылган,
Кушылган сагыш аларга,
Шуңа кара-кучкыллар.
Төшәләр түбән, күтәмен
Кабат чыкканын шуннан,
Калкалар ерак елларның
Кара сыртлары сыман.
Моңнарым баса башымны,
Бетми торган моңнарым,
Онытма, мәңге борчулы
Шул кырларда мин барын.

* * *

Тукта, бер үткән гомерне
Искә төшерим дисәң,
Искә төшереп, бурычны
Өстән төшерим дисәң,
Башка мәшәкатьләреңнең
Карамый барлыгына,
Ялгызың тот та кырга чык,
Карабодай кырына.
Иртән дә, көндез дә түгел,
Көт кояш баеганын,
Көт шәфәкъка манылганын
Ышнада каеннарның.
Карабодай чәчәгенә
Йогар шәфәкъ сарысы,
Хисләргә йогар сарысы,
Уйнар күңел сагышы.
Ахрысы, бу якты дөнья
Бездән дә кала бугай,
Офыклар артына батып
Бара күк карабодай.

* *

Күрше бит... Авыр, күңелсез,
Гомумән, кемдер үлсә.
Бакчасы. Чәчәкләр белән
Беррәттән киндер үсә.
Өч бөртек истәлек-киндер.
Юк эше, юк карасы.
Иделдә авыл, авылда
Иске йорт, җеп кабасы.
Гел киндер суккан анасы.
Шүреләр дә сусалар...
Идел буеннан җепләрне
Еллар монда сузалар,
Сузалар, ике арада
Йөриләр киләп сарып.
Гөрләп яшәр чак, тормышны
Җибәргән көйгә салып,
Өзелә кебек шул җепләр...
Көз. Шакый берсе, җилдер...
Тәрәзәм каршында минем
Үсә өч бөртек киндер.

* * *

Күпме моңайдым авылда
Тәрәзә кадакланса;
Моңайдым караңгы, төпсез
Сүнгән күз карап калса.
Моңайдым күреп нигездә
Ташлар да тузан, тирес;
Иң авыр хисләр уятты
Ташланган, тузган нигез.
Гүя белмичә йөргәнмен
Яшәүнең элек тәмен,
Ничә кат үлеп терелдә
Күңелдә өметләрем.
Яшәр күк иде шул нигез
Төзәлмәс яра булып,
Кайтам, нәкъ иске урында
Яңа йорт, яна бер ут.
Төпләнә, урнаша, яши,
Кулы нык, өйләре нык,
Бирешми шаукымга, бәлә,
Яшәүгә ышана нык.
Юк, бетми нигезләр, халкым
Давылы, җилләренә
Бирешми, бара, ышанам
Мәңгелек җегәренә.

* * *

Кайдан татар шагыйрьләре?
Өчиледән, Дүртиледән
Поэзия дөньясына
Шаулап күпме кеше килгән.

Кайдан татар шагыйрьләре?
Котлап, мактап мин кул чабам,
Талантлылар, ә үзләре
Такталачык, Дүртмунчадан.

* * *

Сугышта һөҗүмдә белдем:
Тылың нык булсын икән.
Шигырьдә тылың — тарихың,
Телең нык булсын икән.

* * *

*Габдулла Шамуковка*

Ходайдан мин сорыйм: алданрак,
Яки соңрак, димен, ал җаным,
Тимә миңа, тимә син миңа
Сабан туе көнне Арчаның.
Мин мәйданда... Мәйдан таралгач,
Бүтән төштән мине син эзлә.
Минем өчен дөнья рәхәте —
Кайту шул көн кичке поездда.
Кала болын артта чәчәктә,
Кала кырлар, кала су-инеш,
Тыгыз, кыен, керә вагонга,
Килеп керә мәйдан шул килеш.
Гармун керә, төшкән салынып
Гармуннардан арып кулбашы.
Тыңлыйм шул кич халкым моңнарын
Җаным тәмам гарык булганчы.
Кешеләрнең ачык йөзеннән
Бар уйларын шунда укыдым,
Рельслардан өскә күтәреп,
Бөек көче шулар рухының
Каядыр бик ерак-еракка
Илтә сыман, узып Казаннан,
Барам, барам, мин бу поездан
Теләсәм дә төшеп калалмам,
Телем, рухым шушы поездда,
Әллә нинди үзенә бер поезд,
Саклап барлык изге хисләрен,
Тигез торсын иде йортыбыз.
Ходайдан мин үтенәм: кичектер,
Халәтемнең үлчәп бар ягын,
Тимә миңа, тимә син миңа
Сабан туе көнне Арчаның.

* * *

Үз ягы үзенең йөзендә
Ни әйтсәң дә чагыла,
Чаллыдан, үткән-узганы,
Киләчәге Чаллыда.
Яңа, зур йортлар алдында
Аның турайганын бер
Күзәтәм, йөзендә моңы
Чаллы тугайларының.

Минем дә шунда йөрәкнең
Бәрелде кыллары бер,
Йөзендә кичке салкыны
Бәрәңге кырларының.
Тарихын, гореф-гадәтен
Бер төшкә җыя торган
Олылык, хәтта нидер бар
Мәчете, зиратыннан.
Таныйм йөз меңнәр эченнән,
Сакал, чәче чал гына...
Тукта, ни булды дигән күк
Карап торам Чаллыга.

* * *

Аны маляр кыз диләр...
Охшамаган малярга,
Шәһәр сәхнәләренә
Чыгып басса әгәр дә?
Аны маляр кыз диләр...
Ил үстергән яшь гөлен,
Хәтерләтә сәхнәдә
Ильская яшьлеген.
Аны маляр кыз диләр...
Хисләр җыр булып ага,
Нинди маляр! Сәхнәдә
Тиң ул Ермоловага.

* * *

Атка күпме өмет багладым,
Бер сукыр ат иде — бар малым.
Кечкенәдән миндә ат җене,
Кырга чыксам, тартты ат юлы.
КамАЗда ат. Атны җәлләдем,
Күз алдымда төште ат чоры.
Без җиккән ат. Сәер, бик сәер
Башка заман, башка масштаб,
Чорлар — баскыч, Кама ярына
Күтәреләм атлап-баскычлап.
КамАЗда ат. Ерак бер вәкил.
Көтүләрдән чабып монда кил.
Өреккәнме бөек КамАЗдан,
Ике күзен аның кан баскан,
Чорын яклап үрә торган ул!
Кем дә әйтмәс: үлә торган ул...
Күзендә моң: тизрәк дагала,
Үткәнемә озат, далага!

Мин ялынам: басып кал шунда,
Тимерчелек цехы каршыда.

* * *

Бар нигезләр бергә буталганда,
Күкрәгемне кайнар ут алганда,

Кургәннәрне теркәп кәгазьгә,
Мин дә йөрдем, йөрдем КамАЗда.
Кама бөек һәм тарихы бөек,
Бөтенесен бер таныйсым килеп,
Торам ярда, Чаллы яланнары...
Ишетелми чалгы янаулары.
Кара-кучкыл булып акты Чулман,
Карады күк Болгар үзе шуннан,
Калтырап ай йөзде су эчендә,
Экскаваторның чүмечендә
Чәбәләнде ае Болгарның,
Болгандың син, Кама, болгандың.
Вакытлы өй-вагоннарга кердем,
Әйтерсең лә давыллардан кердем,
Алды чорнап хисләр давылы,
Чоры шундый, шундый дәвере...
Зур эшләрнең безнең бар бит кылган,
Ташладың син, чорым, Магниткадан
Сталинградка безне, Дугаларга...
Батырлыклар... исәп юк аларга,
Магниткалар аша, язлар аша,
Бөеклекләр — мин КамАЗлар аша
Барам һаман алга, алда — ялан,
Актарыла җирем, кайный ягым,
Янам мин дә, шунда бергә янам,
Чорым, синең хисләр белән янам.

* * *

Партия стажым өч дистә.
Горурланып әйтәм: Дугадан...
Булган, узган. Юлда ник тукталам,
Атларымны нигә тугарам,
Ник ул хакта бүген мин уйланам?
Күптән тынды тавышы зур чаңның:
Булган, беткән. Искә төшеп бүген
Сөендерә нигә шул чагым?
Партиягә кергәнемне хәтта
Сизмәгәнмен, хисләр дулкыны,
Тыл, фронтның көчле бер дулкыны
Алгы сафка чөйгән туп-туры.
Кергәнемне сизмәгәнмен хәтта,
Карьерасы, посты, чиннары
Һич килмәгән башка, син — азатлык,
Син — бәйсезлек, солдат син бары.
Партиядә стажым өч дистә,
Сугышып, яулап алган стажым.
Ә остазың? Остазларга килсәк:
Халык белән Ленин — остазым.

1972

Хәниф Хәйруллин

# КАНАТЛАР ТАЛМАСЫН

ПОВЕСТЬ



Район культура йортында партия активы җыелышы бара. Рәшат Галиевич докладыннан соң авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Урмакаевка сүз бирделәр. Ул төп фикерне әллә кайлардан урап алып килде, авыл хуҗалыгын, аеруча терлекчелекне специальләштерүнең әһәмияте, отышлы якларына тукталды, кайсыдыр өлкәләрдән мисаллар китерде. Президиумда утырган Рамайның эче поша башлады. «Нигә корыны бушка әйләндерә инде, конкретын гына әйтсен дә бирсен иде»,— дип уйлады ул. Район Советы башкарма комитеты председателе Вәрәшов та әнә маңгаен сыпырып-сыпырып куя. Рәшат Галиевич та берничә тапкыр трибуна артында акыл саткан Урмакаевка карап алды һәм, ул да түзмәде, ахрысы: «Конкретрак, конкретрак»,— дип пышылдады. Урмакаев моны ишетте булса кирәк, бер кулы белән трибунага таянды да:

— Ә конкрет килгәндә, иптәшләр, безнең барлык колхозлар да итсөт юнәлешендә специальләшергә тиеш,— диде һәм зур, каз тәпие төсле кызыл кулы белән авызын каплап йөткереп алды, аннары сүзен дәвам иттерде: — Ә тавык, сарыкны барлык хуҗалыкларда да асрау, карлик фермалар тоту зыян гына китерә. Авыл хуҗалыгы идарәсе исеменнән без бу мәсьәлә буенча менә нинди тәкъдимнәр кертәбез. Ул райком бюросында да каралды. Беренчедән, кошчылык фермаларын дүрт хуҗалыкта гына калдырабыз. Һәрберсе елга бишәр миллион йомырка житештерә торган...— Урмакаев шул «бәхеткә» ирешкән хуҗалыкларны санады да кошчылык фермалары бетерелергә тиешле колхозларның исемен укып чыкты.— Бусы менә шул! Ә сарык асрауны кысыр яткан таулары күп булган урыннарда гына калдырабыз. Анысы әле конкрет түгел, тиешле күрсәтмә соңыннан бирелер. Берничә хуҗалыкта, сарыклар, кошчылык фермалары алынган хуҗалыкларда, дуңгыз асрау артачак. Шуннан чыгып, кайбер хуҗалыкларда дуңгызчылык тармагы да калмаячак, аларда савым сыерларны арттырырбыз.

---

Ахыры. Башы 1 санда.

Урмакаев трибунадан төшү белән зал бер мәлгә тын калды. Аннан пыш-пыш сөйләшү китте. Рәшат Галиевич торып басты һәм залга күз йөртеп чыкты да:

— Кемдә нинди тәкъдимнәр бар? — дип сорады. Зал тагын тынды. Шул чак Һәнүзнең кул күтәрүен шәйләп алды. Әнә ул кулын алга сузган килеш әкрен генә урыныннан торды. Рәшат Галиевич аңа кулындагы карандашы белән ишарәли-ишарәли сүз бирде: — Әйдә, әйдә, иптәш Гумеров.

Һәнүз торып басты, бер президиумда утыручыларга, бер залга күз ташлады, аның йөзенә гаҗәпсенү катыш сорау галәмәте чыккан, иреннәре тартышып-тартышып китә иде:

— Специальләшкән фермалар оешмаган килеш фермаларны бетерү дөрес булырмы соң? — дип сорады ул. Рамайның бит очлары кызышты... «Минем кебек уйлый бу, югыйсә, бу турыда аның тел тибрәткәне дә булмады. Вильданов жырын җырлый инде бу, диләр инде хәзер житәкчеләр»,— дип уйлады ул. Урмакаев сорауга җавап бирергә дип урыныннан күтәрелгән иде, Рәшат Галиевич торып баскач, ул яңадан утырды.

— Дөрес сорау,— диде Рәшат Галиевич.— Кошчылыкны специальләштерү зур чыгымнар сорамый. Инкубаторда чебешләр чыгарыла башлады. Чеби үстерү мөмкинлеге булган колхозлар хәзер кошчылыкка специальләшәчәк. Ә яздан ук аларга типовой проект белән кетәкләр төзеләчәк. Башка малларны, ягъни хуҗалыкларны специальләштергәндә, бер колхоздагы сарыклар икенчесенә, бер колхоздагы дуңгызлар икенчесенә генә күчәчәк, бу үзгәреш район балансында сизелмәячәк, баш саны элеккечә калачак. Ә специальләшкәч, продукция житештерү алдынгы технология нигезендә үсәчәк, аңлашылдымы?..

Шул чак тагын Һәнүз чәчрәп тормасынмы!

— Ни әйтсәгез дә әйтегез, Рәшат Галиевич, бу уйланып бетмәгән әле. Специальләшкән хуҗалык аякка басмыйча, мәсәлән, мин үзебездә кошчылык фермасын бетерү ягында түгел.

Тартай теленнән табар дигәндәй, бу дуамал репликасы өчен Һәнүзгә трибуна янына басарга туры килде. Анда да Һәнүз үз фикереннән кайтмады. Җитмәсә, президиумдагыларга карап:

— Специальләшү турында сүз куерткачы, салам ягын кайгыртасы иде хәзер. Ни ашатырбыз кышын малларга? Бөтен басу яна бит,— дип әйтеп ташлады. Бу сүз Рәшат Галиевичның болай да нык тартылган кылларына китереп бәргәндәй булды.

— Сездән сорамабыз, утырыгыз! — дип, Һәнүзне трибунадан куып төшерде.

Җыелышның рәте булмады. Фермаларны специальләштерү, ягъни аерым тармакларын булдыру турында әйбәт карар кабул ителсә дә, аның үтәләчәгенә тәгаен кем генә чын күңелдән ышанды икән. Һәнүзнең җыелыштагы чыгышының шаукымы Рамайга да кагылмый калмады. Нәкъ ул уйлаганча булып чыкты. Башкалар таралып, колхоз председательләренә, партоешма секретарьларына агымдагы эшләрнең барышы буенча ашыгыч күрсәтмәләр бирә башлагач та, Рәшат Галиевич Рамайга сорау бирде:

— Сезнең саламыгыз җитәрлекме?

Рамай ялт кына торып җавап кайтарды.

— Үзебезгә җитәргә тиеш, Рәшат Галиевич.

— Җитсә, сездән салам сорамабыз! Үз фикерләрегезне борын асты кибәргә өлгермәгән малайга көчләп такмагыз һәм аны үзегезнең рупорыгыз итмәгез. Әллә сез монда берни аңламый торган бала-чага утыра дип беләсезме? Табылган районда бердәнбер акыллы баш!..— Ул беравык туктап торды һәм тагын сорау бирде: — Әйтелгән ашлык чыгарылдымы?

— Артыгы белән, Рәшат Галиевич, өстәп, йөз илле центнер тары да озаттык.

— Утырыгыз!

Рамай, урынына утыргач, кульъяулыгы белән маңгаен сөртте, иркен сулап куйды.

Башта кош фермалары калдырылачак колхоз председательләреннән специальләшүгә хәзерлекнең барышын сорап чыктылар. Аннары тавык асрамаска тиеш колхозларга шушы көннәрдә тавык-чебешне Бөгелмә комбинатына илтеп тапшыру көннәрен әйтеп чыктылар. Сүз шул турыда бара башлагач, күрше «Игенче» колхозы председателе чәрелдек тавыш белән президиумдагыларга — бюро членнарына мөрәҗәгать итте.

— Бөгелмәдә алмыйлар аны, әллә ничә кат колхоз базарында юк кына хакка чатып кайтырга туры килде. Үзебезнең колхозчыларга гына чатып булмыймы? Ичмаса, юл рачходларыннан котылырыек.

Бу сүзгә Урмакаев кабынып китте:

— Нәрсә сез, Шамил Сабирович, үз бизмәнегез белән генә үлчисез? Монда район җитәкчеләре һәр кило ит өчен ут йотып утырганда сез таратып бетерү юлын каерасыз! Аннан башка да колхозны талаучы җитәрлек.

«Игенче» председателе дә югалып калмады:

— Анычы дөреч, әйтерең бармы? Чуга батып үлүчеләрне коткару җәмгыятеннән башлап кем генә чыртын кашымый колхозның, әле дә түзә инде...— диде.

Ул авызын йомуга залдагылар дәррәү көлеп җибәрделәр. Рәшат Галиевич, алдында торган графинага карандашы белән бәргәләп, залны тынычландырды да:

— Шамил Сабирович, кәмит оештырмагыз, мәсьәләгә җитди килергә кирәк,— диде.

— Мин дә шаярып чөйләмим инде, Рәшат Галиевич.

Шамилнең бу җавабыннан зал тагын көлеп җибәрде.

Җыелыш үзәк мәсьәлә тирәсенә төпле фикер туплый алмыйча таралды.

Культура йортыннан чыгу белән Рамай райпотребсоюз председателенә сугылды. Бу постта әле яңарак эшли башлаган, элек авыл хуҗалыгы идарәсендә экономист булып утырган Җәлилов аны үз итеп каршылады. Аның белән уртак тел тиз тапты Рамай. Өченче квартал тәмамланырга аз гына калып бара, кайтарасы товары күп икән, машина вәгъдә итү белән, Рамай кайтасы дүртенче квартал һәм яңа елның беренче кварталына да кармак салды. Өченче квартал исәбендәге комбикорманы, Чаллы элеваторыннан алган отходларны да җыештырганда меңярым центнерлап фураж хәстәрләде инде. Бер кулы белән бирде, икенче кулы белән алды, димәк, махы бирмәде. Кыш узганчы Рәшат Галиевич кына сизмәсен. Мал авызына кереп беткәч, сизсә дә берни юк.

Рамай райпотребсоюздан канатланып чыкты. Урамга аяк басу белән «Игенче» председателе Шамил очрады. Ул да райпотребсоюзга таба килә иде.

— Кемне, күпмегә алдадың, Рамай? — диде ул, кысык күзләрен тагын да кыса төшеп. Рамай аның юанаеп килгән корсагына баш бармагы белән төртте дә:

— У-у! Харам малың һаман үсә, тирәү саласы гына калган, ничек күтәреп йөрисең аны? — диде, сорауны ишетмәмешкә салынды. Ә Шамил соравын тагын кабатлады:

— Күпмегә алдадың дим, ничек, моны алдап буламы соң? Әле минем йомыш төшкән юк.

— Синең кебек алдакчымыни мин!..

Шамил:

— Алдамагач предчедатель буламыни ул, хәчрәт! — диде дә райпотребсоюз капкасыннан кереп китте. Рамай аның артыннан елмаеп карап калды һәм кесәсеннән блокнотын алып: «Иртәгә 3 машина райсоюзга, барганда дуңгыз төяргә»,— дип язып куйды.

Ул арада бер төргәк плакат күтәреп, Яхъя Курмашев та килеп җитте.

— Күренмиләрме? Озаклаганнар,— диде ул һәм: — Ронога да сугылдым әле, ике укытучы җитми бит. Юанычлы сүз әйтмәделәр,— дип өстәде.

— Аяз көнне йолдыз санап йөри торгандыр,— диде Рамай, Бөгелмәгә Сәвияне алырга киткән Дамирның озак йөрүенә эче пошып. Рамайның күңеле нидер сизенгәндәй тынычсызланып куйды. Ул сәгатенә карап алды. Дүрт тулып килә иде инде. Райпотребсоюздан туп кебек тәгәрәп Шамил Сабирович та килеп чыкты. Яхъя аны күрү белән:

— Рамай Ибраһимович, син көтсәң көтәрсең, мин Шамил ага белән китәм,— диде.

Рамай, киләп сара башлаган уйларыннан арына алмыйча, башын иде. «Нишләргә, көтәргәме, әллә миңа да иярергәме?» дип уйлады. Универмаг янында торган Шамил «Москвич»ы өзек-өзек сигнал бирде. Рамай башын шул якка борды. Машина тәрәзәсеннән олы башын чыгарып, Шамил аңа кул болгый иде. Рамай җәһәт кенә шунда таба атлады.

— Әйдә кайтабыз, Рамай,— диде аңа Шамил, күзләрен челт-челт йомып.— Үкенмәччең, бажай Камчаттан почылка җибәргән, ачып карадым, эчендә рәт шактый, котырган үгез канына кадәр...

Рамай башта икеләнеп калды, Сәкинәгә бергә кайтырга вәгъдә биргүен исенә төшерде, килеп чыкмаслармы дип югары очка тагын бер күтәрелеп карады да, күренмәгәч, кулын селтәп машинага кереп утырды. Яхъя да шунда иде. Кузгалдылар. Саз күперен чыкканда Шамил артына борылып утырды, утыргыч аркасына ияге белән таянды һәм сакал баскан түгәрәк битен ышкый-ышкый:

— Бу эч-эчпитчиәлләшү белән утырмаек дим әле мин, Рамай. Миңа менә кошларны, чарыкларны бетерергә кушалар. Дуңгыз күп булырга тиеш миндә, аннары чыер җәнлеге... Типовой тораклар төзегәндә, механикалаштырганда аларның баш чанын арттырырга кирәк. Ә аны чалырга кем акча бирә?

— Мал чалырга акча кирәкмени, пычак булса җиткән,— дип бүлдерде аны Рамай.

Шамил аксыл кашларын, түмәр кебек борынын җыерды да:

— Шаярма әле чин, первый раз тыңламыйчың минем чөйләгәнне,— дип сөйләп китте, күңелендә җыелган уйларын аның да чишәсе килгәндер инде,— чыерларга да, дуңгызларга да типовой абзарлар кирәк. Ә өчтәмәгә — тәпи кычка. Аннары нишләп тавык белән чарыкны бетерим ди мин. Урлап булча да ачрыйм мин аларны. Үзең ичәплә, анычы килә, монычы килә, Казан артичтлары килгән чаен тана егып чуеммы мин? Юк, эчпитчиәлләшкәндә дә тавык белән чарыкның орлыгын кортырга ярамый колхозда...

Рамай аны рәхәтләнеп, үзе уйлап йөргәнне чит кеше раславын ишетеп, куанып тыңлады. Шәкүр абзый, Шамил, һәнүз дә нәкъ шулай фикер йөртәләр икән. Аның уйлар йомгагын тагын Шамил үз кулына алды:

— Яшь булча да зоотехнигың боевой чинен. Шарикләры да эшли күренә. Чинең Әхмәтзыяң да зоотехник бит, үзең дә. Җиппәр әле миңа шуны,— диде Шамил.

Аның сүзенә колак салып кайткан Яхъя сүзгә кушылды:

— Сиңа эләксә гел бозыла ул, син үзең дә аннан әллә ни китеш түгел бит,— диде көлеп. Шамил күзләрен челт-челт йомды.

— Әллә ул гөнаһачы бармы?
— Ике йөгән кидереп кенә тартегә кертәбез.
— Кара, чукынган! Яшь бит әле ул, кай арада өлгергән?
— Өлгерергә җимеш түгел ул...
— Шулай да башлы малай...
— Семья белән генә бәхет читләткән аны.
Монысын Рамай әйтте.
Таш юлдан җай гына әлдергән машина тегермән буасы түренә җитә башлагач, Шамил шофер белән ике арадагы посылка тартмасына уч төбе белән сугып алды да:
— Чоң, моны кайдарак ачып карыйбыз? — диде.
Рамай тегермән артындагы әрәмәлеккә таба башы белән ишарәләп, шоферга:
— Әллә кая барып йөреп булмас инде. Кызның да кайтасы бар, борыл әнә шул әрәмәлек артына,— диде.
Шамил посылканы башта ук ачып караган икән. Аның эченнән каклаган балык, биш йолдызлы бер коньяк килеп чыкты. Яр буена, корыган үлән өстенә машина утыргычы чехолларын җәйделәр. Барысы да берәр рюмка салдылар. Балыгы симез, майлы иде. Рамай аны яратып ашады. Бүксәләрен бүлтәйтәп, кырын яткан Шамил, балык башының саңакларын аера-аера, сүз башлады:
— Рамай, Яхъя, мин чезне, чез мине күптән беләчез, аллага шөкер, мин дә уналтынчы елым колхоз камыты чалмаган килеш. Билетларыбыз да барыбызныкы да бер төчле. Бер әйбер турында уйлаганыгыз бармы чезнең?
Рамай белән Яхъя сагая төштеләр. Югары белемле агроном, колхоз тормышын инә күзеннән үткәргән бу кеше тәҗрибәле дә, үткен дә, җор да, вакыты белән, үзенә кирәк булганда, берни белмәмешкә салынып, башын юләргә дә сала белә иде.
— ...Уйлаганыгыз бармы? Чоңгы елларда безнең районда шомарту бара бит, егетләр. Бигрәк тә Маклаков киткәннән соң. Күбрәк бүгенге көн белән яшибез түгелме? Тунга тизрәк чөерергә кирәкме, кирәк. Ни комачаулый моңа? Бачу тулы чалам. Урмакаев гел пожарникка әйләнеп бетте бит хәзер. Үзе яндырып йөри. Безнең бачуга килеп, үзе ут төртеп киткән. Яхшы, малайларны кисәтеп куйган идем. Урмакаев китү белән тракторчылар чүндергәннәр. Бу бит үзең утырган ботакны чабу!
Рамайның сүз куертасы килми иде. Ул Шамилнең үзенә төртеп:
— Шомартырга син үзең дә оста, Шамил. Маклаковка күрсәткән кукурузыңны гына хәтерлә,— диде.
Яхъя, балык әрчи-әрчи, Шамилгә дәште:
— Нәстә ул, Шамил, минем ишеткән юк,— диде.
Шамил йөзен чытып, кулын гына селтәде:
— Чәйнәделәр инде шуны, Федор Михайлович та ничә тапкыр пленумда чөйләде.
— Я, сөйлә инде, шуны гына сөйлә дә, мәҗлес тәмам.
— Чыннан да булдымы соң ул?
Рамай да сорагач, Шамил сөйләми булдыра алмады.
— Үткән эшкә— чалават, диләрме әле? Шулай да булды ул хәл. Баш чатнап авырткан чак ие. Телефоннан чорыйлар бит. Кукуруздан уныш билгеләдегезме? дип. Билгеләдек, мин әйтәм. Күпме? диләр. Мен ярым булыр, мин әйтәм. Шуннан китте ул кулача әйләнеп. Маклаковның яңа килгән чагы. Колхозлар белән танышып йөргән чагы. Килде бу безгә. Кая, Шамил Сабирович, ди, теге 1500 ле кукурузыгызны карыйк әле, ди. Инәеңне ата-аначы белән чабраниегә җибәрим, мин әйтәм, моңа да житкергәннәр икән! Үзем баш кашыйм, үзем уйлыйм. Ничек чудан коры чыгарга. Моментыннан котылырга кирәк бит. Ичкә төшмәченме шунда күрше Чаллы районының кукурузы. Безнең җирләр баш-

ма-баш кына бит. Аларның кукурузы әйбәт, урман кебек. Киттек, безнең кукуруз җиренә життек. Шушымы? — ди. Юк, Чаллы районыныкы бу, мин әйтәм. Ары киттек. Чаллы районы колхозының кукуруз бачуы кырына житкәч, туктаттым машинаны. Төштек. Карыйбыз. Пәрәме — карурман...— Шамил көлә башлады да авызын учы белән каплады:— Федор Михайлович, менә шушы, 1500 центнер чыга моннан, дим. Маклаков кукурузга чокланып карады да: — Анычына бәхәчләшмим. Кем күпме яздыра, вөжданына карый, әмма уңышы әйбәт моның,— диде. Менә шул... Инде моннан котылдым, онытылды бу хәл дип йөргәндә, кукуруз урганда Маклаков килеп чыкмачынмы. Үзем дә кукуруз бачуында чак. Үзебезнең кукурузны урабыз.

— Ә теге урылганмы соң әле? — дип бүлдерде аны Яхъя.

— Тора, чтена кебек тора шул, күренеп тора.

— Я, я, шуннан?

— Шуннанмы? Ник тегечен алдан урмыйчыз, аның урыны күбрәк бит, ди Маклаков. Җавабын таба идем, шул чак тракторчы, авызын корт чаккыры, ул безнеке түгел бит, Чаллы районыныкы, дип әйтеп ташламачынмы. Маклаковның кашлары җимерелде, борыны киерелде.— Как так? — дип кычкырып җибәрде. Мин торам башны түбән иеп.— Дөречме? — дип килә бит бу минем өчкә ыжгырып. Чутып ега, мин әйтәм, хәзер. Бала башы чаклы йодрыкларын күтәргән. Ну, менә шул. Шуннан җае килгән чаен көлде инде миннән.

Рамай да, Яхъя да инеш буйларын яңгыратып көлделәр. Баш очыннан гына бакылдап кыр үрдәкләре очып китте. Аларның канат каккан тавышларына кадәр ишетелеп калды.

Яхъя көлә-көлә урыныннан торды. Рамай шешәдәге коньякка күз кыскан иде, Шамил:

— Анычы карчыкка, нәфчеңне чузма! — дип шешәне бөкеләп, посылка тартмасына ук салып куйды.— Өеңә тикле илтеп куйыйммы, Рамай? — дип, Шамил дә аунаклый-мүкәли урыныннан торды. Рамай, өсбашын кага-кага:

— Рәхмәт, Шамил, күпер чыгасы да тыкрык кына менәсе бит,— диде.

«Москвич» кузгалып китте. Рамай белән Яхъя авылга таба атладылар. Яхъяның бер төргәк күргәзмә әсбапларын Рамай күтәрде. Тыкрыкка кергәндә Кызыл таудан нарат алып кайтучы машиналар куып житте. Урманчыга колхоз аша рәсмиләштереп бер мотоцикл алып биргән иде, шуңа илле фесметр эләктерде. Өй салучыларга түшәм-сайгаклык өләшкән иде. Шуны алып кайталар. Шоферлар Рамайны, сигнал бирә-бирә, сәламләп үттеләр.

— Җаннарын бирерләр иде синең өчен,— диде Яхъя, тузаннан качып юл читенә чыга-чыга. Рамай дәшмәде. Ул олы юлга таба каерылып карады. Юк, «Волга» күренми иде.

Кайтмаганнарын белсә дә, капканы ябу белән, болдырга йөгереп чыккан Сәкинәдән:

— Юклармы? — дип сорады.

— Юк шул, ул-бу гына булмаса инде,— диде Сәкинә аһ орып. Ул затлы күлмәкләрен кигән. Әллә кершәннәр дә сөртеп җибәргән инде. Килешеп тора тагын үзенә. Кызы алдында карт булып күренәсе килми инде үзенчә. И хатыннар, хатыннар...

* * *

Рамайны райбашкарма каршында төшереп калдыргач, Дамир «Сельхозтехника»ның район берләшмәсе ихатасыннан бер читтә, тирән яр буена урнашкан заправка пунктына китте. «Юлда ни булмас, азыклы ат арымас»,— дип уйлады ул. Бензин колонкасында эшләүче кыз белән

уен-көлке сүз сөйләшеп, багын мөлдерәмә тутырды. Кызга талоннар бирде дә кул болгап китеп барды.

Көз ахырлары булса да көн әйбәт, аяз, анда-санда гына каурый болытлар килеп чыга, алар биек, бик биектән агалар. Җил юк. Райүзәк урамнарының ике читенә утыртылган тупыллар, чаганнар сары шәл бөркәнгәннәр. Тротуар кырыйларына сары яфрак түшәлгән. Дамир ГАИ тыкрыгыннан сак кына борылды. Юк сәбәпне бар итеп бәйләнергә йөргән милиционерларның күзенә чалынасы килми иде аның.

ГАИ капкасын узгач, газны арттыра төште. «Минем киләсен белә инде, көтә торгандыр»,— дип уйлады һәм болони плащларын киеп, саквояжын кулына тоткан килеш квартир капкасы төбендә үзен көтеп торучы Сәвия күз алдына килде. Ул, аны күрү белән, саквояжын җиргә куя да аңа таба йөгерә...

Икесе бер класста укыдылар. Бишенчедә бугай, Сәвия аңа Совет Армиясе көне белән котлап открытка бүләк иткән иде. Аннан соң, озак та үтмәде, 8 нче март житте. Укытучылары, хәзерге парторг Яхъя, малайларга әниләрен, классташ кызларын хатын-кызлар көне белән котлап открыткалар язарга кушты. Дамир мәктәптән кайтышлый почтадан күп итеп открыткалар сатып алды. Өйгә кайту белән, сумкасын сандык өстенә атып бәрде дә, ашап та тормастан, открыткаларга хат яза башлады. Иң элек әнисенә язды. Аннары укытучыларына язып чыкты. Иң соңыннан Сәвиягә дигән открытканы алды. Бик тә матур роза чәчәкле иде ул. Дамир аңа озак кына карап торды. Чәчәк кәсәләренең кай җиредер аңа Сәвиянең сусылланып торган алсу иреннәрен хәтерләтте. Дамирның колак яфраклары кызышып китте. Ул кул сырты белән башын кашып алды һәм кире якка авыштырып, сырлый-сырлый, «Сәвия» дип язды. Аны сулышы белән өреп киптерде. Алга сузып карап торды да зур итеп өндәү билгесе куйды, сүзнең астын ике катлап сырлады. Аннары яза башлады.

Соңгы ноктаны куйганда гына әнисе кайтып керде.

— Ай, буран котыра, улым. Кичкә чаклы мал-туарга курмы салып куясы иде,— дип, кар кунган шәлен чишеп җибәрде.

Дамир да киенеп, мал-туар карарга абзарга чыкты. Чыннан да буран котыра иде. Ул сыерга печәнне лапас эчендәге сәндерәдән генә салды. Сарык бәрәннәренә ике бәйләм юкә себеркесе асып куйды.

Ел саен бер машина печәнне председатель китертә аларга. Әнисе өчендер инде. Егерме ел сыер сава.

Дамир өйгә кергәндә, әнисе өстәлдәге открыткаларны укып маташа иде. Дамир ишекне яба-ябышка кычкырып җибәрде:

— Әни, дим, укыма!

— Юк, улым, укытучы апаннарга язганны гына укыдым.

Әнисе шулай дип җавап кайтарды, үзе башындагы алма чуар яулыгыннан да битәр кызарды.

Дамир әнисенә атап язылган открытканы шул көнне кичен бирде. Икенче көнне тәнәфес араларында укытучы апаларына өләшеп чыкты. Сәвиягә бирә алмый йөдәп бетте. Көнозын җае чыкмады. Кайтканда бирергә ниятләде. Соңгы звонок шалтырау белән ишеккә атылды, тыкрык башында Сәвияне көтеп алды.

Бергә кайттылар. Инде урамга керәбез дигәндә Дамир сумкасын ачып Сәвиягә дәште:

— Сәвия, туктале...

Дамир аңа открытка сузды.

— Рәхмәт, Дамир,— диде Сәвия, пышылдап, сумкасын болгый-болгый торып йөгерде. Дамир аны куа китте. Сәвия кече капкалары кулчасына тотынгач, урам уртасында басып торган Дамирга таба борылып:

— Иртәгә чаңгы шуарга барабызмы? — диде.

— Минем чаңгы юк шул...

— Мәктәптән алырбыз! — диде Сәвия ашыгып һәм шундук капкадан кереп югалды. Дамир йөгереп китәм дигән иде, кемгәдер килеп бәрелде. Кашларына төшеп торган бүреген күтәреп караса, Сәвиянең этисе Рамай абый икән.

— Ялгыш, абый, күрмәдем,— диде ул, башын иеп. Председатель ачуланмады тагын. Дамирның иңбашына көрәктәй кулларын салды да, күзләрен кысып:

— Чаңгың юкмыни? — диде.

— Нича әйттем, алмый бит әнкәй,— дип, авыз эченнән ботка пешереп алды Дамир.

— Магазинда бармы соң?

— Бар, кыйбат түлке, ботинкалы. Ботинкасызы кайтса, әнкәй алам ди дә бит.

— Син ничәлене киясең соң?

— Утыз бишлене.

Председатель беравык дәшми торды, үз өенең олы тәрәзәләренә күтәрелеп карады, аннары Дамирның пальто якасыннан эләктерде дә:

— Әйдәле магазинга,— диде. Дамир терек-терек аның артыннан иярде. Магазинда ике-өч ир-ат бар иде, председатель гәүдәсе күренүгә алар шым-шым чыгып тайдылар.

— Кая, Фәния, чаңгылар күрсәт әле,— диде председатель. Сатучы берничә чаңгы китереп бирде. Председатель Дамирга кулын күтәрергә кушты. Дамир, сумкасын идәнгә куеп, кулларын күтәрде. Рамай абыйсы ике чаңгыны аның гәүдәсенә үлчәде дә:

— Менә бусы бара,— дип, Фәниягә икенче сыңарын да бирергә кушты. Ботинкасын карадылар. Утыз җиденче размер иде.

— Әйдә, оекбашны ике-өч кат киярсең, үсәсең дә бар әле,— диде председатель, аның башыннан сыйпап, үзе сатучыга акча сузды.— Әниеңә колхоз хисабыннан мәктәп алып бирде диярсең,— диде председатель урамга чыккач һәм Дамирның аркасыннан кагып, озын-озын атлап, Заман бабай әйткәнчә, сажин салып, өйләренә таба китеп барды. Канатлы коштай очып кайтты Дамир. Очынмаслык та түгел! Авылда кемдә, кайсы малайда бар ботинкалы чаңгы?..

Икенче көнне алар Сәвия белән көнозын Атлан тавында чаңгы шудылар. Бураннан соң тау буйларын дулкын-дулкын сырынты каплаган. Әйбәт кенә шуып төшкәндә, шул кар дулкыннарына эләгәләр дә әллә кайларга очып китәләр. Баштанаяк карга чумдылар. Көн кичкә авышканда, өзелеп ашыйсылары килә башлагач кына авылга карап юл тоттылар. Хәлләре беткән иде, көчкә кайтып җиттеләр.

Шул чаңгы шуган көннән башлап алар гел икесе бергә була башладылар. Дәресләрен хәзерләгәннән соң, китапханәгә барып, Сәвиянең әнисе янында газета-журналлар карадылар, аңа китап витриналары, стендлар оештыруда булыштылар. Шул җәйне колхоз пионер лагеренда бергә ял иттеләр. Лагерь ябыласы кичне, костер ягасы көнне, аларны алырга Сәвиянең этисе үзе килде. «Волга»да гына тирбәлеп кайттылар. Рульдә Рамай абый үзе иде. Нарат урманын чыгып, үргә күтәрелү белән Рамай абый башын борып, Дамирга дәште:

— Рәхәтме, Дамир?

— Самолеттагы кебек!

Председатель көлеп җибәрде һәм:

— Соң синең самолетта очканың бармы? — дип сорады. Дамирның ачылган авызыннан сүз чыкмый торды.

— Соң... самолет та шушылай очадыр инде,— диде ул елмаеп.

— Әйтерең юк, «Волга» — җирдәге реактив самолет ул, килмәгән җире юк. Менә укып кына бетер әле, үземә шофер итәм мин сине,— диде Сәвиянең этисе.

— Юк, ул моряк була, мин — врач,— дип, чәнгелдәп сүзгә кушылды Сәвия, үзе әтисенең чал керә башлаган бөдрә чәчләрен бутап алды.

— Я, Дамир, «Волга» шоферы буласыңмы? — дип тагын дәште аңа Сәвиянең әтисе.

— Булам, укып кына бетерим.

Авызыннан шул сүз чыгуга, Сәвия иреннәрен турсайтты:

— Таптың, председатель ташып йөрмәсәң,— диде. Моны әтисе дә ишетте, ул артта тирбәлеп кайткан Дамир белән Сәвиягә борылып карады да:

— Ә мин аны председатель, я агроном, я зоотехник итәм. Ул вакытларда председательләрне шоферлар йөртмәс, үзләре йөртерләр машиналарны, председательләр, белгечләр дию ем. Автогараждан алып чыгып китәсең, кайтарып куясың. Әнә йөк машиналарын шулай көйләдек бит хәзер. Шоферлар машинаны кабызып кына алып чыгып китәләр. Ремонт, техник карауны башка кешеләр, слесарьлар, автомеханик эшли. Алар янына ике-өч җиңел машина өстәлүдән ни зыян? Тракторчылар да киләсе еллардан шулай эшли башлаячак. Мена типовой гараж белән ремонт мастерское проектын раслаттык. Сызымнарын сызарга гына да ундүрт меңне каердылар. Ну, аны эшләтсәк, күзегез дүрт булыр. Габдерәүф абыйларыңны эшкә барганда-кайтканда ташу юк инде ул чак. Ак яка, кара галстук белән эшкә бара, кайтканда да шул ук кием. Паркка килә... Махсус бүлмәдә, аерым шкафка чиста киемнәрен салып куя. Аннары икенче бүлмәдә эш киемнәрен кия. Гаражга кереп тракторын кабыза да — әллүр эшкә! Ерак басуда булса, анда вахта машинасы белән китәләр. Нефтьчеләр кебек. Ә эштән соң паркка кайталар. Анда душта юына, парга кереп чыгалар. Аннан теге ак яка, кара галстуклы киемнәре белән ялт итеп өйләренә кайтып керәләр.

Сәвия көлеп җибәрде һәм:

— И-и-и! Кайчан була әле ул, коммунизмга чыккачмы? — диде.

— Нигә? Автогаражда эш шулай бит хәзер. Бусысын да эшлибез аның. Проекты бар, иң кәттәсе — акча бар. Төзибез, эшлибез аны. Аннары, шуны да исеңдә тот, кызым: безнең «Беренче Май» колхозы коммунизмга да беренче булып чыгачак. Тоташ бер көндә, бөтен кеше бергә чыкмаячак коммунизмга. Берәүләр алдан, берәүләр арттанрак. Ә без районда, шигем юк, беренче чыгабыз. Безнең халык әйбәт бит, уңган, тырыш. Ә мена сугыштан соңгы яшьләр, сезнең кебекләр, аякка гына бассын, дөньясын әйләндереп ташлыйбыз әле без. Сез барыгыз да миндә исәптә. Аякка гына басыгыз, эш табам мин сезгә.

Сәвиянең әтисе ул чакта юл буе колхозның киләчәге турында сөйләп кайтты. Тимер рәшәткәләр белән әйләндергән стадионнар, йомшак урындыклар тезеп куелган культура сарае, интернаты-ние белән зур урта мәктәп...

«Күпме генә вакыт узды. Алты-җиде ел булыр. Ә ул сөйләгәннәр хәзер барысы да бар бит. Рамай абый башка председательләр кебек юкка шапырына торганнардан түгел ул»,— дип уйлады Дамир. Әлмәтне чыгып, Бөгелмә юлына борылганчы ул уйларыннан арынып торды. Бөгелмә юлы белән җай гына элдертә башлагач, уйлар яңадан Сәвиягә, Рамайга барып тоташты.

«Ничек житешә дә ничек онытмый бу Рамай абый? — дип, уй йомгагын сүтеп җибәрде Дамир.— Кичке мәктәптә укып урта мәктәпне тәмамлады. Аны күреп, бөтен авыл күтәрелде. Урта белем алмаган кем генә калды икән хәзер авылда...»

Кичке урта мәктәпне тәмамлаучы олы кешеләрнең чыгарылыш кичәсен зурлап үткәрә башладылар. Аттестатлы андый кешеләрнең хезмәт хакларын да унар процентка арттырдылар. Рамай Минзәлә техникумына укырга керү белән аңа тагын дистәдән артык кеше иярде. Рамай

белән бергә барып, бергә имтихан биреп йөрделәр. Уку шаукымы әле дә дәвам итә. Имтиханга баручыларны илттереп куйдыра, барып алдыра Рамай абый. «Уку — инә белән кое казу. Юл йөреп тә изаланмасыннар»,— ди ул. Әле монда килгәндә кинәт кенә сорап куйды: «Син, малай, быел документларыңны илтәсеңме, юкмы? Ату машинадан алам мин сине»,— диде. «Аттестатның копиясен генә раслатасы калды, башка документларны хәстәрләдем инде»,— дип кенә котылды Дамир. Райбашкарма янында төшеп калганда да әллә ничек мәзәк итеп, беренче тапкыр күргәндәй сөзеп карап калды. Әллә башлыкларыннан эләккән инде.

Бөгелмәнең үзәк урамнарын узып, автовокзал янына җитәрәк, ике катлы агач йорт янында ул машинасын туктатты һәм өзеп-өзеп сигнал бирде. Менә, күбәләктәй талпынып, Сәвия килеп чыкты.

— Исән килдеңме, Дамир? Кулыңда машина була торып, ник бик озак килми тордың? Әлләниләр уйлый башлаган идем инде... Әни, әти авырмыйлармы? Мәрьям апа ни хәлдә? — дип, мең дә бер сорау биреп ташлады. Дамир аларның кайсына ияк какты, кайсына «юк», «әйе» дип кенә җавап бирде. Үзе дә юксынган, Сәкинә апасы Сәвияне барып алырга туры килер дигәч, ул көннәрне сулышы белән тартып алырдай булып көткән иде. Сәвиянең якынлыгы, әйберләрен биргәндә күпереп торган вак бөдрә чәчләре белән йөзенә, маңгаена сирпелеп китүе аны тәмам исертте. Ул керфекләрен түбән төшерде. Сәвия хәрәкәтләнгән саен аның тән төсле капрон оек кигән тыгыз балтырлары, терекөмеш йөгергәндәй, уйнаклап ала иде.

Дамир Сәвиягә күтәрелеп карады һәм:

— Квартирда әйберләрең бармы соң, апчыгышыйммы? — диде. Сәвия тырнаклары буяулы нәфис бармаклары белән аның битеннән сыйпап алды һәм:

— Бер саквояж гына, хәзер үзем... авыр түгел ул,— дип, йөгереп кереп тә китте, ачылган ишегеп ябып та тормады, шундук борылып чыкты. Хуҗа хатыны аларны кул болгап, хәерле юл теләп озатып калды.

Машина кузгалу белән Сәвия Дамирның руль тоткан көчле беләген ике куллап кочаклап алды һәм:

— Сагындыңмы, Дамир? — диде, үзе аңа табарак елышып утырды. Сәвиянең кулыннан, гәүдәсеннән бөркелгән кайнарлык Дамирның барлык буыннарына йөгерде. Бер кулын рульдән ычкындырып, ул Сәвиянең тыгыз, йомры кулбашын кочаклады, аны сак кына итеп үзенә кысты, маңгаеннан үпте. Сәвия иркәләнеп, башын аның иңнәренә салды.

— Дамир, Дамирым...

— Әү, Сәвия...

— Әйдә, берәр җирдә ял итик, көн озын бит әле...

— Рамай абый, тиз кайт, диде бит...

— Машина ватылды диярбез...

— Ышанмас ул аңа.

— Нигә?

— Минем юлда бер тапкыр да ватылганым юк.

— Ә бу юлы ватылырсың, минем өчен...

Дамир бер мизгел дәшми барды. Бөгелмәне чыккач, ап-ак каен урманын кисеп үткән асфальт юлдан түбән таба төшеп килгәндә Дамир Сәвияне тагын кочаклап алды һәм баягы сүзне дәвам иттереп:

— Кайларга гына алып барыйм икән мин сине, карлугачны? — диде.

— Матур булсын, суы да булсын. Суга карап утырырга яратам мин. Ул күңелгә тулган уйларны хәтерләтә...

Алар бер авылга керделәр. Авыл читеннән үк киртләч таулар күтәрелә, аларның башлары йөз яшәр нарат, чыршылар белән капланган. Ара-тирә тәкә маңгае кебек шәрә тау түбәләре дә күренә. Соңгы йортны үтеп, йөз метр да китмәделәр — җепкә тезелгән кебек шәмдәй нарат-

лар аллеясына килеп керделәр. Һава шундук үзгәрде: тирә-юньнән ылыс исе, нарат сагызы исе аңкый, аның хуш исе күкрәкләргә чымырдап тула. Аллеяның икенче ягында — бөдрә толымнарын җиргә чаклы ук салындырган карт каеннар. Алар да юлның ике ягы буйлап тезелгәннәр. Дамир Сәвиянең аллеяларга сокланып баруын шәйләп алды да:

— Бусы турбазага килү юлы, ә тегесе — каенлыгы — кайту, аерылу юлы. Бояр утары булган монда элек,— диде.

Аллея бетүгә олы гына аланлык пәйда булды. Анда рәт-рәт фин йортлары тезелеп киткән, тирән яр кырыенда гына пыяладан эшләнгән ашханә эчендә кешеләр йөри. Ул турыга җитү белән борынга тәмле ризык исләре бөркелде. Дамир, Сәвиягә карап, машинасын әкренәйтте дә:

— Әллә ашап алабызмы? — диде. Сәвия аның беләгеннән кыса төште.

— Юк, тамак ялгар ризыклар саквояжда да бар, анда кермик,— диде.

«Волга» пыяла ашханә янындагы асфальт юлдан упкын кебек тирән чокырга шуып төшә башлады. Сәвия күзләрен алга төбәде. Бераз төшү белән түбәндә киң аланлык күренде. Сул якта исә, текә тау итәгендәге юан нарат кәүсәләренә кадәр терәлеп, тулган айдай түгәрәк күл ялтырап ята. Аның яр кырыйларына кызыл ком түшәлгән. Бер як ярда йөзү бассейны. Ул җиңелчә басмалар белән әллә ничәгә шакмакланган. Бер басма күл уртасындагы суга сикерү күперчегенә кадәр сузылган. Аның янындагы ике ак көймә, кунаклаган аккошлар кебек, тын гына тора. Һәр тарафтан таулар белән уратып алынган бу үзәнлектә җилле көнне дә тынычтыр кебек тоелды Сәвиягә.

Машина, күлне үтеп, үргә күтәрелгән урман юлына кереп туктады. Дамир, гадәтенчә, машина ачкычын алып, күн тужуркасының күкрәк кесәсенә салып куйды. Талчыга башлаган гәүдәсен язып алу нияте белән, кулын, беләкләрен бөгеп, югары күтәрә-күтәрә киерелде һәм машинадан төшәр-төшмәс торган Сәвияне күкрәгенә кысты. Алар бер мизгел кочаклашкан килеш утырдылар. Аннары Сәвия кинәт читкә тайпылды да Дамирга:

— Саквояжны алып чык әле. Бер сюрприз күрсәтәм,— диде. Үзе тиз генә машинадан төште, кулларын очып китәргә җыенган кош кебек алга сузып, бөтерелеп алды. Дамир машинадан алуга кыз саквояжга барып тотынды һәм:

— Тамак ялгарлык тәм-томнар җитәрлек монда, әйдә кая утырабыз? — диде. Дамир аңа карап елмайды, «Волга»ның арткы ишеген ачып, утыргыч җәймәсен суырып алды, аны иңенә салып, саквояжның бер почмагыннан эләктерде.

— Әнә теге пар имән төбенә барыйк,— диде Дамир. Алар, бер-беренә сыенып, әкрен генә бер аяктан атлап киттеләр. Үләннәр инде корыган, аяк асты тулы нарат күркәсе; юлдан түбәндәге улак кебек уйсулык әле җәйге ямен җуймаган. Ул, яшел палас кебек, яшь пар имәнгә кадәр сузылган. Наратлыклар арасында адашып үскән пар имәндә дә әле көзге моңсулыкның эзе сизелми, яфраклары кара кучкыл яшел, калын. Дамир пар имән төбенә җәймәне иплән кенә җәйде. Сәвия саквояжын аның өстенә куйды да, чүгәләп, аннан консерва, алмалар, ике тәлгәш виноград алып куйды һәм, бер кулын саквояжга тыккан килеш, каршында елмаеп басып торган Дамирга озын керфекләре астыннан сирпеп карады да:

— Ә менә бу минем сюрприз... Бел! Ни диярсең, яле, юра,— диде. Дамир, башын ия төшеп, саквояжга таба үрелде. Сәвия шунда ук саквояжны каплады һәм:

— Ә син карама, болай, болай гына юра,— диде.

— Иң кадерле, изге нәрсә...

— Изге үк түгел. Беләлмисең?..

— Кадерле, изге нәрсә, ни генә булса да!..

Дамир шулай дип анын бераз дугайланып торган, коеп куйгандай муенын кытыклап алды. Сәвия көлә-көлә башын тагын да ия төште һәм:

— Ну, барыбер белмисең инде, Дамир,— диде дә, саквояждан шампан шешәсе тартып чыгарды, үзенең йөзендә шәфәкъ алсулыгы балкыды.

— Я, ник авызын белән кош тотып торасың, ач. Менә рюмка да бар,— дип, кыз саквояждан алып нечкә билле кечкенә генә рюмка суз-ды. Үзе аякларын кырыйга җай гына җибәреп, җаймә өстенә утырды, бер-бер артлы ике-өч бөртек виноград өзеп капты. Дамир бу «сюрприз» турында ни дип тә уйларга, аның кай тирәсенә килеп тотынырга белмичә аптырады.

— Рәхмәт, карлугачым, кыйгач кашым,— диде ул, дулкынлануын бик сиздерергә теләмичә. Аннары җаймә кырыена аякларын татарчалап бөкләп утырды да шампан шешәсенең бөкесен иплән кенә ача башлады. Башта бөкене ныгыткан тимер чыбыкны сүтте, бөке башына пәке очын тигереп алды. Аннан сызгырып һава атылды, бераз ак күбек парлары да сибелде һәм шуның белән шешә тынып калды. Дамир шешәне бик кыймылдатмый гына, рюмкага шәраб агызды, күбекләрне шиңдерә-шиңдерә, рюмканы кочкә тутырды. Аннары эчендә алтын нурлар уйнап торган мөлдерәмә тулы рюмканы Сәвиягә сузды.

— Чыннан да сюрприз ясаган өчен, әйдә, карлугачым, синең иреннәрең беренче татысын шампанны. Минем башка шушы да килмәде бит,— диде. Сәвия ике кулын күтәреп:

— Юк, юк, Дамир, мине кыстама, кыз бала ич мин, кара урман урталарында егетләр белән вино эчеп утырырга,— дип кырым-кырагачлана башлагач, егет башта тезләнде, аннан торып ук басты һәм:

— Әллә кем белән түгел бит син, минем белән, курыкма, карлугачым, эч, я, бусын гына эч инде. Минем кулдан бирелгән, беренче тәкъдим иткән рюмканы гына,— дип ялына башлады. Сәвия рюмкага үрелде. Эчендә вак терекөмешләр уйнагандай саф шәрабкә карап торды да, күзләрен йомып, эчеп җибәрде. Рюмканы шунда ук Дамирга сузды, үзе йөзләрен чытты, иң өсләрен сикертеп алды. Дамир да эчте. Авызларын тәмләп, бәрештереп алса да, ул аны яратып эчмәде, Сәвия сюрпризы булган өчен, аның хәтерен саклау өчен тотты бер рюмканы. Сәвия:

— Син егет кеше бит, эч, нигә эчмисең? — дип кыстаса да, Дамир уенын-чынын бергә кушып:

— Мин рульдә бит... Аннан Рамай Ибраһимович сизсә? Ул өч көн элек эчкәненне дә белә. Аннан, бәхил бул, «Волга», диярсең,— диде. Дамирның, гомумән, эчү дигән нәрсә белән алыш-биреше сирәк. Егетләр белән булган әллә нинди компанияләрдә дә ул үзенә тиешле, дересрәге, йөз грамм тирәсе тота да шуның белән исәп-хисапны өзә. Шуның өчен аны кайбер егетләр өнәп тә житкермиләр. Дамир янадан рюмкага кагылмады. Шампан шешәсен бөкеләп үк куйды. Ә тамагы ачкан иде. Консерваны ачып, Сәвия каршысына сузылып ятып, тәмләп ашады. Сәвия чемченеп кенә утырды. Менә ул Дамирның бөдрә чәчләрен сыпырып маңгаена ук төшерде дә:

— Дамир, мин укуны бетергәч, әйдә Чаллыга китәбез,— диде.

Егет консерва капкачын япты да торып утырды, авызын газет кисәге белән сөртте.

— Ә нигә анда? Авылны яратам мин, Сәвия. Синә авылда да эш булыр. Әнә нинди медпункт өлгерә хәзер. Барлы-юклы больницаң бер якта торсын. Шунда үзебезнең авылның ике врачы эшкә кайтабыз дип торалар. Әнүр белән Әлфия. Колхоз стипендиатлары булып укыйлар бит алар. Быел — соңгы еллары. Безнең кай җиребез алардан артык? — диде Дамир. Сәвия башын аның тезләренә салды, каршында

гына үсеп утырган корыган әнис сабагын өзеп алды, аны иреннәренә якын китереп:

— Ә минем шәһәрдә яшисем килә... Чаллының нинди шәһәр буласын беләсең лә син, перспективалы, заманча. Әле бер көн телевизордан күрсәттеләр... Унсигезәр катлы йортлар салганнар. Җитик, Дамир,— дип пышылдады. Дамир аның күпереп торган чәчләрен сыйпады, бармакларын муеннары буйлап йөртте.

— Әле укып бетер, карлугачым, тагын ел да ике ай бар әле ул көннәргә кадәр. Аннан күз күрер,— диде Дамир һәм Сәвияне, көчле куллары белән ике култык астыннан күтәреп, үзенә таба борды да бөрлегәндәй иреннәренә сөлектәй сарылды. Кинәт Сәвия хәлсезләнде, аның пружина кебек киерелгән гәүдәсе камырдай булды. Куллары салынып төште, аякларын сузып җибәрде. Күзләрен ачып Дамирга сокланып карап торды да башын аның күкрәгенә куйды. Яшьлек каны кайнаган, давылланган Дамир йөрәге нидер көткәндәй, каядыр ашкынгандай, ярсып типте. Ул тын калган, яңа йокыга киткән сабыйдай күзләрен йомган, башы белән куенына сыенган Сәвияне кысып-кысып кочаклады.

Алар шулай озак утырдылар. Үткән көннәрне искә төшерделәр, алга планнар кордылар. Сүз күбрәк Чаллыга киту-китмәү тирәсендә барды. Барыбер анык кына бер фикергә килә алмадылар. Өскә менеп, теге пыяладан гына җиткерелгән ашханәдә ашап та чыктылар.

Аннары машина янынннан ерак китмичә, тауга күтәрелделәр. Бер урында чикләвеклеккә очрадылар. Җыеп бетергәннәр. Шулай да азрак таптылар.

Алар каен аллеясыннан чыгып барганда урман өстенә кояшның соңгы нурлары сеңеп бара иде инде.

* * *

Рамай әллә ничә тапкыр көйрәтергә чыкты. Ул керү белән, юк эшен бар итеп, Сәкинә дә ишек юлыннан аягын өзмәде. Ә Сәвия һаман юк. Рамай, инде ничәнчесе булгандыр, авызына папирос кабып, болдырдан төшкәч тә өй буена ясап куелган эскәмиягә утырды. Шырпы сызды, аның зәңгәрләнеп югарыга сузылган телләренә карап торды да сүнә башлаганда гына папирос кабызды. Тирән итеп бер-ике суыру белән, папиросын юан бармаклары арасына кыстырган килеш, терсәген тезенә куеп, яңагына таянды.

«Кулда — «Волга», янда — чибәр кыз, ник йөрмәсен... Мин дә аның кебек чакта, махы бирмәс идем»,— дип уйлады ул. Йөрсәләр йөрсеннәр инде, тик,— яшь чак, җүләр чак,— ул-бу гына була күрмәсен. Аларга бит, аларга бит...» — дип пышылдады аның җилдә ярылып купшакланган иреннәре. Үзе дә сизмәде, аның күз алдына Дамирның әнисе Мәрьям килеп басты. Күптән булды инде ул хәл...

Рамайның председатель булганчы, ферма мөдире булып эшләгән чаклары иде. Заман карт энесенең кызы ул Мәрьям. Атасы сугыштан кайтмады. Ике өйгә бер хуҗа булып йөрде Заман карт сугыштан соң. Буй җиткән кызларны Иваново өлкәсенә торф чыгарырга җибәргәннәр иде ул елларны. Әнә шуннан кайтып кына төшкән иде Мәрьям. Читтә йөрү авыл кызларын да үзгәртә бит ул. Заманына күрә өс-баш елкылдап тора моның. Сәкинәнең чит авылда укыткан чагы, атнага бер генә кайтып йөри. Азаланды бит шул Мәрьямгә йөрәге. Җае да туры килде. Шәехзада ага белән идарәдә печән эскертләргә каян кеше табарга дип баш ватып утырганда, уттай янып торган Мәрьям килеп кермәсенме! Исәнме-саумы юк.

— Миңа гына гел читтә йөрергә димәгәндер инде, быел атсагыз да китмим торфка, шушыннан эш бирегез, Шәехзада абзый,— диде ул кызу-кызу. Үзе чуар яулыгы астыннан Рамайга өздереп карап алды.

Рамай да аны жавапсыз калдырмады. Шәехзада ага күп уйлап тормады:

— Ярар, башкалар барыр, әнә печән эскертләргә кит, бу тәти чүпрәкләрне сал да. Рамай хәзер шунда, печәнчеләр янына китә,— диде.

— Чыннан дамы, Рамай? — дип сорады Мәрьям, чәчләрен яулык астына яшерә-яшерә.

— Менә бер әйбер генә карыйбыз да, аннан элдерәм Атлан басуына,— диде ул аңа.

— Алайса, мине көт, тиз әйләнәм мин!..

Мәрьям шулай дип җәһәт кенә чыгып китте. Рамай тәрәзәгә күз төшерде: Мәрьям кулларын болгый-болгый өйләренә таба йөгерә иде. Ул чыннан да тиз килде. Рамай болдырга чыгуга, ул, аякларын салындырып, тарантаста утыра иде инде. Рамай аның янына утырды. Олы гәүдәле туры алаша, дилбегә кагу белән, юыртып китте. Тыкрыкны чыгып, тауга күтәрелә башлаганчы, бер-берсенә сүз кушарга базмадылар.

— Болай читен икән лә,— дип, Мәрьям, аякларын күтәреп тарантас утыргычы астына таба сузып җибәрде. Аның таза балтырлары Рамайның аягына тиеп-тиеп китте.

— Нигә уклау йотып барасың, әллә Сәкинәңә әйтерләр дип куркасыңмы? — диде Мәрьям һәм: — Сәкинәңә генә күп буласың син. Бездәйләр күпме — егет исе иснәргә тилмергәннәр! — дип, яшел бәрхет өретелгән басуларны яңгыратып көлеп җибәрде. Рамай дилбегәсен тезләре арасына кыстырды да:

— Егет исе иснәсең киләмени әле синең, мә, алайса! — диде дә, үсмер чактагы кебек, Мәрьямне шытырдатып кочаклап, бит очыннан тешләп алды. Мәрьям чыр-чыр кычкырырга, аяклары белән тыпырчынырга тотынды. Алаша туктады, бу нишләвегез, әллә миңа дәшәсезме? дигәндәй, артына борылып карады. Мәрьям тарантастан сикереп төште, яңагын яулык чите белән ышкый-ышкый, күлмәк кесәсеннән уч төбе кадәр генә көзге алып, аңа карый-карый:

— Әбәү, әшәке җан, ике азау тешеңнең эзләре ярылып ята, ничек күреним мин хәзер кеше күзенә,— диде. Рамай күпме ялынса да, ул тарантаска утырмады. Атлан тавын менеп, каенлык янында печәнчеләр күренә башлагач кына, Рамай янына килеп утырды.

— Кара, кабат шаярма! Миндә дә бар ул теш дигән нәрсә!.. Сәкинәңә җавап бирәлми кәтер китәрсең,— диде, бармак янап. Рамай шунда гына аңа ныклап карады. Матур иде Мәрьям. Ачык киң маңгае шопшома. Кашлары калын. Бит очлары янып уймакланып тора. Йомры кул башлары, беләкләре күлмәгенә көчкә сыйган. Ябыграк вакытта тектергәндер. Күкрәкләрен күтәртеп куйган, ахрысы, тырыстай булып калкып тора. Сәкинәдәй нечкә билле дә түгел. Ана булу дәрте белән кайнап торган, төеп тутыргандай таза гәүдә. Рамай аңа юри генә сыенгандай итте һәм кулын иннәренә салды. Мәрьям читкә тайпылмады, кулына да кагылмады. Тик авыр офтанып:

— Кул салыр кешеләре юк дип көләсеңдер инде,— диде. Рамайга Мәрьям әллә ничек кызганыч та, якын да булып китте. Аның да күз атып, шаярып йөргән егете бар иде дә бит. Телефон баганасыдай озын, мунча ташы кебек кара Хәниф иде ул. Сугышка киткән дә югалган. Мәрьям аны көткән, болай исеме халык теленә кермәгән.

Печәнчеләр янына житәргә күп калмаган иде инде, Рамай аңа таба иелде дә:

— Бүген чыгасыңмы? Клубка килсәң иде,— диде. Мәрьям, яулык читен бармагына бөтерә-бөтерә:

— Бүген Заман бабайлар кунакка китәсе иде, миңа кереп кунарга әйткәние карчыгы. Кич үзең шунда кил,— диде. Рамай Мәрьямне, тыгыз, юан беләкләре астыннан кулын тыгып, кысып кочаклады да:

— Ярар, түлке Сәкинәгә тү-ту, яме,— диде һәм дилбегәне тартып куйды. Мәрьям, чыраен сытып, башын иде.

Нарядта булганнан соң, ул туп-туры Заман картларга таба атлады. Өйдә ут алып азапланмаганнар. Рамай капканы иләп кенә ачып керде һәм түр тәрәзәгә килеп ике-өч чиртте. Кемдер ут алды. Рамай тәрәзәгә карады, пәрдәләр төшерелгән, өй эчендәгеләр күренми. Ул тәрәзәгә тагын чиртеп алды. Шул чак пәрдә ачылып китте һәм Рамайның күзе дүрт булды. Заман карт тәрәзәгә арты белән баскан да сәке өстендә намаз укый. Бер иелә, бер тора. Менә ул муенын чак кына борып тәрәзәгә күз төшереп алды да иелә башлады. Шул чак олы төпле ак ыштаны кинәт тезенә чаклы шуып төште. Сиздеме, сизмичәме — тагын бер торып чүгәләде. Рамай, авызын тотып, урамга атылды, өч йортны узып киткәч кенә шаркылдап көләргә тотынды. Соңыннан Заман картның бу намазы халык теленә мәзәк булып менде. Ул кунакка китә алмый калган икән. Ә тоз күз Мәрьямнәре, киттеләр дип, яшьләргә таратып та өлгергән. Шәфәкъ бату белән яшьләр капка юлыннан өзелми аптыратканнар бит моны. Аптырагач, әнә шулай намаз укырга тотынган Заман карт. Атна буе идарә ишек төбендә үткән-барганга, күрсәттем егетләргә, ичмаса, шәмсекамәр йөзе, бер бите ай, берсе кояш, хушлары китеп капка төбенә чыгып тәгәриләр, дип, саргаеп беткән тешләрен ыржайтып көлде. Рамайга да сөйләде, җиңеннән тарта-тарта, берсенә инде черем итә башлагач, эспесиәльне, иренми торып, утлар алып, намазлыклар җәеп күрсәттем,— дип сөйләде. Рамай, әллә сизгәнме тагын дип, шикләнеп тә куйды. Юк, танымаган иде ул аны.

Заман картның шәмсекамәр шәрифләренә күз салгач, Рамай катышлы кеше кебек, берүзе көлә-көлә урам буйлап барды. Аннары капыл гына көлүдән туктады. Әллә ничек ямансу булып китте. Бераз барды да Мәрьямнәрнең күршесендәге, урам якта үскән карт өянке төбенә, койма кырыендагы сандык кебек таш өстенә барып утырды. Төн карангы. Күк тишелеп беткән таз кебек. Йолдызлар чекерәешеп тора. Ул Сәкинәне исенә төшерде. «Нинди ният белән йөргәнне белсә нишләрие икән?» — дип уйлап куйды. Папирос кабызыйм дип торганда, койма кырыйлап кына ниндидер шәүлә килгәне күренде. Рамай, муенын сузып, тын калды. Менә ул якынайды. Бу — Мәрьям иде. Аның өстендә затлы крепдешин күлмәк. Иңенә мамык шәл салган, яланбаш.

— Кәнсәләр тирәсеннән дә урадым. Сине искәртә алмадым. Теге карт жен киреләнгән, күлмәгемнең якасы кара, дип китмәгән кунагына,— диде Мәрьям пышылдап. Рамай аның кулыннан тотты.

— Өйдә икән шул,— дип елмайды Рамай һәм Мәрьямнең кулбашыннан кочаклап иреннәренә үрелде. Мәрьям аның аскы иренен эләктереп алды һәм суырып үбә башлады. Рамай бер мизгелгә югалып китте, башы җиңелчә генә әйләнгәндәй булды, тыны капланды. Мәрьям кинәт артка тайпылды һәм:

— Сыланырга, бәхетегезгә аркылы төшәргә уйлый бу дип уйлый күрмә! — диде ул өзек-өзек, тыны беткән кеше кебек сулап, үзенең тулы күкрәкләре бер өскә күтәрелә, бер аска төшә иде.— Сине яратмаслыкмыни, Рамай. Авыл тулы кызлар... Кем генә сиңа бер кичен бүләк итмәс икән?..

— Алай димә, кимсетмә үзеңне, Мәрьям...

— Безнең кимсетелер урын калмаган инде... Бәгырьләрен сугыш кискәннәр без үлеп беткәнче, безнең буын туфрак булганчы кимсенер инде... Их, Рамай!..

Алар таш өстенә утырдылар. Мәрьям шәлен Рамайның солдат гимнастеркасы өстенә дә япты.

— Минем белән утырып салкын тидермә тагын, Сәкинәңә ни дип җавап бирерсең? — диде. Рамай аны кысып кочаклады. Сәкинәне кочаклаган кебек Мәрьямне дә үз кочагына ала алуына гаҗәпсенде. «Ике

кешене дә яратып була икән»,— дип уйлады ул. Сәкинәнең йөзе буа өстеннән күтәрелгән иртәнге томан артында калгандай булды. Әнә ул ак ефәк шәл бөркәнгән дә әкрен-әкрен томан эчендә эреп югала. Менә аның күзләре генә күренә, бераздан алар да юкка чыкты. Шул чак Мәрьям аның муенына сарылды һәм:

— Рамай, бәгърем, көлмә... Мин әнкәйгә килгәттә йоклыйм дидем. Әллә кем күзенә чалынуын бар... Мина барыбер... Синең өчен читен булыр, Сәкинәнә дә житкерерләр... Әйдә, киләткә,— диде. Сулышы кайнар иде. Рамай үзенең дә, Мәрьямнең дә нинди хис-теләк белән януын ачык белде. Ул бөтен барлыгы белән шул билгесез рәхәтлеккә омтыла, күңеле шуңа тартыла, йөрәге шуны теләп талпына. Ләкин аек акыл, аннан соң, аннан соң... Аннан соң дөнья ничек булыр, ул үзе нишләр, кинәт кенә ир булу ут-давыллар аша кичкән егетлек хисләрен таптамасмы дия иде. Ул үзен аннан соң итеп күз алдына китерә алмады. Мәрьямнең кайнар сулышы муенына бөркелгәч, түзмәде, аны шашып кочаклап алды һәм пышылдап:

— Нигә көлим?.. Әйдә. Тик уятырга гына онытма, йоклап калмыйк,— диде. Алар, билләреннән кочаклашып, әкрен генә Мәрьямнәр капка төбенә килделәр. Мәрьям кече капка келәсен сак кына ычкындырды. Рамайны эчкә үткәргәч, тагын келәне эләктерде.

Бөтен барлыгы белән бирелде бу төнне аңа Мәрьям. Ләкин шуннан соң ул аны якын да жибәрмәде. Югыйсә, әллә нинди жайлы, уңай чакларга тап булдылар. «Булды, буявы сенде!» — диде дә кырт кисте. Шул көзне янадан ул Ивановога китеп барды. Ә икенче көзгә томраеп торган кара күзле, үзе кебек калын иренле малай белән кайтты.

— Тормышка чыккан идем, бәхетем булмады,— дигән сүз таратты. Шул елны әнисе үлде. Мәрьям шул сабый белән берүзе торып калды. Ул көннәрдән соң егерме ике ел узды. Чибәр, уттай янып торса да, Мәрьям кияүгә чыкмады. Яучылар да ишеген еш кактылар. «Арка таянычым, юанычым бар минем хәзер»,— дип, ул берсен дә кабул итмәде.

Капка төбенә шуып кына «Волга» килеп туктады. Рамай урыныннан торды һәм түр тәрәзә каршында үскән шомырт куләгәсе астына килеп, койма аша үрелеп карады. Әнә Сәвия саквояжын күтәреп капкага таба атлады. Аның артыннан Дамир да килә. Сәвия кулы белән капка бикләгеч тимергә баскач, саквояжын лып иттереп жиргә куйды. Шуны гына көткәндәй, Дамир аны кочаклап алды. Рамай уңайсызланып койма кырыеннан китте. Капка ачылды. Саквояжын күтәреп Сәвия килеп керде. Агач эскәмия янында басып торган әтисен күргәч, кыз кинәт туктап калды. Ләкин үзен тиз кулга алды.

— Әти, менә без кайттык. Исәнме, әти,— диде ул һәм саквояжын Рамайга бирде.

— Исәнме, кызым!.. Озакладыгыз, әллә юлда ул-бу булдымы? — диде Рамай. Шул чак капка ачылды. Дамир башын гына тыгып:

— Рамай Ибраһимович, иртәгә нинди команда? Ничәдә килим? — дип кычкырды. Рамай аңа таба башын борды да кырыс кына:

— Кер әле,— диде. Дамир капканы шапылдатып япты, тужуркасын тарткалый-тарткалый, Рамай алдына килеп басты.

— Зажигание әллә нишләде, кабына-сүнә, кабына-сүнә, аптырап беттем,— диде ул, председательнең ни өчен чакырып кертүен алдан ук шәйләп.

— Иртә түгел микән!.. Зажигание, зажигание...— Рамай шулай дип кашларын жыерды.— Алай бик әтләнгәч, әйдә кер, көтә-көтә көтек булып беттек инде,— диде. Дамир белән Сәвия бер-берсенә карашып алдылар. Ул арада Сәкинә дә йөгереп чыкты. Сәвия аның муенына сарылды һәм:

— Исәннәр тордыңмы, әни, жаным? Авырмадыңмы?.. Кан басымың төшмәдеме бераз? — диде ул, иркәләнә-иркәләнә.

— Әйбәт әле хәзергә, кызым, шөкер, үзең ни хәлләрдә? Тартылып киткәнгә дә охшыйсың, чирләмисеңдер бит?
— Юк, әни, юк, укуы да җиңел түгел бит.
— Әйдәгез, әйдә өйгә, кызым! Дамир, син нишләп торасың тагын?
Сәкинә кызын кочаклап өйгә алып кереп китте. Рамай белән Дамир да алар артыннан өйгә уздылар. Түр якка табын әзерләнгән иде. Түгәрәк өстәлне озынайтканнар. Ризыклар өстенә газета капланган. Өстәл артына түгәрәкләнеп утырганчы, Рамай бер өстәлгә, бер Сәкинәгә күтәрелеп карады да:
— Анасы, әллә Яхъяларга да эндәшәсе инде,— диде. Сәкинә газ плитасы өстендәге ак эмаль кәстрүлгә пилмәннәр коя-коя:
— Бик әйбәт булырые да, кем дәшер икән соң? — диде.
— Алайса, үзем әйләним әле.
Рамай шулай диде дә, салкынчарак булса да, башына да киеп тормады, җәһәт кенә атлап чыгып китте. Сәвия кече якта кул-битен юып керде, иңендәге сөлгесен Дамирга сузып:
— Мә, син дә юынып ал бераз,— диде. Дамир тужуркасын салып куеп, рәхәтләнеп юынды. Сөртенеп, юынгыч өстендәге көзгегә карап бөдрә чәчләрен өзгәли-өзгәли тараганда, сөйләшә-сөйләшә, Рамай белән Яхъя да килеп керделәр.
— Төпчекләре чирләп тора, Флюрасы килә алмады инде,— диде Рамай каршыларына кабалана-кабалана килүче Сәкинәгә.
— Ни булган соң?
— Ангина диме.
— Ялан аяк йөргән бүген...
Яхъя плащын, зәңгәр велюр эшләпәсен чөйгә элә-элә шулай диде һәм, кулларын уа-уа, алгы өйгә узды, Сәвия белән кул биреп күреште. Дамир да килеп кергәч, аңа серле генә күз кысып алды, сыңар кулын сузды. Сәвия, ак алъяпкыч бәйләп, пилмән салынган тәлинкәләрне үзе өләшергә җыенган иде, әнисе:
— Бүген син — кунак. Кунак булсаң, тыйнак бул. Әнә утырыгыз түргә, синең өчен әзерләнгән аш бу,— диде. Үзе, мич кадәр булса да, йөгереп кенә йөри тагын, тик ул баскан саен сайгаклар гына сыкрап кала. Моны Яхъя да сизде бугай.
— Сәкинәттәй, бик ашыкма, әкренрәк бас, сайгаклар сынмасын,— диде.
— Сынсын, барлык бар, куйдырыр әле...
Түгәрәкләнеп утырдылар. Рамай буфеттан бер шешә коньяк алды. Кечкенә рюмкаларга салып чыкты да:
— Я, Сәвия кайту, Дамир зажигалкасын табу хөрмәтенә,— дип, рюмкасын югары күтәрде. Барысы да чәкештерделәр.
— Авызын бәхетле булса, җеп белән тартсаң да килә ул ризык, язмаган булса, аркан белән тартсаң да килми, китә, ди торганые әби мәрхүм,— диде Яхъя, Рамайга күз кысып. Тегесе сүз әйтеп тормады. Рюмканы авызына каплады. Сәвия дә, Сәкинә дә рюмкаларын өстәл түренәрәк этеп куйдылар. Дамир да рюмкага иренен генә тидереп куйган иде, Рамай аны ай-вайга куймады.
— Эчмәгәнеңне беләм, беренчесен җибәр әйдә! Үлмәссең, коньяк кына ич ул,— дип эчереп бетерде. Рамайның үтереп кыставын Сәкинә өнәп житкермәде булса кирәк:
— Нигә кыстыйсың, бармаганына, өйрәнмәгәненә рәхмәт кенә диген,— диде. Кара борыч сеңдереп пешерелгән пилмәнне барысы да яраттылар. Рамай белән Яхъя тагын берәр рюмка тоттылар. Дамир урыныннан кузгалды.
— Рәхмәт, Рамай абый, Сәкинә апа. Мин китим инде,— диде. Рамай аңа текәлеп карап торды, аннары: «Мин хәзер чыгам, китми тор әле,— диде, аның күзләре әллә ничек мәзәк булып ялтырады. Дамир

артыннан Сәвия дә кузгалды. Алар чыгып китү белән Рамай алдында торган чәй тәлинкәсендәге олы йомрыны алды да:

— Авыз чылатып утырырга монда! — дип, аңа тутырып коньяк салды, Сәкинә бу нишли инде тагын дигәндәй, күзләрен челт-челт йомган арада эчеп тә жибәрде. Тиз генә үрелеп пилмән капты, авыз читен кул сырты белән сыпырып алды да Яхъяга:

— Мин хәзер, барса, әнә, сала тор,— дип, яртыга төшеп барган коньяк шешәсенә төртеп күрсәтеп, тышка чыгып китте. Сәвия кереп килә иде, аңа сүз кушмады, урамга таба атлады. Дамир кабинада иде инде, машинасын кабызган, башын ишек тәрәзәсеннән тыгып, председательне көтә иде.

Рамайның башы жиңелчә генә шаулый башлады. Соңгы елларны аз гына төшергәләп алса да, баш дигәне нигәдер ишарәләгәндәй әнә шулай үзенчә сигнал бирә. Чигәләрен кыса торган бу гүелдәүне ул тын калып тыңлый. Чигә тамырына бармагын куеп, пульсын саный, аның ничегрәк тибешен барлый... «Мотор тузып бара, карбюратор да чүпләнгән, нидер тыгылып-тыгылып китә. Юк, шаярырга ярамый»,— дип, ул үз-үзенә әллә нинчә тапкыр сүз дә биргән иде инде. Сәбәбе чыгып тора бит. Менә бүген Шамил күчтәнәченнән баш тартып булмады, болай да серкәсе су күтәрми. Аннары Сәвия белән Дамир хәле. Хәл генәме әле?

Рамай Дамир артына кереп утырды. «Беломор» кабызды. Тирән итеп эчкә суырып-суырып алды да, гаепле кешедәй, башын түбән иеп, ни кычкырып, ни пышылдап түгел дигәндәй, тавыш белән:

— Дамир, әйдә мужикларча сөйләшик әле, мин бит барысын да сизеп йөрим,— диде. Дамир кабина эченә ут кабызды, ялт итеп Рамайга таба борылып утырды. Рамай күзләрен кыса төште һәм:

— Утны сүндер,— диде.

— Нигә?

— Кирәк түгел...

— Нәрсә сизенәсез, Рамай Ибраһимович? Болай тырышып йөрим кебек бит инде... Гөнаһ-фәләнем дә юк...

— Әйттең... Иске авызга яңа аш!.. Их, Дамир, Дамир!.. Эш синең эштә, эштәге гөнаһың турында гына булса!..

— Әллә берәр нәрсә бармы, Рамай абый?

Дамирның тавышы шомланып чыкты.

— Менә сиңа кодагыйрак эшләр чыгарга тора әле монда, Дамир туган...

— Нәстә булыр тагын?..

— Дамир... Сәвия белән арагыз ничек?

Бу сораудан Дамирның тыннары куырылды. Ләкин ул куркып та, каушап та калуын сиздермәскә тырышты. Яхшы әле — председатель утны сүндерткән иде.

— Әйбәт, Рамай абый. Сез каршы килмәсәгез...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, председатель кулын аның иңенә куйды, аны кочаклады һәм:

— Әйбәт икән, анысына молодец!.. Ләкин, ләкин, Дамир...— Аның теленнән чак кына улым дигән сүз ычкынмады. Ә ул сүз менә ничә еллар инде тел очында тирбәлә. Әмма бер тапкыр да ул аны кычкырып әйтә алганы юк.— ...Күтәргә, күп күтәргә туры килер сиңа... Ә онытсаң, ишшу лутчы.. Беткәнмени синдәй егетләргә авылда кызлар...

Председательнең соңгы сүзләре Дамирны тетрәндереп җибәрде. «Бердәнбер кызын миңа бирергә гарьләнә... Мин нәстә, председатель йөртүче гади шофер, аның денщигы... Их, Рамай абый, Рамай абый!.. Үз әтием булмагач, әти дип дәшәргә тилмереп үскән көннәренең ачуын алып, исемеңне әнә шул сабый чакта сусаган сүзгә әверелдереп, салкын чишмә суларына ябырылгандай эчәргә, кешеләргә тереклек бирүче моңлы бер җыр итеп гомер буе авыздан төшерми көйләп кенә йөрергә

өметләнгән, ышанган көннәрдә мондый яман уйлар ничек килде синең башыңа? Сәвиягә гашыйк булмасам да, кеше буларак та атам кебек якын кеше бит син минем. Нишләп башка сыймас мондый сүзләр сөйлисең син?» Күңеле шулай дип иңрәде, йөрәге кан саугандай сулкылдады Дамирның.

— Аңламыйм мин сезне, Рамай Ибраһимович.

Анын тавышы кыллары өзелгән скрипкадай калтыранды. Рамай аны тагын да ныграк кочаклый төште. Бер кулы белән бөдрә чәчләреннән сыйпады.

— Аңларсың, көт әле, у-у... Әй, Дамир...

— Мужикларча сөйләшүең шушымы инде?

— Ачуланма, шушы, башы... Ә хәзергә бусысы да җитәр... Тик, Дамир, бер үтенечем бар. Әйбәт йөр. Берләнбер кыз бит ул минем. Син әйбәт егет, ышанам мин сиңа...

— Председатель кызына үрелмә дигән сүз була инде бу...

Рамай кулын Дамир иңеннән алды, гәүдәсен артка ташлады, «Волга» утыргычлары ыңгырашып алды.

— Син, Дамир, анысын куй! Мине кем дә, Сәвияне кем дип беләсең? Син дә, без дә бер нәрсәдән әвәләнгән. Җирдән яралган крестьяннар бит без...

— Егерме ел председатель булган кеше белән кая китә инде ул безгә чагышу, синең каның да икенчедер инде хәзер... Сәвиянекен әйткән дә юк...

— Син, малай, авызыңны чамалап ач! Ату...

— Нәстә ату?.. Бездә дә бар ул беләкләр!..

Дамирның кинәт дәртләнүендә, урыныннан кыймшанып-кыймшанып куюында, өзек-өзек тавышында Рамайга яшьлеге күзенә күренгәндәй булды. Анын иреннәре елмайды.

— Я, син кызма әле, Дамир... Менә сиңа кодагый дигәндәй, бүген монын очына чыгып булмас... Бер сөйләшербез әле... Тик шулай да күзеңне башка кызларга төшерә тор... Пар түгел сез Сәвия белән... Дөресрәге, ярамый... Ишетәсеңме? Ярамый...

— Ник?

Рамай бу сорауга җавап бирмәде, машинадан төште дә:

— Иртәгә машинаңны кара, ял ит, мин ат белән генә йөрермен,— дип кереп китте. Капка келәсе шалтырап бикләнгәч тә Дамир әле бераваык исенә килә алмый торды. «Пар түгел сез Сәвия белән, пар түгел!» Колак төбендә иң якын кешесенең, өзелеп сөйгән Сәвиясенең әтисе, әтисенең әнә шул сүзләре, өй чикерткәсе сайрагандай, чынлап торды. Буш күңел, дөньясына кул селтәгән баш, ачу кайнап торган йөрәк белән кузгалып китте ул.

Рамай өйгә кергәндә Сәвия баян уйный, Яхъя белән Сәкинә аны тын гына тыңлыйлар иде. Сәвия әнисе яраткан көйне — «Рамай»ны уйный иде. Кашлары җимерелгән, маңгае җыерылган Рамайны ишектән күрү белән Яхъя урыныннан торды һәм шактый кызара төшкән йөзен шифоньер көзгесеннән карый-карый:

— Ни булды, Рамай Ибраһимович? — дип сорады.

Рамай кулын селтәде, сүз дәшмәде. Өстәлдә торган шешәдән тагын бер рюмка салып эчте.

— Әтисе, артыгы китә түгелме соң?

Сәкинә, шулай дип, авыр гәүдәсен диваннан чак-чак күтәреп:

— Грязлечениега барасы иде, Яхъя... Бик тә җәфаланам бит. Колагына төшерсәң иде шуның. Ярар, ярар, ди. Өйдән чыгу белән оныта. Өйгә кайткач кына хатыны барын белә,— диде һәм шешәне, бөкеләп, буфетка алып куйды.

— Нигә, культура работниклары райкомсоюзы аша алырга булыр аны.

Яхъя, тәрәзә кырындагы кадакка элгән костюмын алып, аны кия-кия, Сәкинәнең соравына шулай дип җавап бирде:

— Аннан көтсән...

— Колхоз аша авыррак шул...

Рамай да сүзгә кушылды.

— Май баса сине, карчык. Көн саен Атлан тавыннан бер юыртып кайтсаң, бернинең калмас.

— Ышанмыйсын инде син минем чиргә, этисе...

— Ышанмаска...

Яхъя саубуллашып чыгып китте. Күнегелгәнчә, аны берсе дә озата чыкмады. Капка ябылу белән, Рамай кызына күтәрелеп карады. Ул өстәл өсләрен җыештырып йөри иде.

— Сәвия, кызым,— диде ул аңа, иркәләп.— Моннан соң Дамирдан читтәрәк йөр. Аңладыңмы?

Сәвия комачтай кызарды. Кулындагы тустаганы төшеп китте. Сынар кулы белән битен каплады. Сәкинә кызы янына барып басты, аның иңнәреннән кочаклады һәм Рамайга гаҗәпсенеп карады да:

— Дамирга ни булган, этисе? Чибәр, акылы дисәң, башкалардан аерылып тора. Иң акыллы кешене генә үзенә шофер иткәнне бөтен район белә. Ни булды? — дип сорады.

Рамай кулын селтәде.

— Менә сиңа, кодагый, Дамирга берни булмаган... Тик Сәвия аның тирәсендә күбәләкләнмәсен... Менә шул!

Кыз белән ана бер-берсенең күзләренә карап сүзсез калдылар.

Рамай әкрен генә чишенә башлады. Алар икесе дә кече өйгә чыгып киттеләр. Башын мендәргә төрткәч тә йоклап китәр төсле иде, юк, йокы дигәне бу төнне дә эләкмәде Рамайга. Күзен йому белән Дамир гәүдәсе калкып чыга. Аннары Сәвия. Әнә алар шомырт чәчкә аткан вакытта мәктәптән кайтып киләләр. Икесенең дә кулларында Мактау кәгазьләре, шуны болгый-болгый аңа таба йөгерәләр. Дүртенчене икесе дә отличного бетерделәр бит алар. «Кызым... Улым, улым!» Аның күзләренә яшь килде...

* * *

Председательләр таралганнан соң, Рәшат Галиевич барлык бюро членнарына да кабинетка җыелырга кушты. Кабинетына кереп, сары күн тышлы папкасын өстәлгә генә куйган иде, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Урмакаев килеп тә керде. Ул секретарьның күзләренә текәлеп карады, кин маңгаен йөнтәс кул сырты белән ышкып куйды. Гадәттәге үз урынына утырды да, терсәкләренә таянып, секретарьга дәште:

— Рәшат Галиевич, бер сүз ишеттем бит әле мин.

— Айга менмәгәннәрдер бит безнекеләр, авызың белән кош тоткандай булгансың?

Соңгы вакытта аның бу кешегә ничектер ихтирам дигәне салкыная төште. Юк йомышын бар итеп гел райком тирәсендә урала. Конкрет, төбәген әйтмичә колхозларга да чыкмый. Ни кушсаң да ярар дип кенә тора, кайтып, үтәлешне тикшерә башласаң, берсе дә эшләнмәгән була. Әллә нинди тип.

— Айга менәсе юк, җирдә дә әллә ни эшли икән бездә кешеләр,— дип елмайды Урмакаев.— Рамай Ибраһимович утырткан бит безне төпсез галошка.

— Ничек?

— Әйтәм аны графикны арттырып үтәдек дип лаф орды.

— Нәрсә, әллә үтәмәгәнме?

— Утәгән! Бер кулы белән биргән, икенчесе белән алган. Районга кайткан бөтен комбикорманы үзенә алып бетергән... Дүртенче квартал исәбенә дә кергән хәтта.

— Үткен! Крестьянча хәйләкәр, аягын алдан киенеп куя белә, әйтерен юк. Вот, шельма! Язын фураж сорап килер әле...

Телефон шалтырады. Рәшат Галиевич трубканы алды.

— Әйе, тыңлыйм... Нәрсә? Алты да биш дисеңме? Аз. Республикада жиде дә бер. Жиде дә бергә төзәт. Баш санынмы? Элеккечә бир. Бишенче январьга чаклы ерак әле... Тула ул. Син бүгенге, хәзер бирә торган отчетың турында кайгырт, кызым.

Ул трубканы иплəп кенә куйды.

— Республикада кичә көнлек савым жиде дә бер. Шуннан да ким биреп булмый бит инде. Жилкәгә көн дә удар алып булмый. Алга таба куарбыз, тиздән сыерлар бозаулый башлый. Вәрәшовтан булмады, бюро члены син, әнә шул райстатны кулыңа ал әле,— диде ул Урмакаевка, аның йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Урмакаев яңакларын чалышайтып иснәп алды да:

— Була ул, Рәшат Галиевич, бик тәкәббер кыз ул, райстат инспекторы, гайкаларын борырмын мин аның,— диде.

Урмакаев чыгып киткәч, Рәшат Галиевич графиннан су салып эчте. Чәнчешкәләп торган йөрәге бераз хәл алгандай булды. «Ник кермиләр соң бу бюро членнары?» Ул өстәл кырындагы кнопкага басты. Ишектә оештыру бүлеге мөдире күренде.

— Бюро членнары кайда?

— Бирэдә, иптәш Шәймиев.

— Керсеннәр.

Алдан, пеләш башын кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, Вәрәшов, аның артыннан иреннәрен бөреп, күзләрен ялт-йолт уйнатып, район газетасы редакторы, оештыру бүлеге мөдире Тәлгат Шәяхметов, райкомның икенче, өченче секретарьлары керделәр. Бер мизгелдә Шәймиев һәркайсын күңеленнән үткәрде. Вәрәшов — тәҗрибәле Совет работнигы. Төрле холыклы, темпераментлы секретарьлар белән эшләгән кеше. Бу районда ун елдан артык эшли инде. Сүзен уйлап, үлчәп әйтә.

Район газетасы редакторы — мәзәк бәндә. Газетаны егетләре сөйри, ә бу райкомның мәңгелек вәкиле булып йөри бирә. Үзе дә күнеккән инде шуңа. Газета башында шундый кеше утырырга тиешме? Тәлгат Шәяхметов — әле яшь, әмма акыллы күренә. Авыл хуҗалыгын сөйрәүче икенче секретарь Халикъ Кәримович — пәһлеван буйлы. Районда аннан озын кеше юк, диләр. Югары белемле агроном. Кызу, бик тә турыдан ярырга ярата. Маневрларга баруны әле белми. Әмма Вәрәшов белән бик яхшы мөгамәләдә. Элекке колхоз председателеннән күтәргәннәр аны. Идеология секретаре — белемле егет. Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлаган. Киләсе сайлауда аны я редактор, я идеология секретарена тәкъдим итәргә кирәк булыр... Вәрәшовның тамак кырып алуы аның уйларын бүлде.

— Иптәшләр, озак утырмабыз,— диде Шәймиев, аяк өсте басып.— Бер генә мәсьәлә буенча уртак фикергә килергә кирәк. Тунга сөрү буенча обкомнан тагын звонок булды. Без республиканың уртача күрсәткечләреннән дә түбән барабыз. Нишлибез?

Башлап Вәрәшов телгә килде:

— Берәр атна соңгарсак соңгарырбыз, бөтен көчне салам жыюга тупларга кирәк. Салам жыю буенча удар атна игълан итик. Өмәләр оештырыйк. Басуда туклану оештырыйк.

Халикъ Кәримович та аның сүзен куәтләде:

— Шулай хәерлерәк булыр, Рәшат Галиевич... Сөрүне туктатмаска, һәр тракторны ике смена эшләтергә кирәк. Иң беренче «К-700»ләргә мәйдан ачарга кирәк. Аларны икешәр смена эшләткәндә һәр «К-700»

көнгә егерме биш-утыз гектар бирәчәк. Алар янына барлык чылбырлы тракторны өстәсәң,— диде ул һәм кулындагы кәгазен күтәрә төште: — Шундый расчетлар белән эшләгәндә сөрү егерме бишенче сентябрьдән дә соңга калмый бетәчәк... Моннан да соңга калу — киләсе ел уңышына балта чабу дигән сүз. Болай да август зәбе белән утырдык,— диде.

— Нигә, планны срогында үтәдек бит,— дип бүлдерде аны редактор. Халикъ Кәримович аңа таба борылды һәм калын кара кашларын җыерып:

— Ничек беткәнен белмәмешкә салынмагыз инде. Яхшы әле — сизмәделәр дигән. Рәтләп анализламаганнардыр инде. 30—31 августта көнгә дүрт-дүрт ярымшар мең гектар сводка бирдек. Чәчүмени ул, сөрү бит, сөрерсең көнгә шулай?

Халикъ Кәримовичның бу сүзләрен Рәшат Галиевич яратып бетермәде.

— Үткәннәр турында баш вату өчен җыенмадык. Безнең өчен хәзерге момент кадерле. Көн үзәгендәге төп звеноны эләктереп алырга һәм аны уңышлы хәл итәргә кирәк. Төп звеноны! Партия безне шулай өйрәтә. Мин иптәш Вәрәшовның тәкъдимен хуплыйм. Шуна өстәп менә нәрсә дә эшләргә кирәк. Җирләрне тизрәк ачу өчен ике-өч көн саламны яндырырга кирәк безгә. Ул арада салам эскертләүчеләр дә тын алыр, алар да сөрүгә участокларны өлгертерләр. Ә салам бездә житәрлек, куркасы юк. Төньяк районнарда гел яндыралар әле.

— Аннары безгә салам сорап киләләр,— дип төрттереп куйды Вәрәшов. Рәшат Галиевич аның сүзен ишетмәгәнгә салышты, сүзен дәвам иттерде:

— Иптәш Шәяхметов, иртәгә иртәнге сигезгә активны җый, шушы мәсьәлә буенча колхозларга вәкилләр чыгарабыз. Бюро членнары барысы да бу атнада төп игътибарны шушыңа бирергә тиешләр. Туңга сөрү — бүгенге беренче номерлы бурыч.

Халикъ Кәримович урыныннан күтәрелде. Рәсми сүзе булса шулай итә ул.

— Рәшат Галиевич, каш ясыйбыз дип күз чыгармыйбызмы без? Куәтле техникага юл ачабыз дип саламны яндыруны әйтәм. Соңгарак калсак калыйк, саламга кул тидермик. Үзегез беләсез, районда фураж ягы шәп түгел. Силос, сенаж ярыйсы. Ләкин аның да сыйфаты ничек була бит әле. Ә басуга бер ут төртсәң, аны туктатам димә. Баштан үткән инде ул хәлләр,— диде ул, бармак очларын өстәлдә биетә-биетә.

Вәрәшов башын кыңгыррак салды, яртылаш Рәшат Галиевичка таба борылды һәм:

— Кем ничек уйлыйдыр, Халикъ Кәримович сүзләрендә хаклык зур. Кыш корсагы — алты ай, диләр иде элек. Ә хәзер ул кимендә ун ай. Чөнки табигый болыннар юк, сөрелеп бетте. Берьеллык үлән сабан туйларсыз чабарлык булмый. Кара җир иснәтеп мал җаны саклап йөри торган заманалар үтте. Ел дәвамында өзлексез продукция житештерергә һәм сатарга кирәк. Ә бу азык, тагын һәм тагын бер кат терлек азыгы дигән сүз. Шунлыктан салам яндыру турында авыз да ачмаска кирәк. Без әйтмичә дә яндыралар әле аны,— диде.

Рәшат Галиевич Вәрәшовның сүзенә берни дип тә җавап кайтармады, битен кул сырты белән сыпырды да:

— Ныклы контроль куярбыз. Ике-өч көннән катгый рәвештә тыярбыз,— диде. Бюро членнары, энгәмә-кинәшләшүнен шушының белән бетүен аңлап, барысы да урыннарыннан кузгалдылар. Тик Вәрәшов кына кузгалмады. Ишек ябылу белән Рәшат Галиевич аңа дәште:

— Нәрсә, әллә махсус фикерегез бармы?

— Бар шул, Рәшат Галиевич, аңлашырга кирәк безгә... Икебез дә бер йөкне, халык, партия ышанып биргән хәзинә төялгән йөкне тарта-

быз.— Вәрәшов йөткереп алды.— Һәм, ничектер, Крылов мәсәлендәге чуртан, кысла, аккош кебек килеп чыга...— диде.

Шәймиевнең күзләре кысылды, ул урынына утырды, бер кулы белән яңагына таянды һәм:

— Ничек, анламыйм... Кайсыбыз чуртан, кысла?.. Аккош кем икәне ачык,— диде көлеп.

— Эш кемнең аккош, чуртан, кысла булуында түгеллеген сез яхшы беләсез. Эш — принципта.

— Ничек принципта?

— Туңга сөрүне иртә тәгәллибез дип салам яндырырга әмер бирүегез принцип түгелмени? Бюро членнарының күбесе моңа риза түгел.

— Беренче секретарь әллә үз сүзен үткәрергә тиеш түгелме?

— Тиеш. Дөрес тәкъдирдә. Әгәр дә аның дөреслегенә үзе дә инанса. Сез бит, Рәшат Галиевич, моның дөрес түгеллеген, үзебез утырган агач ботагын үз кулыбыз белән кисүебезне яхшы аңлыйсыз. Ник шуңа барасыз?

Шәймиев папирос кабызды, тирән итеп суырды, урыныннан торып, ишекле-түрле йөреп алды һәм Вәрәшов каршысына басып болай диде:

— Район өчен, аның бүгенгесе өчен мин җавап бирәм.

Аны Вәрәшов бүлдерде:

— Юк, икебез, бергә җавап бирәбез...

— Мин туңга сөрүне егерме бишенче сентябрьгә тәгәлләргә вәгъдә бирдем. Саламны яндырмаганда ул үтәлмәячәк.

— Киләсе елны терлек продуктлары җитештерү турында да вәгъдә бирүегезне онытмагыз. Без исән. Ә исәннәргә аны искә төшерәчәкләр һәм аны да сораячаклар.

— Әле ул көнгә кадәр...

— Мин принципиаль каршы. Һәм моны тиешле оешмалар алдына куюны үземнең коммунистлык бурычым дип аңлыйм.

Рәшат Галиевич ачусыз гына көлеп куйды:

— Габделхак Шакирович, нигә чаң сугарга? Мин бит ике-өч көнгә генә дидем, бераз тын алганчы... Аннан без хәл җыябыз. Максатка ирешү юлында маневрларга барыла инде ул.

— Юк, Рәшат Галиевич, мин моның белән килешә алмыйм һәм кайда салам яндыру күренсә, шундук район янгынчыларын җибәрәм.

— Ут белән уйнамагыз!

— Без аны сүндерүчеләр, уйнарга вакыт юк.

Рәшат Галиевич өстәл артына барып басты.

Вәрәшов, башын югары тотып, нык-нык басып, ишеккә таба китте.

Иртән туңга сөрүнең барышын үз кулларына алырга тиешле вәкилләр белән җыелыш үткәргәннән соң, Рәшат Галиевич колхозларга юл тотты. Кәефе шәп түгел иде аның. Сания тагын бүген өйдә кунмады. Иртән дә кайтмады. Редактор хатыны белән ахиригә әйләнгәннәр дип колагына кергән иде бер. Шунда кунып калды микән?

Ул тәрәзәгә карады. Иксез-чиксез басулар. Алар рәт-рәт тезелгән салам чүмәләләре белән чуарланган. «Кайдан җыеп бетерерсең моны? Хәзер халык бәрәңге ала, чөгендергә ябырылды. Кышлыкка дигәнне басу читләренә эттерергә дә калганын яндырырга,— дип уйлады ул һәм үз-үзе белән сөйләшеп алды.— Съездга килгән елны шулай каршылыйсыңмы, съезд елы уңышына шулай нигез саласыңмы дип мәсьәләне кабыргасы белән куярлар. Сөтне, итне дә ерып чыгасы бар».

Шоферы Зиннур аңа башын борды да:

— Нәрсә, миңа әйтәсеңме, абый? — диде. Рәшат Галиевич оеша башлаган аякларын сузып җибәрде. Зиннурга карамыйча гына:

— Юк, сиңа түгел. Үзем хыялланып барам әле,— диде. Уң якта бик көр тишелгән уҗым басуы күренде. Ул чәүкә күмелерлек булып килә инде.

— Ай, ужымы да ужымы! — Зиннур телләрен шартлатып куйды.
— Нык куакланган, өшемәсә инде.
— Өшеми! Бу хәзер малга ашатырга дигән ужым бит.
— Каян беләсен?
— Халикъ Кәримович белән икенче көн генә әйләндек әле без бу колхоз басуларын. Председатель шулай диде.

Рәшат Галиевич дәшмәде. Шамил Сабирович колхозына барып җиткәнче алар бер-берсенә сүз кушмадылар. Зиннур «Волга»сын идарә болдыры төбенә үк илтеп туктатты. Гадәте шулай аның. Ишекне ачу белән баскычка басарлык булсын. Идарәдә баш бухгалтердан гайре кеше юк иде. Рәшат Галиевич председательне сорады. Бухгалтер, авторучкасы белән колак артын кашый-кашый, түшәмгә карап торды. Аннары, алдындагы кенәгәләрен шкафка ашыга-ашыга куеп:

— Хәзер, Рәшат Галиевич, табам мин аны... Монда гына булырга тиеш ул,— диде дә җәһәт кенә чыгып китте. Рәшат Галиевич бухгалтер урынына утырды, папкасын ачып, егерме дүртенче форманы алды да «Игенче» колхозы астына сызып куйды. Итне күптән үтәде инде бу колхоз. Сөтне үтәргә шактый тырышасы бар. Ә йомырканы үтәми дә үтәми. Кышка кергәндә йомырка агылмый ул. Бетерергә кирәк мондый колхозлардагы кошчылыкны...

Оператив сводка кенәгәсен карау да күңел тынычлыгы бирмәде. Тунга сөрү яртылаш та үтәлмәгән. Трибунадан 25 сентябрьгә бетерәбез дип вәгъдә бирде үзе. Ничек бетерергә уйлыйдыр. Салам җыю да начар. Җыелган һәр гектары сөрелеп барган. Шул, салам җыю тоткарлый моны да...

Менә туп кебек тәгәрәп Шамил Сабирович килеп керде. Күз төбенә чаклы борыны кызарган.

— Ичән-имин генә килдегезме, Рәшат Галиевич! — дип, ул ике куллап килеп күрешә һәм: — Әйдәгез минем кабинетка,— дип, чалбарының тезенә чаклы төшкән кесәсеннән ачкычларын эзләп, Рәшат Галиевичны үз кабинетына алып чыгып китте. Кабинетка керү белән Шамил өстәл артындагы креслосына барып утырды, майланып, ялтырап торган күзләрен секретарьга төбәде. Рәшат Галиевич стена буендагы кәнәфигә утырды, аякларын сузып җибәрде һәм:

— Ну, тунга сөрү ничек бара? — дип сорады. Шамил түбәсе пеләшләнә башлаган башын кыска бармаклары белән сыйпады, аннары куен кесәсеннән блокнот чыгарды да чепи күзләрен челт-челт йомгалап:

— Тәк, бүгенгече көнгә бер мең чикчән дүрт гектар... Безнең бер «К-700», алты «ДТ-75», ике «ДТ-74» бар. «К-700»гә көнгә егерме бишәр, тегеләренә ике чменага унарны чалганда, көнгә йөзәр гектар биреп барырлык рәт бар безнең. Шул әйткән чрокка бетерәбез зәбне, Рәшат Галиевич.

— Ә кичә күпме сөрдегез?
— Кырык биш.
— Аннан алдагы көнне?
— Кырык.
— Соң мондый темп белән эшләгәндә бетми бит.
— Без әле бер генә чмена чөрәбез. Менә иртәгәдән икегә күчәбез. Чалам җыю кулны тота бит. Чтогометатель бирәү генә безнең. Бирегез әле шуны безгә тагын ике-өчне, барыбер башка колхозларда рәтләп эшләтә алмыйлар аны.

— Нишләп, Вильданов эшләтә бит.
— Ул — ичключение, Вильдановтагы механизаторларга завод кончтрукторлары килә. Аларны өйрәтеп җибәрәләр әле алар. Вильдановның көче — механизаторларда аның. Аның колхозында һәр ир кеше ким дигәндә я шофер, я тракторчы. Өеп-өеп, көчләп укыта бит ул аларны.

— Ә син ник укытмыйсың?
— Хәзер бездә дә кытлык юк.
— Әйдә, басуларны әйләник.
Алар кабинеттан чыгып киттеләр. Рәшат Галиевич артка, Шамил белән янәшә утырды. Машина кузгалу белән Рәшат Галиевич председательгә кырыс кына:
— Шамил Сабирович, артыграк шаярасың түгелме син кырыкны белән? — диде. Шамил иңнәрен җыерды.
— Юк, норма, иптәш Шәймиев. Кичә кайниш кайткан иде. Кичәге генә ул.
— Эчсәң сәбәп табыла. Кара аны, соңыннан үкенерлек булмасын.
Юл буенда туктап торган тракторны күрү белән Шәймиев шоферга туктарга ишарәләде. Тракторчы кабинада йокы симертә иде. Шамил аның аягыннан тартты. Тракторчы, тузан сарган битен кепкасының эчке ягы белән сөртә-сөртә, җиргә төште. Рәшат Галиевич аның белән кул биреп күреште.
— Ник сөрмисең, әллә ватылдымы? — дип сорады ул тракторчыдан.
Тракторчы дәшмәде, күрмисезмени дигәндәй, салам чүмәләләрен төртеп күрсәтте.
— Иртәгә чалам эчкертләү звеночы монда күчә. Чин нишләп икенче бригадага китмәдең? Анда җир бар иде бит, шулай әйтелде бит чиңа!..
Тракторчы башын иде.
— Бригадир синлек җир ачтырам, китми тор, хәзер картларны булса да оештырып чыгарам дигәние,— дип мыгырданды.
— Бирермен мин чезгә! Ачтырырмын җир. Менә бүгенге трактор көнен бригадир белән икегезнең чыртыгызга чәпим әле. Аннан белерчез трактор көненең күпме бәһәдә йөргәнен. Аңладыңмы, туганкаем?
— Аңладым, Шамил абый.
Ул да булмады, Рәшат Галиевич читкә, тезелеп киткән чүмәләләргә таба атлады һәм кесәсеннән шырпы чыгарып, саламга ут төртте. Ут шундук үрләп китте. Кызыл ялкын телләре һавага сузылды. Шәймиев Шамилгә дә, тракторчыга да кул болгады.
— Кабинада йокы симерткәнче алдыңдагы бу чүмәләләргә ут төртсәң, күпме җир сөргән булыр идең инде,— диде ул, гаҗәпсенеп авызын ачып торган тракторчыга. Аннары председательгә эндәште: — Шамил Сабирович, райком кушкан һаман барып җитми бугай әле сиңа?..— Секретарь беравык, тотлыккандай, ачкан авызын яба алмый торды.— Трактор тик тормасын, саламны хәзер үк яндырыгыз, менә бу юнәлештә тракторга юл ачылсын!
— Рәшат Галиевич, быел бу юнәлештә чөрергә ярамый. Былтыр да шул уңайга чөрелде. Аннан, авышлыкка карагыз. Рельеф кушмый.
Председатель аңа шулай дип аркылы төшкән иде, Шәймиев күкерттәй кабынды.
— Хәзер нинди сөрү юнәлешләре турында сүз булырга мөмкин?! Көнне, бүгенге көнне кулдан ычкындырмаска кирәк. Агроном кеше бит син. Күпме иртә сөрсәң, шул хәтле отасың. Теләсәң нишлә, ләкин тунга сөр! Уңыш язмышы шунда.
— Аңлыйбыз, Рәшат Галиевич...
— Аңласаң — бетте. Демагогияләреңне зәп астында калдыр, чыгарлык булмасын!
Икенче бригада басуында барган эш райком секретарена ошады. Салам эскертләүдә дүрт трактор, бер эскерт куйгыч эшли иде. Кешеләр дә җитәрлек. Алар килгәндә, төшке ашка җыелалар иде. Урман буенда гына таган асып чәй кайнатканнар. Ашларны зур термослар белән авылдан алып килгәннәр. Шамил Рәшат Галиевичкә тамак ялгап алырга тәкъдим ясады, тик секретарь риза булмады. «Сездән соң Виль-

дановларга китәм, шунда тамак ялгап алырмын, аларның ашханәсе бар бит»,— диде. Шамилнең үзенең өзелеп ашыйсы килгән иде. Рәшат Галиевич салам эскертләүчеләр белән сөйләшкән арада ул тозлый-тозлый ярты әтәчне сугып куйды. Чүмеч белән генә шулпасын да эчте, үзе һаман беренче бригада ягындагы, Шәймиев ут төрткән басудан күзен алмады. Менә төтен сыегая, тарала төште. Киткәндә тракторчыга күз кысып, сүндерергә кушкан иде ул ялкын ялмый башлаган чүмәләләрне — сүндергәндер. Күзгә дә юньле нәрсә күренеп, эчкә дә яшь әтәч ите кергәч, кәефе күтәрелеп китте Шамилнең. Шәймиевнең Рамай колхозына барасын искә төшереп, Шамил кысык күзләрен йома-йома, бригада членнары белән сөйләшеп торучы секретарь янына килде, әңгәмәгә колак салды.

— Жук, иблдәш чеклетарь, яндырмыйбыз, кыш корсагы — ай, зур, каптай кар астыннан тычкан тизәге дә табалмассың. Авыл янындагы салам бүген төнгә юк була ул,— диде колхозлар оештырып йөргән Җәләй карт, кәҗә сакалын сыпыра-сыпыра.

— Ничек юкка чыга?

— Колхозчыга да корма кирәкме — кирәк. Вәт, бүген төнлә ниятлибез. Иртәгә иртәнчәк анда шырпылы салам калмас. Кичә шулай килешендек бит авыл җыенында, сельсәвит уздырды. Әнә, ышанмасагыз, Шамил оланнан сорагыз. Үзе дә шундаие... Ә ул теге тракторчыга исегез китмәсен, иблдәш чеклетарь, шулай, аяк өсте йоклый, бер аягын алганчы, икенчесен эт ашый торган мәхлук нәстәкәй ул. Трактор түгел, дилбегә дә тоттырасы түгел аңа.

— Алай димә,— дип сүзгә Шамил үзе дә кушылмый түзә алмады.— Мәхмүтнең аның баш йомры. Мең дә бер техникадагы электрооборудованиене кем белә? Ул. Нигә килеп терәлчәк тә шуңа егылабыз. Укуга хиреч ул. Инчтитутның дүртенче курчында механическида укый. Гел бишлегә. Бетергәч ачпирантурага кил диләр үзен. Мине укыткан укытучылар шакката аның башына. Әллә чин аны йоклап яткан дисең? Йоклар! Я укып, я күзен йомып, мәчьәлә чишеп, я чертеж чызып яткан ул. Быел ук механик, ә укуын бетергәч, инженер итәм мин аны.

— Кара, кара, ничек яклый!

— Кызың җитеп килә, киявең дә ит, Шамил абый...

Бусын да коры калдырмады Шамил:

— Андыйларны яклыйм да, кирәк икән, ичнәшкәннәр икән, кияүитәргә дә каршы түгел.

Колхозчылар күтәрелеп көлделәр. Йөзләрдә елмаю чаткылары сүнә төшкәч, Шамил җитди, кырыс тон белән:

— Иртәгә чоңгы чрок. Бу бачуда бәбкә чыгарганчы утырмагыз. Юкәлек буена күчәрчез,— диде.

Рәшат Галиевич колхозчылар белән җылы гына хушлашты. Машинага кереп утыргач:

— Ник башта ук ул басу саламының халыкка бирелгәнен әйтмәдең? — дип сорады. Шамил, зур корсагын тота-тота, кеткелдәп куйды.

— Әллә яратачыз, әллә юк, дип уйладым,— диде.

— Төлке син, Шамил Сабирович.

— Чак булмачаң, кайчак бүре авызына да кабачың...

— Райком секретаре бүремени сиңа?

— Алай димәдем ич, Рәшат Галиевич, валлаһи, уема да килмәде...

— Шулай да төлке син.

— Мин төлке булгач, кемдер бүре, куян, сарык та булырга тиеш инде, алайса!..

Икесе дә көлеп җибәрделәр. Рәшат Галиевич аны идарәгә кадәр илтеп куйды. Алар дустанә генә аерылыштылар.

«Беренче Май» колхозы идарәсендә берәү дә юк иде. Типовой проект белән салынган бинаның һәр ишеген тартып чыкты Шәймиев. «Дежур-

...лар» бүлмәсенең генә ишеге бикләнмәгән иде. Анда тәрәзә каршына урындыклар тезеп бераү йоклап ята. Өстенә яшел тышлы әйбәт толып ябынган. Шәймиев ике-өч тапкыр тамак кырды. Әмма әлеге кеше башын күтәрмәде. Борын сызгырта-сызгырта йоклый, тора-бара гырлап та ала. Шәймиев аның иңнәренә сак кына кагылды. Толып якасы күтәрелде, аннан кара бәрхет түбәтәйле, житен сакаллы бер баш калыкты. Менә ул күзләрен тырышып-тырышып ачты, йөзенә елмаю чыкты.

— Ә, ибдәш секлеталь,— диде ул нечкә тавыш белән һәм жәһәт кенә торып утырды, аяк очындагы озын кунычлы киез катасын киде, алдында яткан толып чабуын бер читкә алып куйды да:— Оятлы буласың булса көт тә тор. Шул чаклы ятма, Заман, төн бар, житешерсең йокларсың әле, дидем. Юк, шайтан жиңде. Әле яңа, бисмилла, күз генә йомганием. Ни арада йоклап кителгән диң, ә? Быбшый кызыл партизан башың белән пустта йоклап ят инде син, ә? Сугыш заманы булса, валлаһи, трабунал! Ике сүләшү юк...

Рәшат Галиевич Заман картны шунда ук таныды. Ул елмая-елмая аңа дәште:

— Хәлләр ничек соң, бабай, картаеп буламы?

— Карт аю урманда гына була ул, улым. Ә хәлләргә килгәндә, хәзер, иншалла!.. Син белмәгәнсеңдер әле, мине бер күмделәр бит инде, яңадан тудым. Әле унбиш-егерме көнлек кенә сабый мин...— Ул өске иренен күтәреп, саргайган бердәнбер тешен күрсәтеп кеткелдәде.

— Ничек күмделәр?

Заман карт почмактагы чөйгә элеп куйган бер көпшәле мылтыгын алып караган булды. Аны янадан элеп куйды.

— Шулай икән ул, улым. Әжәл якадан алды бит бер көнне. Выжт мине Рамай олан «Волга»сы белән район бүлнисенә. Шәфкать кызлары гына дисәң аз булыр, ожмах хурлары кебек кызлар тотмаган жиремне калдырмадылар... Тән читенсенә, ә күңел — һаман эт. Сыпырыгыз, озаграк сыпырыгыз, ди. Үлгәч әллә сират күперен кичеп була, әллә юк. Аны кичәр өчен дип тавык та чалган юк бит минем. Сират күперен кичсәң дә, анда ожмахка керергә чиратның исәбе-чуты юк, ди. Инде, алла насыйп итеп, ожмахка керсәң, район бүлнисендәге кебек хур кызлары әллә була, әллә юк, мин әйтәм. Үзем үлеп ятам, үзем хур кызлары кочам шулай. Теге дөньяга китә башлаганмындыр инде. Хирур кереп, укол бирегез бабайга, ди. Йөзле кадак кебек энә белән кадыйлар гына бит. Билыгым тотмый башлады. Шулай да үтермәделәр болар мине. Атна дигәндә аякка бастым. Хупжамалым саклады. Янымнан китмәде. Тернәкләнгәч тә көн саен диярлек килде. Өч атналар үтте шулай. Колхоздан хәл белергә килүче юк бит. Беләм, Рамай районга килеп йөри. Заман абзый, хәлләрең ничек? дип ник кенә бер сугылсын. Көннәрдин бер көнне дежуркага кердем. Телефоннан сорап колхозны алдым. Бухалтир аксак Кәрам туры килде. Тамакны кырдым да: «Кем бу?» мин әйтәм. «Беренче Май» колхозы бухалтиры», ди бу. Шәп, алайса, мин әйтәм. Сездә Заман исемле карт бариеме, бүлнистә ята идеме? Ята иде. Ятса, шул хәзер генә өзелде, шарт, мин әйтәм. Китсәнә, ди, Заман абый да үләр икән, ышанмыйм, ди. Ышанмасаң, тагын шалтырат дим. Шулай дидем дә трубканы куйдым. Күп тә үтмәде, тагын телефон шалтырады. Бусы Рамай олан. Аны да ышандырдым. Ике сәгать үтте микән, «Волга» белән Рамай олан, аның артыннан хуш исле урман печәне түшәлгән йөк машинасы килеп житмәсенме!.. Мине күргәч, Рамай оланның күзеннән яшьләре чәчрәп чыкты. Аксак Кәрам гына башта, эштән бүлеп, дип кыбырсыды. Аннары ул да килеп кочаклады, гөнаһасы кирәк түгел... Менә шулай, ибдәш секлеталь, мин үлгәнгә кырыгы тулмаган әле, ә яңадан туганыма егерме беренче көнем. Бездә бит кешенең кемлегенә үлгәч кенә бәһа бирәләр. Менә мин дә үлеп аңлаттым әле шуны...

Зиннур да кергән, ачык ишектән башын гына тыгып тыңлап торган икән. Ул коридорларны яңгыратып көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха! Утырткансың икән Рамай Ибраһимовичны.

Рәшат Галиевич та рәхәтләнеп көлде. Картның юморындагы энҗе бөртеген тоеп, рәхәтләнеп көлде ул. «Чыннан да шушындый картларга, пенсионерларга игътибар аз шул»,— дип уйлады. Аннары:

— Ә председателегезне кай тирәдәнрәк эләктереп булыр икән? — дип сорады.

Заман карт Рәшат Галиевичның алдына ук килеп басты, керфексез күзләрен челт-челт йомды, башын бер яккарак кыйшайтты да:

— Җене котырып чыгып китте. Теге мәгънәсез вәкилегез белән,— диде.

— Нинди вәкил, кем ул?

— Гәҗит чыгара диме ул шунда.

— Ә, редактор беләнме?

— Шул инде, мәгънәсез бер нәрсә. Тыңлап тордым... Кем салам яндыра ди инде бу вакытта? Аз булса бер хәл иде. Сару кайнатып йөри шунда...

Рәшат Галиевич Заман картны сабыр гына тыңлады. Шамил Сабирович янында күтәрелгән кәефен бозасы килми иде аның. Ул тагын председательне сорады.

— Персидәтел әйтте, килгәнсең икән, мә, яндыр, дип, вәкилгә бер кап шырпы бирде. Мин торба юллап Әлмәткә китәм, диде. Яңгыр кудырып үстерә торган болынлык ясап йөри бит ул, шуның белән җенләнә. Көтүчеләрне дә бетерәбез, электр белән көтәбез, ди.

Рәшат Галиевич сүзсез генә кулын Заман картка сузды. Заман карт та аны, бер сүз катмыйча, болдырга чыгып, озатып калды.

«Терлекләр җәйләүдән кайтыр вакыт җитә, фермаларында кышка хәзерлек ничек икән, юл уңаенда сугылырга кирәк»,— дип уйлады Рәшат Галиевич һәм Зиннурга авылның төньягындагы фермаларга таба төртеп күрсәтте.

— Фермаларны карыйк әле,— диде ул әкрен генә.

Күңеле белән тирән тынлык көтеп килгән иде ул монда. Ләкин юраганы юш килмәде. Сыерлар фермасында төзүчеләр бригадасы эшли иде. Алар купкан, черегән сайгакларны алыштыралар. Эшләре бер башта гына калган. Савымчылар стеналарны агарта. Бер сварщик автоэчергеч трубаларын ябыштыра. Барысы да үз эшләре белән мавыкканнар. Бер мәлгә алар райком секретарен шәйләмәделәр дә. Стена агартучы хатын-кызлары янына җиткәч, Рәшат Галиевич кычкырып сәлам бирде:

— Исәнмесез! Беләкләрегез талмасын!

Стена буендагы сәндерәгә менеп баскан хатын сискәнеп китте,— артка тайпылды, чак кына егылмады.

— Ай, куркыттың!.. Әйбәт кенә әле. Менә килен төшерергә җыенабыз. Вакыт әз калды. Өч көннән бу фермада эш бетәргә тиеш. Аннан тегесенә күчәбез,— диде ул, кулындагы пумаласын стенага терәгән килеш. Ремонтлап, акшарлап барган урыннар чыннан да кунак көткәндәй чиста, пөхтә булып кала иде. Тирес чыгару, азык өләшү, эчертү, саву — барысын машина эшли. Рәшат Галиевич боларны сафка бастыру өчен никадәр көч куелганны күз алдына китерде. «Шулай да молодец син, Рамай Ибраһимович! Ул төзүчеләр янында да туктап сөйләште. Аларның да кәеф күтәренке иде.

— Рамай Ибраһимович әйткән вакыттан бер көн алдан ничек тә бетерергә кирәк эшне монда,— диде какча чырайлы бераү.— Мәгәр шулай булмаса, менә бу иптәшнең,— ул сайгаклык юнып маташучы карсак буйлы бер кешегә төртеп күрсәтте,— комбайнчы ул, комбайнын чистартып, юып куйды да монда килде,— өен күтәрәсе бар.

Рәшат Галиевич карсак буйлы әлеге кешегә дәште.
— Быел күпме урдыгыз?
— Урып буламыни хәзер,— диде теге кеше балта очын тактага чукып.
— Нигә?
— Нигә дип, комбайн күп, җир аз. Үз участогың беттеме — әмер көт. Башка комбайнчының да эшләп каласы килә бит.
— Кая, быел алай эшләдекмени? — дип сүзгә кушылды арадан берәү.
— Дөрес, быел группалап булгач, ярыйсы булды. Ватылсаң гына сафтан вәләй!.. Ә кем ватыла бездә? Элекке кебек бер комбайнга карап ятсаң, утырасың хәзер төп башына. Унбиш көнгә җитмәде быел урак. Йөз алтмышар гектар төшә комбайн башына уру. Әле совхозга барып эшләп кайттык. Барысы өч йөзләп гектар булды бугай быел.
— Ә уңыш?
— Үзебездә егерме алты центнер, совхозда егерме өчәр булды.
— Ә кесә ягы ничек?
— Совхозныкын кушып, егерме дүрт көнгә 560 сум төште.
— Әйбәт!
— Әйбәтен әйбәт! Ә ипине ничек бирәләр, хөкүмәт бәясе белән...
— Ник, кыйбатмыни?
— Кыйбат та түгел, ләкин дөрес тә түгел.
— Ник?
— Игенчегә килешә торган эшмени ул.
— Аңламыйм.
— Ниен аңламыйсың аның? Игенчегә, үзе ипи үстергән кешегә, ашлыкны үзкыйммәт бәясе белән сатарга кирәк. Аннан колхозга күпме зыян? Планнан тыш, сортлы ашлык саткан өчен алган өстәмәләр аны шартлатып каплый. Быелгы отчет-сайлауда кабыргасы белән куябыз әле моны. Колхозның яңа Уставындагы демократиядән файдалана беләргә кирәк.— Ул үзен тыңлап торган иптәшләренә карап алды да, баш бармагы белән борын кырын сыпырып сүзен дәвам иттерде: — Ашлыкны үзкыйммәт белән сатканда ул безгә бушка бирелгәндәй була, колхозчыда кызыксыну тагын да арта, җиргә кендеге тагын да ныграк берегә. Тик монда инде, брат, шалишь, коммунизм принцибы бармый. Кем күпме тели — шулай алмый. Күпме кеше-көне эшләүгә карап бирергә кирәк ипине. Шул вакытта гына дөреслек булачак.
— Ә пенсионерларга, инвалидларга?
— Аларга, семьясына карап, гел бушка бирергә кирәк.
— Кызык фикер йөртәсез сез.
— Йөртерсең, кыш буе тик ятсаң...
Сүз куерды. Балта осталары барысы да эшләрен ташлап, аларны уратып алдылар. Берничә кеше аваз салды.
— Дөрес әйтә Хәкимулла.
— Өрлек кебек башың белән өйдә ят әле.
— Хатыннан, бала-чагалардан оят...
Рәшат Галиевич көч ташып торган ирләрнең барсына күз йөртеп чыкты:
— Проблема бу, иптәшләр, ил буенча проблема булып бара хәзер бу,— диде ул, йөткерә-йөткерә; кайдадыр салкын тигерде, һаман үтми,— механизация ныграк үтеп кергән саен авыл хуҗалыгында яшәүчеләр саны кимергә тиеш. Промышленностька китәргә кирәк. Әнә Чаллыдагы автомобиль заводына, янда гына бит, сездән китүчеләр бармы соң?
— Бик юк шул, яшьләрдән генә бераз бар,— диде Хәкимулла.
— Туган туфрактан бик аерыласы килми шул,— дип өстәде берсе.
— Рамай быелдан эш табам диде, ничу читкә китәргә безгә.

— Безнең колхоздан юньле кеше китә димени, җибәрерсең!
Бусын серәйгән муенлы, чалу мыеклы кеше әйтте. Шәймиев аңа таба борылды һәм:
— Нинди эш тапмакчы була Рамай Ибраһимович? — дип сорады.
— Атлан тавында таш карьеры ачабыз. Разведка килеп китте инде. Унике метр калынлыктагы таш ята аның астында. Бөтен районны таш белән күмәбез,— дип җавап бирде әлеге серәйгән муенлы кеше.— Автозавод белән дә сөйләшеп кайтты инде председатель, алар техника бирә, ә кешесе бездән. Башы эшли аның Рамайның...
Сүз әле тагын дәвам итә иде, зоотехник Һәнүз килеп керде. Ул Рәшат Галиевич белән бик җитди, рәсми генә исәнләште.
Рәшат Галиевич төзүчеләр белән барган әңгәмәдән үзенчә нәтиҗә ясый-ясый, сыер саву цехына таба атлады. Аның артыннан Һәнүз дә иярде. Саву цехы ялт итеп тора. Ул нинди дер лабораторияне хәтерләтә. Сыерлары күп бу колхозның, һәр йөз гектарга уникешәр баш туры килә. Барысы биш йөз баштан артык бугай. Колхоз май заводын үзенә салдырырга йөри. Бу турыда Рәшат Галиевич белән Рамай Ибраһимович арасында әллә ничә тапкыр сөйләшү булды инде. Аның, председательнең, дәлилләре саллы: күпме кеше эшкә урнаша, аннары күпме акча колхозның үзендә кала. Аннары транспорт. Менә ничә ел инде ике автомашина сөт ташый. Ә яз-көз тракторлар. Төзелеш ике елда үзен тулысы белән аклый. Шул исенә төшеп, ул артында басып торган Һәнүзгә дәште:
— Май заводы белән хәлләрегез ничек?
— Проекты кайтты инде.
— Кайчан төзи башлыйсыз?
— Атлан тавыннан таш чыгара башлагач, кышын булыр инде.
— Һем!
Рәшат Галиевич, ишекне ачып, сыерларны һавада йөртә торган утарга чыкты. Ул киртә белән әйләндереп алынган. Аяк асты чиста, шар тәгәрәтерлек тигез. Салам сала торган рәшәткәле утлыклар барысы да тәртиптә.
Алар барлык фермаларны карап чыктылар. Нәсел юнәлешендә үстерелә торган бозаулар аеруча ошады Шәймиевкә. Көрләр, тиреләре елкылдап тора. Һәнүз аларны, юеш борыннарыннан сыйпый-сыйпый, иркәләде.
— Биш елдан бездә токымсыз бер сыер да калмаячак,— диде ул.— Әле кырык баш Холмогор таналары алып кайттык,— дип тә өстәде.
— Ничә яшьлекләр?
— Яшь тә ике айлыклар. Бер ферманы Холмогор, икенчесен Бестуж итәбез. Икесен кушкач, ит тә, сөт тә була.
«Үз эшен ярата булса кирәк бу егет» — дип уйлады Рәшат Галиевич. Алар амбулаториягә — буазлыклары соңгы көнгә җиткән сыерлар торагына керделәр. Бура кебек, ишелеп-ишелеп торган сыерлар янында кечкенә гәүдәле, бүлтерек кебекләре дә бар. Аларны күргәч Шәймиев теш арасыннан гына сөзеп:
— Болары ни тагын? — дип сорады.
— Болармы, Рәшат Галиевич, эксперимент болар.
— Ничек?
— Безнең принцип — ана терлекнең берсеннән дә үрчем алмый калмаска, начармы, яхшымы — барыбер алырга. Узган елгы гомуми җыелышта кабул ителде бу карар.
— Соң болардан ни көтәсең?
— Алай димәгез, Рәшат Галиевич. Әгәр без бу тананы, моннан барыбер сыер чыкмый инде дип, шул көе дәүләткә озатсак, күп дигәндә өч центнер килә инде ул. Ә буазлангач, организмда матдә алышу көчәя, тизләнә, тана калыная, үсә. Аның өстенә, бозавы кала. Билгеле,

мондыйлардан без сөт көтмибез. Менә шулай эшләгәндә, шушы юкына тана бер ел, ел ярым артык асрау исәбенә, безгә кимендә дүрт биш центнер өстәмә итлек рәт чыгара.

— Дуңгызлардан да шулай файдаланасызмы?

— Дуңгыз бу яктан аеруча файдалы. Бер тапкыр балалаганнан соң ул ике-өч айда центнерның теге ягына чыга.

Азык эшкәртү цехын караганнан соң, Рәшат Галиевич «Волга»сына таба атлады. Ишек тоткасына тотынгач, Һәнүздән:

— Сезнең быел сыерларның баш саны үтәләме? — дип сорады.

— Әнә сез күргән теге бүлтерекләрне дә кертсәң, үтәлә. Ләкин без аларны кертмибез.

— Бозаулагач сыер була бит инде ул, нигә кертмисез?

— Алардан сөт алып булмый бит.

— Ничә башлап андый таналар?

— Кырык җиде.

— Ә ничә баш тулмый?

— Ике дистә тирәсе.

— Менә нәрсә, Рамай Ибраһимовичка әйт. Бу ай азагына ул таналарны сыерлар исәбенә кертеп бирегез. Быел бозаулый торганнардыр бит алар?

— Бозаулыйлар.

— Бик шәп! Бозаулаган, димәк, сыер, отчетка кертегез. Сыерларның баш саны белән район авыр хәлдә, аңлагыз...

— Соң бит, Рәшат Галиевич, уйлап карагыз. Без аларны сыерларга керттек ди. Ә алар сөт бирми, савып алынган сөтне алар исәбенә дә бүләргә кирәк. Аннан һәр сыердан көнлек савым кинәт түбән төшәри. Сез үк сүгә башлыйсыз аннан безне. Аннары, ел башында план җиткергәндә, алар исәбенә дә задание төшә. Әнә бит ул кая таба китә. Юк, Рәшат Галиевич, моңа мин дә, гәрчә, бәләкәй кеше булсам да, риза түгел. Ә Рамай Ибраһимовичны, әйтмим дә, бармаячак ул моңа.

— Мин сезгә районның хәле авыр дип татарча әйттем ләбаса! Район исеме кыйбат түгелмени сезгә?

— Кыйбатын кыйбат...

— Ел азагына кадәр тагын сатып алырсыз.

— Алабыз. Нәселле булса. Ә җирле токымны фермага аяк та бастырмыйбыз, Рамай Ибраһимовичны кыздырсаң, егерме башны ул җир тишегеннән дә таба.

— Ә шулаймы? Алайса, бу кырык җидене планнан тышка кертерсез...

Шәймиев янадан колхоз идарәсенә сугылып чыгарга булды. Бу юлы баш бухгалтер Кәрам шунда иде. Райком секретарен ул, титаклый-титаклый, өстәл арасыннан чыгып каршылады. Шәймиев тәрәзә кырындагы өстәл артына барып утырды.

— Оператив сводкагызны бирегез әле,— диде ул бухгалтерга. Кәрам шкаф ишегенең бер почмагына җеп белән асып куелган сводка дәфтәрен алып, аны Шәймиев алдына илтеп куйды, бүгенге көн битенә чаклы ачты һәм бер кулы белән өстәл читенә таянып тын калды. Шәймиев салам җыю, тунга сөрү графаларын алдагы көннәр белән чагыштырып карады. Сөт савуны күздән кичерде. Аннары кинәт кенә:

— Нигә чөгендер алмыйсыз? — дип сорады.

— Менә бәрәңгене бетерәбез дә шуңа тотынабыз.

— Башка колхозларда алалар бит.

— Без дә алабыз. Быел һәр бригадада комбайн эшләячәк. Көйләп куелган, эшләтеп каралган. Тиз тотабыз аны.

— Тунга сөрү ник әкрен бара?

— Салам җыю тоткарлый.

— Кышка җитәрлек салам эскертләндеме соң?

— Житәргә тиеш.
— Шулай булгач, ни көтәсез? Басу чүпләгәнче, яндырыгыз!
— Бер елны яндырып карадык, авыз пеште, Рәшат Галиевич.
— Пешмәслек итеп яндырыгыз... Партоешма секретарен булса да табасы иде бит.
— Укытудадыр ул. Хәзер Заман бабайга дәшәм, чакыртыр.
Ул шулай диде дә чатанлый-чатанлый чыгып китте. Бераздан коридорда Заман картның чәрелдек тавышы ишетелде: «Син нәрсә, аксак шайтан, миңа ике камыт кигерәсең. Постта да тор, кеше дә чакырт. Миңа Рамай олан посттан китмәскә кушты. Ул гына алала мине посттан».
Рәшат Галиевич елмаеп куйды. Тәрәзәгә карады. Заман карт, бүреген кыңгыр салып, бишмәтенен бер җиңен кия-кия, таякка таянып, мәктәпкә таба китеп бара иде. Кәрам, ишектән керә-керешкә:
— Үлеп терелгәннән соң бигрәк үз кадерен арттырды. Рамай оланга әйтәм дип кенә тора,— диде көлә-көлә.
— Иптәш Фәрхетдинов, быел керемегез кай тирәдә?
— Икегә тулып җитәр микән?
— Миллионга?
— Әйе.
— Шәп! Ә саф керем күпмеләп?
— Алты йөз мең булыр.
— Нәрсәгә тотмакчы буласыз?
— Генераль план буенча быел кирпеч заводы сала башлыйбыз. Аннары сугарулы көтүлек тә байтак суырыр кебек әле.
Алар шулай колхоз хәлләре турында сөйләшкән арада җил-җил атлап партоешма секретаре Яхъя Курмашев килеп керде. Алар җылы гына күрештеләр.
— Соңгы Пленум карарын җыелышка куйдыгызмы әле? — дип сорады Рәшат Галиевич, терсәге белән өстәлгә таянып. Яхъя өстәл янына урындык алып утырды. Кирәк була калса диптер инде, кесәсеннән кара күн тышлы блокнотын алды:
— Уздырдык, Рәшат Галиевич, һәр цех оешмасында аерым уздырдык. Берсендә Рамай Ибраһимович, икесендә үзем катнаштым.
— Конкрет нинди тәкъдимнәр керде?
Яхъя җитен кебек чәчен ике бармак очы белән генә сыпырып алды да:
— Төп сүз экономия режимы тирәсендә тәйнәлде. Әле саксызлыкның беткәне юк бит. Машиналарга, тракторларга ягулык салуны автоматлаштырырга дигән тәкъдим кергән иде, анысы үзәктә эшләнде инде. Икенче бригадага яңа елга хәтле куябыз. Запчастьларга лимит керттек. Алайса, әз генә туздымы, давай яңасын. Ремонтсыз йөрү чорын озынайткан механизаторларга кызыксындыру чаралары билгеләдек.
Рәшат Галиевич аны игътибар белән тыңлады. Яхъя сөйләп бетергәч, секретарь урыныннан торды һәм:
— Әйдә, кабинетыңа керик әле,— диде. Аларны Кәрам күзлек астыннан карап озатып калды.
Кабинет ишеге бераз ачык калган иде. Шәймиев аны үзе барып ябып бетерде. Озын-озын атлап, зәңгәр бәрхет ябылган өстәл артына барып утырды.
— Үзәк Комитетның декабрь Пленумы һәр коммунист алдына нинди бурыч куйганны истән чыгармадыңмы, иптәш Курмашев,— диде ул Яхъяга.
— Беләм, истә. Һәр коммунист үзенә тапшырылган эш өчен шәхси җавап бирергә тиеш.
— Ә менә син үзеңне уйлаганың бармы?
— Әллә мин белмәгән берәр нәрсә бармы?

— Юк. Белә торып бюро карарына каршы барасың, Вильданов жырын жырлыйсың.

— Аңламыйм, Рәшат Галиевич.

— Ә специализация? Нәрсә, әллә ул кызык өчен уйлап чыгарылган нәрсәме?

— Безнең ферма кечкенә. Аны бетерүе дә, оештыруы да безнең өчен проблема түгел. Әмма барны бетергәнче, юкны бар итәргә кирәк бит. Без шулай уйлыйбыз. Оешсын әле кош фабрикалары, аннан күз күрер.

— Бусы Вәрәшов көе, сүзләре генә синеке. Район масштабы белән фикер йөртергә иртәрәк түгелме икән сезгә, иптәш Курмашев? Аның өчен тиешле кешеләр куелган. Анысын аларга калдырыгыз.

— Мин түгел, хәзер гади колхозчы да үз колхозы турында гына уйламый. Район, ил, бөтен дөнья масштабына тарала аның уйлары, шуларны колачлап уйлый ул хәзер. Үтте инде ул заманнар: бер тамагын уйлап, бөтен нәрсәне йомран кебек үз өненә ташучы крестьяннардан җилләр исеп бара. Газета укый, радиосын тыңлый, телевизорын карый, куелган бер кино, спектакльне калдырмый. Кышын аеруча гыйлем жыя. Хәзергә эштән бушраклар шактый. Телиме-теләмиме әнә шул барлык информация чыганаклары аңа барып житә... Бүгенге колхозчылар уен әйтәм, алар масштабы белән уйлыйм мин, Рәшат Галиевич.

— Галим-социолог диярсең сезне.

— Алар да безнең кебек кеше.

— Менә шул, Яхъя иптәш, директив органнар карарын син, коммунист буларак, үтәргә тиеш. Үтәгез. Ә дөресме, түгелме икәнен тикшерүчеләр булыр. Риза булмасаң, партконференциядә тәнкыйтьләрсең мине.

Ул шулай дип кулын сузды. Ләкин Курмашевның сүзе бетмәгән иде әле. Ул секретарьның кулын тоткан килеш:

— Рәшат Галиевич, тәнкыйть белән үткән ялгышны төзәтеп, кире кайтарып алып булмый бит. Тәнкыйть ул алга таба ялгыш җибәрмәү өчен профилактика гына. Уйлап карагыз: специальләштерәбез дип ферманы бетерик. Киләсе елга йомырка заданиесен кем үтәр? Безгә план житкерә алмыйсыз, чөнки тавыклар юк. Бу тагын шул өйдән өйгә чиләк күтәреп йомырка җыюга кала. Фатыйма җиңгиләр кетәгендә тавык кытаклаганны сакларга кала.

— Калмас. Индивидуаль сектор да сатарга тиеш.

— Индивидуаль секторныкы колхозга өстәлгәндә генә тәбә калыная.

Яхъя Рәшат Галиевичның кулын җибәрде. Ул аны озата чыкты. Рәшат Галиевич, машинага кереп утыргач, Яхъя белән эшләпәсен күтәреп кенә саубуллашты да китеп барды. «Нинди колхоз бу? Үзе алдынгы, кайсы тармагын алсаң да аякка нык баскан. Әмма кешеләре?.. Барысы да коеп куйган демагоглар... Юк, бер карасаң, алай дип тә әйтеп булмый. Алар үз якларын, колхоз ягын каералар. Алай дисәң, кошлар фермасын бетерсәң, үзләренә бер мәшәкать кенә кими бит... Масштаб, масштаб. Теге төзүчесен ал тагын. Кызык фикерләр йөртә. Барысы да уйлый... Һәркемне уйларга, хыялланырга, баш ватарга өйрәткәннәр болар...»

Ул шундый уйларга бирелеп, аркасын ныграк терәп утырды. Тегермән буасын чыгып, олы юлга гына күтәрелеп киләләр иде, каршыларына бишекле мотоцикл килеп чыкты. Бишектәге кеше кул күтәрде. Колхоз механигы белән редактор икән. Туктадылар. Рәшат Галиевич машинадан төшмәде, ишекне генә ачты да редакторның сузган кулын кысты.

— Рәшат Галиевич, Рамай Ибраһимович райком күрсәтмәсен бар дип тә белми,— дип, тотлыга-тотлыга сөйләп китте редактор, үзенең күзләре ялт-йолт килә, иреннәре дерелди иде.— Мин салам яндырырга

дигәч, чигәсен бораулап, шарикларың эшлиме синең, диде дә сөйләшеп тә тормады, Шыгайга китте — теге культуралы көтүлегенә. Миңа әйдә дә димәде. Аптырагач, механик белән артыннан куа киттек. Анда тотып, сезнең күрсәтмәләрне сөйли башлаган идем, кулга шырпы тоттырды да: «Мә, яндыр, үзеңне утка тотып атмаслармы?» — диде. Сөйләшми дә, һаман шул яңгыр яудыргыч ясаучылар белән мәш килә. Ә мин, райком вәкиле, әллә бар, әллә юк.

Рәшат Галиевич ойый башлаган бер аягын ачык ишектән җиргә салындырды, башын да тышкы якка чыгарды.

— Ә син аңа хәлне аңлаттыңмы?

— Тыңламый бит ул.

— Ул һаман да шундамы әле?

— Юк, ул Әлмәткә китте. Мин механик белән Шыгай тау өстендәге саламнарны яндырмакчы булган идем. Механигы да киреләнде. Якын да бармыйм, сезне дә җибәрмим, ди. Менә юл буе талашып кайта идек әле шуның өчен. Үзе — коммунист.

Рәшат Галиевич түзмәде, машинадан чыкты. Механик та рульдән төште. Куна җилкәле, аю кебек таза кеше иде ул.

— Сез нәрсә, райком күрсәтмәләрен кире кагасыз? — диде аңа Шәймиев әкрен генә. Тегесе күзләрен дә йоммый, тыныч кына басып торуында дәвам итте.— Райком вәкиле, бюро члены бала-чагамыни сезгә?

— Рәшат Галиевич, мин бәләкәй кеше, Рамай абыйның үзе белән сөйләшегез,— диде механик тамак төбеннән гөбердәп чыккан калын тавыш белән.

Шәймиев кул селтәде:

— Теләсә нишләгез, әмма тунга сөрү планы срогында үтәлсен!

Артыннан зәңгәр төтен алкалары тезеп «Волга» кузгалып китте. Редактор белән механик, бер-берсенә карашып, инде нишләргә дигәндәй, аптырашып басып калдылар.

Рәшат Галиевич юл буе редакторны тиргәп кайтты. «Бюро члены... Бер председательне тыңлата алмагач».

Әллә нинди хәерсез көн булды әле бу: кабинетына гына кергән иде, телефон шалтырады. Таныш тавышны ишетү белән ул гәүдәсен турайтты. Телефонда өлкә комитетының беренче секретаре иде. Ул да иң элек тунга сөрүнең барышын сорады, артталыкның сәбәпләрен ачыклады һәм әйтелгән вакытка тунга сөрү төгәлләнмәсә, обком бюросына хәзерләнә торырга кушты. Йомшак, ягымлы гына итеп әйтте.

Шәймиевнең маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул телефон трубкасын сак кына куйды. Бер мизгел секретарь белән сөйләшкән һәр сүзен бизмәнгә салып торды. «Тунга сөрү, тунга сөрү... Тунга сөрү» — дип пышылдады ул һәм һәр колхозда бу эшнең торышын анализлый башлады. Бригада килгәнче яки бюрога барганчы ничек булса да кискен сикереш бирергә кирәк. Шул гына аны аклаячак. Ул барлык чылбырлы тракторларны ике сменага күчереп бетерде, барысыннан да норма үтәтте. Ләкин алай да көтелгән нәтиҗә чыкмады. Ә бит аек акыл белән карaганда, барлык чылбырлы трактор да сөрүдә катнашмаячак, вату лучысы да, башка эштә файдаланылганы да булыр, барысы да смена нормасын үтәмәс.

Кәгазь өстендә, баш кашып, шактый утырды Шәймиев. Кинәт башына бер уй килде. Әгәр район оешмаларындагы барлык тракторларны эшкә җиксәк? Аларны барлый башлады. «Сельхозтехника» бүлекчәләреннән, мелиорация станциясеннән, юл төзү оешмасыннан утызга якын трактор җыела икән әле. Аннары ул «Җәлилнефть» идарәсенә шалтыратты. Аннан да җылы сүз ишетте: дүрт «С-100» тракторы бирел торырга булдылар. Шәймиев яңадан исәп-хисапка керешә. Юк, теләгән сан чыкмый.

«Ник хисаплыйм соң әле мин моны, Урмакаев эше лә бу, ясасын исәп-хисап!» — дип, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигына шалтыратмакчы булган иде, тагын бу уеннан кире кайтты. Тәрәзә каршына килеп урамга карап тора башлады. Асфальт юлның ике ягына утыртылган эре яфраклы тупылларга сарылык иңә башлаган. Агачтан-агачка күчеп чыпчыклар чыркылдаша. Менә алар райком тәрәзәсе каршындагы алмагачны килеп сардылар. Алмагач әле көр, аның сары яфраклары аз. Гелән су сибеп тордылар, үсешне дә әйбәт бирде ул быел, кышын өшемәсә инде яшь үрентеләре. Әнә үз «Москвич»ы белән район архитекторы үтеп китте. Вәкил иде бит ул.

Шәймиев сәгатенә күз төшерде. Биш тулып килә икән. «Эш сәгате чыгуга кайта, бар соң дөньяда типлар!» Ул тешләрен кысты һәм өстәл янына килеп звонокка басты. Ишек ачылды.

— Хәзер үк архитекторны чакыртсыннар,— диде ул секретарь кызга. «Үлчәве житмәсә дә, итне үтәп булыр инде. Ә менә сөтне ничек үтәргә? — Шәймиев яңадан уйлар йомгагын сүтәргә кереште.— Силосны хәзердән ашата башласаң? Иртәрәк булыр. Фураж ягы да такытокы. Бу вакыттан базны ачтырырга ярамый».

Секретарь кыз көндәлек почтаны кертте. Шәймиев, гадәтенчә, хатларны укый башлады.

Ике баласын сугышта җуйган карчык яза. Өем туздыы. Үзегез дә хәтерлисездер. Фәлән колхоз кәнсәләре каршында җиргә иңгән бер йорт булса, шул минеке булыр. Матча төшеп килә. Бер бәләкәй генә куыш салып бирсен иде колхоз, дип язган. Хат өстенә колхоз председателе, партоешма секретаре исеменә «Нинди җансызлык бу! Салып бирегез йорт»,— дигән резолюция салды. Икенче хат Казаннан, Вера Александровнадан иде. Ул аны иплэп кенә ачты.

Озаграк Казанга бармый торсаң, шалтыратса шалтырата, әмма болай хат яза торган гадәте юк иде Вера Александровнаның. Күңеле белән нидер тойды Рәшат Галиевич. Хатның беренче юлларына күз генә йөртеп, хат язарга мәҗбүр иткән сәбәпне тизрәк беләсе килде.

«Рәшат Галиевич! Мин бу арада гаять хафалы көннәргә дучар булдым. Кинәт кенә апам үлде. Кичә шуны җирләдек. Менә мин япа-ялгыз торып калдым. Бер башыма ике бүлмәле квартира. Ике бүлмәгә бер үзем. Бушлык. Күңелдә дә бушлык. Инде миңа нишләргә? Шушы авыр көннәрдә син дә Казанга килеп чыга алмадың. Иялэштем мин сиңа. Сине күрсәм көчем артып киткәндәй тоям үземне. Кайчан киләсең? Хәбәр ит!.. Башка төрле уйлар килә. Әллә, мин әйтәм, сезнең районга эшкә барасы, барысын ташлап. Сезнең больницада барыбер врачлар житми бит. Аннары синең авторитетыңа күләгә төшәр дип тагын шикләнәм... Нидер уйласы, хәл итәсе иде бит. Бик тә ачык беләм: син дә бит бәхетле түгел... Сонян ул синең өчен яратылмаган. Нидер эшләргә, нидер эшләргә кирәк безгә Рәшат Галиевич! Һәр кеше дә шәхси тормышында бәхеткә омтылырга тиеш бит. Әнә шул теләк, омтылыштан мәхрүм кебек без. Бу турыда күп уйландым мин. Башка әллә нинди уйлар килә, аларның очына чыгып булмас кебек тоела...

Ярар, хуш, көтәм, шалтырат!!!»

Рәшат Галиевич хатны конверты-ние белән костюм кесәсенә салып, Верага шалтыратырга дип телефонга гына үрелгән иде, секретарь кыз кереп, архитекторның килгәнлеген әйтте.

— Керсен!

Чиртсән каны чыгардай кызыл йөзле архитектор, керү белән, итагатьле генә баш иеп исәнләште.

— Утырыгыз,— дип урын тәкъдим итте аңа Рәшат Галиевич һәм: — Сез кайсы колхозга барырга тиеш идегез әле? — дип сорады.

— «Маяк»ка, Рәшат Галиевич.

— Бардыгызмы соң?

— Бардым, Рәшат Галиевич. Беренче бригадага мәктәп балаларын чыгардым, үзәктәге бригадада механик белән комплекслы бригада бригадирлары үзләре яндырды. Бөтен басуын ут каплады «Маяк»ның. Район үзәгеннән дә күренә аннан күтәрелгән төтен. Ышанмасагыз, тәрәзәдән карагыз...

Рәшат Галиевич үзен кинәт җинаять өстендә тотылгандай хис итте. «Менә шундый, кушканны гына үтәүче роботлар белән эшләсәң кая барыр идең икән?» — дип уйлады ул.

— Ә кышлык саламнарына да төртмәдегезме соң?

— Юк, Рәшат Галиевич, анысын сорамадым. Басу кырына чыгарылганнар житәргә тиеш,— диде председатель.

— Тагын кайсы колхозларда яндыралар?

— Барсында да диярлек. Бүген чалт аяз иде бит. Ә кичкә эңә нинди болыт күтәрелде, салам төтене ул!

Бу сүзләрне архитектор горурланып әйтте. Рәшат Галиевич аны чыгарып җибәрде. Һәм үзе тагын күңелсез уйларына бирелде. Мондый кешеләр ни өчен партия сафына керәләр? Алар партиягә нинди файда китерәләр? Алар үзләрен партия солдаты дип йөриләр, җае чыккан саен шул исем белән күкрәк сугалар, инде картая төшкәч, шул исем белән персональ пенсия дәгъвалый башлыйлар. Бирми кара! ЦКның үзенә чаклы җәяүләп баралар. Шулай бит ул. Тиешлесе сабыр гына көтә, аңа хакы бармы-юкмыга үзе дә инанмаганы бер дистанциядән икенчесенә чаң суга. Күбесе теләгәненә дә ирешә. Юк, алар партия солдаты түгел!.. Партия солдатлары Рамай Ибраһимович, Шамил Сабировичлар. Аларның һәрберсенең дөньяга үз карашы бар, партия куйган бурычларны үтәүгә үзенең уйлары, планнары бар, алар иҗат итәләр, хыялланалар. Вакыты белән гел уңга, сулга тайпылсыннар, ләкин аларның үз башлары бар. Алар кайчак синең фикереңә каршы килаләр, бәхәсләшәләр, нервларыңны соңгы чиккә кадәр киерәләр. Әмма дөреслек каршылыкларны җиңеп, бәхәсләр белән туа. Бәхәсләшер, көрәшер кешеләр роботлардан ай күпкә өстен, өстен! Хәзер менә ул Рамай Ибраһимовичны райком күрсәтмәләрен санга сукмаган өчен бер кулы белән сугып егар дәрәҗәдә, ә икенче кулы белән ул аның башыннан сыйпый. Чөнки ул робот түгел. Аның киреләнүенең үз сәбәбе бар. Егерме ел кышлаган председатель ул. Тунга сөрүне үз вакытында бетерүенә ул ышанган, ә районның гомуми күрсәткече аны әллә ни борчымый. Чөнки ул аңа турыдан-туры кагылмый. Шуңа ул тунга сөрүне дә кумый, саламны да яндырмый. Район артталыгы өчен район житәкчеләре бар, үзләре җавап бирсен, дип кенә уйлый. Бер карасаң, дөрес уйлый. Я, шул салам яндырмаган өчен син аңа җәза биреп кара! Төрлечә квалифицировать итәргә мөмкин. Ә матур фразаларга төрелгән аргументны шәрәләндерсәң, асылын ачсаң, аның нигезендә барыбер шул салам яндыру-яндырмау факты калачак. Юк, күпме ачуы килсә дә аңа бармаячак ул.

Аның күз алдына кинәт Вера Александровна килде. Ул телефон трубкасына үрелде. Казанга заказ бирде. Ләкин Вера Александровнаның телефоны җавап бирмәде.

* * *

Яңа елдан соң кинәт буран котыра башлады. Менә икенче көн инде төньяктан искән әче җил кар өермәләре уйната. Авыл урамнарын, абзар-кура тирәсен кар сырындысы сылап китте. Рамай урамнарга, ферма юлларына, авыл араларына бульдозерлар чыгарды. Бер бульдозерны район Советы башкарма комитеты Чаллы трактын ачарга сорап алды. Ә буран һаман котыра. Ул, электр чыбыкларына уралып, шомлы улый. Җил көчәйгәннән көчәя. Көн авышканда җәяүле буран башланды.

Иртәнге якта фермалардан бер әйләнгән иде инде Рамай. Бүген беренче фермада санитария көне. Кичке савымнан соң шуңа йомгак ясалырга тиеш. Үзе катнашырга булды әле бу юлы Рамай, барысын да үз күзеннән кичерергә теләде. Ә күңел түрендә икенче бер уй төенләнеп килүен ул үзенә дә икърар итми. Дөресрәге, әнә шул уй аны фермага, магнит кырына эләккән тимер күк, үзенә тарта, әйди. Иртәрәк булса да, ул кыска бүрс туны өстеннән яшел кожан киеп, башлыгын күзенә чаклы төшереп, фермага таба китте. Җил каршы. Ул кожан чабуларын әйләндереп-әйләндереп сала, ялмап, өзеп алырдай итеп тарткалый. Бульдозер сыдырттырып киткән юлга әлләни кар салмаган. Атларга җиңел. Рамай, алга түнә төшеп, башта җәһәт элдерткән иде. Бераз бару белән тыны кысылды. Ул адымнарын әкренәйтте, җилгә аркасын куеп барды. Юк, ни дисәң дә сиздерә икән илленең өстенә чыгу. Кырык яшькә чаклы ул ару-талу дигәннең ни икәнен дә белми иде. Әле моннан ике-өч ел элек кенә бик талчыкса да, ашап-эчеп алгач, бернис дә калмый, тагын үзендә егет чагыдай көч, энергия сизә иде. Хәзер алай түгел. Менә күпме генә каударланып барган булды, ә йөрәге инде лепелдәргә тотынды. Житмәсә, гомер булмаганны, тез буыннары йомшады. Артын-артын әкрен генә бара торгач, хәл кереп киткән булды тагын. Ул җилгә каршы борылды, башын ия төшеп, салмак кына баруын дәвам иттерде. Ферма янындагы салам эскертләренә күзе төште. Бернича ел инде алар барлык берьеллык, күпьеллык үләнне ферма янына кайтарып эскертлиләр. Җир катыру белән кыш житәрлек саламны да, барлык тракторларны эшкә җигеп, трослар белән ферма янына тарттыралар. Эскерте-ние белән сөйрәтәләр. Җир буе эскертләрне ике-өч урыннан гына өзәләр дә тракторларга тагалар. Кымшанмый да. Ә элек ат белән ташып иза чигәләр иде. Ат дигәннән, Рамайның атка мәхәббәте үзенә бертөрле. Бөтен эшне техника башкарса да, ул аттан йөз чөермәде. Колхозларны хәзерге көнгә, техника заманына сөйрәп чыгаручы, алып килүче изге җан итеп карый ул аларга. Башка колхозларда атның орлыгы корып барганда да ул элекке игенченең өмет-хыялын, арка терәген кыерсытмады. Колхозчыга вак-төяк йомышка йөрергә, ферма тирәсендә эшләргә аннан да кулай транспорт каян табасың. Аннары, сыер, дуңгызга күрсәткән тәрбия кирәкмени ул мескеннәргә. Саламнан өзмәсәң, берәр соскы чүпле ашлык эләксә, шуның белән канәгать алар.

Терлекчеләр йортының ишеген ачып кергәнче Рамай әнә шундый уйлар уйлады. Бу йортны күптән, җиренә җиткереп салганнар иде алар. Өч бүлмәле ул. Бер бүлмәсендә төнге дежурлар, сыер савучылар ял итү өчен йокы бүлмәсе. Аңа пружиналы никель караватларга чаклы алып куйдылар. Икенче бүлмәсендә газ плитәсе, шунда ук ваннасы, юыну урыны. Залы иркен. Түрдә, ике тәрәзә арасында, «Сигнал-2» телевизоры. Уң як почмакта радиоласы белән бергә радиоалгыч. Бүлмә тактасында — Мәрьямнең портреты. Ленинград сәнгать училищесы дипломанты эшләгән иде. Культура йортын ачуга Яхъя Ленинградтан махсус рәвештә художниклар чакыртты. Атказанган колхозчылар галереясы эшләтте. Культура йортында торалар алар. Барысы сигез. Ә Мәрьямнекен савымчылар монда куйдырттылар. Бер художник кыз Рамайның да рәсемен ясарга омтылып караган иде. Яхъя да әллә нича тапкыр әйтте. Ләкин Рамай кул гына селтәде. Сурәт өчен ике йөз сум акча әрәм итәргә. Әнә колхозчыларныкын ясасыннар. Болай да ныкаералар, ике йөз сумның җирдән ничек алынганын күрсеннәр, янсә шуны алар үзләре эшләп алып карасыннар иде, дип ул, көнозын пумала белән полотно буяп утыручыларга кырын күз белән карады. Әмма барыбер бәрәкәтле орлык чәчеп киттеләр алар Рамай күңеленә. Шулардан соң ул әйбәт кенә лозунглар язып йөрүче, тумыштан бер аягы гарип Альбертны художество училищесына укырга җибәрде. Культуралы шабашникларга колхоз сыртын каезлатканчы, ичмаса, үз кешебез

булыр. Үзе яраткан эш белән мәшгуль булучы тагын берәү артыр, диде.

Рамай «Ана терлекләр» журналы өстенә иелеп, борынын төртә-төртә нидер язып утыручы Һәнүзгә кычкырып сәлам бирде. Кожаның башлыгын төшереп куйды да стенадагы Мәрьям портреты каршына килеп басты. Якыннан караганда ул әллә ни охшамаган кебек. Читкәрәк китсәң, нәкъ үзе, коеп куйган кебек. Рамай арткарак чигенде. Мена-менә Мәрьямнең керфекләре тирбәлеп китәр, алсуланып торган ирennәре: «Яшьлегең исеңә төшеме, яшьлегеңне эзләп килдеңме әллә, Рамай?» — дип ачылыр кебек тоелды аңа. Мәрьям әле дә чибәр, элекке матурлыгыннан әле ул төс ташламаган. Художник та аның йөзенә нур өсти торган һәр детальне дөрес тотып алган, аны купайтыбрак, күзгә ташланырлык итеп бирә белгән. Кашларын ныграк дугайлаткан. Ияк очындагы чокырын аермачык ясаган. Борын төбендәге миңе дә зуррак кебек. Чәчләре чуар яулыгы астыннан күпереп тора. Хәзер Мәрьям чәчләрен шома итеп тарап йөртә. Иреннәре сусыл чия кебек янып торалар. Рамай бер мизгел ул иреннәрнең тәмен, кайнарлыгын үз иреннәрендә тойгандай булды... Шактый карап торды Рамай Мәрьям портретына. Рәсеме кебек саф, эчкерсез гүзәл күңеленә сокланып карады ул аңа. Берни дә таләп итмәде, күпме еллар бер сер чыгармады, сыкранмады, көнләмәде, горур башын түбән имәде. Кайбер кәнтәй хатыннар кебек аның тирәсендә сырпаланмады. Ә бит җае килгән вакытлар күпме булды. «Кеше түгел, алтын син, Мәрьям! Үлмичә, исән кайткан булса, бик тә бәхетле, меңнәр көнләшерлек бәхетле буласы икән синең Хәнифең»,— дип уйлады Рамай. Ул кожанын салып чөйгә элде, сәгатенә карады. Савымчылар килергә унбиш-егерме минутлап вакыт бар әле. Рамай, артсыз урындык алып, Һәнүз каршысына утырды.

— Ни җимерәсең? — дип сорады ул һаман журнал битләрен бер ачып, бер ябып нидер хисаплаган Һәнүзгә.

— Каплатылмыйча, буш йөргән сыерларны барлыйм. Күп җыела, Рамай Ибраһимович. Бер айда гына да 410 көнгә тула. Бу, беләсеңме, нәрсә? Бер сыер, ике мең ярым литр сөт җилгә очты дигән сүз. Осеменатор белән аяк терәп сөйләшми булмый.

— Сөйләш, миенә сеңдер син аның моны. Үз сыерың, кысыр калса, каравыл кычкырасың бит дин!

— Бу бит кысырлык түгел.

— Аңлыйм, көне белән, барыбер бер сыер кысыр йөргән булып чыга бит.

— Артыгы белән.— Һәнүз авторучкасын ачык журнал бите өстенә куйды, башын артка ташлап, стенага аркасын терәде дә кулларын югары сузып, киерелә-киерелә: — Чукынган, баш авырта. Кичә управлениенең главный зоотехнигы белән чәйнәштек-чәйнәштек. Барыбер рәт чыкмады. Ачудан төшергәнием... Рамай абый, артык эшләп булмас, китәм мин сездән... Синнән яшермим, Ася да чакырып тора... Нәсимә белән яши алмыйм мин. Кызганам да үзен. Ләкин җан тартмый, булмый...

Рамай Һәнүзнең ычкына башлаган моменты икәнен шәйләде, сүзне интим яктан куертмаска теләп, аны ишетмәмешкә салышты.

— Баш зоотехник белән тагын ни килеп чыкты? — дип сорады.

— Быелга терлек продуктлары җитештерү буенча колхозларга планнар бүлгәләп утыра иде. Шунда үзебезнекен карадым. Без үзебез быелга алган йөкләмәләрне гел үзгәртеп бетергән. Сөтне гел әллә нәрсә ясаган. Теге кырык җиде баш тана-бозауларга да өчәр мең килограмм сөт чәпәп куйган. Быел кимендә мең ярым центнер сөтне юктан бар итәргә туры киләчәк.

Күңелле хәбәр әйтмәде Һәнүз. Мең ярым центнер. Болай да барлык резервларны искә алып төзелгән планга тагын мең ярым центнер сөт!

— Житкерсеннәр! — диде Рамай ачу белән.— Үзебезнең нык планны арттырып утәрбез. Ә ул мең ярымны узләре теләсә каян тапсыннар. Районда сыерларның баш саны аз булуга мин гаеплеме?

— Шуны кертеп, законлаштырып план гына житкерсеннәр әле. Карап тор, өлкәгә, үзәккә барып житәм, әмма ләкин дәреслекне тапмый кайтмыйм. Күптән уйлап йөрим инде мин. Үзәк Комитеттан, гомумән югары оешмалардан дөрес, ифрат дөрес карарлар чыга, ә шушында безгә, аны үтәүчеләргә килеп житкәндә ул әллә ничәгә үзгәртелеп, төрләнеп бетә. Безнең терлек продуктлары сату буенча бишьеллыкка ныклы планыбыз бармы, бар. Нигә тагын мөгез чыгарып утыралар анда — авыл хужалыгы идарәсендә.

— Идарә тиргәп йөрәккә май кунмый, син юкка кызма. Бозаулары исәйгәч тә, бер-ике ай интенсив симертүгә куябыз да, озатабыз аларны дәүләткә. Син әнә шулар урынына яңа резерв әзерләү ягын кара. Калганына мин жавап бирермен.

— Бер башка гына жавап бирү кайчак авырга килә ул, Рамай абый.

— Шулай да акыллы малай син, Һәнүз... Тик менә теге ягын гына...

— Әллә син мине бик рәхәттән эчә дип беләсеңме, Рамай абый. Болай да янган йөрәгеңә баш зоотехник кебекләр учлап тоз салып торсын әле.

Сыер савучылар килә башлады. Алар һәрберсе Рамай белән исәнлек-саулык алышып, кием бүлмәсенә үттеләр. Өс-баш алыштырып, фермага ашыктылар. Һәнүз белән Рамай да урыннарыннан кузгалдылар.

Тышта жил басыла төшкән иде инде. Ферманың кысыбрак куелган ишегеннән жылы су, силос исе бөркелә. Һәр савымчы үз малы тирәсендә мәш килеп эшләп йөри. Әнә берсе пычракка яткан сыерын иркәли-иркәли урыныннан кузгата.

Фермага жилләнеп Мәрьям килеп керде.

— Саумысез, кызлар?—дип, ул яңгыратып сәлам бирде. Үзәк коридорда председатель белән Һәнүзне күргәч, соңгарак калуының сәбәбен аңлатырга тырышкандай: — Дамирым кәжәли... Авызына бер сүз алган, Чаллыга китәм, ди. Эчәр чәйләремне эчмичә шуны игәүләп утырдым,— диде. Рамай аның һәр сүзенә колак салды. «Сөйләшергә кирәк, бүген үк, хәзер үк»,— дип уйлады ул һәм Мәрьямгә йомшак кына:

— Ә ник китәм ди соң ул? — дип сорады. Мәрьям шәл астыннан чыгып торган чәчләрен жыя-жыя:

— Кем белә аны. Әйтми бит. Тикмәгә түгелдер инде,— диде.

— Миңа да бер тишкән иде инде ул. Син борчылма, Мәрьям. Мин аның белән сөйләшермен. Аннары, үзең дә иртәнге савымнан соң идарәгә сугыл әле.

Мәрьям, сөлгесен беләгенә салган килеш, башын иде, саву агрегатлары урнашкан бүлмәгә кереп баручы Рамай белән Һәнүзне озатып калды. Рамай, зоотехникны ияртеп, барлык фермаларны әйләнеп чыкты. Дуңгызлардан үрчем алу цехының вентиляциясе эшләми икән. Пар белән жылытыла торган бинаның һавасы авырайган.

— Кичә кич кенә эшләми әле ул,— дип акланды цехта дежур торучы кыз. Былтыр гына унны бетереп килгән иде ул монда. Минзәлә техникумына барып керде дә фермага эшкә төште. Бик чая, сәхнәләрне иңләп йөрүче кыз үзе. Аны берәр культура агарту йортына жибәрергә иде Рамайның исәбе. Кем белә, бәлки шәп кенә артистка чыгар үзеннән. Ләкин кыз үзе каршы килде: эшлим әле, аякка басыйм әле, жырлап-биергә безнең үзебездә дә ирек иң. Безнең культура сарае кебекләр Казанның үзендә дә бармак белән генә санарлык, диде. Бармады,

калды. Бригадир беренче кушу белән фермага киткән. Исеме ничек соң әле, хәтердән чыккан. Элекке бригадир Заһир абый кызы инде.

— Үскәнем, болай ярамый, кормокухнядагы абыйларыңа дәшәсең калган. Алар хәзер ялт итеп куялар бит аны,— диде Рамай кызарудан борын очларына кадәр тирләгән кызга. Кыз башын ия төште һәм:

— Искәреп житкермәдем инде, абый,— диде.

Фермаларда хәл зарланырлык түгел иде, сарыклар утары гына тыгызрак. Тәңгелеккә ябарга урын житми. Быел аны кинәйтми булмас. Кошчылыкны бетерсәләр, аның фермасыннан әйбәт кенә бер нәрсә эмәллэп була инде. Яшьрәк бәрәннәр, кәздән үпкәсенә салкын элэктергән сарыклар өчен. Юк, кошчылыкны бетереп булмый. Быел менә бетәргә тиеш иде дә бит. Бетергән булсак? Ә йомырка планы барыбер житкерелде. Фермаларны бетергән колхозлар нишли икән хәзер?

Колхоз идарәсенә кайтканчы ул әнә шундый чуалчык уйларның әле бер очына, әле икенче очына тотынды. Һәнүз фермада калды. Санитария көненә йомгак ясасы бар аның.

Идарәнең киң коридорында аны күрше «Таза Чишмә» колхозы председателе, зур корсагына терәү салмый ничек йөрүенә гажәпләнерлек Габитов көтеп тора иде.

Кабинетка керделәр. Рамай өс-башын салып куйды, теге дә изүләрен чишеп жибәрде, урындык алып, өстәлнең икенче ягына кунаклады. Габитов тамак кыргалап, май баскан күзләрен ялтыратып:

— Рамай Ибраһимович, мин тагын бүрек салып синең янга инде, үтермә, слушай... Тагын бер-ике йөз центнер гына булса да бир инде,— диде.

Рамай тәрәзәгә күз төшерде. Буран һаман котыра, салкынайтып та жибәргән, ахрысы. Кар бөртекләре, ком шикелле, тәрәзә пыялаларына сибелә дә чәчрәп жиргә коела.

— Бирсәм үземә авыр, бирмәсәң сиңа авыр,— диде Рамай, өстәл тирәсендәге ак кәгазьгә күнегелгән гадәте буенча каләм белән параграф билгеләре ясап.— Әйттем мин сиңа, якын итеп. Яна ул салам... Аннан үзеңне дә яндыра. Янасыңмы хәзер?

Габитов авыр гына мышнап куйды.

— Терсәк якын да бит...

— Син, брат, менәтерә кодагый, иске авызга яңа аш дигәндәй, башыңны җүләргә дә салма, простофиль дә булып кыланма. Андый заманнар үтте инде. Тунга сөрү буенча премияне элэктерергә кирәк иде сиңа. Байрак та кулыңда, премияң дә кесәңдә... Ну? Их, сине, сине!

— Я, кызма әле, Рамай Ибраһимович. Ел саен мондый хәлгә калмабыз. Синең дә безгә йомышың төшәр...

— Син шәп. Үтечкә ике пар тәгәрмәч бирмәдең, «ГАЗ»ларга.

— Юк иде бит ул...

— Күзеңнең үк нуры юк. Ичмаса, хәзер алдама. Мин бит аны, синнән сораганчы, складыгызга кереп, үз күзем белән күреп, менә шушы кулларым белән тотып чыктым.

— Рамай Ибраһимович, үткән эшкә салават инде, я, юкка үпкәләшмик.

— Әнә-әнә! Шул, үткән эшкә салаватлар ашый да синең башыңны! Үз башыңны эшләтмәгәч, бүгенге көн белән яшәүчеләрнең кубызына бии башлагач, таяк таянып салам эзләргә чыктыңмы хәзер бөтен район буйлап?

— Соң, үзең беләсең бит, вәкилләр жиппәреп яндырттылар. Нишлисең. Каршы килсәң, ник райкомга каршы барасың? диләр.

— Андагы ике-өч кеше райком түгел әле ул.

— Попробуй шулай диярга!

— Ә нигә әйтмәскә? Райком менә син, мин, безнең кебек коммунистлардан тора ул. Аның ялгышы — безнең ялгыш. Безнең уңыш —

аның уңышы. Без ялгышсак — ул ялгыша. Безнең ялгышырга хакыбыз юк. Аңлыйсыңмы, юк! Чөнки безнең чәнчә бармак очы чаклы ялгышуыбыз да бик кыйбатка төшә. Райком — олы, изге исем. Аның олы хокукы бар. Һәр сүзе уйлап әйтелергә тиеш. Аның бер генә ялгыш сүзе дә кайчак халык җилкәсенә миллион сумнар булып төшә, колхоз, совхоз кесәсенә керергә тиешле миллионнарны җилгә очыра. Безгә, коммунистларга, аеруча райком составында тулы хокуклы член булып торучыларга моны онытырга ярамый, бер генә минутка да ярамый. Ә син былтыр көз шуны оныттың, Габитов туган. Тәти сүзләр сөйли белмим мин... Әле син яшь. Менә боларны, аеруча, председатель кешенең ялгышырга хакы юклыкны онытма, борыныңа киртләп куй!..

— Керендерецне белеп килдем. Туры сүзең өчен рәхмәт, Рамай Ибраһимович. Тик үтермә инде.

— Бирәм. Ләкин аңлап ал... Без бит икебез дә бер иман белән дәүләткә дип, халыкка дип эшлибез. Шунлыктан, булганда бирүе күңелле генә ул. Ике йөз центнерга акча түләрсез. Сезнең як басудагы, каенлык буендагы өченче елгы борчак саламы эскертен болай гына алыгыз... Мал-туар астына җәяргә ярап куя ул.

— Рәхмәт, Рамай Ибраһимович.

Габитов чыгып киткәч, озак та үтмәде, Мәрьям килеп керде. Аның бөтен өстен, хәтта йөзен кар сарган. Ишекне ябу белән ул, бияләен салып, битендәге юеш карны сыпырып төшерде. Рамай Мәрьямгә түргәрәк килеп утырырга кушты. Үзе утырмады, ишеккә таба күз ташлады да:

— Менә нәрсә, Мәрьям,— диде, беравык, йомгак очын таба алмагандай, сүзсез торды.— Дамирның Чаллыга китәм диюе аңлашылып җитми бит әле. Мин бу турыда аның үзенә әйткән идем. Ул теше-тырнагы белән каршы килде. Ә хәзер кинәт кенә, менә сиңа кодагый, ни ди икән. Сәбәп нәрсәдә?

Мәрьямнең шомырт кара күзләрен яшь пәрдәсе каплады. Беренче салкыннар суккан бөрлегәндәй иреннәре тартышып алды.

— Ник икәнен беләсеңдер, Рамай...

— Юк шул...

— Сәвиян Чаллыга китәргә язу алган...

— Күнгән иде бит ул монда кайтырга. Яңа амбулаторияне, бала тудыру йортларын карап йөрде... Их, аңламассың бу яшьләрне. Һәрберсенең ни белән сулаганын беләм дип йөрим. Үз кызымның уйлары да томан аша гына күренгән икән.

— Кеше турында күбрәк уйлыйсың шул син, Рамай...

— Мәрьям... Мин сине хөрмәт итәм...

— Мин дә, Рамай... Бер үпкәм дә, йөрәк түрендә тузан хәтле дә үпкәм юк минем сиңа. Буласы — булган, буявы сеңгән. Тик менә болай булулары гына.

— Нишләргә соң, Мәрьям?

— Белмим. Башларым катты минем хәзер, Рамай...

— Соң бит аларга семья корырга ярамый.

— Аңлыйм, Рамай... Аңлыйм, бәгърем!..

Мәрьямнең күзләрен каплаган яшь пәрдәсе кинәт юкка чыкты: иртәнге чык төсле саф яшь тамчыларыннан бите буйлап ике эз сызылып калды. «Ике юл, яшь тамчылары... Берсе — Сәвия, икенчесе — Дамир»,— дип уйлады Рамай. Аның йөрәге чәнчешә башлады. Өстәл тартмасыннан тиз генә валидол алып капты. Рамай тагын соравын кабатлады:

— Нишләргә соң, Мәрьям?

Мәрьям кесәсеннән кулъяулыгы алып, яшьле күзләрен сөртте һәм тирән итеп сулады да:

— Син ир кеше бит, Рамай... Дамир да инде үз акылындагы егет. Ирләрчә сөйләшегез... Тик Сәвия белән Сәкинә генә ишетмәсеннәр, белмәсеннәр... Мин генә ни йөзләрем белән күренермен Дамирыма, бәгыремә?.. Шуны күз алларыңа китерәсеңме син, Рамай? Их, бу сугышлар!.. Мондый көннәргә кала торган кыз, хатыннар идемме соң мин?.. Үз язганым исән-иминнәр кайткан булса!.. Менә шул, шулай сөйләш, ирләрчә... Ирсезлекне ил белән күтәргәндә берни түгел иде әле, ялгыз башың улсызлыкны ничек күтәрерсең? Дамирым!.. Ярый ла аңласа, гафу итсә ул мине!

Рамай ни дип тә әйтергә, хисләр өермәсеннән аек башын калкытырга өлгермәде, Мәрьям, күзенә кулъяулыгын каплап, кабинеттан чыгып китте...

Өстәл артында, башын тотып, озак уйланып утырды Рамай буран котырган бу көнне.

* * *

Ике айлык йомгаклар белән зоотехникларны район Советы башкарма комитетының авыл хуҗалыгы идарәсенә чакырдылар. Өч көн алдан хәбәр итеп куеп яхшы эшләделәр әле. Һәнүз ныклап әзерләнде. Баш зоотехникның үзенә бәйләнәсен күңеленнән сизеп, барлык зиһенен җикте, нинди генә саннар белән тутырмады ул кара күн тышлы блокнот битләрен. Быелгы эш нәтиҗәләрен узган елгы чор белән чагыштырды. Азык берәмлеге, кеше-көнгә күпме продукция җитештерелү, үзкыйммәткә кадәр хисаплады. Төп ударны, әлбәттә, былтыргыга караганда һәр сыердан сөт савып алуның ни өчен кимү сәбәпләрен ачуга бирде. Тулай җыем, сүз дә юк, артык. Дәүләткә сатудагы үсеш 10 процентган артып китә. Ит җитештерү һәм хәзерләүнең квартал планын үтәделәр. Анысына бәйләнерлек түгел. Тапшырылган терлекләрнең яртысыннан күбрәге югары көрлектә. Уртача авырлыклары да таләп иткән стандартка туры килә. Йомырканың квартал планын үтәү авыррак булыр. Ләкин, Һәнүз исәбе буенча, көннәр җылыта башлау белән йомырка тәгәрәргә тиеш. Аннары, моңа әллә ни исе дә китми Һәнүзнең. Эш принципка китсә, аларның кошчылык фермасы КПСС райкомы бюросы, район Советы башкарма комитеты карары белән бетерелгән дә бит. Юк фермадан нәрсә таләп итәсең! Бу тирәдә сүз куерта башласалар, Һәнүз башын җүләргә салырга уйлады. «Әле соңгы сводкада гына бездә тавыклар барын белдем. Күздән үк бетерелгән иде бит инде ул. Яз җитә башлагач җылы яктан гына кайтмасалар инде»,— дияргә булды. Ә кыса башласалар: «Сезнең юк фермага план житкерергә хакыгыз юк. Әнә специальләшкән фермаларыгызга житкерегез. Безнең үз планыбыз бар, шуны үтәрбез. Күктән төшкән планнар белән ми черетә торган заманалар әллә кайчан үтте инде, безнең бәхеткә каршы»,— дигән җавап та уйлап куйды. Нигә куркырга, турысын әйтмәскә, бөкәй түгел бит алар. Алдынгы колхоз сыртында яшәргә өйрәнмәсеннәр әле. Арттагы колхозларны аякка бастыру турында күбрәк баш ватсыннар. Район җитәкчеләренең төп эше шул булырга тиеш.

Әнә шундый уйлар белән хәзерләнде, шундый хисләр белән килде Һәнүз район зоотехниклары киңәшмәсенә. Башлыкларны өлкә комитет бюросына да чакыралар икән. Шуңадыр инде, киңәшмәгә барлык бюро членнары да катнашты. Киңәшмәне авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Урмакаев ачты. Ул һәр колхозда терлек продуктлары җитештерү, хәзерләү, үрчем алу, үлем, баш саннарының үтәлеше һәм башкалар турында сөйләде. Аннары сүзне баш зоотехникка бирде. Озын буйлы, чәчен тап-такыр итеп алдырган баш зоотехник мәсьәләне конкрет куя башлады. Шәймиевкә карап-карап алып, район хуҗалыкларында

терлекләрне кышлату буенча хәвефле хәл турын әйтте. «Күп колхозда ашатырга салам да калмады. Ярый әле, күрше районнар ярдәм кулларын сузалар»,— диде. «Ә без менә ярты кыштан бирле «Таза чишмә» леләрне сөйрибез»,— дип уйлап алды Һәнүз. «Беренче Май» колхозын баш зоотехник бөтенләй диярлек телгә алмады. Һәр сыердан сөт, һәр тавыктан йомырка алу буенча гына тәнкыйтьләде.

Һәнүзнең уйлары бу тар кабинеттан чыгып, канатлы кош кебек, әллә кайларда очып йөри башлады. Куен кесәсеннән блокнотын алды. Аңа ияреп телеграмма чыкты. Ася телеграммасы иде бу. Аны Совет Армиясе көне белән котлаган телеграмма. Күз алдына Ася килде. Әнә ул аның муенына сарылып елый. «Яратам, өзелеп яратам да бит, нишлим? Ярамый. Туганнарның берсе дә риза түгел...» Әнә шулай бәгырьләре телгәләнерлек итеп аерылышканнар иде алар. Һәнүз өйләнгәннән соң, Ася араны бөтенләй өзгән иде. Үткән ел республиканың зоотехниклар конференциясендә очрашкач, өзелгән өмет кыллары тагы ялганды. Килерме? Әнә шундый уй белән Һәнүз бер көн алдан очты Казанга. Гостиницага урнашкач та әллә кая китмәде, администратор бүлмәсе тирәсендә уралды. Асяны да ул иртәрәк килер дип өмет итте. Әмма Ася ул көнне килмәде. Икенче көнне дә Һәнүз аны очрата алмады. Инде өмете өзелеп, янган йөрәгенең ярсуын басарга теләп, бер төркем иптәшләре белән ресторан ягын каера башлаганда, ул Асялар районында яшәүче зоотехникны очратты. Институтта бер тирәләрдә укыган егет иде ул. Күрешеп, хәл-әхвәл сорашу белән Һәнүз Асяны сорады.

— Бергә килдек, «Заря» гостиницасына урнаштык,— диде егет. Һәнүз җыелган компаниягә кул гына селтәде һәм, Бауман урамына сыймый агылган кешеләрне ера-ера, трамвай тукталышына йөгерде.

Ася үз номерында иде. Һәнүз җиңелчә генә шакыганга ул үзе ишекне ачты. Алар, гаҗәпсенүдән, күзләрен-күзгә терәшеп сүзсез калдылар. Һәнүзнең тыны кысылгандай булды, шатлыктан илереп елаган күңеле түреннән күзләренә яшь тамчылары сыгылды. Асяның да иреннәре дерелдәде. Һәнүз, гадәтенчә, башын артка чөебрәк җибәрде, шулай итсә, дулкынлануы бераз басыла төшә иде аның.

— Асюк, килдеңме?.. Исәнме, Асюк!.— диде ул аңа, кулларын сузып. Асяның күзләренә моңсулык күләгәсе инде, ул башын ия төште. Чәчен кистергән, бөдрәләткән.

— Исәнме, Һәнүз?.. Килдек әле менә,— диде ул һәм: — Әйдә, кирәгез, чит кешеләр юк, үзебезнең районнан ул апа, түбәсе тишек түгел, курыкма,— дип, татарчалап өстәде.

Һәнүз өстәл янында газета укып утыручы өлкән яшьтәге ханым белән исәнләште дә бер урындыкны читкәрәк тартып утырды.

— Син үзгәрмәгәнсең,— диде Һәнүз татарча һәм алар татарча сөйләшә башладылар.

— Ә син үзгәргәнсең... Күз кабакларың капчыклана башлаган, әллә йокы әләкмиме? — диде Ася, кулын кая куярга белмичә.

— Йокысы бар инде аның... Барып чыкмасам инде... Үземнән-үзем курка башлыйм кайчак,— диде Һәнүз, авыр уфтанып.

— Ник эчәсең?..

— Их, Ася, аңласаң икән син!..

— Аңлыйм, Һәнүз...

— Ике кеше мин... Берсе эшли, берсе гел сине уйлый. Бер генә минут бер кеше булып эшлисе, бер кеше булып берәүне генә сөясе иде...

— Соң син икешәрне, өчәрне сөясеңмени?..

— Дөрес әйтеп бетермәдем мин аны. Сөйгәнең белән бергә, аның йөрәк җылысы белән эшлисе иде дим. Андыйлар бәхетледер. Андыйлар гына зур эшләр башкарырга сәләтледер дип уйлыйм мин.

— И хыялый, бәхетсез хыялыем минем!..

Күзләрдәге сагыш, сагынуларны ханым да сизенә, ахрысы, ул ара-тирә аларга карап-карап ала иде. Ася уңайсызлана төште. Моны Һәнүз дә шәйләде һәм:

— Әйдә, Ася, урамга чыгыйк, берәр кинога керербез, юлда иркенләп сөйләшербез,— диде. Ася каршы килмәде, бүлмәдәшенә:

— Мин кинога барам әле,— диде дә тиз-тиз өс-башына киенде.

Тышта караңгыланып килә иде инде. Тротуар кырыендагы юкәләрне бәс сарган. Сыкылы, томанлы кич. Урамга чыгу белән Һәнүз Асяны култыклады, аның беләген назлап кына кысты. Алар бер аяктан атлап киттеләр. Чехов базары янындагы кинотеатрга гына бардылар. Алар укыганда салынган иде бу кинотеатр. Картинасы әллә ни искитәрлек булмаса да, башка барыр урыннары булмагач, карарга булдылар. Дөресрәге — сөйләшергә, аңлашырга кирәк иде аларга. Ике ел — аз гомер түгел бит! Шуннан соң да бер-берсенә тартылган күңелләргә ни диясең. Һәнүз генә түгел, Ася да күптән, күптән зарыгып көткән булып чыкты бу күрешүне...

— Сүз «Беренче Май» колхозы зоотехнигы иптәш Гумеровка бирелә.

Урмакаев тавышы аны сискәндереп җибәрде. Уйлар җебе өзелде. Асяның йомшак кулларын тотып утыра иде бит әле ул, аңа соңгы, иң актыккы сүзен әйтергә генә дип авызын ачкан иде... Әнә, әнә, Асяның мамыктай куллары эреп юкка чыкты... Һәнүз башын артка чөеп җибәрде, блокнотын бармак араларына кыстырып, урыныннан кузгалды.

— Ни сөйлим? Безнең айлык планнар үтәлгән инде,— диде ул әкрен генә.

— Узган елга караганда һәр сыердан савым ни өчен ким?

— Иптәш Урмакаев, моны аңлатып торуның кирәге юк, минемчә. Сез моны үзегез дә яхшы беләсез...

— Бернәрсә дә белмим, мин бары дәүләт отчетын беләм. Сезнең колхоз ике айда һәр сыердан сөт савып алуны узган елга караганда утыз алты килограммга киметкән. Отчетка башта син кул куйгансыңдыр бит?

— Мин...

— Кимегәнен белә торып ник кул куйдың?

— Кул куйганда гына арттыра алмыйм бит инде мин ул сөтне.

— Чәчә белгәнсең, ура да бел!..

— Икенче уңыш көтеп чәчелгән эш ул. Сөт өчен түгел...

— Бюро членнарына сөтнең кимү сәбәпләрен аңлат!

Һәнүз блокнотының кирәкле битен ачты һәм теге сөт бирмәүче кырык җиде баш сыерны кертмичә савымның ничек булуы турында сөйләргә кереште.

— Мәсьәләгә реаль килгәндә бездә һәр сыердан савым артык, тулай җыем, дәүләткә сату да бишьеллык үсеш темпларына туры килә. Әле бу кышкы, иң авыр айларда, сыерларның күпләп бозаулау чоры житмәгән вакытта. Май айларында башлана бездә масса төсендә үрчем алу. Шулай итеп, лактация чоры яшел азык мул вакытка туры килә. Сөтнең тулай җыемы быел кимендә 20—25 центнерга артачак...

Аны тагын Урмакаев бүлдерде:

— Конкрет сорауга конкрет җавап бирегез, иптәш Гумеров!

Һәнүзнең колак яфраклары кызышты. «Менә бит, ни өчен казып чыгара ул моны, нинди мәкер белән?» — дип уйлады ул һәм блокнотының икенче битен ачты.

— Алайса, сезнең исәп белән менә болай була,— диде Һәнүз, дулкынлануын бераз баса төшеп.— Колхоз идарәсе каршы килүгә карамастан, ана терлекләрдән интенсив файдалану өчен дип каплатып бозаулаткан нәселсез, браковать ителгән таналарны ни өчен сез сыер итеп исәпкә алдырдыгыз? Без бит сезгә ел азагында болай да баш

санын үтибез дип вәгъдә бирдек. Һәм үтәдек. Акча кызганып тормадык, утыз баш холмогор тана алып кайттык, буазларны. Алар барысы да яңа елга кадәр бозаулап бетте. Баш саны өчкә генә булса да арттырып үтәлде. Ит өчен, бер бозау булса да алып калу өчен асралган ул кырык җиде баш бозаудан бозаулаган мүкләк кәҗәләрне нигә сыер итеп безгә тагасыз? Юк, һәр сыердан сөт савуны ким дип санамыйм мин.

— Ә соң менә бу ни? Филькина грамотамыни синә бу дәүләт отчеты?

Урмакаев 24 нче форманы тотып селкеде, аны өстәлгә атып бәрде.

— Районда сыерларның баш саны тулмауга «Беренче Май» колхозы гаепле түгел. Баш санын андый кәҗәләр белән тутырмыйлар аны...

Урмакаевның ялан хәтле кабинетындагы барлык зоотехниклар, бюро членнары тын калды. Урмакаев бер Шәймиевкә, бер Вәрәшовка карап алды. Шәймиевнең йөзендә тимгелләр торган саен куера бара. Вәрәшов, берни уйламагандай, төз генә утыра. Редакторның очлы борыны күтәрелгән, авызы ачылган. Ул нидер әйтергә тели булса кирәк. Урмакаев аңа, әйдә сөйлә, дип ым какты, Һәнүзгә кисәк кенә: «Утыр», диде.

Редактор торып басты. Калтыранып торган озын кызыл бармаклары белән өстәлдәге кәгазьләрне кирәккә-кирәкмәскә дә актаргалап, тәкәбберлек өчен генә тамак кырып алды.

— Иптәшләр, миңа иптәш Гумеровның позициясе берничек тә аңлашылмый,— дип башлады ул сүзен,— гомумән, «Беренче Май» колхозы җитәкчеләренең. Мин, бюро тарафыннан шунда беркетелгән вәкил буларак, бу колхозны, аның җитәкчеләрен яхшы беләм. Алар үзләренчә, үзләренә файдалы булганча гына эшләргә яраталар, өйрәнгәннәр. Директив органнарның күрсәтмәләрен алар әле башта үз бизмәннәренә салып үлчиләр. Аннан соң гына, әгәр дә ул, басым ясап әйтәм, әгәр дә ул үзләренә файдалы булса үтиләр, ә инде үз бизмәннәренә туры килмәсә, юк, пушка белән дә алдыра алмыйсың. Менә бит алар нинди! Алар район хәленә дә кермиләр, дәүләт интереслары белән дә исәпләшмиләр. Дисциплинасызлык бит бу. Үзәк Комитетның декабрь пленумы мондыйларга кискен сүзен әйтәчәк. Без дә әйтергә тиеш. Бюро, район Советы башкарма комитеты карарларын кире кагып, туңга сөрүне чак кына өзмәделәр. Авыл хуҗалыгын үстерүнең генераль линиясе — специальләштерүгә каршы килделәр.

Һәнүз ничек торып басканын да сизми калды.

— Аның каравы, без салам сорап теләнеп йөрмибез, ярты районны үзебез тәэмин итәбез. Йомырканы да йорт саен җыеп йөреп колхоз исәбенә тапшырмыйбыз. Анысы авыл Советы эше аның. Аннары, бик акыллы булгач, ни өчен карар белән фермалары бетерелгән колхозларга йомырка тапшыру планы җиткердегез? Кая монда логика? Кая монда дөреслек? — диде ул һәм ялт итеп урынына утырды.

— Мин катырак торсам, сез дә яндырып бетерә идегез инде саламыгызны,— дип, авыз эченнән мыгырданды редактор. Залдагылар дәррәү көлеп җибәрделәр.

Шәймиев торып басты. Барысы да шым булдылар. Рәшат Галиевичның бөтен битен тимгел каплаган иде. Редакторга җен ачуы чыкты аның. «Әйбәт кенә башлаган фикеренә бер кашык деготь өстәде»,— дип уйлады ул.

— Иптәшләр, сез районның төп таянычлары,— дип тыныч тон белән сөйли башлады Рәшат Галиевич.— Нинди зур вакыйга алдында торганны беләсез. Илебез партиябезнең чираттагы съездына килә. Һәркайда миллионнар съезд хөрмәтенә удар хезмәт вахтасына бастылар. Районыбызның алтын куллары да, барлык совет халкы кебек үк, бу зур тарихи вакыйганы — Коммунизм тантанасын якынайту өчен,

халык хуҗалыгын үстерүнең яңа программасын бирүче партиябез съездын яңа җиңүләр белән каршы алу өчен көрәшәләр.

Шәймиев озак сөйләде. Күп хуҗалыкларны, зоотехникларны тәнкыйтьләп телгә алды. Тик, ни өчендер, «Беренче Май» колхозына әле һаман кагылмый. Чү, менә аларга да чират җитте.

— «Беренче Май» колхозы зоотехнигы, хөрмәтле иптәш Гумеров биредә «кая монда логика, кая монда дөреслек?» — дигән кискен сорау куйды. Партия моңа, әлбәттә, җавап бирергә тиеш. Һәм бирәбез, иптәш Гумеров,— дип сүзен дәвам итте Рәшат Галиевич.— Фактлар бик кире нәрсә бит алар, алардан бер кая да китә алмыйсың. Сезнең тел төбегез шуңа бара: имеш, ни өчен браковать ителгән таналар бозаулагач, аны сыерлар исәбенә керттегез? Ә без аны кайсы графага кертик? Бозаулаган ич алар, димәк, сыер, димәк, факт. Ә сезнеңчә килгәндә, иптәш Гумеров, инде ул сыерларны бозауламаганга санасак, алардан алынган үрчемне кая, нинди графага куярга? Аны сез, бәлки, үлемне яшерү өчен резерв итәргә боерырсыз? Юк, бу номер да үтми, туган бозаулар да факт һәм алар исәптә булырга тиеш.

— Ә алар керемгә алынган...

— Бүлдермәгез. Хәзер мин сөйлим. Димәк, район партия комитеты сезнең ул сыерлардан сөт таләп итәргә хаклы. Биредә логика бар һәм ул һәркемгә барып җитәрлек, иптәш Гумеров. Ә йомыркага килгәндә, мәсьәлә тагын да ачык: тавыкларыгыз бармы — бар. Факт. Алардан алынган йомырканы, телисезме-юкмы, барыбер дәүләткә сатарга мәҗбүрсез. Бу да факт. Шунлыктан директив органнар планны дөрес җиткергәннәр; дөресрәге, әле бу тармак буенча үзегез эшләгән планны раслаганнар. Бу да бик логикалы. Дөреслек һәм логиканың кайсы якта икәнен аңладыгызмы, иптәш Гумеров?

Һәнүз янадан басты. Аның тез буыннары җиңелчә генә дерелди иде.

— Юк, Рәшат Галиевич... Аңламадым, барып җитми бу минем башка. Ачыктан-ачык әйтүемне дә дөрес аңлагыз. Бу мәсьәләләр буенча без күп сөйләштек, уртак фикергә килеп җитмәде. Мин үз позициямне югары органнарга хәбәр итмичә булдыра алмыйм. Ялгышам икән, сезнең алда, шушы коллектив алдында чын күңелдән гафу үтенермен. Ләкин артык болай эшләп булмый...

— Рәхим итегез, иптәш Гумеров. Бездә һәр партия члены өчен тулы демократия...

Киңәшмә озак дәвам итте. Сүз күбрәк азыкларны эшкәртеп ашатуны оештырудагы кимчелекләр турында барды. Күпчелек хуҗалыкларда фураж җитәрлек икән әле. Тик салам юклыктан җәфа чигәләр.

— Элек, ичмаса, ферма түбәләрендәге саламны ашата идек, хәзер алары да шифер бит аның,— диде кайсыдыр. Аннардан дәррәү күтәрелеп көлделәр.

Соңыннан беренче кварталда дәүләткә терлек продуктлары тапшыру буенча һәр хуҗалыкка задание җиткерелде, аны үтәү өчен нинди мөмкинлекләр булуны ачыкладылар. Һәнүз «Беренче Май» колхозы өчен җиткерелгән заданиеләрдән бары ит буенча әйтелгән санга гына каршы килде. «Безнең баш саннары үтәлгән. Планнан тыш сату файдалы. Тагын 50 центнер өстәргә кирәк. Югары көрлектәге ун баш үгез бар әле безнең, диде. Урмакаев моның белән тиз килеште, 50 санын өстәп куйды...

Башка вакытта Һәнүз ашханәгә керсә тамак чылатмый калмый иде, бу юлы нигәдер күңеле тартмады. Шул килеш, «коры килеш» кенә, кәешләрын чишеп җибәреп, тәмләп ашады. Аннары банк тирәсенә китте. «Синең дә барасың булгач, мин дә ярим әле, банкта эшләрем бар иде»,— дип, Карам да килгән иде. «Волга» банк каршысында тора иде. Һәнүз кабинага карады. Дамир юк иде. Шул вакыт алар икәүләшеп банктан чыктылар.

— Әллә эшең бетте, Кәрам абый? — дип каршылады аларны Һәнүз.

— Бетте. Китәбезме?

— Киттек.

Дамирның сөмсерләре коелган. Килгәндә дә бер сүз дәшмәгән иде. Кайтканда да юл буе авызын ачмады. Авылга кергәч, Һәнүз үз йортлары янында төшеп калды. Нәсимә эштә иде әле. Һәнүз ишекне үзе ачып керде. Өй җылы, рәхәт иде. Иплəп кенә өс-башын чишенде. Өстәл өстенә ябылган кәгазьне күтәреп карады. Шакмаклы дәфтәр битенә Нәсимә язу язып калдырган. Бер аягын күтәрә төшеп, бер кулы белән өстәлгә таянган килеш, ул язганнарга күз йөртте. «Һәнүз, кайтсаң, барысы да өстәлдә. Суынса — җылытып ал. Мин соңрак кайтырмын — репетиция. Нәсимә»,— дип язылган иде дәфтәр битенә. Һәнүз ризыклар өстенә газетны яңадан ябып куйды. Сизмәде дә: аягы туңып киткән бит. Аннары идәннәре дә салкын аларның. Мич өстендәге киез итеген алып киде. Ул ишекле-түрле йөрергә тотынды. Башында әле бер, әле икенче уй янара. Әле Шәймиевнең тимгел йөгергән йөзе, әле Асяның чиядәй иреннәре күз алдына килде. Һәнүз башын артка чөеп җибәрде, стенадагы фотога карады. Путаллы рам эчендә Һәнүз белән Нәсимәнең рәсеме. Язылышкач та төшкәннәр иде. Нәсимә аны Әлмәттә зурайттырды. Бу кыйммәтле рамны да шуннан алып кайтты. Әнә, ничек пар килгәннәр алар, югыйсә. Һәнүз янында Нәсимә янып тора. Йөзе тулган ай кебек. Художник аның калын кашларын бераз нечкәртеп дөрес эшләгән. Болай тагын да матур күренә Нәсимә. Борыны матурлык алласы Венераныкыннан бер дә ким түгел. Иреннәре калынрак, әмма үтә килешле. Күкрәк турына чаклы ачык муены мәрмәр сын кебек. Беренче күргәндәй итеп карап торды ул Нәсимәнең озын керфекле күзләренә. Шул күзләре белән аның серләрен укый кебек тоелды ул аңа.

«Их, Нәсимә, Нәсимә,— дип пышылдады Һәнүзнең иреннәре.— бер елганың ике яры кебек бит без. Үзебез бергә, күзгә-күзләр карашып торабыз, бергә гомер иткән булабыз, ә якыная алмыйбыз... Аралардан салкын дәрья ага да ага. Бер елганың кара-каршы ярлары шул без. Елга яры... Ярлар түгел».

Нидер исенә төшкәндәй, Һәнүз фотодан читкә борылды һәм язу өстәле артына утырып, тартмалардан юньлерәк, күңеленә охшаганрак чиста кәгазьләр эзли башлады. Кәгазьләрен дә тапты. Өстәл артына утырып, әле бер хәреф тә төшмәгән битләргә карап торды. Авторучкасын куйды. «Язаргамы, язмаскамы?» Әнә шундый сорау алдында туктап калды. Аның бит әле гомергә дә жалоба түгел, Асядан башка берәүгә дә хат язганы юк. «Жалоба язучы!» Һәнүз иннәрен җыерып куйды. Әнә шул чиркандыргыч сүз аның уйларын бөтенләй чуалтып җибәрде. Ул янагына таянды, тәрәзәдән тышка карады. Кыш язга авышып бара, шифер түбәдән торып-торып тамчы тама. Баеп баручы кояшның алсу зөбәрҗәт нурлы көлтәләре, түр тәрәзәдән кереп, идәнгә таралган.

Һәнүз, торып, ишекле-түрле йөрергә кереште. Биш бармаклап чәчен тарап-тарап җибәрде. «Язаргамы, язмаскамы?» Тел очында туктаусыз шул сүзләр тирбәлде. Бераздан икенче сорау туды. «Кая язарга? Өлкә комитетынамы, Үзәк Комитетның үзенә үкме? Уйлана торгач, күтәрәсе мәсьәләләрнең зурлыгын, җитдилеген уйлап, ул хатны Үзәк Комитетка язарга ниятләде.

Озак, һәр сүзен, җөмләсен уйлап язды. Райком секретаре Шәймиевнең бүгенге көн белән яшәве, аның ялгышларының районга, аерым колхозларга нинди экономик зыян китерүен нигезләп, исәп-хисап ясап күрсәтеп язды. Терлекләрнең баш санын үтәлгән итеп күрсәтү өчен кайбер хуҗалыкларда бозауламаган, хәтта каплатылмаган таналарны да сыер исәбенә керттерүен дә конкрет язды. Үз колхозларындагы ва-

кыйганы, ана терлекләрдән интенсив файдалану алымын, шунын аркасында нинди «ЧП»га дучар булуларын да хәбәр итте. Тунга сәрүне вакытында тәгәлләү максаты белән салам яндыру, кышка терлекләрнең тупас азыксыз калуларын ачынып язды.

Үзен борчыган уйларның берсен дә калдырмый язды Һәнүз. Өч биттән артып китте, аннары чистага күчерде. Конвертлап, адресын пөхтәләп язды. Менә аның уйлары, теләкләре өстәл өстендә зәңгәр конверт эчендә. Һәнүз иркен сулыш алып җибәрде, иңнәреннән авыр йөк төшкәндәй булды.

Колхоз идарәсенә барырга дип өстенә киенә башлаган иде, Нәсимә кайтып керде. Аның бит очлары алсуланган, ак шәле астыннан чәчләре күпереп чыгып тора. Ишектән керү белән ул өстәлгә күз төшерде һәм ягымлы гына итеп:

— Әллә ашамадың, Һәнүз? — дип сорады.

— Ашап кайттым мин...

Нәсимә аның күзенә тутырып карады. Юк. Һәнүзнең күзләре саф, гадәтенчә, район үзәгеннән кайткандагыча, майланып, елтырап тормый. Киресенчә, нигәдер ачулангандай, кырыс иде алар. Нәсимә моны сизенде һәм:

— Һәнүз, нәрсә булды? — дип сорады.

— Юк, берни дә булмады.

Ул, күзгә каршына килеп, шарфын рәтләде һәм киим дип бүреген кулына алган иде. Нәсимә тагын сорау бирде:

— Кая барасың соң? Әзрәк капкалар идең, бер чыгып китсәң, кайчан кайтасың тагын?

— Мин хәзер кайтам. Председательне генә күрәсем бар.

— Аны районга чакыртып алдылар. Бик ашыгыч. Әле мин кайтканда гына китеп барды.

Һәнүз беравык, инде нишләргә икән дигәндәй, идән уртасында басып торды. Аннары бүреген бастырып киде дә:

— Фермалардан бер әйләнәм әле,— дип чыгып китте. Нәсимә, пальто төймәләрен ычкындырган килеш, аны моңсу карашы белән озатып калды.

Һәнүз салмак кына атлап, югары очка, фермаларга таба китте. Аяк астында кар шыгырдый. Багана башларындагы лампочкалардан урамга нур коела. Атлан тау башын тулган ай яктырта. Дулкынланып торган кар сырындылары өстендә салкын ай нурлары уйный. Ай нуры кебек аның Нәсимәгә мәхәббәте. Якты, матур, әмма салкын. Кояш нуры кебек җылытмый. Ни өмет итәсең син, Нәсимә? Минем өчен яратылган җан түгел бит син. Сине кызганып, гомер буе баш очында ай булып балкыйммы?

Нәсимәнең томан пәрдәсе артыннан күренгән шәүләсен әкрен-әкрен Ася каплады.

...Кинодан кайткач, алар Асяның бүлмәсенә керделәр. Теге ханым анда юк иде. Ася бу минутларны, кавышу минутларын күпме өзгәләнеп көтсә дә, Һәнүзне үзенә якын җибәрмәде. Хәтта иңнәренә кулын да салдырмады.

— Ярамый, Һәнүз...— диде ул, үзе алсуланып янды, каушады. Тыелгысыз яшьлек дәртләреннән, ялкын булып кабыначак мәхәббәтеннән курыкты, дөрләп янган учак янында очып йөргән күбәләк хәлендә каласы килми иде, ахрысы.

Һәнүз башын иде, идән ярыгына карап утырды. Аннары кинәт башын күтәрде, Асяның каршысына килеп басты, кулларын кесәсенә тыккан килеш, пышылдап диярлек сөйли башлады:

— Ася, мин сине мәңге күтәргә риза. Ташла шул туганнарыңның сүзен. Без бергә булырга тиеш, бергә! Ишетәсеңме — бергә!..

— Ишетәм, Һәнүз... Туганнарым да каршы түгел хәзер...

— Соң, шулай булгач?

— Син икенче кеше белән булгач, күңелем тартмый... Күз алдына китерәм дә, син әллә нинди чит, ят кешегә әвереләсен, ераклашасың. Ләкин күздән югалмыйсың, һаман кул болгап елмаясың, чакырасың.

— Ася, газапламыйк болай үз-үзебезне. Телисең икән, мин сезнең районга күчәм, теләсәң, үзебезгә алып кайтам. Безнең председательнең ниндилеген белсәң иде син!.. Синең турыда күп сөйләдем мин аңа. Аңлый ул безнең хәлләрне. Нәсимәне дә кызгана, ләкин сине якын күрә. «Яшь чакта шартлатып өз, кайсы якка да булса, аннары соң булыр»— ди. Хак әйтә ул. Кайтыйк безнең колхозга, Ася?

Ася түзмәде, Һәнүзнең муенына сарылды. Күкрәгенә капланып елый башлады.

— Үземне тагын сыныйм әле... Синең икенче кеше яры икәнлегеңне, ятсынуымны җиңә алсам, хәбәр итәрмен, хат язармын,— диде Ася.

Ләкин аңардан һаман хат юк...

Фермада кичке савымга әзерләнеп йөриләр, беренче төркем сыерларны саву залына кертәләр иде. Һәнүз, исәнләшә-исәнләшә, ферманың аргы башында асрала торган, аерып куелган теге кырык җиде баш сыер янына китте.

«Бер ел артык асрауны бише белән кайтарасыз бит, малкайлар!» — диде ул. Аның күңеле күтәрелеп китте, гәүдәсенә ниндидер көч өстәп җылы агым йөгерде. Фермадан кайтышлый колхоз идарәсенә сугылды. Анда бухгалтер Кәрам белән Заман карттан башка кеше юк иде. Заман карт бишмәтен иңенә салган да Кәрамга нидер сөйли. Кәрам, бер кулы белән счет төймәсен тоткан килеш, авызын ерып утыра. Һәнүз аяк очына гына басып ачык ишек кырына килде дә Заман картның сүзенә колак салды.

— Шулай, җәлләмәдем, кышлау тавыкны суеп киттем. Хупҗамалларның ата-аналарына, күчтәнәчле кунак булып. Баргач, аны олылап биатайга тоттырдым. Хәлле кеше иде, мәрхүм. Кияүне оятлы итмим дигәндер инде. Минем тавыкны табында күрсәтмәде. Кияү күчтәнәче дип, кышлау тәкә чаклы, билләһи, булгандыр, каз чыгарды. Җиң сызганып ботарлап бирдем кунакларга. Авыр туфрагы җиңел булсын, биатай әйбәт кеше иде, мәрхүм. Әз генә борын төшә, аш үтми башласа, хатын-кыз галәмәтенә сиздерми генә мунчага алып китә дә бал белән сыйлый. Бер алып барды бу, ике алып барды. Эчкән саен минем нәфес дигән аза бара бит. Җилеккәндер инде, мәрхүм. «Мөхәммәтзаман кияү, барса, кая икәнен белдең инде. Үзең чамала»,— ди бу. Чамаламаган кая инде ул. Кичкә, баш өянәгем кузгалып, идәнгә егылганмын да нарасыйлардай мес-мес мин...

Кәрам счет төймәләрен шалт-шолт бәреп җибәрде, үзе иелә-сыгыла көлә башлады. Заман карт, берни булмагандай, сүзен дәвам иттерде:

— Бер заман кендектән түбән эч авырта бит. Кисеп-кисеп ала. Әһә, мин әйтәм, әҗәлләрем шушы икән. Ул башны әйткән дә юк, кайнаган сумала тутыргандай. Капшанам, кырымда — Хупҗамал. Аңа төрткәләдем. Юк, уянмый. Тукта, мин әйтәм, болай булмый, ишегалларын урап, һавалар алып керим. Торып утырдым. Киттем сәке буйлап шуып. Шуам аякны алга сузып. Бәрәкалла! Нинди йөзлексез сәке соң бу? Барам да стенага төртеләм, барам да стенага төртеләм. Аптырап беттем. Тышка чыгарга кирәк. Анда чыгу өчен идәнгә төшәргә кирәк. Идәнгә төшү өчен сәке йөзлеген табарга кирәк. Миләр чиреде, болай да таман зиһен бөтенләй бетте. Маневрынный поезд кебек, тагын килеп сөрлектем Хупҗамалга. Ахырда түзмәдем, кабыргасына үтемле генә итеп төрттем. Торып та утырды Хупҗамалым.

— Нишләвең бу? — ди, йокылы-уяулы килеш пышылдап.

— Тышка чыгаргае, нинди йөзлексез сәке соң бу, идәнгә төшәлмим бит...

— Бәй, идәндә лә без... Сәкегә менеп ята алмадың бит... Хурлар иттен, әнкәйгә баш өянәге бар шул аның дигән булдым инде. Әткәй, беләм мин аның өянәген, иртәгә иснәтмәм дә, буена сендерә алмаса,— дип әйтте дип, пыш-пыш пешерә Хупҗамал. Сәке йөзлеге эзләп, идәндә шуып йөргәнмен бит шулай.— Заман карт кет-кет көлеп алды, аннары, житен сакалын сыйпый-сыйпый, болай дип өстәде:— Бүген иртәнчәк мәктәптә булганыем. Музейларында шунда крестиян өе дип сәкеләр ясап куйганнар, өйнең буеннан-буена. Ишекне кергәч тә бозау араны. Аның янында олы агач лакан... Менә бит, Кәраметдин, элек без яшәгән өйләрне музейларга куя башлаган бу заманнарга да ирештек. Без дә үлеп бетсәк, ул көннәрне искә дә алучы да булмас. Хәер, ниемә кирәге бар ул элекке тормышның!

Һәнүз әкрен генә ишек шакыды. Кәрам, йөзенә житди төс биреп, кычкырды:

— Да! Әйдә, кер, кер!

Һәнүз аяк очларына басып, елмаеп-елмаеп килеп керде. Заман карт стена буена чүгәләгән жиреннән торды.

— И-и, Шымытыр! Бур мәче кебек йөрмәсәң! — диде һәм билен тотып чыгып китте.

— Рамай абыйны ник чакырдылар икән? — дип сорады Һәнүз бухгалтердан.

— Белмим. Рәшат Галиевич сәгате-минуты белән килеп житсен дигән.

— Шалтыратмадымы соң?

— Юк.

Кәрам счет төймәләрен бистә башлады. Һәнүз бүгенге почтаны караштырып, бер көйрәтеп алды. Аннары өенә кайтып китте.

Нәсимә кичкелеккә аш-су әзерләгән, Һәнүзне генә көтеп тора иде. Килеп керүе белән, ул ана өс-башларын салырга булышты. Пәлтәсен, бүреген алып элде. Киез итеген мичкә тыкты.

— Ямансулап тора идем әле... Яхшы — тиз кайттың. Иртәгә ял бит, берәрсенә юлыкмаса гына ярар иде дип теләгән идем. Минем дә теләкләрем кабул була икән... Әйдә, юын, умывальникка жылы су салдым,— дип сөйләнә-сөйләнә ул өстәл әзерләргә керешә. Һәнүз сүзсез генә өстәл арасына кереп утырып, кулына ак күмәч телемен алуга, Нәсимә буфетка таба карап алды, ым какты. Һәнүз кул селтәде.

Күкәй белән басып киселгән йорт токмачын үлеп ярата Һәнүз. Ул аны өстәтә-өстәтә ашады. Аннары кара карлыган вареньесы белән бер йомры чәй эчте. Сәгатенә карады. Житенче китсән. Һәнүзнен Нәсимә белән ялгызы гына бер өйдә каласы килми иде. Ялгыз калдыларамы, ул сырыша, иркәләнә башлый. Жаен чыгарып, оста итеп, үз горурлыгын да югалтмыйча эшли белә ул моны. Һәнүз кул-битләрен юып сөртенде дә:

— Клубта ни бар икән? — диде.

— Кино, жидедә башлана.

— Ни дигән?

— «Освобождение».

— Әйдә барабыз.

— Хәзер, Һәнүз. Мин өстәлләрне печтек кенә тәртипкә китерим дә.

Нәсимә өстәлләрне жыештыргалаганчы Һәнүз «Казан утлары» журналының яна санын караштырды. Сөббүх Рафиковнын яна романынын дәвамы кайткан икән. Башын укыган иде, бер башлагач, ташлап булмас, кинодан кайткач укырмын әле дип, журналны киштә өстенә алып куйды.

Кинода кеше күп иде. Картинасы да әйбәт шул. Шундый көч алдында баш имәгән, бөтен Европа промышленностен үзенә эшләткән фашизмны жиңгән совет кешесенә мәдхия булып янгырый бу картина.

Мондый киноларны дулкынланып, тетрәнеп карый Һәнүз. Әле күптән түгел «Партком секретаре» дигән кино караган иде. Бүгенге колхоз тормышыннан. Ул да ошады. Тик председательне генә бер яклы биргәннәр. Һаман председательләр яңаны тоя белмиләр. Кинорежиссерлар конфликт таба алмый. Безгә килсеннәр иде алар. Рамай абыйны алдынгы хуҗалыкны тагын да алга таба үстерү өчен янып-көеп йөрүен күрсеннәр иде.

Кинодан кайтышлый, беләгенә ике куллап асылынган Нәсимәгә янтаерак төшеп, ул шундый уйларга бирелде. Кулына «Казан утлары» журналын алгач та, башында кайнаган шул уйларыннан арына алмый гаҗизләнде. Рамай аны үзенә җәлеп итә алмадымы, артык арыган идеме — керфекләре бер-берсе белән очрашты да күз кабаклары йомылды. Ул диванда яткан килеш йокыга киткәнен сизмәде. Кемнеңдер әкрен генә чәчләренгән сыйпавыннан уянып китте. Урындык куеп, баш очына Нәсимә утырган. Ул үтә күренмәле кыйммәтле ефәк эчке күлмәктән. Тулып торган шәрә беләкләренә, кулбашларына әллә лампочка, әллә эчке күлмәге алсулыгы төшкән. Аның бөтен гәүдәсе ниндидер нур чәчеп торгандай.

— Һәнүз, әйдә, чишен, урынга ят,— дип пышылдады Нәсимә.

Һәнүз күзләрен йомды һәм:

— Хәзер, ята тор,— диде. Әмма ул шул килеш йокыга китте. Иртән таң белән уянды. Торып басуына, Нәсимә дә күбек кебек мендәре өстеннән башын калкытты. Аның күз кабаклары кызарган, шешенгән иде.

* * *

Март ахырларында кинәт җылытып җибәрде. Ике-өч көн дигәндә Атлан тау сыртлары ачылды. Аның итәгеннән башлап авылга кадәр уҗым чәчелгән иде. Кайбер урыннарда, алаланып, уҗым җирләре дә борын төртте. Тау сыртына якын, сөрү полосасы беткән урыннарда күренде алар. Урам, тыкрыкларда да гөрләвекләр юл ала башлады. Инеш буендагы карт өянке башларында каргалар туй ясый: әнә аларның кайберләренең томшыкларында чыбык, салам, чүбек кебек нәрсәләр дә күренә, оя ясарга хәзерләнәләр.

Минзәлә елгасында су кинәт ташыган елларны үзәндәрәк утырган дуңгыз фермасын су баса. Шул хәвефне искәртү, булдырмау чарасын күрү өчен Рамай иртүк шунда китте, идарәгә дә кереп тормады. Ферма тирәсендә йөргән Һәнүзне күргәч, ул елмаеп куйды. «Нишләп йөри бу таң тишегеннән? Әллә махмыр куып йөриме тагын?» Юк, Һәнүз анадан яңа туган сабый төсле саф иде.

— Исәнме, Һәнүз, ни югалттың? — диде аңа Рамай, кулын сузып.

— Исәнмесез, Рамай абый... Югалтмадым. Өч көнләп бар инде бу фермада булмаганга, башка бригада фермаларына чыгып киткәнче монда сугылыйм дигән идем. Аннары, икенче чиратта балалыйсы ана дуңгызларның да вакытлары җитеп килә бит, балалары белән җәйләүгә чыга торганнарын әйтәм. Аларның рационын үзгәртәсе бар.

— Җәйләү дигәннән, аны да су баса бит, аның тирәсеннән дә суга юллар ерасы булыр әле.

Һәнүз беравык сүзнең ни турыда барганын абайламый торды. Аннары, килеп җитте бугай, маңгаен чәпелдәтеп:

— Хак әйтәсең, Рамай абый, ферма тирәләрен дә казып чыгарга кирәк,— диде.

— Хәзер бульдозер төшерәбез,— диде Рамай. Алар икесе дә ферма тирәсен әйләнеп чыктылар. Аннан эчкә үттеләр. Һәр ана дуңгыз үз клеткасында ишелеп ята. Авыр мышныйлар. Нәселле яңа дуңгызлар. Барысы да кыска тәпиле, озын торыклы. Үсешне кай айларны көнгә

артистка булыр дип өметләнгән кыз, иде. Ферма эче чиста, жылы. Рамай үзләре артыннан әкрен генә атлап килүче кызга борылып:

— Вентилятор эшлиме соң инде? — дип сорады. Кыз башын түбән иде һәм:

— Эшли, абый, шул син әйткән көнне үк төзәттеләр аны,— диде.

— Молодец, тырыш. Менә бу дуңгызларның баласын алып үстерсәң, акчага күмәм мин сине. Бирнәгә «Волга» алып бирерсең.

— «Волга»ларым булса, кияүгә дә чыкмыйм мин,— диде кыз, сүзгә күршегә кереп тормады тагын.

— Дөрес, шаяртып кына әйтәм. Егет булса, үзе алсын ул «Волга»ны.

— Әнә тракторчы Ризван алды бит тәки. Сыерына чаклы сатты, тәки алды. Сыер алырга кредит алды тагын.

Сүзгә Һәнүз дә кушылды:

— «Фиат»лар кайткан икән. Әхмәтзыя белән Әнвәр дә дагалаганнар. Алырга барырга сездән рөхсәт сорарга йөриләр.

— Тәк, ничәү була инде бездә хәзер җиңел машина? — Рамай. коридор уртасында туктап, бармакларын бөгә-бөгә саный башлады: — Ризванда — «Волга», Лотфуллада — «Запорожец»... — Әхмәтзыя белән Әнвәрне дә кертеп уникене санады ул.— Кая таба бара дөньялар! Элек минем җиңел машина больница юлыннан кайтып керми иде. Әле йөкле хатын илтә, әле берәр сабыйны, әле карт-корыны. Хәзер менә ике еллап бар инде, сораучы юк.— Рамай тиз-тиз алга атлап китте һәм Һәнүзгә карап болай диде: — Машиналар — уникe, ә мотоцикллар күпме? Аңысының чутын югалттым инде. Ә син беләсеңме, аларның күбесе парктагы колхоз бензины белән заправить ителәә бит. Быел автомашиналарның бензинга расход ясауларының сере шунда. Алар өчен аерым цистерна куймый булмый. Талонын сатып алырлар. Айлык заданиеләр житкергәндә искә төшер әле, онытсам. Моны хәзер үк эшләргә кирәк. Кар беттеме, чаба башлыйлар алар. Аннары, механикка әйтеп куярга кирәк, алар өчен кирәкле запчастьларга заявка җыйсын. Машина җене кагылган кешене беләм мин. Бер җире килеп чыкса, кирәкле әйберсен тапмый күзенә йокы керми аның. Аннары, шуны эзләп, ул теләсә кая чыгып чаба. Ә монда эше тора. Бер очтан механик аларга да запчастьлар юнәлтсен. Бушка алмый бит алар аны, тегеләй дә, болай да...

Фермадан чыккач, азык эшкәртү цехына кереп, барлык агрегатларны эшләтүче комбайнчы Лотфулланы алып чыктылар. Рамай аңа, бульдозер төшкәч, кайсы җирләрне кардан чистартырга, кар суларына юллар ясарга кирәклекне күрсәтте.

Рамай белән Һәнүз колхоз идарәсенә бергә кайттылар. Идарә болдыры янында гына «ГАЗ-69» машинасы тора. «Кем килде икән?» — дип уйлады Рамай. Килеп җиткәч, номерына күз төшерде, район авыл хуҗалыгы идарәсе машинасы иде бу. Идарәнең баш агрономы белән бер очучы килгән икән. Алар бухгалтерлар бүлмәсендә колхозның басу картасын карыйлар иде.

Рамай эшнең нидә икәнен шундук сизенде, йөзен чытып куйды. Алай да сиздермәде, баш агроном белән дә, очучы белән дә кул биреп күреште һәм, иртәнге якта бухгалтерияне кеше басучан булганга, аларны үз бүлмәсенә чакырды. Баш агроном, картаны кулына тоткан килеш, аның артыннан иярде. Рамай өстәл янына килеп утырды. Бу якларда әллә ничә ел ужым тукландыруда,— гербицидларны сиптерүдә эшләгән озын буйлы, кара-кучкыл битле бу очучыны Рамай күптән белә. Татар егете. Казанның үзеннән. Тик менә кем дип дәшергә генә читенсенә, фамилиясе хәтердән чыккан. Очучы Рамай алдына договор кәгазьләре куйды.

— Ничә гектарга, нәрсәләр тукландырабыз? — диде ул һәм фураж-

касын салып, кояш нурлары төшкән тәрәзә каршысына барып утырды. Баш агроном картадан һаман нәрсәдер ачыклый иде.

Рамай договор кәгазьләрен өстәлдән алып, әйләндереп-әйләндереп карады да кире үз урынына куйды, яңагына таянды һәм очучының күзләренә туп-туры карап:

— Без бит барыбыз да бер ата балалары — илгә хезмәт итәбез. Дөресен генә әйт әле, бу эшкә тотынырга иртәрәк түгелме? — дип сорады.

— Управление заявка биргәч, без килдек инде. Төньяк районнарда кар бетте. Анда эшләдек. Ә сездә кар яңа кыймшанып килә,— диде ул, туры җаваптан качарга теләп. Баш агроном да картага иелгән башын күтәрде.

— Иптәш Урмакаевка мин дә кимендә берәр атна көтик дигән идем. Ул инде авиация чакыртып телеграмма биргән булып чыкты,— диде ул һәм кулындагы папкасын өстәлгә куеп, ишекле-түрле йөри башлады. Сизелә, баш агроном да икеләнә.

— Менә нәрсә, егетләр,— диде Рамай, яңагына таянган килеш.— Сез начальствога теләсә ничек әйтегез, мин бу эшкә бара алмыйм. Иртә. Өчләтә җинаять эшли алмыйм.

— Ничек өчләтә? — Агроном шулай дип сорады.

— Ашлама бушка килмәгән, бу — берме? — диде Рамай, бармагын бөгә-бөгә.— Аны бу тәтәй егетләр бушка чәчми, әнә, сәгате 80 сум дип туш белән язып куйган, булдымы — ике! Өченчедән, хәзер чәчкән ашлама кар суы белән агып бетә, акмаганы уйсу урынга җыелып, уҗымны кара яндыра, инде бурага керәм дип торган уңышны югалта. Бусы өч була аның, иптәш баш агроном...

— Сезнең тау сыртлары ачыла башлаган дип Урмакаев җибәрде безне,— диде очучы.— «Беренче Май»дан башларсыз дигән иде.

Рамай урыныннан торды, икесен дә тәрәзәгә чакырды.

— Әнә, карагыз: шул инде ул, кояш бер көлү белән ачыла торган түбәтәй чаклы җир. Район үзәгеннән үк күренеп тора. Урмакаевның кабинет тәрәзәсеннән дә ап-аермачык күренә...— Рамай эчтән генә сүгенеп куйды.— Колхоз бай дигәч тә... Алай булмый ул. Ай-яй, авыр бер сумны ике итүләр. Үзе иген иккән кеше генә ипинең тәмен белә, ди торган иде эти мәрхүм. Ипинең чын тәмен белгән кешеләр эшләп тапканны кар суы белән агызырга хакым юк минем. Игенче буларак бер, коммунист буларак мең дә бер тапкыр хакым юк.

— Соң, без нишлик, самолетлар тик торалмый бит, аларга түләргә кирәк. Ә район Советы башкарма комитетының да, безнең, управлениенең дә анлык рәте юк,— дип мыгырданды баш агроном.

— Безнең әти, мәрхүм, кергәнче чыгар җиреңне кара, ди торган иде.

— Мин нишли алам инде, Рамай Ибраһимович?

— Менә шул шул! Шушы нәрсә үтерә дә безне. Алны-артны уйлап бетермибез. Миннән өстәге абзый нәрсә әйтсә, йомышчы малай кебек чыгып йөгерәбез. Имеш, белми әйтмидер. Ә аның һәр сүзен йөрәк аша үткәреп, үз акылыбызга салып үлчәмибез. Җаваплылыкны үз өстебезгә алырга куркабыз, теге абый җавап бирер әле дип, нигә тотынсак та, аның фатихасын алырга ашыгабыз. Үзебезнең уй, карашларыбызны шул югарыдагы абзыкайга җайлаштырып бетерәбез. Алай эшләве жинел шул. Начальство белән дә, кимчелекләр белән дә тыныч янәшә яшәп була болай...— Рамай Атлан тавына таба төртеп күрсәтте.— Син бит аның авыл көтүе йөри торган 35 гектарлы тау сырты икәнен яхшы беләсең. Син бит районда беренче ел түгел. Белә торып, ник риза булдың вакытыннан элек самолет чакыртырга? Аннары, безгә килергә? Ник иптәш Урмакаевка шуны әйтмәдең? Фәлән гектар уҗым тукландырылды дип сводка бирү өчен эшләмибез бит без.

— Рамай Ибраһимович, сез бигрәк тагын, малаегызны керендергәндәй сугә башладыгыз әле.

Очучы көлеп җибәрде.

— Сыя ул сезгә, мин шәһәр кешесе булсам да, метр калынлыгындагы кар өстенә ашлама сипмәс идем,— диде ул. Баш агроном аның бу репликасын яратып бетермәде.

— Сезгә нәрсә, эшләсәгез дә, простой торсагыз да акча килә,— диде.

— Алай димәгез. Файдалы эш башкару белән иләктәген чиләккә түнтәреп йөрү арасында бик зур аерма бар. Председатель монда бик матур сүз әйтте әле, без кергәч тә. Без бит бер ата балалары, диде. Синең кебек үк, мин дә шул бер ата баласы, туган.

Рамай тәрәзә яныннан китте. Өстәл янына үз урынына кереп утырды.

— Рәшат Галиевич беләме соң бу пожарныйлар алган йөкләмә кебек нәрсәне? — дип сорады ул баш агрономнан.

— Белергә тиеш. Аннан сорамыйча Урмакаев бер нәрсә дә эшләми. Оператив сводканы да ана күрсәтмичә Казанга бирдерми әле ул.

— Менә шул инде, ничә әйтсәң дә бая мин әйткән нәрсәгә килеп төртеләсең. Барысын да олы абзый уйласын. Әллә син аның башын акыл сандыгы дип беләсенме? Кая житешсен ул барысына да? Ул бит мондый нәрсәләрне бюрода сорамый, бюродан башка эш арасында хәл итәсе нәрсәләр күпме? Барысын да беренче секретарь хәл итсенме? Барысына да дөрес җавапны ул ничек биреп бетерсен?! Менә шуны уйлап бетерми безнең әйбәт кенә дип йөргән җитәкчеләр. Шул җөмләдән сез дә, иптәш баш агроном. Ә районда кимчелек өчен җавап бирә башлаганда кем кала? Беренче секретарь. Чөнки башкаларда гаеп юк, алар һәр эшне шул олы абзый хәер-фатихасы белән эшләгәннәр. Андыйларны да күрдем мин. Беркатлы мәхлүккә әйләнеп, бөтенесен беренче секретарь өстенә аудара алар һәм шундыйларның күбесе судан коры да чыга. Рәшат Галиевичне жәллим мин. Сезнең кебекләр өчен җавап бирәсе бар әле аның. Аның ялгышын үзенә әйтәсе, үз ялгышын үзеннән кичекмәстән төзәттерергә ярдәм итәсе урында, сез, районның баш белгечләре, аның ялгышларын күрмәмешкә салышасыз, алай гына түгел, ана үзегез дә җайлашасыз...

— Гел безне диаматтан укыткан профессор кебек сөйлисез сез, Рамай Ибраһимович,— дип, аның сүзен бүлдерде баш агроном.

Рамайның йөзенә елмаю чыкты.

— «Ди» ике дигән сүз бугай әле ул, дилогия, трилогияләр укыган бар минем дә. Мина ирек куйсалар, мин сезнең кебекләрне, үз урыныңда утыра да, утырган урыны өчен җавап та бирә белмәгәннәрне дио — ике мат белән янадан ике кат анадан тудырыр идем,— диде ул һәм баядан бирле бармаклары белән әвәләгән папиросын кабызды. Түшәмгә таба төтен алкалары чөеп җибәрде дә: — Менә шул, туганнар, сораучылар булса, газеталарда язганча, сөйләшүләр чын күңелдән, иптәшләрчә, дуслык шартларында барды, диярсез. Ләкин хәзергә договорыгызга кул куя алмыйм, колхоз өстеннән самолет та очыра алмыйм. Кабат иске авыздан яңа сүз көтмәгез, бигайбә,— диде. Очучы дустанә генә кул бирде. Баш агроном өстәлдә яткан папкасын алып, аны бер кулыннан икенче кулына күчерде.

— Рамай Ибраһимович, үпкәләмәгез, служба. Сөйләшүләрне райкомга җиткерми булмас,— диде, эшләпәсен кырын күтәрә төшеп.

— Аңлыйм, аңлыйм. Тик үзеннән арттырып сүз өстәмә. Сезнең кайбер братлар анысына да оста,— диде.

Баш агроном белән очучы чыгып киттеләр. Рамай, яңагына таянган килеш, уйга талды.

* *

Рәшат Галиевич райком ишеген ачып кергәндә әле таң да беленми иде. Сания тагын өйдә кунмады. Кичтән белешкән иде, редакторларда булып чыкты. Редактор хатыны сүзгә бик оста хатын, әле пышылдап, әле юмакайланып тезеп китте:

— Рәшат Галиевич, Сонечканың кәефләре шәптән түгел әле, мәктәптән бергә кайттык та чәй генә җылытып эчтек. Әллә ни туңам дип бөркәнеп ятты. Врач чакыртыйммы дигән идем, кирәкми, диде. Уятырга да кушмады. Сабыйлар кебек эреп йокыга китте әле. Иртәнгә аякка басмасмы?.. Борчылмагыз, Рәшат Галиевич. Торуына менә кара карлыган вареньелары әзерләп куйдым...

Тагын әллә ниләр такылдый башлаган иде, Рәшат Галиевич кискен генә аны бүлдерде:

— Уянгач та кайтсын!..

— Ярар, ярар, әйтермен, Рәшат Галиевич...

Рәшат Галиевич телефон трубкасын шап итеп куйды... Алан чаклы квартирында берүзе кунды. Уянгач, бик озак күзенә йокы кермәде. Тып-тын. Стенадагы сәгатьнең генә келт-келт йөреп торганы ишетелә... Ичмаса, өй чикерткәсе дә сайрамый, ул да бер иптәш булыр иде», — дип уйлады Рәшат Галиевич, янында җан иясе булмаудан гаҗизләнеп. Күз алдына авылдагы үз өйләре, аның зур миче, ут сүндерү белән гөлбәчтә чикерткә сайрый башлавы килде. Әнә ул беравык тынып тора да тагын ярсый-ярсый сайрарга керешә. Рәшат этисеннән калган зур толып астында шым гына ята. Аның этисе ачлык елны дөнья куйды. Гражданнар сугышында яраланганнан соң мантый алмады, шунын өстенә ачлык килде. Коры сөяккә калып үлде этисе. Зур гәүдәле, эре сөякле иде ул. Рәшат аны яхшы хәтерли. Язын, баскыч төбенә чыгып, бик озак кояшта кызынып утыра иде. Рәшатны чакырып алып, башыннан сыйпый һәм:

— Акыллы булып үс, улым, әниеңне тыңла, икебез дә аның сыртында яшибез бит. Сырхавым да озакка сузылды. Җәйгә терһәкләнеп булырмы? — дия торган иде. Әмма терһәкләнә алмады шул. Яңгыр сибәләп торган көннәрнең берсендә салкын кабер үз куенына алды аны. Кабер казырга кеше таба алмый интектеләр. Зиратка күрше-күлән генә озатты. Рәшат ул җәйне көн саен диярлек этисе каберенә барды. Кабер өстенә моңаеп карап тора-тора да, хәлсез аякларын көчкә сөйрәп, өйалдындагы агач караватка кайтып егыла иде. Яшьлек елмаймады ана. Әмма әнисе тырышты, карыны белән кар ертып, борыны белән боз тишеп булса да Рәшатны кеше итәргә тырышты, укытты. Сугыш башланганда ул педагогия училищесында укыта иде. Аны беренче көннәрдә үк сугышка алдылар. Ике тапкыр яраланды, әмма башы исән кайтты. Кеше рәтендә орденын да, медальләрен дә алды. Сугыштан соң, педагог буларак, аны тиз демобилизацияләделәр. Ләкин укытырга насыйп булмады. Авылда кадрлар аз иде. Аны райкомга оештыру бүлеге мөдире итеп алдылар. Партиягә сугышка хәтле үк кергән иде. Аннары республика партия мәктәбендә укыды. Аны тәмамлагач, партия-совет эшендә. Байтак районнарда булырга туры килде аңа. Бер нәрсәгә генә үкенә ул: эш белән күмелеп, югары белем ала алмый калды. Ә хәзер үзен нык сиздерә бу. Дөрес, мөмкинлек булганда, ул үзлегеннән укый. Ләкин бер системасыз, максатсыз укуның файдасы да шунын чаклы гына.

Икенче катка, үз кабинетына менгәндә аның башыннан әнә шундый уйлар үтте. Райком коридорында аяк тавышлары ишетелә башлаганчы ул барлык колхозлар белән сөйләшеп чыкты. Яз якынлашу үзен сиздерә, председательләрнең күбесе үз урынында. Башта ул механиза-

торларының куст киңәшмәсенә килергә тиешле председательләр белән сөйләште. Аларга агымдагы эшләр буенча киңәшләр бирде һәм барлык механизаторларны оешкан төстә килүен тәэмин итәргә кушты. Аннары оператив сводканы анализларга кереште. Сөт һаман кими иде. Азык ягы үтә такырайды. Силоста гына утыручы колхозлар да бар. Аларга фураж белән ярдәм итәргә кирәк. Ул календарь битенә: «9 сәгать. Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән сөйләшергә!» дип язып куйды. Фуражы булган колхозлар салам юклыктан тилмерә. «Быелдан соң саламны басу кырыена эттереп чыгарырга кирәк, житешкән кадәре эскертләнсә эскертләнер. Калганын яз яндырырбыз»,— дип уйлады. Ә сөт белән нишләргә соң? Ул сөт-май комбинаты директорына шалтыратты. Үткән биш көнлектә сөтнең майлылыгы белән кызыксынды. Анысы әйбәт булып чыкты — 3,9 процент икән. Директорга моннан соң барлык сөтнең майлылыгын базис белән — 3,7 процент белән хисапларга, кабул ителгән сөтнең күләмен майлылык исәбенә арттырырга кушты. Директор дәшми торды. Ник дәшмисең? дигәч, Рәшат Галиевич, урыннарны алыштырып кую белән ике санның суммасы үзгәрми бит, безгә барыбер, тик аңламыйм, диде. Максатын яшермәде Рәшат Галиевич. «Һәр сыердан савым ник кимеде. Ә 0,2 процент аны байтак күтәрә але»,— диде. Директор каршы килмәде, аңладым, аңладым, диде.

Рәшат Галиевич чиста кәгазь бите алып сөтне базис майлылыгына китергәндә район буенча һәр сыердан сөт савып алуның күпмегә артуын хисаплый башлады. Болай ярыйсы чыга икән. Шулай эшләгәндә, бу бишкөнлектә, өчәр килограммга «сикереш» биреп була.

Әнә шундый шөгыль белән утырганда, кабинет ишеге ачылды һәм анда Урмакаевның башы күренде. Теге каты бәрелүдән соң ул үзен сак тота, һәр сүзен алдан уйлап, үлчәп әйтергә тырыша. Ләкин бөкрене кабер генә төзәтә дигәннәре хактыр инде, бу кешегә симпатиясе бетте Рәшат Галиевичның.

Урмакаев йомшак кына басып өстәл янына килде. Рәшат Галиевичның кул сузуын көтеп торды, ягъгыратып бирелгән сәламенә секретарь башын гына игәч, секретарь өстәле янына куелган тәбәнәк өстәл янына утырды да, үзенә төбәлгән күзләргә карап, нәзакәтле генә сүз башлады:

— Рәшат Галиевич, уҗымнар тукландырыр вакыт житте бит.

— Әйе, бу эшкә сезгә жигелергә туры килер.

— Мин инде самолетлар да чакырткан идем.

— Эш нидә тералеп тора?

— Кайбер колхозлар, әле иртә дип, эш башлауга каршы килә ләр.

Рәшат Галиевич керфекләрен төшерде, нечкә бармакларын ялтырап торган өстәл өстендә биетеп алды:

— Ә син үзең ничек уйлыйсың? Чыннан да иртәрәк түгелме?

— Калкулыклары ачыла башлаган җирләрдә иркенләп эшләргә була хәзер. Әнә, «Беренче Май» басулары моннан ук күренеп тора, райоиннан ук, ачылып беткән. Ә Вильданов кичә летчик белән баш агрономны договорга кул куймыйча борып кайтарган. Иртә, ди, имеш. Кая иртә булсын инде?

— Вильдановның үзе белән сөйләштеңме?

— Юк.

— «Беренче Май»да үзең булдыңмы?

— Баш агроном булгач?..

— Үзегез булдыгызмы? — дип сорыйм мин сездән.

— Юк, Рәшат Галиевич...

— Үзегез булыгыз, үз күзегез белән күрегез. Рамай Ибраһимович белән сөйләшегез. Аның доводларын тыңлагыз. Аннан хәлне бюрода

сөйләрсез. Кич бюро була бүген, аңлашылдымы? — диде секретарь, катгый итеп.

— Аңлашылды, Рәшат Галиевич. Тик самолетлар белән нишлибез? Простой өчен дә акча суыралар бит алар. Каян алып түлибез? Райбашкарманың, безнең дә анлык рәт югын сез үзегез дә әйбәт беләсез. Эшләмәгән өчен колхозлардан да алып булмый. Менә шул борчый мине, Рәшат Галиевич,— ул кулын авызына куеп, тамак кырды.— Әллә, мин әйтәм, самолетларны эшләтә тору хәерле булмасмы? Иртә түгел лә. Очып кая китә ул ашлама? Барыбер басудан-басуга күчә, җир куенына керә, ничек тә файдасы тими калмас әле. Аннары, быел тукландыру планы да зур. Барлык уҗым культураларына, бәрәңге, кукуруз, шикәр чөгендере җирләренә дә ашлама кертәсе бар. Хәзердән тотынмасаң, кая житешәсең аңа. Монысын да уйламый булмый аның, Рәшат Галиевич...

Секретарь Урмакаевның теле ачылуга гаҗәпсенеп карап торды. «Кыюланып киткән әле бу, тикмәгә түгелдер»,— дип уйлады. Урмакаевның дәлилләрендә, әлбәттә, дөреслек тә бар. Ләкин төп максаты ул түгел иде аның. Рәшат Галиевич аны тиз тотып алды һәм:

— Бу вакыттан кем чакыртты ул самолетларны? — дип сорады.

— Управление инде, без...

— Кем белән киңәштегез?

— Казаннан, Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан шалтыраттылар. Самолетлар тик тора. Төньяк районнарда эшләп кайтканнар да алар.

— Кем белән киңәштегез дип сорыйм мин сездән? — Рәшат Галиевич тавышын көчәйтә төште.

— Сез колхозларда идегез... Бик басым ясагач, риза булдым инде.

— Риза булсагыз, үзегез чакырткан, үзегез теләсә ничек котылыгыз... Тик яткан самолетлар өчен колхоз сыртын каезларгамы исәп?.. Рамай Ибраһимович дурак түгел ул. Ашламаны иң күп кем кайтартты? «Беренче Май» колхозы. Ипигә ягып ашамыйлар ул ашламаны. Вакыты җиткән булса, Рамай Ибраһимович самолет сорап әллә кайчан үзе шалтыратып, кирәк булса, сезнең агрономнарның бугазыннан буып алыр иде әле. Аңлый башладым мин Вильдановны. Сезнең белән минга аннан күп нәрсәгә өйрәнергә кирәк әле. Әйе, әйе, өйрәнергә кирәк. Борынынны югары чөймичә!..

Урмакаев Шәймиевтән моны көтмәгән иде. Ул утырган урынында кыбырсый башлады.

— Амбарда яткан ашламадан ни файда? — диде ул, әтисе алдында гөнаһ кылган сабый кебек.

— Вильданов яткырмас!.. Менә шул. «Беренче Май»га бар, барысын да җентекләп тикшер.— Рәшат Галиевич урыныннан торды, ишеккә таба атлаган Урмакаевны туктатып: — Рамай Ибраһимовичка әйт. Бюрога ул да килсен,— дип өстәде. Урмакаев чыгып китүгә телефон шалтырады. Обкомның авыл хуҗалыгы бүлегендә инструктор булып эшләүче иде. Аның беренче сүзләреннән үк Рәшат Галиевич коелып төште. Рәтләп сөйләшә, сораштыра да алмады. Хәвефле хәбәр ирештерде ул аңа. «Сезнең өстән ЦКга жалоба бар. Хатның эчтәлеген белә алмадым.» ЦК вәкиле белән обкомнан комиссия килтәчәк. Чамала, итәкләреңне җый»,— диде.

Гөнаһ кылган кеше үз гөнаһысын үзе күбрәк белә. Рәшат Галиевич уйлап житкермичә җибәргән ялгышлыкларын искә төшерә һәм аларны ике төркемгә аера башлады. Беренчесе — эш буенча, икенчесе — мораль як. Кайсы күбрәк, кайсы баса төшәр? Райстат мөдире ни дияр? Аның белән, әлбәттә, сөйләшү булачак. Әллә комиссия килгәнче барысын да туздырыргамы? Райстат мөдирен Урмакаев кысты бит. Отчетларны ул төзәттерде. Безнең ике арадагы сөйләшүне башка бюро членнары белми. Кулы белән эшләгән, иңе белән күтәрсен.

Рәшат Галиевич Казанга заказ бирде. Тиз ялгадылар. Обкомның авыл хуҗалыгы бүлеге мөдиренә үзенен Урмакаевка булган карашын сөйләде. Сүз арасында аның гөнаһларын санады һәм КПСС райкомы бюросының мондый хәл белән түзеп тормаячагын, Урмакаевка үзенең кискен сүзен әйтәчәген белдерде. Һәр нәрсәне тәптән уйлап хәл итә торган, элек үзе дә күп еллар районнарда беренче секретарь булып эшләгән мөдир аны сабыр гына тыңлады, бүлдермәде. Рәшат Галиевичның дулкынлануын сизде, ахры, башта ук сүзен болай дип башлады: «Сез нигәдер бик кайнарланганс ыз, әллә бүгенгә калдырасызмы? Сүреләрәк төшкәч, сабыр акыл белән тикшерү хәерле булмасмы?» — диде ул. Рәшат Галиевич инде бу хәлгә күп түзүен, хәзер чигенергә урын калмавын кат-кат әйткәч, бүлек мөдире болай диде: «Тикшерегез, партия җәзасы бирегез, ләкин вазифасына кагылмагыз, ул сезнең вазифага керми. Обком номенклатурасындагы кешеләр белән обком үзе шөгыльләнер»,— диде. Рәшат Галиевич анысына да риза булды. Ни әйтсәң дә, үз өстенә ябырылып килгән давылны читкә бору өчен кирәк, бик кирәк иде Шәймиевкә бу. Телефон трубкасын кую белән ул өстәл кырындагы звонокка басты. Тавышсыз гына ишек ачылды.

— Сәгать кичке алтыга райстат мөдирен бюрога чакырыгыз,— диде ул секретарь кызга. Секретарь, ярар дип, ишекне япты.

Рәшат Галиевич сәгатенә карады. Унынчы ярты булып килә. Ә механизаторларның куст киңәшмәсе унда башлана. Ул тиз генә киенде дә оештыру бүлеге мөдире Шәяхметов янына кереп: «Сорасалар, куст киңәшмәсенә китте диярсез. Ашыгыч хәл итәсе әйбер булса, эзләп табарсыз»,— диде. Зиннурга кичтән әйтеп куелган иде. Ул Рәшат Галиевичның чыгуын көтеп тора иде инде.

Куст киңәшмәсе болай җанлы гына үтте. Ләкин Рәшат Галиевичның теле бер нәрсә сөйләде, ә күңеле һаман да жалоба тирәсендә чуалды. Паркта дүртәр чәчкеч белән агрегатланган тракторларны карагач, звеноларга житкерелгән заданиеләр, маршрутлар белән танышкач, киңәшмәне йомгаклау өчен клубка җыелдылар. Рәшат Галиевичның йомгаклавы сыек чыкты, үзе дә сизде. Ләкин алда гына утырган бер механизаторның күз карашы аның бөтен зиһенен таратты. Йотылып тыңлый иде ул. Беренче күз төшерү белән ул аны «Беренче Май» зоотехнигы Гумеровка охшатты. Кем әйтмешли, суйган да каплаган инде менә. Үзе сөйләде, үзе аңа карый-карый, Гумеров белән ике арада булган тарткалашларны искә төшерде. «Юк, ул кырык жиде баш белән алдыра алмыйсың син мине, туган»,— дип уйлады. Жалобаны башка кеше түгел, ул язган булырга тиеш. Киңәшмәне япканда ул моны күңеленә беркетеп куйды һәм аңа ихлас күңелдән ышана иде инде. «Беренче Май» колхозына шалтыратты. Баш бухгалтер туры килде.

— Рамай Ибраһимовичка әйтегез. Кичкә бюрога зоотехнигыгызны да алып килсен,— диде.

Бюрога чаклы күңел дулкынлануларын басарга, тынычланырга кирәк иде. Юлга чыгу белән ул төрле анекдотлар сөйли башлады. Зиннур да кесәгә керә торганнардан түгел, берничә анекдот сөйләде дә:

— Рәшат Галиевич, ачуланмасагыз, чын анекдот, үзебезнең район анекдотын сөйлимме? — диде.

— Әйдә, тыңлап карыйк.

— Булгандырмы, юктырмы, ләкин хак дип сөйләделәр моны. Кыш уртасында Казаннан бер зоотехник килгән монда. Сөт арттырырга йөргән фермаларда. Һәм мондый әмер биргән: сөтле буласыгыз килсә, һәр сыерга ярты килограмм шикәр бирегез дигән, һәм тәки бирдерткән. Авылларда шикәр беткән. Әмма сыерларның сөте артмаган. Шуннан сыер савучылар дәгъва күтәргән: шикәр килешмәде, магазинда сатылмый яткан шоколадны сорап мөгери хәзер сыерлар дип, председательләргә ябырылганнар. Ә председательләр Урмакаевка, Урмакаев тәге

зоотехникка ябышмакчы икән дә тегеннән инде җилләр искән ди.— Зиннур аз гына елмайды, күз кырые белән генә Шәймиевкә карады.— Менә шушыны Казаннан, запчасть алырга барган җирдән ишетеп кайттым. Күзне дә ачырмыйлар. Шоколад тешләрен коймыймы соң сыерларыгызның? — диләр.

— Дөнья тинтәкләре беткәнмени! Сөйлиләр тузга язмаганны!— диде секретарь. Зиннурның бу анекдоты Шәймиевнең болай да янган йөрәгенә тоз салгандай булды. Урмакаевка булган ачуы тагын да күперде һәм ул инде нәфрәткә әверелде. Бу районга билгеләнгәч тә Маклаковның обкомда биргән киңәшен искә төшерде. «Урмакаевны урынында тотма, таянырлык кадр түгел ул»,— дигән иде. «Эшләсен, күз күрер әле. Аннары, нигә мин һаман Маклаков кушканча, ул әйткәнчә генә эшләргә тиеш соң? Үземнең баш юкмыни минем?» дип уйлады, үзенчә эшләде. Чыннан да таянырлык кеше булып чыкмады. «Ну, чамала егет!» — Ул шулай дип тезенә йодрыгы белән сукты. Зиннур аңа ялт итеп карады. Рәшат Галиевичның яңакларына кызыл тимгелләр чыккан иде. «Хәтере калды теге анекдотка, ник сөйләдем»,— дип уйлады Зиннур. Алар райком алдына килеп туктаганчы бер сүз дә сөйләшмәделәр. Шәймиев райкомга кереп тормады, койма буендагы тротуардан өенә таба атлады. Ишек ачык, Сания дә өйдә иде. Ни гаҗәптер, квартирны әйбәтләп җыештырган, кухнядан, борыннарны кытыклап, тәмле ис аңкый. Рәшат Галиевич ишек янындагы кечкенә бүлмәдә чишенде, юынды. Сания диванда китап укып утыра иде.

— Ничек соң хәлең, Сания? Кичә авырып киткәнсең бугай,— диде аңа Рәшат Галиевич.

— Рәхмәт, Рәшат... Хәзер әйбәт,— диде Сания һәм китабын куеп кухняга чыгып китте. Бераздан аның талир тәңкә чыңы төсле саф, матур тавышы яңгырады:

— Рәшат, кухняга чык. Рәтләп ашаганың да юктыр инде синең... Пилмән пешердем.

Рәшат Галиевич бу үзгәрешкә ни дип тә әйтергә белмәде. Сания каршысына утырып тәмләп ашады. Кәефе күтәрелеп китте. Җитмәсә, Сания сөрмәле күзләре белән аңа карап-карап ала. Нидер әйтергә тели, ләкин кыюлыгы җитми иде, күрәсең.

Рәшат Галиевич түзмәде:

— Нәрсә бар, Сания? — дип сорады.

Сания колак яфракларына кадәр кызарды һәм әкрен генә:

— Кызганам, чын күңелемнән җәллим мин сезне, Рәшат абый. Әйбәт тә кеше сез. Минем өчен аеруча. Ләкин нишлим соң?..

Рәшат Галиевич аны бүлдерде:

— Сания! Зинһар, бүген түгел. Әйтмәгез. Нервалар шундый киерелгән көн бүген. Әллә ни әйтеп ташлавым бар. Ничәмә еллар түзгәнне, түз бүген. Мин дә кыл өстендә торам. Һич югында, бюродан соң сөйләшербез. Өйдә кунасыңдыр бит? — диде.

— Өйдә кунам.

— Бик әйбәт! Мин бюроны ничек тә тиз тотарга тырышырмын.

Сания өстәл янында утырып калды, Рәшат Галиевич райкомга кереп китте. Бюро члены җыелган иде инде. Рамай Ибраһимович та, Гумеров та килгәннәр. Кабул итү бүлмәсендә җыелып торучыларның барысы белән дә кул биреп күрешкәч, Рәшат Галиевич аларның һәммәсен дә кабинетка чакырды.

Башта «Таза Чишмә» колхозы партия оешмасы һәм агитколлективының язгы кыр эшләре өчен эш планын карадылар. Берничә төзәтмә кертү белән кабул иттеләр һәм аны район газетасында игълан итәргә дигән тәкъдим керттеләр. Шуннан соң «Таза Чишмә»ләр чыгып китте.

Ишек ябылу белән Рәшат Галиевич торып басты. Кысып тоткан карандашы белән өстәлгә таянды, бер кулы белән көл төсле чәчләрен

артка сыпырып куйды. Иөзенә экрен генә тимгелләр йөгерә башлады. Бюро членнары сагаеп калдылар.

— Иптәшләр, бу мәсьәлә аерым бюро членнары белән киңәшелде,— дип башлады ул сүзен.— Безнең кайбер иптәшләр, бюро членнарыннан, үз постларыннан файдаланып, партия һәм дәүләт алдында күзбуяучылык белән шөгыльләнә, авыл хуҗалыгы белән идарә итүдә башбаштаклыкка юл куя башладылар... Сүз иптәш Урмакаев турында бара. Исегездәдер, кошчылык фермаларын специальләштерүнең инициаторы кем булды? Ул. Кошчылык фермалары төзелмичә, районда ярты колхозда кем кошчылык фермаларын бетертте? Ул, хөрмәтле иптәш Урмакаев...

Урмакаев кулын күтәрә-күтәрә авызын ачкан иде, Шәймиев аны шунда ук шып утыртты.

— Ашыкмагыз! Сезгә сүз бирербез әле. Сөйләр, җавап бирер нәрсәләрегез җитәрлек.— Ул бераз туктап торды, барлык бюро членнарын күздән кичерде.— Ә райстат мөдире белән сөйләшүдән шул ачыкланды,— ул үзе дә бирәдә,— иптәш Урмакаев бездә сыерларның баш санын шул кадәр бутап бетергән, хәзер кайсы колхозда ничә баш сыер барын анык кына ачыклап та булмый. Аның ачык мисалы менә «Беренче Май» колхозында. Рамай Ибраһимович, иптәш Гумеровлар әнә шуны дәлилләү өчен китерелделәр бюрога.

Һәнүзнең бит очлары гына түгел, уч төпләренә кадәр кызыша башлады. Ул, гаҗәпсенүдән, күзен Рәшат Галиевичтан ала алмады. «Менә, аңлаган бит, ә мин бөтен гаепне аның өстенә яктым. Ә ул уңайлы момент житкәнче, чын гаепләне ачканчы түзгән»,— дип уйлады. Рамай Ибраһимович исә тыныч. Блокнотын кулына тоткан да, башын ия төшеп, игътибар белән тыңлый.

Рәшат Галиевич сүзен дәвам иттерде:

— Аннары, күп колхозларның кышка саламсыз калуларында да Урмакаев беренче булып җавап бирергә тиеш. Барлык хуҗалык эшләрен дөрес оештыру аңа йөкләтелгән. Райком бюросы тарафыннан аңа кайчан терлекләрне саламсыз калдырырга дип күрсәтмә бирелгәне бар? Бу да аңлашыла. Тунга сөрүне алдан бетерергә, премия алырга кирәк иде иптәш Урмакаевка. Инде килеп, җавапсызлык һәм күз буяучылыкның чын өлгесе...— Рәшат Галиевич Рамайга таба борылды.— Сез кичә ни өчен уҗым тукландырудан баш тарттыгыз?

Вильданов торып басты, башын күтәрә төште.

— Иртә, Рәшат Галиевич, файдасы юк.

Бюро членнары барысы берьюлы аңа таба борылдылар. Урмакаевның муенына кызыллык йөгерде. Ул галстугын бушатып җибәрде.

— Табигый көтүлекне тукландырырга була бит,— диде ул.

— 35 гектар өчен самолет чакыртып булмый, иптәш Урмакаев. Аны без үзебез дә җиңәбез. Бүген ул җирләр, Атлан тау сырты ашланды инде.

Рәшат Галиевич Вильдановка утырырга ымлады, үзе сүзен дәвам иттерде:

— Басуларда кар ястык калынлыгы килеш, беркем белән киңәшмичә, иптәш Урмакаев самолетлар чакырта һәм мина, беләсеңме, нинди тәкъдим ясый: простой торган өчен каян акча алып түлисең, колхозларда тукландыра торсыннар, файдасы тими калмас әле, дип, колхозчы мангай тире белән тапкан сумнарны кар суы белән агызырга тәкъдим ясый. Бу бит күрә торып корткычлыкка бару!.. Житәкчелектәге мондый хәлгә бюро членнары аек күз белән карарга һәм иптәш Урмакаевның бу җинаятьләренә, әйе, җинаятьләренә партиячел принцип белән килергә тиешләр. Ә хәзер, минемчә, иптәш Урмакаевның үзен тыңларга кирәк!..

Рәшат Галиевич утырды. Киң, шома маңгаен кулъяулыгы белән сөртте. Урмакаев урыныннан кузгалды. Аның иңнәре салынган. Кара костюмының җиңендәге бер төймәсе менә өзеләм, менә өзеләм дип салынып тора.

— Ничектер көтелмәгән һәм көтмәгән удар булды әле бу миңа,— дип сүз башлады Урмакаев, өске калын ирене дерелдәп алды. Алдында яткан кәгазьләрне бер ала, бер куя сөйли башлады: — Рәшат Галиевич сөйләгәннәр, иптәшләр, барысы да дөрес. Ул кимчелекләрдә, әлбәттә, минем гаебем зур. Ләкин шуны да әйтми булмый, аларның барысы да Рәшат Галиевич белән килешенеп, бюро членнарының күбесе белән киңәшеп эшләнде. Самолет чакыртудан башкасы. Анысына башымаягым белән мин гаепле. Министрлыктан бик үтенгәч, эшсез торалар бит, сезнең колхозлар экономик яктан нык дигәч, риза булдым. Ә башкаларны, башка кимчелекләрне мин үз өстемә генә ала да, таный да алмыйм.

Рәшат Галиевич сикереп торды.

— Ә, партия конкрет, персональ җаваплылык сорый башлагач, куак артына посмакчы буласызмы? Барып чыкмас, үтмәс бу номер... Иптәш Гумеров, теге таналарны сыерга кертеп кем рәсмиләштерде?

Һәнүз сискәнеп китте. Тиз генә торып басты.

— Авыл хуҗалыгы идарәсе,— диде ул, бераз каушый төшеп.

— Утырыгыз!.. Ишеттегезме, иптәш Урмакаев? Мин фактлар белән, җанлы кешеләр, шаһитлар белән сөйлим. Райстат мөдирен, һәр отчет биргән саен, тинтерәтүче кем? Сез!

— Соң, иптәш Шәймиев, бу эшне үз кулыгызга алыгыз, дип сез куштыгыз бит моны.

— Ялган! Безнең арада андый сөйләшүнең беркайчан да булганы юк. Һәм булмас та! Ничә ел партия эшендә эшләп, андый демагогия белән шөгыльләнергә әллә сез мине бала-чага дип беләсезме?

Урмакаев беренче секретарьга таба борылды.

— Сезнең тактика турында ишеткәнем бар иде. Рас икән... Әмма, Рәшат Галиевич, безнең обком бюросына да барасы бар әле. Шуны истән чыгармагыз. Анда бөтен гаепне минем өскә аудара алмассыз. Сезгә бик урынлы сорау бирерләр. «Сез нәрсә карадыгыз?» — диярләр.

Бюро членнарының берсе дә Урмакаевтан моны көтмәгән иде. Рамай Ибраһимовичка да Урмакаевның бу җавабы ошады. «Әйе, әйе, Рәшат Галиевич. Сез нәрсә карадыгыз, сез нәрсә карадыгыз? — диде ул үз-үзенә.— Мондый хәлләрне беренче секретарьдан башка ничек хәл итмәк кирәк».

Рәшат Галиевич Урмакаевка дорфа гына дәште:

— Утырыгыз!

Бюро членнары башларын ия төшеп, уйга калдылар.

— Я, кем сүз ала, кемдә нинди тәкъдимнәр бар? — диде Шәймиев. Берәү дә кул күтәрмәде.

Рәшат Галиевич Вильдановка, Һәнүзгә, райстат мөдиренә ягымлы гына итеп:

— Ә сез, иптәшләр, азат, чыгарга мөмкин,— диде. Алар чыгып китү белән Рәшат Галиевич бюро членнарына:

— Нәрсә, әллә иптәш Урмакаевның җинаятьләре берегезгә дә барып җитмәдеме? Ул вакытта мин яңадан исегезгә төшерә алам,— диде.

Калтыранган кулын күтәрә-күтәрә, редактор торып басты. Ул костюм итәген тартып куйды, иреннәрен очлайтып, теш төбен суырып алды.

— Кадерле бюро членнары,— диде дә ул тотлыгып калды.— Мин, мин Рәшат Галиевичның иптәш Урмакаев турындагы бу информациясен тыңлаганнан соң гаҗәпкә калдым. Кесәндә партия билеты йөрткән килеш ничек шушындый юлга басарга мөмкин? Бу ич, Рәшат Галие-

вич әйткәнчә, җинаять. Кеше буларак та иптәш Урмакаев турында халык арасында күңелле сүзләр йөрми, мораль яктан диюем.

— Әле минем ике хатын белән торган юк...

Урмакаев Шәймиев бакчасына әнә шулай дип таш атты һәм ул туры тиде. Рәшат Галиевич аскы иреннәрен тешләштерә башлады, ләкин дәшмәде.

— Минем тәкъдим шул: мәсьәлә — бик җитди. Моны тиешле органнарга җиткерүне секретариатка йөкләргә кирәк.

Редактор сүзен шулай дип тәмамлады.

Халикъ Кәримович сүз алды.

— Мин бу мәсьәләне тиешенчә хәзерләнгән дип тапмыйм. Урмакаев шул хәтле җинаятьләр эшләгән икән, аны җентекләп, авторитетлы комиссия белән тикшерергә, нәтиҗәләрен аннан соң гына бюрога кертергә кирәк,— диде ул.

— Сезгә җиткерергә истән чыккан. Комиссиянең иң авторитетлысы киләчәк, бүген обкомнан шалтыраттылар. Шунлыктан комиссия килгәнче безгә радикаль чаралар күрергә кирәк,— диде Шәймиев.

— Алайса тагын да яхшы. Шул комиссия нәтиҗәләре безнең өчен ышанычлы нигез булачак.

Халикъ Кәримович урынына утырды. Пеләш башын сыпыра-сыпыра Вәрәшов кузгалды.

— Халикъ Кәримовичның фикеренә мин дә кушылам,— диде ул.— Ашыгып, каш ясыйм дип күз чыгаруың бар. Иптәш Урмакаевның кошчылыкны специальләштерү буенча таякны кинәтрәк бөгүенә район Советы башкарма комитеты үз вакытында киртә куймаса, без быел район буенча нинди хәлдә калыр идек? Инкубатор станциясен күчерергә фәрман биргән. Имеш, инкубатор станциясе кошчылык фабрикасында булырга тиеш. Бу да дөрес. Аның үзенә кайтарырга кирәк. Ә районлагы бердәнбер станцияне туктатырга, таратырга кем хокук биргән аңа? Халыкка гына илле мең чеби сатарга тиеш без. Зәйтүнә, Мәймүнә апалар булмаса, йомырка сату буенча квартал планы өзелгән иде бит. Рәхмәт аларга! Колхозлар планны 50 процентка гына үтәп калды. Планның калган өлешен индивидуаль сектор исәбенә үтәдек бит. Ул 50 процентка ничек җыелды? Шул Зәйтүнә, Мәймүнә апалардан җыелган йомырканы колхозлар үзләренеке итеп саттылар. Кызык хәл бит. Район газетасында игълан ителгән сводканы карагыз әле бер. Кошчылык фермасы юк. Ә колхоз йомырка тапшырган...

Рәшат Галиевич Вәрәшовка реплика ташлады.

— Район Советы гына эшли инде... Сез мәсьәләгә якынрак килегез.

— Алай дип әйтмим. Ә мәсьәләгә менә шулайрак якын киләсем килде минем. Шомартулар, күз буяулар бар. Аңа бер Урмакаев кына җавап бирмәс. Барыбызга да, менә бу өстәл янында утыручыларга, бергә җавап бирергә туры килер.

Оештыру бүлеге мөдире Тәлгат Шәяхметов та үз фикерен әйтте.

— Хакыйкатьтән беркая качып булмаган кебек, шеш тә бер тула һәм тишелә. Организмга вируслар үтеп кергәнен сизендек, ләкин вакытында профилактик чаралар күрмәдек. Хәзер бергәләшеп җавап бирергә кирәк.

Рәшат Галиевич бюроның мондый борылыш алуын көтмәгән иде. Ул соңгы рычагларга басарга булды.

— Иптәшләр,— диде ул, үзен ничек тә тыныч тотарга теләп.— Четерекле мәсьәлә тикшерәбез. Урмакаевның кылган ялгышларын партия куйган бүгенге таләпләр күзлегеннән бәяләргә кирәк. КПСС Үзәк Комитетының декабрь Пленумы дәүләт планнарының үтәлешен тәэмин итмәүне дисциплинасызлык, партия алдында җавапчылык хисен югалту дип бәяләде һәм һәр җитәкче работниктан үзенә тапшырылган эш өчен конкрет, шәхси җавап бирүне таләп итә. Урмакаевның эш стилен, аның

җибәргән ялгышларын әнә шул күзлектән бәяләгәндә партиянең иң каты җәзасына тартылырга тиеш ул. Һәм мин аның үз постында калу-калмау мәсьәләсен тиешле органнар алдына куячакмын. Ә комиссия килгәнче безгә иптәш Урмакаевны бу килеш кенә калдырырга ярамый. Минем тәкъдим: күз буяучылык белән шөгыльләнгәне һәм район мас-штабындагы хуҗалык мәсьәләләрен, КПСС райкомы бюросын әйләнеп үтеп, үз башына гына хәл иткәне һәм шуның белән дәүләт планнарының үтәлешен куркыныч астына куйганы өчен район Советы башкарма комитетының авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы иптәш Урмакаевка учет карточкасына язып каты шелтә белдерергә һәм үз постында калу-калмау мәсьәләсен югары органнар алдына куярга. Кем дә кем шушы карарны кабул итәбез, ди — шул бюро члennарының кул күтәрүен сорыйм.

Башлап редактор кул күтәрде. Берәздән идеология секретаренең кулы күтәрелде. Аларга партия контроле комитеты председателе, ферма мөдире булып эшләүче Сорур Шаһиеваның да кушылуын шәйләгәч, Шәймиев тә кул күтәрде һәм калган бюро члennарына дәште:

— Ә сез каршымыни? — диде.

— Мин каршы,— диде Урмакаев.

— Мин бер якка да кушылмыйм,— диде Вәрәшев.

Халикъ Кәримович белән Тәлгат Шәяхметов та бер якка да кул күтәрмәделәр. Рәшат Галиевич үз тәкъдимен үткәрде. Бюро члennары, иңнәренә авыр йөк баскандай, теләр-теләмәс кенә таралыштылар. Башка вакытта бюро үткәргәннән соң Рәшат Галиевич үзендә ниндидер көч сизә, алга куйган максатына ирешүдә ышаныч тоя һәм эшлисе эшләрен ачык күрә иде. Ә бу юлы ул андый хис кичермәде. Киресенчә, кабинет һавасы яшенле яңгыр явар алдыннан булганча авыраеп калган сыман иде. Каяндыр кабарып килгән кара болытлар аның өстенә ишелә кебек тоелды. Йөрәге чәнчешә башлады. Бер кулы белән өстәл тартмасын ачып, тиз генә валидол алып капты. Сулыш алуы җиңеләеп киткәндәй булды. Пульсын санап, йөрәк тибешен тыңлап әле байтак утырды Шәймиев. Маңгаена салкын тир бәреп чыккач, бераз җиңеләеп китте. Әкрен генә киенде, кабинетның утын сүндерде. Квартирына чаклы араны бик авырлык белән генә үтте. Болдырга менеп баскач, звонок төймәсенә сузылган кулын кире төшерде. Йөрәге тагын чәнчешә башлады. Баскыч култасына күкрәге белән ятып тын калды. Тын. Үзәк урамда аяк тавышлары да ишетелми. Район үзәге йоклый. Урамнардагы электр утлары көлтәсе, прожектор кебек, кара кучкылланып торган иксез-чиксез күккә сузылган. Еракта трактор гөрелтесе ишетелеп-ишетелеп китә. Спирт заводыннан барда алып кайтучы булырга тиеш. Аның тавышы якынайганнан-якыная бара. Әнә ул дөбердәп күпергә дә килеп керде. Өске урам буйлап югарыга таба үрмәли. «Электро» яки «Искра» колхозынадыр, дип уйлады Шәймиев. Йөрәкнең чәнчешеп торуы беткәндәй булды. Рәшат Галиевич папирос кабызырга теләде. Ләкин, йөрәгеннән куркып, аны болдырның бер ягында җыелып торган суга ыргытты. Звонок кнопкасына басты. Тавыш-тын ишетелмәгәч, тагын кабатлады. Менә Саниянең тамак кырганы, эчке бүлмә ишеген ачып чыкканы ишетелде. Сания кем дип тә сорамады, ишекне ачып, өйгә йөгереп кереп китте.

Сания аны көткән иде. Ул, гадәтенчә, караватына менеп юрган астына чумды. Чишенмәгән дә. Рәшат Галиевичның кәгазь төсле агарган йөзен күргәч, ул урыныннан торды һәм:

— Ни булды, Рәшат? — дип сорады.

— Йөрәк шаярта, нервалар бер нигә дә ярамый хәзер,— диде ул, костюмын шифоньерга элә-элә. Сания аптечкадан ниндидер дарулар карый башлады. Бармак башы кебек бер флаконнан борчак кадәр генә ниндидер дару алды да аны Рәшат Галиевичка сузды.

— Мә, ин яхшы дару дип биргәннәр иде аптекадан. Шушы флаконы алты сум утыз тиен. Польский. Йөрәк авыруыннан,— диде Сания, тиз генә кухняга чыгып, ярты стакан каты чәй алып керде. Рәшат Галиевич Сания биргән даруны эчеп җибәрде. Чыннан да, тәэсире тиз тиде. Җиңелчә генә башы әйләнгәндәй булды, аннары баш сафланды, йөрәк тибеше дә әнә ничек нормальләшеп бара. Рәшат Галиевич стенадагы сәгатькә карады. Илле яшь тулган көнне бүләк иткәннәр иде аңа. Беренче унбиш минут. «Озак утырылган икән»,— дип уйлады һәм йокларга җыена башлады. Ләкин шул чак Сания аның янына диванга килеп утырды.

— Бераз тынычландыңмы инде, Рәшат? — дип сорады ул, аның күзләренә карап.

— Ярыйсы хәзер. Рәхмәт даруың өчен.

— Сөйләшергә кирәк безгә бүген, Рәшат...

Рәшат Галиевичның пыяла төсле күзләре зур булып ачылды.

— Ни турында, Сонечка? Соң бит инде... Йоклыйк.

— Юк, Рәшат. Бүген, бүгеннән калдырырга ярамый.

— Ни булды соң, Сонечка?

— Син мине гафу ит, Рәшат... Син миңа яхшылыктан башка бернәрсә дә эшләмәдең. Ә мин, мин...

Саниянең күзләрен яшь пәрдәсе каплады, ул башын Рәшат Галиевичның иңнәренә куйды. Бу якынлыктан, исерткеч якынлыктан Рәшат Галиевичның миенә кайнар кан йөгергәндәй булды. Ул Саниянең таза, йомры ак муеныннан, чәчләреннән сыпырды.

— Ни булды, Сонечка?

— Мин, мин сезне ничек тә яратырмын, үземне кайчан булса да күндерермен дип уйладым. Инде менә ничәмә ничә еллар үтте, уналты ел!.. Булмады... Гафу ит мине! Мин сиңа бәхет тә, семья шатлыгы да китермәдем... Китерә алыр кебек тә тоймыйм... Китәм мин иртәгә, Рәшат... Бөтенләйгә. Мин дә утыз биш яшькә җитеп киләм бит. Ике-өч елдан инде соң булачак. Мин дә үз бәхетемне табыйм. Икебезнең беребез бәхетле булыйк, ичмаса...

Ул башын күтәрде, кулындагы яулык чите белән күз яшьләрен сөртте. Рәшат бер мәлгә тораташ кебек катты, секунд эчендә тәнләре кипте.

— Кая китәсең, Сонечка? — диде ул, иреннәрен көчкә тирбәлдереп.

— Чаллыга...

— Кем белән?

— Теге, безнең районда эшләгәндә, ВЛКСМ райкомы секретаре Рәхимов бар иде бит әле, ул финансовый институтны бетергән икән, аны хәзер Чаллы ОРСына җибәргәннәр. Шуның белән китәм. Аңа квартир да биргәннәр. Ул биредә... Мине алырга килгән. Иртән китәбез...

— Сонечка, син ни сөйләгәнеңне беләсеңме? Беренче секретарь хатыны ирен ташлап китә! Обком алдында, халык алдында мин ни дип җавап бирермен?

— Анысы өчен кайгырма. Обкомга мин хат яздым инде. Сиңа амораль дигән ярлык такмаслар. Ә районда безнең болай яшәүне халык күптән белә инде. Болай яшәгәнче аерым яшәү мең тапкыр артык.

— Бик критический моментта ташлыйсың син мине, Сонечка, һич югында, берәр айга түзәсе иде.

— Рәшат абыем, бәгърем, артык үгетләмә мине, булмый... Яшьтән үк сөйдем мин Рәхимовны. Инде хәл ителгән. Акыллы бит син, әшең, яшең буенча да олы кеше, бәхет кенә теләп син безгә. Мин дә бәхет телим. Син дә болай кангырып йөрүеңне ташла. Дөнья булгач, аерылышу, яңадан өйләнүләр бар. Алар агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Мин китү белән Вераңны алып кайт. Ярата ул сине, Рәшат,

өзелеп ярата. Берничә ел хат алыштык без аның белән. Кин күңелле, олы җанлы хатын ул...

Саниянең бу сүзләре аяз көнне яшен суккандай булды. Рәшат Галиевичның тыннары куырылды. Ул Саниянең иңенә салган кулын алды. Торып, ялан аяк йомшак келәм өстеннән арлы-бирле йөри башлады. Сәгать сукты. Бер тулды, төнге бер. Яңа көн туды, аның менә бер сәгате үтте. Тагын Саниянең ничә сәгать кенә торасы калды бу квартирда, ничә сәгать? Рәшат Галиевичның буталган миендә әнә шулар кайнады. «Ярата ул сине, Рәшат, өзелеп ярата... Олы җанлы хатын ул». Саниянең авызыннан чыккан шул сүзләр колак төбендә чыңлый. Кинәт Вераның елмаеп килүе, табын янында аңа елышып утыруы, суга сусаган кына гөләдәй иреннәре күз алдына килде. Аның шушы минутта Вераның күкрәгенә капланып тын каласы, бәхетсез мәхәббәте, эшендәге «ЧП»ларны сөйләп, күңелен бушатасы килде. Миен туктаусыз бораулап торган чуалчык уйлар йомгагы сүтелеп бетмәс, күкрәкне басып торган авыр йөк юкка чыкмас иде микән?

— Әгәр абынсаң, инде болай да бәхетеңне таба алмасаң, Сонечка, дөньяда мин барын онытма... Минем йөрәк кайчан гына килсәң дә сине кабул итәр, ул синең өчен яратылган... Ә Вера Александровна минем өчен күңел юаткыч кына шул, аның белән мин семья бәхете таба алмам,— диде ул, һаман йөренеп.

— Бергә яшәп карагыз әле. Ул сине, Рәшат абый, яңа туган сабый баладай итәчәк...

— Белмим шул, белмим... Нигә очраттым икән мин сине, Сания?!.

Рәшат Галиевич өзгәләнеп, ачыргаланып әйтте бу сүзләрне. Аның битен генә түгел, муеннарын да кызыл тимгелләр каплады. Ул кинәт, эчкән кешедәй, чайкалып китте һәм идәнгә гөрселдәп ауды. Сания, курkуыннан нишләргә белмичә, кычкырып җибәрде һәм Рәшат Галиевич өстенә иелде. Тиз генә аның күлмәк якаларын ычкындырды, як-якка ташланган кулларын күтәреп, ясалма сулыш алдырырга керешә. Кафендәй агарган йөзенә аз гына алсулык йөгерә башлагач, телефоннан «ашыгыч ярдәм» машинасы чакырып, больницага шалтыратты. Рәшат Галиевич исемен ишетү белән дежур врач: «Ун минуттан сездә булырбыз, ясалма сулыш алдыра торыгыз», диде. Телефоннан шалтыраткан арада Рәшат Галиевич күп-күмгәк булган иде. Сания илереп елап аның өстенә ташланды:

— Рәшат, Рәшат абыкаем, җаным, үлмәсәнә, үлмә, әйбәт кеше бит син, бер рәхәтләр дә күрми үлеп китәрсең микәнни? — дип, кулларын әле баш очына сузып, әле күтәреп, ясалма сулыш алдырырга керешә. Үзенең кайнар күз яшьләре Рәшат Галиевичның яшәү өмете качкан битенә тама. Врачлар чыннан да тиз килеп җиттеләр. Баш врач үзе килгән иде. Килеп керү белән ул авыруның пульсын карады, үзе белән алып килгән ике сестрага ниндидер укол әзерләргә кушты. Баш врачның йөзе җитди иде. «Яхшы, ясалма сулыш алдырып торгансын»,— дип пышылдады ул Саниягә. Сания Рәшат Галиевичның баш очына басып тораташ катты. Күзләрен аның йөзеннән алмады. Баш врач Рәшат Галиевичның беләгендәге кан тамырына укол кадады. Икенче беләгенә дә нидер җибәрде. Тезләнгән килеш, йөрәген тыңлады. Аннары тагын пульсын санады. Чигә тамырларына бармагын куйды. Бераздан баш врачның йөзе яктырды.

— Моторга ягулык килә! — дип пышылдады ул. Менә Рәшат Галиевичның күкрәге, әкрен генә булса да, бер күтәрелә, бер төшә. Йөзендәге кара янган тутлар да эреп югала башлады. Алар башта кызардылар. Аннары алсуландылар. Хәзер, әнә, агарып килә. Менә күз кабаклары тартышып куйды һәм Рәшат Галиевич күзләрен ачты. Үзе өстенә иелеп торган баш врачны күреп, ул башта берни аңламады. Читтәрәк тагын кемнәрдер басып тора иде. Ләкин алар еракта, томан эчендә ке-

бек күренделәр. Колакка баш врачның кайдадыр, тирән баздан ишетелгән төсле тавышы керде.

— Тынычланыгыз, берни дә юк, Рәшат Галиевич, бераз ятыгыз әле...

Ул тагын күзләрен йомды. «Баш врач нигә монда, нигә бераз ятыгыз әле, ди ул? Ятмадымыни соң әле ул? Сания, кайда син? Йөрәгемне генә тот, синең кулларың тисә авыртмас төсле... Вера... Вера... Кала алмыйм шул... Миңа кайтырга кирәк. Обкомнан шулай диделәр... Комиссия килде дәмени инде? Барысына да Урмакаев гаепле!..» Рәшат Галиевич шулай дип саташырга кереште. Баш врач тагын ниндидер укол хәзерләргә кушты. Аны кадаганнан соң авыру йокыга китте. Носилка алып керделәр. Рәшат Галиевичны «ашыгыч ярдәм» машинасы белән больницага алып киттеләр. Сания дә аларга иярде.

Икенче көнне төш авышкач кына аңына килде Рәшат Галиевич. Баш очында утырган Санияне күреп, аңа елмаеп карады. Нидер әйтергә теләп иреннәрен кыймылдатты, ләкин сүзе чыкмады. Хәлен белергә барлык бюро членнары таң белән төшеп життеләр. Сәгать саен хәлен белешеп тордылар. Вәрәшев обкомга да шалтыраткан. Баш врачның сигналын гына көтәләр. Казанга алып килергә дип махсус самолет билгеләнгән. Сәгать икеләрдә Рәшат Галиевичның хәле бераз яхшырды. Баш врач Казанга шалтыратты. Сәгать өчләрдә Рәшат Галиевичны аэродромга алып киттеләр. Озатучы сестра белән Сания дә Казанга очты. Рәшат Галиевичны өлкә комитеты клиникасына салдылар. «Инфаркт миокарда» диагнозы куйдылар. Сания барында профессорлар карадылар. «Кризис үткән, беренче ярдәм вакытында һәм бик төгәл, дөрес ясалган, кайгырмагыз, барыгыз, ял итегез»,— диделәр Саниягә.

Сания кая таба барганын белештермичә, атлады да атлады. Бер чаттан борылгач Толстой урамына килеп чыкты. Шулай каңгырып йөри торгач, ул үзен Маяковский урамында күрде. ГИДУВ бинасына карап торганда кинәт Вера Александровна исенә төште. «Шушы урамда тора бит ул. Инде өендә булырга тиеш»,— дип уйлады ул һәм сәгатенә, туган көнендә Рәшат Галиевич алып биргән йөзек кашы хәтле генә алтын сәгатенә карады. Җиде тулып биш минут үткән иде. Ул Вера Александровна яши торган йортны тиз эзләп тапты. Квартир ишеге төбенә житкәч, бераз икеләнеп торды. «Кирәргәме, юкмы? Хәле рәтләнә төшкәч, Рәшат Галиевич аны барыбер чакырта бит. Бу килеш, авыр хәлдә күрмәсенме әллә?» Ул, кырт борылып, урамга чыкты. Өзелеп ашыйсы килүен исенә төшереп күнеленнән якын тирәдәге ашханәләрне барлап чыкты. Якында гына юк шул. Ул ридикюлен ачты. Анда көмеш тиеннекләр генә иде. Өенә кереп тора алмады шул. Больницага төшкәндә гадәт буенча гына кулга килеп кергән ридикюльдә нәрсә булсын. Ул яңадан зур тәрәзәләреннән якты ут балкыган йортка таба атлады, калиткадан үтеп, цемент баскычтан өскә менде, звонокка басты.

— Мактап кем йөри, жинел аягы беләнме? — дип сорады бер хатынкыз жырлап торган бәрхет тавышы белән русчалап.

Саниянең тамак төбенә ниндидер төер тыгылгандай булды.

— Вера Александровна, бу мин — Шәймиева, Сания,— диде ул көчкә үзен кулга алып. Ишек чылбыры чылтырап төште. Ишек ачылды һәм аны парчалы ефәк халат кигән, сары бөдрә чәчле, зур гәүдәле хатын кочагына алды.

— Нинди җилләр ташлады? Әйдә, әйдә, Сонечка, түргә уз, чишен. Пилмән ясап йөри идем әле. Гомер уздыру өчен,— дип, ул аны биек, якты, зур бүлмәгә алып керде, өстен чишендереп урын тәкъдим итте. Саниянең һаман бүлмә уртасында басып торуын, утырмавын күргәч, ул хафаланып сорады:

— Әллә берәр хәл булдымы?

Саниянең ирennәре дерелдәде.

— Рәшат Галиевич авыр хәлдә, обком клиникасында...

Бу сүзләрне ишетү белән Вера Александровнаның ак йөзенә кинәт балавыз сарысы коелды. Ул ике чигәсен тотты, артын-артын өстәлгә таба китте һәм биек артлы креслога лып итеп утырды. Башын артка ташлады, күзләрен йомган килеш пышылдап сорау бирде:

— Диагнозы?..

— Инфаркт миокарда.

— Кайчан?

— Кичә төнлә...

Вера Александровна, ике чигәсен тоткан килеш, башын кәнәфи кулчасына куйды. Аның бөдрә чәчләре, киң, көч ташып торган җилкәсе дерелди. Дерелди дә тын кала. Тавышсыз, чын йөрәктән сулкылдап елаган бу хатын алдында Сания үзен ничек тотарга белми гаҗизләнде. Ни дип дәшәргә, ни дип юатырга? Башына уй, теленә сүз килми өнсез калды. Ни дисә дә, чын күңелдән әйтелгән дип кабул итмәс ул аның сүзләрен. Сания әкрен генә Вера Александровна янына килде, халат якасы каплап бетермәгән матур, ап-ак муенына кулын куйды. Вера Александровнаның тәне ут кебек яна иде. Сания көйдереп алырдай кайнарлыктан сискәнеп, кулын югары күтәрде, аннан, үз-үзен белештермичә, идәнгә тезләнде һәм Вера Александровнаның муеныннан кочаклап, йөзен аның ниндидер татлы хушбуй исе аңкып торган сары бөдрә чәчләренә терәп, илереп елап җибәрде. Кайнар күз яшьләре сары бөдрә чәч араларына терекөмеш тамчылары кебек кереп югала барды. Вера Александровна Санияне сыңар кулы белән кочаклап үзенә кысты, аның чәчләреннән, аркасыннан сыйпап, тавышсыз гына, күңеленә иңгән бу авыр хәсрәт болытын тарата алмый үкседе.

Менә Вера Александровна башын күтәрде, халат изүләрен рәтләп куйды, һаман идәндә тезләнеп торган Саниянең башыннан сыйпады. Аларның икесенең дә күзләре яшь белән тулы иде. Ләкин алар бер-берсеннән читтенсенмәделәр. Сания торып басты, җиң эчендәге кулъяулыгын алып күзләрен сөртте. Вера Александровна кухня ягына чыгып битен юды. Сөлгесен иңенә салган килеш залга керде, көзге каршына килеп сөртенде, күз төпләренә буынтыкланып торган ап-ак бармаклары белән массаж ясагандай итте дә:

— Сонечка, сез нәрсә әйтсәгез дә әйтерсез, мин клиникага бармый түзә алмыйм,— диде. Сания аның сылу озын гәүдәсенә сәерсенеп һәм сокланып карады. Яратырлык, әле сыендагы хатын иде бу. Сания аның буен Рәшат белән чагыштырып карады. Биек үкчә кигәндә нәкъ Рәшат буе булачак икән. Ул аларның икесен бергә күз алдына китерде. Шушы хатын белән шушы бүлмәдә алар менә ничә еллар бергә булганнар бит. Тик Саниядә Рәшатка да, Вера Александровнага да көнчелек хисләре уянмады. Рәшатның авыр хәлдә икәнлеген белгәч, йөрәгенә кан саварлык итеп әче хәсрәткә төшкән бу хатынны ул көндәше итеп күз алдына китерә алмады. Көндәш булу өчен Рәшатны яратырга кирәк иде, ә ул аны булдыра алмады. Яратмаган кешеңнән, ул синең кеше алдындагы законлы ирең булса да, сөйгән ярларын күңел күпсенми дә, көндәш тә, дошман да итә алмый икән. Сания әнә шундый халәтне сизенеп, үз кайгысын Вера Александровна башына килгән авыр хәсрәт белән чагыштырып карады. Кеше булгарак Рәшат әйбәт иде, аның өчен әйбәт булды. Ул аны шул ягы белән искә ала, кызгана, чын йөрәге белән аның терелүен, менә шушы, аның өчен җан атып торган хатын белән бергә булуын тели иде. Ә Вера Александровна өчен Рәшат, беренче мәхәббәте җимерелгәч, көтеп алынган, эзләп алынган бәхеттән соң икенче тапкыр тетрәнү иде. Сөйгән кешеңне менә-менә югалту хисеннән дә авыр хәсрәтне, кем әйтмешли, хода дошманына да китермәсен. Шуңадырмы, үз башына килгән бу кайгыдан Сания тизрәк айныды.

— Профессорлар кризис үтте диделәр. Хафаланмагыз, Вера Александровна,— диде Сания, әле һаман тамак төбендә торган нииндидер төерне үткәреп җибәрә алмыйча.

— Шулай да, Сонечка, мин бармый кала алмыйм.

— Әйдәгез, әйдә, Вера Александровна, мин дә барам...

— Ой, Сонечка, әйбәт булыр иде. Минем нервыларым шул чаклы какшады. Мишаның суга төшүен ишеткәннән дә битәр... Бик сонармыйк, алайса. Кертмәсләр... Минем анда танышларым да бар-барын.

Алар тиз генә җыенып чыгып киттеләр. Бәхетләренә, урамга чыгу белән, такси очрады. Шофер яшь кенә егет иде. Вера Александровна аңа адресны әйтте. Ун минут та үтмәгәндер, алар обком клиникасы вестибюлендә иделәр инде. Вера Александровна дежур врачка шалтыратты. Ниндидер юан тавышлы ир кеше тавышы килде. Башта ул тыңларга да теләмәде. Саниянең бөтен гәүдәсе куырылды. Дежур врачка җен ачулары чыкты. Вера Александровна искәрми дә калды, Сания аның кулындагы трубканы алды да:

— Сез нәрсә, иптәш дежурный врач, Рәшат Галиевичның хатыны ич ул. Ул-бу булса? Күрми калса? Ул аның янында булырга тиеш, аңлыйсызмы? — дип кычкырды.

— Берни аңламыйм... Әле ул бер сәгать кенә элек моннан киткән иде ич...

— Тагын килгән, ә мин Рәшат Галиевичның сеңелесе, аңлагыз. Мондый чакта кайда булырга тиеш аның хатыны?

— Менегез!..

Калын тавышлы кеше трубканы куйды. Бу сөйләшүне тыңлап торган Вера Александровнаның күз алмаларын яшь ярысы каплады, ирен өстендәге кечкенә генә миңе дерелдәп, тартышып алды.

— Сонечка, ник кирәк булды бу? Рәхмәт, рәхмәт сезгә, әйдәгез,— диде.

Сания аның дымланып торган зәңгәр күзләренә тутырып карады, Вера Александровнаның кулыннан тотты да:

— Вера Александровна, мин бирсдә кәтәм. Сез үзегез генә менегез. Аңында булса, мине сораса, хафаланмагыз диегез, бирсдә. Казанда, диегез. Сезне озата килгән, диегез. Әгәр кирәк булса, ун-унбиш минуттан килеп җитәчәк, диегез... Барыгыз, Вера Александровна!.. Сез рух өрә алмассызмы?.. Әйбәт кеше бит ул,— диде.

Вера Александровна аңа үз итеп, ягымлы итеп карады. Сүзсез генә башын ия төште һәм ашыга-кабалана икенче катка менеп китте. Сания, хәсрәт тулы уйлар өермәсенә уралып, вестибюльдә басып калды.

* * *

Рамай бюрода Шәймиевнең тактикасын тиз аңлады. Кайбер бюро членнары да моңа төшенде булса кирәк. Шәймиевнең тәкъдиме көчкә үтте бит. Үз фикере булмыйча, беренче секретарь рупоры булып йөргән Урмакаевка шул кирәк тә аңа. Җәзасы, партия җәзасы аңа дөрес бирелде. Ләкин формулировка гына дөрес булмады. Шәймиевнең үзенә шулай ул. Шәймиев тә үткен, башсыз кеше дип әйтеп булмый аны. Баш очында куерган болытларны ничек итеп Урмакаевка күчереп куйды.

Кичәге сәер бюро утырышы турында уйланып утырганда, партоешма секретаре Яхъя Курмашев килеп керде. Председатель өстәлдәге кәгазьгә күз төшерү белән, ул Рамайның нәрсә белән мәшгуль икәнен шунда ук төшенде һәм:

— Әллә карап чыктыгыз да? — дип сорады.

— Карадым. Берничә пунктын әзрәк үзгәртми булмас.

— Чөгендер алучы комбайнчыларга кызыксындыру чарасы бәләкәй. Бер комбайн сезонга 40 гектар чөгендер алырга тиеш. Бу пунктны болай итсәк нишләр икән? Һәр алынган гектарга өчәр сум өстәмә. Ә сезон нормасыннан арткан һәр гектарга 25 әр сум куйсак? — диде Рамай.

— Күпкә китмәсме? Чөгендер алучыга төп түләү дә әйбәт бит. Нормадан артыгына куйыйк. Ә тегесе нигә кирәк?

— Яхъя туган, эшләсен генә, эшләтсеннәр генә чөгендер комбайның жәл түгел. Күтәртелгән бер гектар уңышны кул белән жыюның ни икәнен беләсең бит син. Бөтен авыл халкы, бигрәк тә хатын-кыз, бу каторжный эштән котылачак. Аннары, безнең яклар өчен эшләнгән комбайнмыни алар?! Механизаторлар аңа күпме реконструкция кертте. Алар эшләтсәләр, безнең шартлар өчен яңа комбайн туды дигән сүз.— Вильданов бераз дәшми торды. Аннары чал йөгергән бөдрә чәчләрен сыйпап алды.— Ярышта беренче, икенче, өченче урынны алган комбайнчыларга кыйммәтле бүләкләр дә билгеләргә кирәк. Калганын уйлагыз. Өченче урынны алучыга да телевизордан ким әйбер булмасын. Без алайса бөртекле ашлык комбайнында эшләүчеләрне генә бүләкләргә өйрәнеп киттек. Аннары, тракторчыларны да онытмаска кирәк. Иртә яздан кара көзгә кадәр кем басуда — шулар. Ипигә нигезне алар сала. Алар базис, комбайнчылар — өскормә. Менә шулай, иптәш парторг!

— Рамай Ибраһимович, ә мораль кызыксындыру, социалистик ярыш оештыру яклары ничек? Шулай ярармы?

— Андый киңәшне син миннән сорарга тиеш түгел инде. Үзеннең дүрт аяк дагаланган, таярлык түгел. Ә шулай да бер әйбер эшлисе иде. Колхозлар төзелгән беренче елларны оештыралар иде аны.

— Мин аларны белмим шул.

— Соңгы орлыкларны жир куенына салган кешене бөтен авыл халкы каршы ала иде. Юлларына кызыл күкәйләр тәгәрәтеп. Аннары аны, бөтен семьясы белән пар атка утыртып, урам әйләндерәләр иде. Уракка төшкәч тә, ин беренче көлтәне дә шуңа урдыралар иде. Менә шуны үзеңчә, заман сулышы, рухы өреп тергезеп жибәрсәң, иске авызга яңа аш дигәндәй, бер әйбер килеп чыгар иде. Ифрак та күңелле чыга ул.

— Эшлибез моны, Рамай Ибраһимович.

— Уйлагыз әле...

— Рамай Ибраһимович, сез очрашуны онытмагансыздыр бит?

— Юк. Ничәдә дидең әле?

— Дүртләрдә дигән идек. Ашап-эчеп, өс алмаштырып та килсеннәр дигән идем.

Шул чак ишек ачылды һәм бухгалтер Кәрам килеп керде.

— Ишеттегезме бер хәбәр? — диде ул титаклый-титаклый өстәлгә таба атлап.— Рәшат Галиевичны паралич суккан диме, Казанга алып киткәннәр.

— Кайчан?

Рамай да, Яхъя да икесе бер авыздан шулай дип сорадылар.

— Самолет әле яңа күтәрелеп киткән. Больнистан шалтыратканнар иде. Хәкимулла шунда иде бит. Аның белән сөйләштем.

Рамай Ибраһимович телефонга үрелде.

— Райбашкарма председателен бир әле, үскәнем...

Вәрәшов жавап бирмәде. Халикъ Кәримовичны ялгатты. Ул кабинетында булып чыкты. Искәрмәс хәбәр чын икән. Рамай Ибраһимович секретарьның хәлен жетекләп сораштырды. Аның йөзе уйчанланды. Трубканы куйгач, «Инфаркт миокарда, инфаркт»,— дип пышылдады һәм: — Әнә шулай куасың, сөйрисең дә дөньяны, ә бер көнне барысы да житә... План да үтәлә... Кирәкмәс, артык йөкләр дә күп тартты шул синең йөрәк,— диде.

Кәрам чыгып китте. Яхъя, папирос кабызып, сүнгән шырпысын ıрәзә төбендәге гөл чүлмәге балчыгына кадады. Рамай карап торган ...эн.

— Ташла әле шул гадәтеңне, Яхъя! — диде ул, кырыс кына.— Син ...дап китсәң, мин иртән чүплэп йөрим.

Яхъя сүнгән шырпыны алып, шырпы кабы артына кыстырды. Папи...эсын тирән итеп суырды да бүлмәгә төтен алкалары таратып, Рамай ...брарһимовичка дәште:

— Әллә чыгарылыш классы укучыларының исемлеген карап чыга...ызмы? — диде.

Рамай Ибраһимович кесәсеннән блокнотын алды һәм:

— Барысы шул утыз ике килешме? — диде.

— Әйе.

— Шуның ничәсе безнең колхоздан?

— Унсигезе.

Алар һәр укучының нәрсәгә сәләтле булуын, нәрсә яратуын ачыклап ...ыктылар.

— Менә бу икесе — Әхмәтнең малае белән Заһид абый кызының ни...елән сулавын тәки белә алмадым,— диде соңыннан Яхъя.

— Равил белән Резидәме?

— Шулар инде. Укулары да чамалы.

— Равилнең нигә гашыйклыгын беләм мин. Комбинезон киеп, ак ...алстук тагып, «Волга» шоферы булу аның хыялы. Дамирда рәсемен ...үрдем. Минем комбинезонны киеп, галстукны тагып район үзәгендә ...ште, диде. Моның кылын тартабыз бүген. Ә Резидәгә, беләсеңме, нәр...ә тәкъдим итәбез? — Рамай кул сырты белән чигәсен сыпырды.— ...аборантлыкны. Быел көзгә май заводы аякка басамы, баса. Ә анда ...аборанткалар бераү генә дә кирәк булмас әле. Укуын бетерү белән ...итсен курска. Мастер-технолог быел укуын бетереп кайта. Үтә бит ул ...омер. Әле яңа кебек иде. Ике ел искән җилдәй үтте дә китте.

— Рамай Ибраһимович, бу очрашуда тагын бер нәрсәне истән ...ыгармыйк әле без.

— Анысы ни тагын, хәтерләмим?

— КамАЗга, Чаллыга кеше җибәрергә тагын разнарядка бар бит. ...ина моның өчен райкомда каты әләкте. Әлеккесен дә өздегез, диделәр.

— Соң, бездән китүчеләр юк бит. Этап белән озата алмыйм бит ...ин аларны!

— Анысы шулай. Дамир да тагын киреләнгән әле. Китмим ди ...әзер.

— Аны җибәрәсем килми, ә аңа китәргә кирәк.

— Ни өчен?

— Анысы секрет. Комиссар булсаң да әйтә алмыйм, бигайбә. Да...ирны мин көндерермен. Башка кандидатуралар эзли тор.

— Күп сөйләштем инде мин.

— Менә, Яхъя, нәрсә, әйдә, бу турыда баш ватмыйк әле. Һәм менә ...и өчен,— дип сөйләп китте Рамай, терсәге белән өстәлгә таянып.— ...артия политикасын мин дә синең кебек дөрес аңлыйм. Төзелешне ...адрларсыз алып барып булмый. Авыл хуҗалыгына техника үтеп кер...ән саен авыл халкының күбесенең эшсез калуын, аларның шәһәрләргә ...үчәргә мәҗбүр булуларын да аңлыйм. Англиядә әнә барлык халык...ның 6 проценты гына авыл хуҗалыгында бит. Әмма бу чагыштыру ...рынлы түгел, беләм. Син менә бер әйбер турында уйлаганың бармы? ...игә бездәй җиргә кендеге белән берегеп үскән кешеләрне җирдән ае...ырга? — Рамай күзләрен кысты, бер мизгел Яхъядан җавап көтте. ...әкин аның авызыннан сүз чыкмагач, үз соравына үзе җавап бирде.— ...өрес түгел бу. Һәр колхозны бер тарак белән тарамыйлар. Менә мин ...олай уйлыйм. Әле бездә җәен эшләп, кыш буе бер эшсез ятучы авыл-

лар бар. Аннары бер-ике фермалы авыллар. Анда даими эштә күпме кеше бар дисең син? Андый авылларны күчерү, эреләндерү, карлик фермаларны бетерү турында күпме карарлар кабул ителде, күпме романнар язылды. Күптән түгел мин «Бунт сыновей» дигән китап укыдым. Укыганың юкмы? Булмаса, укы әле. Анда кызык кына фикерләр бар. Ләкин авыл хуҗалыгының, сугыштан соңгы авыл хуҗалыгы проблемалары мәзәк кенә бер әйбергә китереп тери. Хуторлар, вак авыллар бер урынга күтәрелергә, агрошәһәр салынырга тиеш. Шул идея белән атасы белән малае — председатель — архитектор чәпәләшеп бетәләр. Атасы, имеш, искелеккә ябышып ятучы, малае — архитектор — яңалык алып килүче, прогресс! Төбенә төшсәң, һаман шул бер балык башы — аталар һәм балалар проблемасы. Ясалма! Ышандырмый, авылларны берләштереп кенә бу проблемадан котылып булмый. Биредә саннар чагыштырмасын үзгәртергә кирәк һәм якын елларда. Авыл бит ул эшчеләр сыйныфын, промышленностьны тудырган ана. Аңа икесе дә газиз: шәһәре дә, авылы да, бармакның кайсын тешләсәң дә авырткан кебек. Шунлыктан бездәй ныклы хуҗалыкларда кеше ресурсларына кагылмаска кирәк. Алар хәзер квалификацияле, белемле, тәҗрибә туплаган кадрлар. Алар кулына син күбрәк хәзерге заман техникасын гына бир. Бер колхоз ике-өч колхоз җирен эшкәртә, продукциясен житештерә һәм ул шулай булачак та. Мин ни өчен күрше «Таза чишмә» колхозының икенче бригада җирләрен үзебезгә сорыйм? Чөнки аны эшкәртергә безнең көч җитә хәзер. Алар асраган хәтле малтуарны да таба алабыз. Кечкенә авылларны, әнә андый көчсез бригадаларны төзелешләргә, промышленностьларга җибәрергә кирәк. Тормыш таләп итә моны. Менә кая таба бара заманалар. Авылларны эреләндерү генә проблеманы хәл итми. Кешеләргә эш бирергә кирәк. Ярар, авылларны эреләндереп бетердек ди. Әллә нинди культура сарайлары, стадионнар төзеп куйдык ди. Кышка керү белән ярты авыл эшсез. Төкерә ул вакытта халык синең культура сарайларыңа. Аңа эш бир син! Менә шуңа күрә ул разнарядкага, Яхъя туган, баш ватма. Район өстенә төшкән разнарядканы әнә мин сөйләгән авыллар, бригадалар исәбенә үтәп була. Район житәкчеләренең безне бер тарактан тарау шаукымы гына бу.

— Бу лекцияне, Рамай Ибраһимович, бүген укучылар алдында да сөйләсәң шәп булыр иде. Колхозның киләчәгенә бәйләп,— диде Яхъя елмаеп һәм болай дип өстәде: — Армиядән кайту белән укырга иде сиңа, Рамай Ибраһимович. Кем чыгар иде микән синнән?

— Ибраһим малае, кем чыксын!.. Бөтенебез койрыкны сыртка салсак, кем эшләр иде ул вакытта авыл хуҗалыгында? — дип җавап кайтарды Рамай аның сүзенә.

Яхъя өстәлдәге дәфтәрен алып куенына тыкты, тагын папирос кабызды һәм:

— Уйласаң искитәрлек шул хәзер. Сезнең белән унбишенче ел эшлим. Шушы вакытта гына авылда, кешеләрдә нинди үзгәрешләр булды. Элекке наряд дәфтәрләренә күз төшергәнең бармы синең, Рамай Ибраһимович?

— Юк, ә нигә?

— Күз төшер әле бер иренмичә.

— Хәзер көнлек наряд бирү дә юк бит димәкче иеңме?

— Юк. Эш анда түгел. Авылда һөнәр нясе артуга гаҗәпкә каласың. Элек кемгә наряд бирелгән? Фәлән фермага өч олау салам алып кайтырга. МТС тракторларына су илтергә, көрәк белән кар тотарга чыгарга. Шулаймы?

— Шулай.

— Ә хәзер? Нинди профессияләр генә юк авылда! Механизаторларын әйткән дә юк. Газовик, электрик, гараж мөдире, автомеханик,

инженер, төзелеш механигы, культура йорты директоры, ясле мөдире, саный китсәң, очына чыгарлык түгел.

— Гажәпләнерлек берние дә юк моның. Яңа тормыш — яңача эшләүне таләп итә. Әхезмәт процессында, без телибезме, теләмибезме, яңа профессия кешеләре туа.

— Ул кешеләрне тәрбияләү, алдан әзерләү безгә төшә дип тә өстә.

— Дөрес.

Председательнең исенә нидер төште, ул алдында яткан счет төймәсен тартыбрак китерде дә нидер хисапларга керешге.

— Рамай Ибраһимович, сәгать дүрткә, озакламагыз, инде җыела торганнардыр,— дип, Яхъя да ишеккә юнәлде.

Ул чыгып киткәч тә Вильданов счет төймәләрен әле байтак биетте. Кайбер саннарны кәгазь битенә дә төшерде. Чыгарылыш классы укучылары белән очрашканнан соң, аның әле Юлтимер бригадасы белән киңәш-табыш итешәсе бар иде. Узган айда планда каралганча сөт җитештерелсә дә, азык лимитына сыешмаганнар. Силос күп тотылган. Кая киткән? Монда сулагай якка каеру юкмы? Әнә шуның төбенә төшәргә кирәк. Кем булыр? Ул фермада эшләүчеләрне, бигрәк тә ат җигеп йөрүчеләрне бер-бер артлы күз алдыннан уздырды. Ләкин шикләнерлек кеше тапмады. Фермада сыналган кешеләр. Силос базын ачык калдырганнар. «Таза чишмә»ләрдер, мөгаен. Аларда кытлык. Саламнары да юк бит, дип уйлады ул. Сәгатенә күз төшерде. Дүрт туларга унбиш минутлар калып бара иде. Ул счетны бер читкә этеп куйды һәм ишектән кергәч тә уң яктагы гади генә кием шкафын ачты. Костюмын салып элде. Аның түшләренә ике «Дан ордены», бер «Кызыл Йолдыз» һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, дистәләп медаль тагылган кителен алып киде. Плащын иңенә генә элде дә, бухгалтерия ишеген ачып, Кәрамга кычкырды:

— Сораучы булса, мин мәктәптә булырмын!

Кәрам күзлек астыннан карап, аңа ияк какты. Рамай дагалы итекләре белән шык-шык басып идарәдән чыгып китте. Өстенә китель кию белән ул үзендә ниндидер көч сизә, яшәреп киткәндәй була. Аяклары үзеннән-үзе җиргә ышанычлы адымнар белән баса башлый. Әнә ул егетләрчә җил-җил атлап мәктәп ягына элдертә. Читтән карап аңа илленең өстендәге кеше дип берничек тә әйтә алмыйсың. Җилкәләре төз, киң. Гәүдәсе дә килешле, артык йөк басмаган.

Ул кергәндә мәктәп залында кеше күп иде инде. Ул кайсына баш иеп, кайсына кул биреп, кайсына күз йөртеп, барысы белән дә исәнләшеп чыкты. Тәрәзәләре кояшка караган зур мәктәп залының алгы рәтләренә быелгы чыгарыш класс укучылары үзләренең әти-әниләре, туганнары белән бергә утырганнар. Әнә Әхмәтзыя белән Равил. Заһит абый да үзе килгән. Резидәсен ничек киендергән! Кем әйтмешли, өстендә хөллә генә. Бусы ярап бетми, Заһит абый. Үзебез кием күрмәдек, киенсеннәр, дисең инде син, артыграк тырышкансың. Күзенә чалынган һәркем турында шулай уй-фикер йөртеп, ул президиум өстәле янына барып утырды. Мәктәп директоры Яхъя Курмашев колхозның иң могътәбәр кешеләрен президиумга чакырды. Беренче сүзне авылның аксакалы, шушы колхозны оештыручы, атказанган колхозчы, колхозның персональ пенсионеры тимерче Хәсәнша картка бирделәр. Ул трибунадан сөйләргә гадәтләнмәгән. Түгәрәкләп кырылган сакалын сыпырасыпыра, ул өстәл арасыннан чыкты, халык алдына барып басты да, таягына ике куллап таянып, сүз башлады:

— Сырхаулап киттем әле. Гаепләмәссез инде... Оланнар, бәбекәчәйләрем, килешмәгән җирләрен килештереп аңларсыз. Сиксән җиде яшьлек Хәсәнша бабагызны күз алдына китерегез, тыңлагыз... Мин кем идем, кем булдым? Моны сөйләп торуның кирәге юк. Эш кешесеме мин, эш кешесе. Шуңа хәзерге миңа булган хөрмәтне кем күрә? Миндәйләр

күрә. Озын сүзнең кыскасы шул: очар канатларыгыз талмасын. Алар сезне минем кебек бәхетле, хөрмәтле картлыкка алып килсен. Әгит мәгит көтмәгез инде миннән. Үзем әгит мин, үземә карагыз да гыйбрәт алыгыз. Менә шул оланнар, бәбекәчләрем. Башыгызга зиһен, күңелегезгә акыл, миһырбан утырсын, миннән хәер-фатиха шул.

Хәсәнша карттан соң Мәрьям сөйләде. Аннары Рамайга сүз бирделәр. Аны һәркем йотылып тыңлады. Чөнки ул һәр укучының киләчәге турында конкрет сөйләде.

Рамайдан соң укучылар сүз алдылар. Аннары аларга колхоз идарәсе, партоешмасы, мәктәп дирекциясе исеменнән «Профессия сайлаганда» дигән истәлек бүләкләре тапшырылды. Җыелышны ябам дигәндә генә Вильданов яңадан сүз сорады:

— Бер генә минутка, иптәшләр! Кадерле укучылар, хәзер барыгыз да тегү-чигү түгәрәге кабинетына керегез. Район көнкүреш комбинатыннан мастер чакырттым. Чыгарыш кичәсе балына кызларга затлы күлмәкләр, егетләргә костюм тегү өчен үлчәү алырга кирәк. Колхоз исәбенә тектерәбез. «Беренче Май»дан иканегез әллә кайдан күренеп торсын!

Ул сүзен әйтеп бетерүгә, бөтен зал кул чаба башлады. Яхъя Курмашев моны көтмәгән иде, ул гаҗәпсенеп Рамайга карады һәм эчке бер җылылык, якынлык тойгысы белән: «Һәр вакыт шулай, бер мөгез чыгармый калмый», дип уйлады.

* * *

Вәрәшов шушы районда туып үсте. Әти-әниләре ярыйсы гына хәлле кешеләр иде. Колхозлар оеша башлагач та әтисе беренчеләрдән булып гариза бирде. Ике атын да колхозга тапшырды. Хәзер дә хәтерли ала ул көннәрне Габделхак. Ишек алдында ат булмагач, өйдән мәет чыккан кебек булып калды.

Урта мәктәпне тәмамлаган елны сугыш чыкты. Шул елны әтисе белән әнисе бер-бер артлы үлеп китте. Аларны җирләүгә, аны да сугышка алдылар. Сугыштан кеше кебек күкрәк тулы орден белән кайтырга туры килмәде аңа. Лагерьларда өйрәнүләрдән соң фронтка да барып житә алмады, аларның эшелонын бомбага тоттылар. Тула шәһәренә житеп киләләр иде. Аның уң кулы ике җирдән яраланды. Уч төбе тавык йомыркасы сыярлык тишелгән, беләк сөяге чәрдәкләнгән иде. Госпитальдә кулын кисмәкче дә булдылар. Үзе дә риза булган иде. Ләкин олы яшьтәге врач хатын, яраларын җентекләп карагач, гангрена сизелми, болай дәвалап карыйк әле, диде. Беләгенә гипс салдылар. Госпитальдән госпитальгә елга якын йөрде. Куйбышев шәһәрендә ак билет тоттырып, өенә озаттылар. Шунда, госпитальдә ятканда, ул Саимә исемле санитарка, татар кызы белән танышкан иде. Авылга кайткач, сугыш беткәнче хат алыштылар. 1945 елның июнь аенда Саимә аны эзләп килде. Һәм шул китүдән ул кабат китмәде. Матур гына семья корып җибәрделәр. Габделхак сугыш вакытында башта колхозда счет төймәләре тартты (сул кулы белән шунда язарга өйрәнде). Аннары аны ВЛКСМ райкомының беренче секретаре итеп сайладылар. Район үзәге якын булгач, авылга кайтып-китебрәк йөрде. Соңга калганда кабинетында гына йоклады. Саимә килгәндә ул КПСС райкомында инструктор иде инде. Саимәнең урта белеме бар иде. Ул авылда башлангыч классларны укыта башлады. Шул ук елны Алабуга укытучылар институтына читтән торып укырга керде. Бер кыз, бер малай үстерделәр. Олысы хәзер Түбән Кама шәһәрендә эшли. Химия-технология институтын тәмамлады. Ә төпчекләре Розалия әнисе эзеннән китте. Казан педагогия институтында укый.

1958 елда МТС зонасы буенча райком секретаре итеп сайладылар. Ләкин ул эш озын гомерле булып чыкмадылар. Ул штат бетте. Район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары иттеләр. Маклаков беренче секретарь булып килгән елны жирле сайлауларда район Советы башкарма комитеты председателе итеп күтәрделәр. Менә ун елдан артык инде аның муеныннан шул камытның тәшкәне юк. Беренче секретарь әйбәт кеше булганда эшләве рәхәт. Маклаков белән эшләү күп нәрсәгә өйрәтте аны. Гади дә, таләпчән дә, иҗади да кеше иде Маклаков. Үз эшенә аның кебек фанатикларча бирелгән кешене хәтерләми Вәрәшов. Язгы чәчүгә чыгу белән басуда булыр һәм чәчү бетмичә кабинетына кайтып кермәс иде. Оештыру бүлеге мөдире белән генә һәр вакыт элемтәдә торды. Кешеләргә ышана иде ул. Кем дә булса шул ышанычны акламаса, кара көя, кайгыга сабыша һәм үзен бәхетсез итеп сизә иде.

«Кешеләрне белмибез, иң зур бәла — ялгышлык бу»,— дия торган иде. Бюродамы, берәр активтамы кемгә карата булса да катырак, артыграк бәрелсә,— ә дөнья булгач анысы да була аның,— арысланнымыдай горур башын иеп, түбәнчелек белән гафу үтенә иде. Үз ялгышын аннан да авыр кичерүче кеше бар микән?

Маклаков килгән елгы беренче урып-җыю вакыты иде. Бюро Вәрәшовны «Корыч кул» колхозына вәкил итеп беркетте. Председатель булып элекке мәктәп директоры, үтә кызрач, хәзер дөрләп кабынырга торган Сөләйманов дигән кеше эшләгән чак. Хәзер укытуга күчте инде ул, картайды. Элек колхоз председателе булып эшләгән берәү иртә таң белән Маклаковка шалтыраткан.

— Михаил Федорович, «Корыч кул» колхозында ипи яшерәләр. Иске таш мәчетне тутыралар инде. Аннары Баланлы авылы ригасына салып, өстен салам белән капладылар,— дигән. Моны ишетү белән райстат, райпланнан исәп-хисап работникларын төяп, килеп житмәсенме? Машинадан сикереп төшүе булды, идарә капка төбендә менә-менә басуларга китәбез дип торган Сөләйманов белән аның өстенә ыжгырып килә башлады. Исәнме-саумы юк.

— Нәрсә? Бюро члены житәкчелегендә ипи яшереп ятасызмы? Үтмәс бу номер! Комиссия алып килдем. Яшерә алмассыз, бер граммын да,— диде дә артында басып торган комиссия членнарына кычкырды.— Барыгыз! Башта документация эшен энә күзеннән үткәрегез. Аннан барлык ашлыкны үлчәргә!

Комиссия членнары идарәгә кереп киттеләр. Ул арада идарә тирәсенә кешеләр дә җыела башлады. Маклаков чыгырыннан чыккан иде, ул колхоз председателенә дәшергә дә ирек бирмәде, тетмәсен тетте. Сөләйманов та үз сүзле, кире кеше. Ул башын иеп тыңлап торды да кинәт кенә кырт борылды, ачу белән кулын селтәде дә кайтып китте. Маклаковның «кая китәсең син?» дип кычкыруына борылып та карамады.

Комиссия ике көн ятты. Сөләйманов ике көн эшкә чыкмады. Урып-җыю барышын Вәрәшовның үзенә кулга алырга туры килде. Комиссия «яшергән» артык ипи тапмады. Киресенчә, чүплелеккә чыгарылган 25 центнер отход житмәде. Аны дуңгыз фермасы мөдире боерыксыз килеш кенә алып киткән булып чыкты. Комиссия районга кайтып китте. Шул көнне кич Маклаков колхозга килде. Янында өлкә комитеты вәкиле дә бар иде. Вәрәшовны ул комбайнчылар яныннан эзләп тапты. Көрәктәй кулын сузып исәнләшү белән:

— Габделхак Шакирович, гафу итегез мине, чын күңелдән сорыйм, күңелеңдә тузан кадәре дә кер сакламый гафу ит, ялгыш информировать иткәннәр мине,— диде. Идарәгә кайттылар. Сөләймановны алырга жибәрделәр. Килмәде. Маклаков башын кашыды, йөзләрен чытты.

— Тзем барам, нелгән башны кылыч кисми,— диң, җаяу генә урам буйлап председатель үзе китте. Байтак торды. Әмма Сөләймановны алып килде. Анда ни сөйләшкәннәрдер, билгесез. Ләкин идарәдәге сөйләшү-аңлашуның нинди дулкыннарда баруын билгеләү авыр булды. Сөләйманов кара көйгән. Маклаковның күзләре кысылган, маңгае җыерылган, тирән буразналар бер-берсе өстенә менгән иде. Сөләйманов кабинетка керү белән ишекне әйбәтләп япты, сейфны ачты, аннан печатьне алды да шап итеп өстәлгә куйды һәм: — Менә, иптәш Маклаков, алыгыз, сезгә дә хилаф булмас ул председатель булып эшләү, минем кебек контр, ышанычсыз кешене председатель итеп тотмагыз,— диде, өстәл артындагы председатель урындыгына төртеп күрсәтеп. Маклаков үзен кулга алып өлгергән иде инде.

— Мин сезгә контр димәдем, иптәш Сөләйманов.— Ул председательнең иненә авыр кулларын салды һәм: — Менә иптәшләр алдында, кирәк икән, отчет-сайлау җыелышында килеп колхозчылар алдында гафу үтенәм. Секретарь дигәч тә әллә син мине ялгышмый дисеңме? — диде.

— Сезгә ялгышырга ярамый, иптәш Маклаков, сезнең ялгышулар партиягә дә, хөкүмәткә дә, безгә дә бик кыйбатка төшә.

Бу сүзләрне Вәрәшов беренче тапкыр Сөләйманов авызыннан ишетте. Соңыннан ул Маклаковның яраткан гыйбарәсенә әйләнде. Вәрәшов тә ул сүзләрне, аеруча кайбер мәсьәләләрне ялгыз гына хәл итәргә туры килгәндә еш искә ала.

Сөләйманов өлкә комитеты вәкиленең уңайга сыпыруына да җайга килмәде. Маклаков өстәлдәге печатьне бер алды, бер куйды, нидер уйлады.

— Иптәш Вәрәшов,— диде ул, аннары йомшак кына итеп,— ия табарбыз, алыгыз печатьне. Минем дуамаллык белән әйбәт председательне югалту гына авыр.— Ул тар кабинет буйлап ишекле-түрле йөри башлады. Сөләйманов тәрәзә буендагы урындыкка утырган да урамны күзәтә. Анда да ике мин көрәшкәне сизелә, бер агара, бер күгәрә, аскы иренен тешләп-тешләп ала. Менә Маклаков идән уртасында туктады һәм корсагына каккалап, Сөләймановка дәште:

— Инде эш буенча алай җенең чыккан икән, кеше буларак әзрәк ихтирам ит әле син, Сөләйманов. Без бит фронтовиклар! Ишетәсеңме, эчтә бүре концерты. Иртәдән бирле тамак ялгамаган мин бүген...

Сөләйманов бухгалтерлар ягына чыгып китте. Анда кем беләндер сөйләште дә:

— Әйдәгез, безгә генә кайтыйк,— диде. Юл буе бер сүз дәшмәде Сөләйманов. Кайткач хатынын чакырып алып, аның колагына нидер пышылдады. Тегесе, ярармы, бар дигәнне аңлатыпмы, ияк какты.

Табынга утырыштылар. Йомырка басып кискән токмачлы тавык шулпасы тәлинкәләр белән өстәлгә килгәч, Михаил Федорович Сөләймановка күзен кысты.

— Мондый нигъмәтне коры килеш ашау гөнаһ,— диде ул.

Сөләйманов урыныннан кузгалды. Гади генә буфеттан бер шешә алды. Хатыны рюмкалар китергән иде, Сөләйманов аларны читкәрәк этәрде:

— Стаканнарны китер әле, мәҗлестә утырыр чак түгел,— диде. Стаканнарны тутырып салды да аны югары күтәрде һәм беркем белән чәкештермичә эчеп тә җибәрде. Маклаков та кешегә карап тормады. Ашап-эчкәч, Маклаков Сөләймановны өй түрендәге алма бакчасына алып кереп китте. Шактый сөйләштеләр. Алар аннан көлешә-көлешә чыктылар. Сөләймановның кәефе килгән иде.

— Иптәш Вәрәшов, үзегезнең эшләргә исәбегез булмаса, бирегез печатьны,— диде ул бакча коймасы буендагы бүрәнә өстендә тәмәке көйрәткән Вәрәшовка. Маклаков белән ул дусларча аерылышты. Сө-

нынан, Маклаков киткәннән соң, Сөләйманов болаи дип сөйләгән иде: бакчага кереп утыргач та Маклаков йөрәген уып, йөрәк яна, су сибәргә кирәк, теге күгәрчен сөтең минем гәүдәгә ни ул, кая, тагын рәтен бармы? дигән. Сөләйманов ачык тәрәзәдән хатынына дәшкән. Ул бер ярты белән стакан сузган. Беседка кырыендагы түтәлдән суган өзеп алып, алар тагын берәр стакан җибәргәннәр. Аннан Маклаков болай дигән: «Син, Сөләйманов, мине гафу ит. Итмәсәң, өегездән, бакчагыздан чыкмыйм. Үз ялгышымны төзәтми минем күземә йокы керми, кулым эшкә бармый. Үтермә мине! Үзең беләсең, хәзер урып-җыю вакыты. Бу бишкөнлектә ашлык тапшыруны үтәргә кирәк... Ә әләкченең җиде кат тиресен туныйм мин аның». Аннары үзенең нинди авырлык белән үсүен, Ерак Көнчыгышта моряк булып хезмәт итүләрен, беренче секретарьның эш серләрен инәсеннән җебенә кадәр сөйләгән.

— Йөрәген ачты да салды, беренче секретарьдан битәр кеше булачак кемлеген белгәч, эредем дә төштем, иптәш Вәрәшов,— дип сөйләде Сөләйманов. Әнә шундый кеше иде Маклаков. Хәзер ул Үзәк Комитетның авыл хуҗалыгы бүлегендә инструктор. Әнә шул районга комиссия житәкчесе булып килә икән. Вәрәшев жалобаның кем тарафыннан язылганын ачык сиземли.

Бүген иртән ул Халикъ Кәрамович белән киңәшеп, «Беренче Май»га барып кайтырга булды. Вильданов белән дә сөйләшәсе бар. Ул партия съездына делегат итеп сайланган иде. Китәр көннәре дә якынлаша. Мәскәү хәтле Мәскәүгә баргач, район йомышларын да кушмый булмый. Тиешле кешеләрне эләктерә белә ул Рамай Ибраһимович. «Беренче Май» колхозына барып җиткәнче әнә шундый уйлар биләде аның күңелен. Минзәләгә су төшкән иде инде. Су тимер күпер өстенә күтәрелергә тора. Нефтьчеләр салып биргән иде бу күперне колхозга.

Вильдановның кайдалыгын идарәдә анык кына белүче булмады. Инде нишләргә, әллә фермалардан бер уратыргамы дип торганда, бот төбенә чаклы резин итек кигән зоотехникның тыкрыктан ашыга-ашыга идарәгә таба килгәне күренде. Вәрәшов аның белән күреште дә:

— Кая ашыгасың, ут капкандай? — диде.

— Отъемчный дуңгызларда рожа күренә, ветлечебницага хәбәр итәм әле. Үзем сизенгәннәрен аертып куйдым да менә,— диде Һәнүз, маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирләрен сөртеп.

— Аерып куеп дөрес эшләгәнсез... Председательнең кайдалыгын белмисезме?

— Шыгайдадыр ул... Теге культуралы көтүлегендәге ясалма яңгыр яудыргычларын боз җимерә башлаган диме. Шуны ишеткәч, иртән идарәдән чыгып йөгергән иде, шуннан бирле күренгәне юк.

— М-м да!.. Иптәш Гумеров, теге, ана терлекләрдән интенсив файдалану буенча тәҗрибәнне сорыйлар бит, «Степные просторы» журналыннан. 15 нче майларда алар кулында булырга тиеш. Үзенне күргәч искә төште әле. Кичә Халикъ Кәрамовичка шалтыраттылар, мин нәкъ шул чакта аның янында идем.

— Ул бит әле беренче адымнар. Аның турында авыз тутырып сөйләргә иртә. Дүрт-биш елдан ул кандидатлык, докторлык диссертациясе өчен менә дигән материал булачак, анда шигем юк. Шулай да аларга кем тиште икән моны, Габделхак Шакирович?

— Каш җыермасаң, мин. Ул журналда минем белән партия мәктәбендә укыган бер иптәш эшли. Быел аның белән Казанда очрашырга туры килде. Сүз иярә сүз китте дә, шунда синең исемеңне дә төрләндереп алдым.

Һәнүз бераз дәшми торды.

— Иртәрәк булмас микән, Габделхак Шакирович? Сыер җәнлеге белән сарыктан шикләнмим. Дуңгызлар белән эш башкачарак тора. Теоретик яктан дөрес, шигем юк. Әмма практик тормышка ашыру

авыр. Икешәр мең дуңгыз асраган колхозда аны эшләү өчен, беләсезме, күпме торак һәм механизация, азык кирәк булачак? Дуңгыз бит ул геометрик прогрессия буенча үрчи...

— Ә сез шул шик-шөбһәләрегезне дә кертеп языгыз.

— Уйланырмын әле, Габделхак Шакирович. Ярый, мин шалтыратыйм әле.

— Барыгыз! Тик онытмагыз, 15 нче майга!

Һанүз йөгерә-йөгерә идарәгә кереп китте. «Башлы егет!» — Вәрәшов, машинасына утыргач, шулай дип уйлады. Стартерга басуга, моторга җан керде. Ул Шыгай бригадасына китте. Чаллы юлы трактына чыккач, тизлекне киметте. Язгы сулар юган урыннарны хәтерләп барды. Беренче мөмкинлек белән юл төзү участогын бу юлларны ремонтларга чыгарырга кирәк булыр. Чәчүлек орлыкның шактыен алыштырасы бар. Күбесен Чаллыдан бирделәр. Әлмәттән урап йөрсәң, ничә йөз чакрымга әйләнгеч.

Вильданов чыннан да Шыгайда иде. Яр кырыендагы күчмә яңгыр яудыргыч агрегатын сүткәннәр, аны зур ара калдырып ике тимер чанага төягәннәр дә ике трактор белән тауга таба сөйрәтәләр иде. Рамай Ибраһимович үзе дә муеннан пычракка чумган иде ул. Вәрәшов машинасының күпер янына килеп туктавын күрмәде. Кемдер төртеп күрсәткәч кенә, саз ярып, юлга таба атлады. Дамбаны мышный-мышный менде. Вәрәшов аңа кулын сузды.

— Гаеп итмәгез инде, дуңгыз урынына ауналды,— дип, терсәген күтәрде Рамай һәм: — Килеп җитмәсәм, китә иде яңгыр яудыргыч. Әнә су ничек арта, бүген кичкә боз күтәрелә. Сабак бу. Көздән үк яр буйларындагысын сүттереп куярга кирәк икән,— диде ул һәм юлның икенче ягындагы чокырда җыелып торган суга таба тырык-тырык төшеп китте. Кар суы белән кулын, битләрен юды, резин итекләреннән балчыкны кырып ташлады, шунда тыгып чайкады. Бушлатының пычрак тиеп, инде кипкән урыннарын уыштыргалады.

— Әзрәк адәм рәте керде бугай, юкса, шүрәле итеп күрсәтерлек хәлгә килгән иде кеше,— дип, елмая-елмая күтәрелде ул таш юл өстенә.— Габделхак Шакирович, менә шушыны эшләтсәм, шундый җирләрнең нинди хәзинә бирә алуын исбатласам, валлаһи, үкенмичә, отставкага китәм. Бигрәк тә Шамил Сабировичка үч итеп эшлим мин моны. Җитлекми туган специализация генә ул, акчаңны суга салганчы, безгә генә бир, ди. Быел ук исбатлыйм мин аның өстенлеген! Иңе ике, озынлыгы ун метр ике участок билгеләдек. Өч уңышны да икәүләшеп чабып карыйбыз, чалгы белән, ялап чабып. Гектардан 80 центнер да печән алмасам, исемем Рамай булмасын дип бәхәсләштем. Менә бит эш кая таба бара!

Вильданов тургайлар сайравы белән күмелгән басу өсләрен яңгыратып көлеп җибәрде. Кинәт аның йөзе житдиләнде.

— Рәшат Галиевичның хәле ничек? — дип сорады ул.

— Бүген дә белешкән идем. Һаман рәтләп аңына килә алмый. Паралич суккан диләр...

— Үзен бетерде кеше, йөкне турыга тартмыйча бетерде.

Рәшат Галиевичны искә төшерү икесе өчен дә авыр, уңайсыз булып китте. Алар бер мизгел тракторларның саз ярып, ташбака кебек, үргә таба үрмәләвен карап тордылар.

— Рамай Ибраһимович, съездга китәр көннәрең якынлаша. 25ләреннән дә соңга калмыйча чыгып китәргә туры киләчәк. Аннан кайткач та бергә эшләсе кеше булгач, эреләнмәссең әле, кайбер йомышларны үтәрсең,— диде Вәрәшов.

— Эрелек бар инде ул бездә, әйттегез, иске авызга яңа аш, мине беренче күргән кеше кебек!

— Шулай да кем белгән, монарчы съезд делегаты булганың юк иде бит әле.
— Исемә төшсә, чәчләр үрә тора. Минем кебек кешеләрне дә сайлыйлар икән анда. Рәхмәт инде, олыладылар.
— Мәскәү хәтле Мәскәүгә баргач, минем дә йомышларны үтәргә тырышсаң иде. Нефть һәм газ министры безнең депутат бит. Безнең якта эшләгән кеше.
— Беләм, «Елховнефть»тә эшләде ул, ферма салганда торба бирде ул безгә.
— Барысын да белгәнгә сезгә мөрәҗәгать итәм дә. Министрны туры китерергә тырыш. Съезд барган көннәрдә кабул итүен сора. Аннан мондый үтенеч әйт: үзең беләсең, нефтьчеләр эксплуатация срогы чыккан машиналарны я списать итәләр, я башка учреждениеләргә бирәләр. Үзебезнең территориядәге шундый машиналарны мәктәпләр өчен дип сора. Колхоз, совхозга бирмиләр алар. Мәктәпләр өчен соравы җиңелрәк. Һич югында, һәр урта мәктәп өчен бирегез, дисәгез, кулай булыр. Сигез бит алар бездә хәзер.
— Ярар, Габделхак Шакирович. Тик, рөхсәтең алсам, берсен безнең мәктәпкә, вәгъдә-иманмы?
— Сезнең бар бит инде.
— Бар янына бар сыя ул...
— Анысын карарбыз, рөхсәтен генә ал.
— Шәкүр карт кадры ла мин. Сорый белербез.
Алар икесе дә тәмәке көйрәттеләр.
— Үзәк Комитет комиссиясе килә,— диде Вәрәшов, папиросының көлен кага-кага.— Беләсеңме, кем җитәкчелегендә?
— Кем?
— Маклаков җитәкчелегендә.
— Ул булганда куркырлык урын юк. Районны да, кешеләрне дә белә. Төрле якка ага башлаган инешләр бер якка борылырлар, ичмасам.
Вәрәшов дәшмәде, папиросын җиргә ташлап, аягы белән басты.
— Гумеров ниндирәк кеше, масштабы, фикер йөртүе белән? — дип сорады ул аннары.
— Хурлый алмыйм. Эш өчен туган егет. Бергә эшләсәк, минем урынга менә дигән председатель чыгачак. Баш дигәне бик йомры аның.
— Ә теге яклары ничек соң?
— Күз тимәсен димме? Казанга барып кайтканнан бирле коеп куйгандай йөри.
Вәрәшов кабина ишеген ачты, саубуллашырга дип кулын сузды. Рамай кул бирмәде:
— Юлдаш машина белән килдем,— диде дә машинага кереп утырды.
Ике чакрымга сузылган Шыгай тавын менгәч, Рамай Вәрәшовка дәште:
— Габделхак Шакирович, мин быел бер «җинаять» кылырга йөрим әле, гел шуның белән баш ватам, сез ничек карарсыз икән?
Вәрәшов карап алды да көлемсерәп:
— Әйтеп кара, ничәнче статьяга туры килер икән? — диде.
— Борчакны яртылаш киметәм мин быел.
— Сәбәп?
— Сәбәпме? Хәзер аның бәясе төште. Бу булдымы — бер. Аннары, бодай уңышы бездә тотрыклы да, югары да, бусысы — ике.
— Ә уҗымны кая чәчәрсең? Хәзер бит аның мәйданын арттырабыз.
— Исәпләдем, анысын да исәпләдем. Сенаж өчен чәчелгән борчак җире, берьеллык үлән, яшел масса өчен үстерелгән кукуруз җирләре уҗым культуралары өчен тулысынча җитә. Уҗымны әнә шушы мәйдан-

нар пропорциясендә чәчүне планлаштырырга кирәк. Ә бөртек өче борчакны хәзергәчә күп чәчү файдалы түгел. Үзегез беләсез, уры жыюы ифрат авыр бит аны. Явым булдымы — жиргә сылана. Ме бәла белән теземнәргә салгач та әле ул синеке түгел. Янгыр яуса — үр корыга китсә — ярыла. Бер кат теземнәргә сал, аннан шул комбайнн жыеп суктыруга көйлә. Мәшәкать өстенә мәшәкать.

Вәрәшов газны кимәтә төште, кашларын жыерды һәм:

— Ирек куйсалар, Вильданов, син борчак игүдән гел кул селтәрг жыенган кеше кебек сөйлисең,— диде.

— Юк, Габделхак Шакирович, борчакның кирәклеген аңлыйм Башка өлкәләр белән бертигез, ил үзенең ихтыяжларын канәгатьләнде рү өчен бездән таләп иткән дәрәҗәдә игү кирәклеген мин аңлыйм. Бу — закон. Әмма соңгы елларда без бу культура белән артык мавы гып киттек. Сәбәбе — ул кыйммәт һәм колхоз экономикасын ныгыту га ярдәм итә иде. Ә хәзер центнеры — 8 сум. Сортлыга күпме ген тапшыра аласың. Ни булса булыр, мин быел бөртеккә сез житкергә борчакның яртысын гына чәчәм.

— Мин моңа ризалык бирә алмыйм.

— Шунын өчен дә жинаятькә барам дим мин.

— Ә син, Вильданов, жинаятькә барма, быелга планлаштырылган ны шул килеш чәч. Үзең уйлаганча бөртеккә аерып куй. Калганын сенажга, яшел азыкка файдалан.

— Анысына фатыйхамы?

— Ике куллап.

— Алай эшләргә була... Ләкин, Габделхак Шакирович, сездән яшермим. Бу вариант турында да нык баш ваттым мин. Болай эшләгәндә, сенаж өчен чәчеләчәк борчак мәйданын почти бетерергә, аның урынына бодай чәчәргә кирәк.

— Анысын кара, ләкин чәчү планнарың бюрода каралган чәчү әйләнешеннән үзгәрмәсен, экспериментың акланмаса, бөтен гаеп үзенә төшәсен онытма. Персональ жаваплылык, үзең беләсең.

— Анысын беләм лә... Менә шул, минем уйлар, планнарның реальлегенә сез бераз ышанасызмы? Менәтерә, кодагый, кебегрәк нәрсә килеп чыкмасмы?

— Нигезләрең нык, фикерең дә төпле синең, Рамай Ибраһимович. Барып житә бу миңа. Дәүләт интересларын күздә тотып колхоз экономикасын ныгыту — социалистик авыл хужалыгының нигезе. Син әнә шуңа омтыласың. Эшлә үзеңчә. Һәр культура буенча житкерелгән заданиенең үтәлешен тәэмин ит. Бәйләнүче булмас. Тик бу турыда хәзергә бер кешегә дә ләм-мим. Хәтта Рәшат Галиевичкә. Ул мондый үзгәртүләрне кабул итә алмый, барыбер уртак тел таба алмассыз.

— Мин дә шулайрак сизенеп сезнең белән киңәшәм дә инде.

— Рамай Ибраһимович!

— Тыңлыйм...

— Син төш күрәсеңме?

— Менәтерә, иске авызга яңа аш...

— Төшендә ни күрәсең икән син?

— Женләнеп бетәсең инде.

— Во-во! Төшеңдә дә һаман шул колхозың белән женләнә, акча каеру буенча ачышлар ясап бастырыласыңдыр син.

— Анысы да булгалый... Нигә? Акча — ай, зур көч әле бездә. Ансыз адым да атлап булмый. Ә аны таба белергә кирәк, таба белергә! — Рамай кинәт көлеп куйды.— Тавык төшенә тары керә дисез инде сез. Кайчак энже бөртеге дә керә икән. Әле тәнәгән яшь чакларны күреп саташтым... Картаела, Габделхак Шакирович, картаела, болай йөргәчтә, бер көн калдырмый ярты гасырдан артык яшәгән абзаң бит инде бу чаларган баш.

быз, гомер үтә...

Юл буе сөйләшеп кайттылар.

Вәрәшов аны өенә хәтле китерде. Рамай күпме кыстаса да, ул кереп тормады, ашыгып китеп барды.

* * *

Дамир гаражга көндәгечә иртә килде. Кабызып чыгыйм гына дигән иде, мотор төчкергәләп алды да сүнде. Бензин суыртып, тагын стартерга басты, яңадан шул хәл кабатланды. Моторның томавын куганчы шактый вакыт үтте. Ул идарә янына килеп туктаганда Рамай Ибраһимович юк иде инде. Баш бухгалтер банкка барып кайтыйк әле, дигән иде, моторның көе юк әле, дип үзенчә сәбәп тапты. Кәефе юк иде аның. Кичәге хат, Сәвиянең хаты аның болай да чуалчык уйларын бөтенләй бутап бетерде. Рамай Ибраһимович белән егетләрчә сөйләшүдән соң ул Сәвиягә эшкә Чаллыга билгеләүләрен сорарга киңәш биреп хат язган иде. Әнә шуңа мең дә бер сорау һәм шикләнүләр белән тулы җавап килде.

«Аңламыйм, Дамир бәгърем. Без бит инде килешкән идек, әтигә дә мин үзебезнең авылга кайтам дип вәгъдә бирдем. Хәзер ник алай дип язасың? Үзең дә Чаллыга китәм дип язасың. Аңламыйм, берни аңламыйм. Син бит ул турыда бөтенләй уйламый идең, нәрсә булды сиңа, Дамир? Әллә арага күләгәләр иңә башладымы? Дөресен яз! Бер кыз да егетләргә көчләп тагыла алмый. Алар моңа көчсез, ирекле түгел. Дамир! Җүләркәем, акылсыз башым, акылыңа кил! Мин бит синең күзләреңә тутырып карау белән ни уйлавыңны беләм. Озакламый язгы, бер атналык каникул. Килеп ал, яме. Шунда шомырт күзләреңә карап торырмын да бу хатны язуга этәргән «сәбәп»ләреңне чегән хатыны кебек сөйләп бирермен. Нидер яшерәсең син миннән. Барыбер күзләреңнән укырмын мин аны. Алырга кил, яме! Үбеп, үбеп — Сәвияң».

«Сәвияң, Сәвияң...» Җиде төн урталарында уянып киткәндә дә, таң белән гаражга юл тотканда да тел очында әнә шул сүзләр тирбәлде. Ул «Волга»ны гаражга кертеп бикләде дә өйләренә кайтып китте. Көздән мунча бурый башлаган иде. Ике ниргәсен салган килеш калды. Хәзер ул да, бүрәнәләр дә җир астыннан чыкты. Абзар артларында гына, салам, тирес каплаган урыннарда гына кар өелеп тора. Шул мунчаны бурарга булды бүген Дамир. Бүрәнәләр пешеләнгән, буравы авыр түгел. Чамалап чапмасаң, балта сызыгыңны-мызыгыңны белми, кереп чума. Төшлектә сыерларын савып кайткач, энисе дә аның тирәсендә чуалды. Каезлаган каерыларны, йомычкаларны җыйды, кояшка каршы бакча коймасы буена иренмичә, утын өйгән кебек, шакмаклап өйде. Нык эшләде бу көнне Дамир. Инде көн кичкә авышып бара. Кояш инеш буендагы карт өянкеләр арасыннан кызарып күренә. Өянке очларындагы кош оялары өстендә каргалар каргылдый. Келәт кыегындагы сыерчык оясына куелган кунычада парлап сыерчыклар сызгыра. Дамир, маңгай тирен сөртеп, балтасын бүрәнәгә чапты да баш бирмәгән сызгысын эзли башлады. Шул чак капка ягыннан бер тавыш килде:

— Эшләрең уң булсын!

Дамир сискәнеп китте. Койма өстеннән башын сузып Рамай Ибраһимович карап тора.

— Сезне монда бирсен! — диде Дамир, нигәдер каушый төшеп. Берәр җиргә барасы булгандыр да мине эзли торгандыр, нигә кеше генә җибәрмәде икән, дип уйлады. Рамай Ибраһимович ишегалдына керде, кулын сузды.

— Барамы? Ә, ярыйсы җибәргәнсең, ике ниргә салгансың түгелме соң?

— Бер ягына саласы бар әле.

Рамай бүрәнәгә чабылган балтаны алды, йөзенә бармакларын тидереп карады да бушлатын салып куйды һәм:

— Тагын балтаң бармы? — дип сорады.

— Бар.

— Булса алып чык. Бусысы җилле күренә. Уч төпләре дә кычытып тора. Булышыйм әле бераз. Их, яратам да балта эшен. Үземнең мунчаны да ял вакытында беркая бармый җиткердем мин.

Вильданов уч төбенә төкерде дә билгеләп куелган почмакны киерелеп-киерелеп чаба башлады. Дамир, балта алып чыгып, икенче почмакны чабарга тотынды. Кояш интәнче алар ике ниргә салдылар. Соңгы бүрәнәне шыпылдатып утырткач, Рамай Ибраһимович бура тирәли әйләнеп чыкты да:

— Керәшен дәдәйләрдән ким түгел, бура бурап кына йөрисе икән сиңа, Дамир,— диде һәм юынырга комган алып чыгарга кушты. Юынгач, бушлатын киде дә, бура өстенә менеп, аякларын салындырып утырды. Папирос кабызды. Аннары Дамирга дәште:

— Кил әле, монда утыр әле,— диде. Дамир аның кырыенда өелеп торган бүрәнәләр өстенә утырды һәм сораулы күзләрен Рамай Ибраһимовичка төбәде.

— Озакламый съездга китәм... Анда киткәнче синең белән сөйләшмичә булмый.— Ул папиросын тирән итеп суырды.— Изге җиргә барганда күңелем саф, пакь булсын...

Дамир сагаеп куйды. «Тагын Сәвия турындадыр»,— дип уйлады ул һәм ялгышмады.

— Сәвия белән арагыз ничек хәзер? — дип сорады Рамай Ибраһимович.

Дамир җавап бирмәде, чалбарының арт кесәсеннән бер кәгазь алып, аны Рамай Ибраһимовичка сузды, үзе башын читкә борды. Рамай Ибраһимович моны көтмәгән иде. Кайсы атага үз кызының егетләргә язган хатын укырга туры килә. Җитмәсә, егете кулыннан алып. Кай җире беләндер, әллә ургып торган хисләре белән Сәкинәнең үзенә язган хатларын хәтерләтте ул. Күңел кыллары әллә нишләп китте. «Газизләрем, әллә әйтмәскәме соң?» — дип тә уйлады. Ләкин аек акыл өскә чыкты. Ул хатны Дамирга бирде, башындагы бүреген салып тез башына каплады, папирос төпчеген сүндереп читкә, йомычкалар чәчрәмәгәнрәк тирәгә ыргытты:

— Дамир, минем сине Чаллыга китәргә димләвемнең, Сәвиягә әйләнергә каршы килүемнең сәбәбен белмисең бит син,— дип башлады ул сүзен, авыр гына көрсенеп.— Икегез дә газиз бит сез миңа, икегез дә!..— Ул бер мизгел уйга калды, Дамирга озак кына карап торды. Аннары калтыранган тавыш белән болай диде: «Дамир!.. Улым!.. Теләсә ни диң, йөземә төкер... Телисең икән, мә, чап! — Ул бүрәнәгә очы белән кадалган балтаны алып Дамирга сузды.— Мин бит синең атаң...

Дамирны корт чаккандай булды, юк, алай гына түгел! Аның бөтен тәне уттай кызыша, гәүдәсе көчле электрга эләккәндәй дерелди башлады. Сикереп торганын да сизмәде. Кинәт кенә агу йоткан бүредәй күзләре аларды. Ул Рамай Ибраһимович алдында йөренергә тотынды, аңа бер якын килде, бер читкә китте. Килеп-килеп бушлат якасын умырып тотты, тагын җибәрде, тагын читкә йөгерде. Рамай, балтаны сузган килеш, башын иеп тын калды. Менә аның кулыннан балтасы шуып төште. Ялтырап яткан балта йөзенә терекөмеш кебек яшь тамчылары коелды. Дамир иелеп балтаны алды һәм ачу белән келәт ишеге төбенә томырды. Ул ишеккә барып тиде. Рамай сискәнеп китте. Шул чак капка

ачылды һәм Дамирның әнисе Мәрьям кайтып керде. Чал чәчле башын иеп утырган Рамайны, ишегалдында бәйдән ычкынган үгездәй котырып йөргән Дамирны күргәч, аның йөрәге жу итеп китте һәм ул куркып:

— Ни булды? — дип сорады. Рамай иелгән башын күтәрмәде. Ишегалдында Дамирның ачулы тавышы яңгырады:

— Бар, бар, өйгә кер, уйнашчы!..

Мәрьям кәфендәй агарды. Беләгенә элгән чиләге шалтырап җиргә төште. Үзе лып итеп болдыр баскычына утырды, башындагы яулыгын йөзенә тартып төшерде дә кычкырып елап җибәрде.

Дамирның бу сүзе Рамайның йөрәгенә утлы хәнҗәр белән кадагандай булды. Ул үз-үзен белештермәде, бура өстеннән сикереп төште дә Дамирны, якасыннан алып, уңлы-суллы чабып җибәрде.

— Не смей! Синең әниең кебек изге кешеләрне шәм яндырып та табалмассың... Аның хәлен анларлык бит инде син... Ничек телен күтәрелде? Андый уең булса, кабат шул сүз авызыңнан чыкса, буып үтерәм!.. Сиңа җан бирүче мин булсам, җаныңны да үзем алам! Ишеттеңме?

Рамай көчле иде. Дамирның тыны куырыла башлады, күзләре иләсләнде.

— Җиппәр... үтерәсең бит, Рамай абый,— диде ул, көчкә гыжгылдап. Рамай кулын Дамир муеныннан алды. Икесе дә, авыр йөк тарткан атлар кебек мышлап, мунча бурасына барып сөялделәр.

— Мәрьям, син, чыннан да, бар, өйгә кер. Дамир сабый түгел, аңлашырбыз,— дип, Рамай ишек төбендә елап утырган Мәрьямне өйгә кертеп җибәрде. Рамай бер-бер артлы ике папирос тартты. Дамир күн итек башы белән аяк астындагы йомычкаларны читкәрәк җибәргәндәй эткәләп тора.

— Менә шул, иске авызга яңа сүз була бу, Дамир улым. Моңарчы бу хәлне авылда берәү дә белмәде. Һәм белмәсен. Минем дә семьям бар, синең дә әниең бар. Моңарчы яманаты чыкмаган хатынны, ил өстенә сүз чыгарып, яман атын тарату килешми. Ә әниең әйбәт синең.

— Әйбәт булгач, ник алмадың?

— Ул аны теләмәде... Аның беренче мәхәббәте сугыш кырында башын салды. Кияүгә чыкмады. Оныта алмады. Хәзер дә күңел түрендә ул аның. Ул аны һаман көтә.

— Кем иде соң?

— Түбән оч Вәлишә абый малае — Хәниф иде ул.

Дамир башын түбән иде. Аның күз алдына стенадагы рәсем килде. Агай-эне идек без Вәлишә абыйларга, шуның малае бу, дип, әнисе аның карточкасын Әлмәттә зурайтып кайтарган иде.

Чибәр егет. Дамир җиңе белән күзен сөртеп алды.

— Хәзер күнегелде. Сабый чакларда әти дип эндәшергә ничек тилмергәннәрне, малайлар алдында ничек борлыкканнарны белсәң, Рамай абый! Ә ул тирәмдә йөргән икән. Ник эләкләр сиздермәдең, кеше юк чакларда гына булса да әтием дип дәшәр идем... Ә хәзер, хәзер... тел әйләнми. Әти дип әйтә алмыйм мин сиңа. Мәңге, Рамай абый, әйбәт председатель генә булып каласың инде.

— Анысын йөрәгең ничек куша, шулай әйтерсең. Тик син миңа үз улым булдың, шулай булып каласың. Минем дә сиңа кычкырып улым дип дәшәсе килгән чакларым күпме булды. Элегрәк, әле син ыштансыз йөргәндә, урамда эләктереп, тупылдатып, улым дия-дия сөеп китә торган идем. Үсә төшкәч, аралар ерагайды. Һәм менә хәзер бер-беребезгә ике дошман кебек кара-каршы басып торабыз.

— Юк, дошман түгел син миңа, Рамай абый.

— Ә миңа күптән!

Ул Дамирны күкрәгенә кысты.

— Ни алып кайтыйм Мәскәүдән? Беренче бару бит эле минем,— диде.
— Тәтиләр белән күңел юатма, Рамай абый. Кызлар да, сабый да түгел мин. Син миңа җан биреп җанымны, бәхетемне алдың... Болай булгач, китәм мин Чаллыга... Ә Сәвияне җибәрмәгез... Чит җирләрдә, бәлки, онытырмын...
— Ир бул, Дамир. Бу сөйләшүне Сәвиягә тишмә...
— Яулык бәйләгән юк әле.
— Ә әниеңә каты орынма. Олы җанлы, изге мәхәббәтле кеше ул...
— Ярар...
Ата белән ул соңгы тапкыр кул биреп хушлаштылар.

* * *

Рәшат Галиевич аңына килә алмады. Вакыт-вакыт иреннәре нидер әйтергә теләп ачылды. Ләкин сүзе чыкмады, керфекләрен күтәрә алмады. Аны Сания белән Вера Александровна алмашлап сакладылар, янынннан бер минутка да китмәделәр. Хәлен өлкә комитетыннан да белешеп тордылар. Дуслары, танышлары килде.
Бер көнне палатага баһадир гәүдәле, зур башлы берәү керде. Өстенә япкан халаты иң өстендә генә тора. Ул, урындык алып, Рәшат Галиевичның баш очына утырды. Кәгазь битедәй агарган авыруның йөзенә озак кына карап торды, көрәктәй кулларын маңгаена куйды.
— Рәшат Галиевич, Рәшат Галиевич!.. Мондый хәлдә очрашырбыз дип күз алдыма да китермәгән идем. Сине дә бөгәр икән дөнья! — диде ул пышылдап. Аннан соң шактый утырды. Вера Александровнага түбәнчелек белән баш иеп, хушлашып, палата ишегеннән чыкканда Рәшат Галиевичка таба тагын бер кат каерылып карады.
Бу — Маклаков иде. Рәшат Галиевич өстеннән язылган жалобаны тикшерү өчен килде ул Казанга. Өлкә комитетыннан инструкторлар бирергә тиешләр иде. Ә анда кергәч менә нинди хәлгә тап булды. Жалобаны, әгәр аңына килсә, үзенә сиздерми генә тикшерергә булдылар. Ул икенче көнне Рәшат Галиевич эшләгән районга очты.
Ә ике көннән, шул, аңына килә алмаган килеш, Рәшат Галиевичның йөрәге тибүдән туктады. Янында Сания иде. Йоклаган килеш кенә сулыш алуы бетте Рәшат Галиевичның. Сания башта күзләренә ышанмады. Менә-менә күкрәге әкрен генә бер күтәрелә, бер төшә башлар кебек тоелды. Ул аңа да риза иде. Тик Рәшатта җан әсәре сизелмәде. Йомык күз керфекләре аз гына өскә таба күтәрелгәндәй булды. Тоныкпыяладай күзләре сызылып күренде. Алар хәрәкәтләнми иде. Бераздан Рәшатның йөзенә самовар җиздәй сары коела башлады. Юк, уянмады, уянырлык түгел иде Рәшат. Сания артын-артын ишеккә таба чигенде. Һәм коридордан йөгереп чыкты да, йөзен каплап, илереп елап җибәрде.
— Үлде, үлде-е! Шундый кешене дә саклап кала алмады-гы-ы-з!..
Аның тавышы, озын коридорларга таралып, әллә ничә кат кайтаваз булып яңгырады. Бер-бер артлы палата ишекләре ачылды. Дежур врач кабинетыннан ак халатлы кемнәрдер йөгереп килә башлады. Сания кинәт хәлсезләнеп китте һәм коридордагы кара күн тышлы кәнәфигә барып ауды. Кемдер аның башын тотты, кайсыдыр су эчерде. Аннары бөтен гәүдәсе ниндидер эремәгә әләккәндәй эреде, буыннар җебеде. Менә-менә таралып, агып китәр кебек сизде ул үзен. Күзен ул Вера Александровнаның тезләре өстендә ачты. Вера Александровна аның маңгаеннан, чәчләреннән сыйпый, үзенең күзләре кызарган иде. Саниянең сөрмәле керфекләре ачыла башлау белән чын йөрәктән сөенде.

— Сонечка, Сонечка, үзеңне кулга ал... Тынычлан,— дип пышылдады ул. Аның сулышы кайнар иде. Ул Саниягәниндидер дару эчерде. Дежур врач килеп пульсын санады һәм ул да йомшак, ягымлы итеп:

— Үтә, үтә. Тынычланыгыз,— диде. Вера Александровнаның тезенә башын куйган килеш, Сания әле беркавым ятты. Аннары гына торып утырды. Алар сагыш, хәсрәт тулы йөрәк белән Вера Александровналарның квартирына кайтып киттеләр.

Ике көннән Рәшат Галиевичны Арча кырындагы зиратка күмделәр. Баш очына йолдызлы пирамидалы һәйкәл утыртып, тимер рәшәткәләрне коруга, ябалак-ябалак кар ява башлады.

Аны соңгы юлга озатучылар тарала башладылар. Ә кар ява да ява. Әнә кабер өстендәге кызыл балчык өемен ап-ак юрган каплады. Бераздан бу кабер дә башкалардан аерылмас булды. Беркем дә әле монда янә гына җирләү үткәргән димәссең...

Кар һаман ява. Яшелгә буялган чардуган янында һаман ике хатын басып тора...

* * *

Вильданов иртәнге самолет белән очарга булды. Аэропорттан гына колхозга да шалтыратты. Иртәнге тугызларга машина чакыртты. Әле регистрациягә керә башларга бер сәгатьләп вакыт бар. Ул аэропортның халык белән кайнап торган касса залыннан бәрелә-сугыла аэродром ягына чыкты һәм, таң нурлары балкышына сокланып карый-карый, беседкага барып утырды.

Ә күңел хисләр белән тулы. Съездда алган тәэсирләре, күңелдә туган уйлары бер-берсен күмә. Аларны бер эзгә салу өчен әле күп уйланырга кирәк булыр. Шунысына күңел бигрәк сөенә, олы трибунадан партия, хөкүмәт җитәкчеләренең, съезд делегатларының авыл хуҗалыгын тагын да үстерү юллары турында сөйләүләре аның уй-хыяллары белән тәңгәл килә, съезд делегатлары нәкъ менә аның шул фикерләрен тормышка ашыру өчен җыелганнар кебек хис итте ул үзен. Юк, аныкын гына түгел, авылдашларының, хезмәттәшләренең уй-теләкләре, иртәгәге көнгә өметләре якты факель булып балкыды съездда.

Ул блокнотын алып, съезд барышында язып барган язмаларын карый, аларны тәртипкә китерә башлады. Кайту белән колхозчылар, район коммунистлары алдында чыгыш ясамый ничек түзәсен. Радиодан тыңлау, телевизордан карау бер хәл, ә ун көн буе бөтен дөньяның игътибарын үзенә беркеткән, коммунизм тантанасын якынайтуга практик юл сызган съездның үзендә катнашучыны тыңлау инде ул бөтенләй икенче нәрсә. XXII съездга Маклаков делегат булган иде. Ул үзенең хисләрен ничек сөйләде! Кайда гына очрашса да, халык тын да алмый тыңлады һәм аны сорауларга күмде. Рамай аның чыгышларын искә төшерде. Чыгышын шуның үрнәгендәрәк төзергә планлаштырды. Блокнотының икенче битен ачкан иде, анда нефть-газ министры Шашин! Ул машина белән язылган. Габделхак Шакировичның үтенеченә дә үтәлде. Танымас та инде дип уйлаган иде Рамай министрны. Таныды бит. Записка язып бирде. Министрның бер сүзе һәм имзасы ун машиналы итте район мәктәпләрен. Министрлыкта язуын гына күрсәткән иде, бөтен документларны сәгать эчендә рәсмиләштереп кулына да тоттырдылар. Болай булгач, бер машина безгә әлегә тек әлегә инде,— дип уйлады ул.

Шул чак репродуктордан дикторның ягымлы тавышы яңгырады:

— Иртәнге рейс белән Бөгелмәдә очучыларны беренче кассада теркәү башлана!

Диктор аны ике-өч тапкыр кабатлады. Рамай аэропортка кереп китте. Касса алдын икенче-өченче рейста очучылар сырып алган, алга

үтәрлек түгел. Ул, аяк очларына басып, үрелеп билетын сузды. Шул вакыт касса каршында гына басып торган йонлач бүрекле берәү башын залга таба борды, күзе белән кемнедер эзли башлады. Бәй, Һәнүз ич бу! Каян килеп чыккан, нишләп йөри бу малай?! Әллә ул юклыктан иркенәеп, туарылып, кәеф-сафа корып йөриме? Алай дисәң, йөзләре шалкан кебек.

— Һәнүз, Һәнүз! Гумеров!

Ул, аны очратуына куанып, шулай дип кычкырды һәм билетын аңа сузды. Һәнүзнең авызы колакларына җитте.

— Әллә бусында очасыз, Рамай Ибраһимович? — дип кычкырды ул һәм билетны алып, ялт итеп кассага таба борылды. Ул билетларны теркәтеп, зәңгәр талоннар тотып, халыкны ера-ера килеп чыкты да Рамайны кочаклап алды.

— Рамай Ибраһимович! Исәнмесез!.. Радио сөйли башласа, телевизорга күз төшерсәм, гел сезне уйладым. Менә бу минутларда нишләп йөри микән, ни уйлый микән, мин әйтәм...

Рамай аңа сөзеп карады. Һәнүзнең кыланышына, өс-башына карап исе китте. Болай пөхтә киенеп йөргәнен хәтерләми иде ул аның. Нәрсәләр бар бу егеттә.

— Ну, үзегез исән-иминме соң? Колхозда ни хәлләр бар? Чәчүгә төштегезме әле?

— Әйбәт, барысы да әйбәт, тырмага төштек. Бүгеннәрдә культивациягә дә керештеләр инде.

— Ә нинди яңалыклар бар?

— Яңалыклар да байтак.

Һәнүз шулай диде дә Рамай Ибраһимовичны, култыклап, пассажирлар көтә торган залга алып китте. Аның колагына иелә төшеп пышылдады: — Хәзер беренче яңалыкны күрсәтәм, тотып карарсың.

Ул янып торган алсу йөзле, коеп куйган статуядай, кечкенәрәк гәүдәле кыз янында туктады.

— Таныш булыгыз, минем авыз суым корытып сөйләгән Рамай Ибраһимовичым шушы була инде,— диде Һәнүз. Кыз, каушыйрак төшеп, Рамайга кулын сузды.

— Ася...

Рамай Һәнүзгә ялт итеп карады. Аның күз карашында ике сорау ачык чагылды: Асяң шушымыни инде, ә Нәсимәң нишләр? Һәнүз моны аңлады.

— Син киткәч, Нәсимә белән без аңлаштык. Билгеле, аңа авыр булыр. Ләкин мин дә, Ася да һаман элеккечә яши алмыйбыз бит инде. Нәсимә шул эшендә эшләр әле, кумассыз,— диде.

— Эшләсен, ник аны куасың...

Рамай Асяга каш астыннан гына карап алды да тагын Һәнүзгә сорау бирде:

— Тагын ни яңалыклар бар?

— Рәшат Галиевичны ишеткәнсеңдер инде?

— Аны обкомда әйттеләр...— Рамай авыр сулап куйды.— Ә беренче секретарь кем?

— Габделхак Шакирович.

— Китсәнә!

— Әйе.

— Менә бусысы дөрес! Шундый кеше кирәк иде безнең районга Маклаковтан соң, шундый кеше! Районны, кешеләрне белгән.

— Син киткәч, комиссия килде. Тикшерделәр генә безнең колхозны. Әй, чәпчеде Урмакаев, әй, чәпчеде. Үз башына булган икән. Минем доводлар барысы да дөрес дип табылды. Урмакаевны чөйделәр. Дөбердәтеп алып ташладылар.

— Ә аның урынына кемне, шул баш зоотехникны куйдылармы?

— Юк.
— Кемне?
— Әйтсәм ачуланмассызмы? Әйтергә куркам.
— Я инде.
— Мине дисәм...

Рамай Һәнүзне яңа күргәндәй башыннан аягына чаклы карап чыкты да иңбашына шапылдатып сукты.

— Молодец! Ник ачуланыйм. Синең оча торган чагың. Канатларың гына талмасын!.. Ә Вәрәшов урынына кемне тәкъдим иттеләр?

— Ул урын буш әле... Сезне көтәләр дип ишеттем. Изге урын буш тормас,— диде Һәнүз көлеп.

— Юк, минем канатлар анда ук күтәрелерлек түгел инде хәзер,— диде Рамай уйчан гына. «Синең кебек белемем булып, моннан бер ун еллар элек булган булса, бәлки, тарткан булыр идем мин ул йөкне», дип уйлады ул, Һәнүзнең уены-чынын бергә кушып әйткән сүзләрен күңеле аша кичереп.

— Игътибар! Игътибар! Бөгелмәгә иртәнге рейс белән очучыларның «А» серияле зәңгәр талон белән утырту полосасына чыгулары сорала.

— Безгә, Ася,— диде Һәнүз, аларның сөйләшкәнен дикъкать белән тыңлап торган кызга. Алар өчесе дә умарта күче кебек шаулап торган аэропорт залыннан ашыга-ашыга чыгып киттеләр.

Кояш аэродром өстенә күтәрелеп кенә килә иде әле. Аның тәүге нурлары самолет канатларында уйный иде.

Тиз кереп утырдылар. Рамай Ибраһимович, йомшак креслога чумып, тәрәзәдән тышка карады. Менә трапны алдылар, ул тавышсыз, шуып кына тимер рәшәткәле койма буена китте.

Самолет кояшка таба күтәрелде, күтәрелгән саен көмеш канатларында кояш нурлары күбрәк уйный башлады.

Бераздан аның «үз биеклегенә күтәрелүен» хәбәр итеп, таблода ут янды.

Бу хәл Вильдановны, яңа бер ачыш ясагандай, дулкынландырып җибәрде. Үз биеклегенә күтәрелгән кешеләрнең бәхете турында уйлады ул. Һәнүз белән Ася үз биеклекләренә күтәрелергә көч таптылар. Ә менә Рәшат Галиевич үз биеклеген таба алмады. Аның үз биеклеге ул кадәр үк булмаган. Һәм менә канатлар талды...

Рамай тәрәзәдән зәңгәр киңлеккә карады. Аның уйларын исбатлагандай, аста, әллә кайларда бер моторлы «АН-2» самолеты оча иде. Аның түшәме — әнә шунда; күр, беркемгә комачауламыйча кичек иркенләп оча. Беркем бер сүз әйтми. Ул лайнер очкан биеклеккә күтәрелми. Күтәрелергә ярамаганны белеп күтәрелми. Ә эшен эшли...

Үз түшәменә күтәрелгән лачын исә, зәңгәр офыктан тәгәрәп менеп килгән кояш нурларына коенып, өзлексез алга юл ала иде.

1971.

Сарман.

## Әхмәт Гадел

### Каска

Дәһшәтле көннәрне искәртеп,
Тирәкләр астында,
Чирәмгә күмелгән бер сукмакта,
Күрәштә
Солдатның башыннан
Төшкән каска ята...
Кемдер, сукмактан үткәндә,
Баладай гамьсез
шаярып
Каскага бер типкән...
Ул кояш күзендә ялтырап
һәм үрдән тәгәрәп,
аптырап,
сискәнеп киткән...
— Янә сугыш чыктымы икән?! — дигән.
Ә бер карт
Аны күреп алган да:
— Эй, дускай, миңа бак,
Юк хәзер сугышмак!
Башкача син миңа
Хезмәт ит! —
Дип торкан.
Аннан тазарткан да тоткан,
Эченә
Нәфис гөл утырткан.

### Гитара

Кулымда серле гитара.
Кара төн, якты учак.
Утыра иде якташлар
Башларын иеп шул чак.
Бармакларым арасыннан
Сызылып чыкты көйләрем,
Мин аларга сагышымны
Кыллар аша сөйләдем:
— Еракта йөргән чакларда,
Диңгезләрдә, чүлләрдә,
Сез идегез, якташларым,
Уйларда, күңелләрдә...

Туган як дип
Җир шарының
Яртысын мин айкадым.
Сезнең уйчан елмаюлар
Туган ярга кайтарды.
Кулымда серле гитара.
Кара төн, якты учак...
Җылы итеп елмайдылар
Авылдашларым шул чак.
Күпме җирләр, күпме илләр...
Менә үз җирем минем!
Безнеңчә җырлый гитара,
Өздерә татар көен,
Әй, газиз туган илем!

## Кайту

Чемоданын куйды туфракка,
Сокланыпмы,
Уйланыпмы
торды
Карап ерак-еракка...
Ә шәһәрнең өстендә
Ап-ачык зәңгәр күк,
күгәрченнәр...
— Менә бу минем илем,
Бабайларым җире! —
Диде
һәм елмайды
үтеп барган малайга:
— Атың ничек?
— Рәшит.
— Ә синең?
— Минем дә...
— Килдеңмени?
— Кайттым...
Китте...
Ә йөрәк малай белән
Сөйләшүен дәвам итте:
Ватан, ватан...
Кан тамырларында
Шатлык ага!..
Менә шушы инде Түбән Кама,
Әкияттәй Түбән Кама!..

## Гомер

Чуен юллар буйлап
Очкан тимер аткайлар.
Чуен юллар буйлап
Киткән эткәйләр...
Кулларына чиккән яулык тотып,
Яуга озатып калган әнкәйләр...

Чуен юллар буйлап
Чаба атлар,
Тимер атлар чаба — поездлар...
Кулларына чиккән яулык тотып,
Бүтәннәрне озата яшь кызлар...

* * *

Тиздән, әти, мин дә
чалланырмын.
Тормыш, хатын, бала...
Язгы ташкын да ташларга
бәреләп
Агара...
Михнәтсез көннәрем үтте...
Үткән янды,
Бүгенем — яна.
Йөрәгемнең сүнмәс уты
Тетрәп ял-
кын-
ла-
на...
...Ана-җирнең дә сагышлары
Чыга ялкын булып.
Тирә-якка, кешеләргә
Хәят бирә ул, ут...
...Башкаема ут кабына,
ялкын,
ялкын,
ялкын...
Тирә-якны җылытам мин,
Ә үземә — салкын...

## Кавказлы дусларыма

Тагы килдем, дуслар.
Сәламәтлек сезгә!
Шат аваз ишетелсен
Өегездә.

Тагы килдем...
Бик сагындым сезне мин бу юлы;
Муса, Атау, Казбек, Гекки улы!..
Таулардай зур сөю,
Дуслар, сезгә миндә,
Иделдәй саф хисләр
Йөртәм йөрәгемдә...
Рәхмәт дим Мәскәүгә,
Безне таныштырды,
Шигърият балында
Безне кавыштырды.
Эй, дусларым минем,
Парлак көнел бүген!
Баш очымда биек,
Нурлы ачык күгем.

Эдуард Касыймов

# ҺАВАЛАРДА ТУРГАЙ

РОМАН



Үзәк лабораториянең физхимия группасы беренче каттагы өч бүлмәне били иде. Ярыйсы гына иркен, якты бүлмәләрнең һәркайсында да төрле прибор-аппаратлар, җиһазлар урнаштырылган, буш урыннар инде калмаган да диярлек.

Бүген лабораториядәге группа җитәкчеләре һәм лаборатория активы шул өч бүлмәнең берсенә, киңрәк һәм зуррак тәрәзлесенә җыелды.

Урталыкта — кыйммәтле аппарат-прибор дериватограф. Ул әле җыелып та бетмәгән. Аның төп өлеше тәбәнәгрәк өстәлгә куелган. Прибор үзе көл төсендәрәк булса да, хром-никельле регулятор-боргычлары, серле шкала, көмеш тигельләре белән ялтырап, кукыраеп утыра. Бүлмәдәге бар яктылык та шушы затлы әйбердән сибелә иде сыман.

Сары сакалбай Рәшит Сәлмәнов барын да җиренә җиткереп аңлатырга тырыша. Ул әле Мәскәүнең үзеннән күз карасыдай саклап алып кайткан полярограф янына читкәрәк тайпыла да аның зәңгәрсу-яшькелт почмак ырмавыннан сыйпаштырып куя, әле үз әрсезлеге белән Түбән Каладан табып алган дериватограф янына янә кайтып, аңа кул салгалый. Үзе тавышын корырак, гамьсезрәк чыгарырга тырыша. Күе сакал-мыегы арасындагы иреннәре дә әледән-әле җәелеп китәргә итенә шикелле. Әйе, һәркем аермачык сизеп тора: куанычы күлмәгенә сыймый егетнең!

Тыңлаучылар зиһенендә чын кызыксыну уятып, күңелләренә хуш килде кебек: Рәшит сүзен тәмамлауга, тегеннән дә, моннан да кубып, аңа сораулар яудыра башладылар. Ләкин яшь инженер каушап калмады, химик процессларның ниндирәк хасиятләрен өйрәнгәндә бу приборларга таянырга кирәклеген инде тирәнгәрәк үтеп, төпле, гыйлемле һәм ышандырырлык рәвештә җавап бирә белде.

Азактан ул:

— Инде боларын да алай озакка сузмыйча, эшкә җигә алырбыздыр дип уйлыйм мин. Аннары инде теләгән кешегә аларны эшләгән чакларында да күрсәтергә мөмкин булыр. Без сезнең ихтыярда,— диде һәм әчкерсез елмаеп, кулларын күкрәгенә куйды.

Шуны гына көтеп торгандай, сульфат тозлары группасыннан чая гелле Ира Лямина:

---

Дәвамы. Башы 1 санда.

— Дөрестән дә, тизрәк нәрли күрегез инде, Рәшит! Аннан соң без сезнең үзегезне дә жигәрбез, сыртыгызга атланып, чыбыркы белән яра-яра чүмәлә тарттыра башларбыз,— дип куйды, шул сүзләре белән залдагыларны көлдереп алды.

— Аптырамыйбыз: җилкә-сырт таза безнең...

— Кызлар кулы тигән төш тәмугта янмый, ди... Бик рәхәтләнеп чыбыркыларсыз, әйдә! — диештеләр Рәшит белән Марс.

Стена буендагы приборлар тирәсенә сырышкан дүрт-биш кыз, группадашлары, егетләрнең мондый җавабын өнәмичә, иңбашларын тартыштыргалап куйдылар. Арадан иң яше, Венера исемлесе, сөйкемле йөзен кырысландыра төшеп:

— Монда без дә бар әле! Алай сырт ярырга ирек бирмәбез! — дип кычкырды.

Янә шаркылдашып көлешеп алырга сәбәп булды.

Тик моның белән генә бетмәгән икән. Урта яшьләр тирәсендәге таза гына гәүдәле тол хатын Римма Семелькина тагы да өстәп җибәрде:

— Син, Марс энекәш, кызлар диден дә диюен... ә безнең ише хатыннар сарылса, нишләрсең?..

Тагы шаркылдашып көлешә башладылар.

Җитди генә төс белән кул кушырып утырган цехком председателе Җәүһәрия Муллина сикереп торды да ачуланып:

— Бу ни хәл бу, иптәшләр? Күрегез инде, шундый да әһәмиятле, шундый да җитди информацияне тыңлаганда, сүзне җыен юк-бар көлкегә бордыгыз да җибәрдегез...— диде.— Аннары теге Ира Ляминага бармак янады.— Бары да синнән башлана!..

— Ә мин... Болай уйнап кына бит...

— Уен-көлкенең дә үз урыны, үз вакыты бар!..

Тынлык урнашты. Барысы да җитәкчеләре ягына күз салды. Монарчы Госман Әхмеров гәпкә катнашмаган иде. Ул бер кырыйда, нечкәтер күләгәдәрәк, өстәлгә терәлгән хәлдә мыштым гына басып тора иде. Аңа, әлбәттә, җыелган кешеләр алдында сүз әйтмичә калырга ярамас иде.

Урталыкта тәбәнәк өстәл янында таптангалап торган Рәшит читкәрәк тайпылды. Бүгенге сөйләшүнең төп сәбәпчесе булган һәйбәт прибор дериватограф янына, шома паркетны кыштырдаткалап, хуҗа үзе чыгып басты. Бер тын бармак очы белән ияк чокырын сыйпаштыргалап торды.

— Сезнең белән, иптәшләр, эшләве күңелле дә, рәхәт тә: юморны һичкайчан онытмыйсыз... Шулай да уен-көлкене беразга читкәрәк куеп, сөйләшик әле.— Госман, дустанә елмаюын әкрен генә сүрелдерә барып, тавышына җитдирәк төсмер бирер өчен тамак кыргалап алды да: — Моннан ике-өч ел элек, шушы якты, зур бинага күчкәнче без ничәү идек? Егерме ике кешелек, әллә егерме дүртме? Инде ничәү булдык? Җитмеш бер булдык. Алтыбыз — ир-ат, алтмыш бишебез — хатын-кыз... Бик тә җегәрле, сәләтле, зиһенле хатын-кызлар... Юк, салпы ягыгызга салам кыстырырга җыенмыйм: уйлаганым шул...— Бу мизгелдә Госман тагын да эчкерсезләнеп көлемсерәмичә булдыра алмады.— Ләкин якын арада безнең ишәюебез инде булмастыр. Инде бер сызыкка җиттек шикелле. Иске бинада, капиталист Ушков хәзрәтләре калдырган борынгы утын сараенда өелешеп яткан чагыбызда, шушындый өр-яңа аппарат-приборлар безнең төшебезгә дә кермәгән иде. Ә хәзер? Әле тагын булыр, әле яңадан-яңасына ирешә барырбыз, хәтта электрон микроскоп шикелле кыйммәтле нәрсәләрне дә, тырыша-йолыккалый торгач, кайтарта алырбыздыр... Әмма аңарчы, булган хәтлесе дә зур таяныч безнең өчен... Мин ни әйтергә телим? Үзебез өчләтә үскәнбез икән, җитмәсә тагы, шушындый иң яңа, иң шәп техниканы да авызлыкларга җыенабыз икән, без боларны заводыбызга, дәүләтебезгә

эшебез белән кайтарырга тиешме? Ничек, ни рәвешле, ни микъдарда тиеш?

— Әлбәттә, өчләтә кайтарырга тиеш,— дип сүз кыстырды Муллина.

— Арифметиканы шәп тә беләсең, Җәүһәрия: унлата кайтарырга тиеш! Кеше, гадәттә, үзенең зиһен сәләтенең нихәтлесен генә эшкә җигә? Я, кем әйтә?

— Унбиш-егерме процентын гына, Госман Габдулыч,— диде Ира Лямина.

— Дөрес, Ира... Менә мин шул хакта безгә ныклап баш ватарга кирәктер дип уйлыйм әле. Без бар сәләтебезне җигеп эшли беләбезме соң? Иҗади эзләнүләргә тагы да җиң сызганыбрак керешергә вакыт җитте түгел микән? Инде бөтен мөмкинлекләребез бар, иҗат сикереше өчен трамплиныбыз да ышанычлы сыман — бик вакыттыр шикелле... Менә шулар турында безгә озакка сузмыйча җыелышып, әйбәт һәм төпле итеп бер сөйләшәсе иде. Бу хакта сез ни әйтерсез икән?..

— Димәк ки, җыелыш? Профсоюзныкын итәбезме, үзем җыйыйм-мы? Әллә комсомолмы? — дип кыбырсый башлады цехком җитәкчесе Муллина.

— Ничек тә килешер. Хикмәт исемендә түгел, җисемендә... Безнең унбер коммунистның унбере дә, һәр чактагы кебек, бусында да уртада кайнашыр,— диде партгруппорг Таиса Мироновна.

— Тик ул диспут төсендә булсын, диспут төсендә!..— дип кычкырды комсорг Наилә Сафина һәм, шундук бәхәскә керешергә җыенгандай, ңгырт чәч толымын җилкә аша артка чөеп җибәрде.

— Ярар, диспут икән диспут, мин риза,— дип ияк какты Муллина.

— Чыннан да әйбәт булыр ул. Тик һәркайсыбыз да төптәнрәк уйласын иде,— дип, кыюсыз гына теләк белдерде араларында иң өлкән, иң тәҗрибәле Мөстәкыймә апалары...

## 13

Акбалыкка Госман үзе барып кайтырга исәп итте. Бөгелмәгә зур омыш белән сәфәр тотканчыга кадәр, мондагы нефть мәйданнарының озлы су горизонтлары һәм аларның тулаем куәте хакында геологлар елән күзгә-күз карап, төптәнрәк сөйләшәсе, тупланган хәтле материал-арны тизрәк кулга төшерәсе килгән иде аның. Ләкин «Чулманнефть» дарәсенең баш геологы Волкова да, геология бүлеген җитәкләүче аякин да үз урыннарында булып чыкмады.

Геология бүлегендә контурлы карта һәм карротаж сызымнарына умып утырган егет үз эшеннән теләр-теләмәс кенә бүленде. Юка бо-ыны өстендәге дәү күзлеге аның болай да какча йөзен тагын да ябыг-ак итеп күрсәтә иде. Кул кысышканда, ул үзен Роберт дип атады. османның каян һәм кем икәнлеген белгәч, егетнең кырыс чалымнарын ктылык дулкыны юып узгандай булды.

— Шалтыратып белешәсегез калган. Людмила Ивановналар иртән-яктa ук чыгып киткәннәр иде. Безнең геолог халкы шулайрак инде: абинетта утырырга бик үк яратмый.

— Сер түгелдер бит, кая киттеләр икән?

— Сезнең заводтан әллә ни ерак түгел: Бәзәкә үзәнлегенә. Анда з бер скважинада нефть катламын күкерт кислотасы белән эшкәртеп, инау үткәреп маташабыз.

— Ничек соң?

— Өметле кебек.

— Һе, алайса, Роберт энекәш,— диде Госман, көлемсерәп,— безнең е химиклардан да сезгә бер заман файда чыгып куясы икән. Сезнең омыселлар чатында тикмәгә генә һава сасытып ятмыйбыз икән.

7*

— Ник алай дисез әле, Госман абый?

— Соң, нефтьчеләр арасында кайберәүләр безгә әледән-әле: «Бездән аркада гына рәхәткә ирештегез сез!» дип тәрттереп кенә торалар. Имеш, сезнекеләр салдырган асфальт юллардан әлдертәбез, газга, ягулык ишесенә муеннан туенып яшибез, фәлән дә фәсмәтән...

— Сәер, сәер...— Роберт, иягенә таянган килеш, авызын ямьсез кыйшайтты. Ул Госманның тавышындагы җиңелчә юморны бөтенләй исенә кертмәде.— Аптырыйм мин андый вак җанлы кешеләргә. Кунак ашы — кара-каршы бит инде ул. Соң, химиклар ярдәменнән башка без үзебез нишләр идек икән? Татарстанның бик күп промыселларындагы термо-химик установкаларында нефтьне судан арындырган чагында яки бораулау эшендә әйбәт измә әзерләгәндә, бар, химик реагентларсыз гына берәр юньле нәрсә кырып кара... Ә киләчәктә ул тагы да...

— Ярар, алай тирәнгә китмик, мин шаяртыбрак кына бит, Роберт энекәш... Алайса, Людмила Ивановна белән Таякин тиз генә әйләнмәсләр әле, шулаймы?

— Әйтүе кыен, Госман абый... Алар Бәзәкә үзәнлегенә төшкәнче, Комаровка мәйданындагы буровойга да сугылмакчылар иде. Буровиклар белән киңәш-табыш итешергә... Анда менә өченче тәүлеген инде скважинадан ыжгыртып газ аттырып ята...

— Газ? Нәрсә, бик куркынычлымы әллә?

— Юк, куркыныч түгел түгелен: саф азот газы бәрә. Мәшәкате күп. Инде өченчеме-дүртенчеме буровойда шулай. Көч-хәл белән генә авызлыклый алалар. Бер, шешәдән чыгып, котырына башласа, ай-яй, ул диюне йөгәнләве!

— Саф азот димсең, ә?

— Кайбер бүтән инерт газлар да бар. Әйтик, гелий.

— О, бик кызык бит бу! Килер бер көн, Роберт энекәш, андый газ фонтаннары бик тә кирәкле булыр әле. Дөресме?

— Әлбәттә, Госман абый! Илгә байлык табып бирү безгә, геологларга, йөкләнелгән. Бер үк вакытта без ул хәзинәләрнең сагында торучылар да...

«...Төтене туры чыга кебек егетнең... Әле язын гына күренмәгән иде, идарәдә юк иде кебек, каян инде икән? Әйе, Әлмәтнең үзеннән, диде бит... Эх, сорашмады, аңгыра баш: җир астының тозлы эремәләре хакында ни уйлый, ни әйтер иде икән бу асыл егет-геолог?»

Госман атлаган җирендә капыл тукталды. Ләкин соң иде инде: «Чулманнефть» идарәсе дә, нефтьчеләрнең икешәр һәм дүртәр катлы игезәк йортлардан төзелгән яшь поселогы да арттарак үр өстендә калган иде. Түбәндә, яссы иңкүлектә, аз гына томанлы дымсу һавада ярым җимерек, ала-кола чиркәү гөмбәзләре, әүвәлге сәүдәгәрләрнең заманнар үтүдән соргылтланып калган икешәр-өчәр катлы ташпулатлары һәм сирәк карт тупыллары белән Акбалыкның борынгы өлеше җәйрәп ята иде.

* * *

Чат башында, һич уйламаганда, Госман авылдашы, мәктәп директоры Сабир абыйсы белән маңгайга-маңгай диярлек бәрелешә язды. Монысы инде бәхетнең үзе иде!

Берара, кул кысышкан хәлдә, «аһ-ваһ» килеп тордылар да үзара хәл-әхвәл сорашырга тотындылар. Сабир абыйсының борын-күз тирәсендә җыерчык бик нык ишәйгән, тирәнәйгән, чигәләрендә дә кыска чәч төкләре инде бөтенләй бәсәргән, әмма шулай да кысынкы күзләрендәге әүвәлге дәрт һич тә тоныкланмаган шикелле...

— Җәл, бик тә җәл, Госман: җәен, син авылга кайткач, күрешә алмадык шул. Нишлисең, читтә утырган аулак бер авылның мәктәп ди-

ректорына тегендә дә чабарга туры килә, монда да. Көн саен йомышы да чыгып кына тора.

— Аңлыйм, Сабир абый, бик аңлыйм. Җитмәсә тагы, мәктәпләрне, янә кайтып, житен сүсе кебек талкыргаябыштылар, ахрысы.

— Әйе, уку-укыту эшләрендә янә дә, сезнең ишләр әйтмешли, реконструкция... Кайбер фәннәрне, студентларга укыган кебек, телдән яздырып укыта башладык: имештер, элекке дәреслекләр ярамый, ә яналары юк, кайтмаган. Шуннан мин, чукынмый, дидем дә әүвәлге дәреслекләргә ябышырга куштым. Мәктәп баласын дәреслекләрсез укыту эшмени ул? Ярым-йорты белем биреп чыгарыйкмыни? Инде аптыраш!

— Алай да әллә ни картаймагансыз әле, Сабир абый, һаман да яшьләрчә җегәрле күренәсез...

— Кая инде ул, яшьләрчә!.. Баш түбәсендә, бозау ялап алгандай, бөртек тә чәч калмады — күзгә итеп карарга була. Менә! — Сабир абыйсы эшләпәсенә кул тидереп алды, ләкин баш түбәсен үк ачып күрсәтмәде.— Ә сине, Госман, авылда һаман да мактап телгә алалар. Бигрәк тә карт-коры. «Партийный булса да, изге бер җан икән, тикмәгә гыйлем өстәп йөрмәгән икән, рәхмәт яугыры» дип...

— Ничек-ничек! «Изге бер җан» дипме?

— Әйе. Соң, син авылга кайткач, үз кулың белән хәер-сәдака өләшеп йөргәнсең түгелме?

— Менә бу, ичмасам, юмор! — диде Госман, баскан җирендә таптангалап һәм ихтыярсыздан көлемсерәп. Әмма аның йөзе шундук җитдиләнде.— Күперткәннәр...

— Күперткәннәр микән? Дөрес, әлегә: «Солдат Габдулла малае әүлия икән» димиләр диюен дә...

— Кара син, ә...— дип сузды Госман, бөтенләй пошаманга бирелеп.— Соң бит, мин, әнинең бүләге итеп, аның ахирәткәе Нурдидә апага шәльяулык тоттырдым да әтинең әүвәлге дусты, авыру Хөснетдин абзыйга кибеттән бер эшләпә алып бирдем. Картлык көнендә, әйдә, бер юансын, дидем. Ә инде теге «хәер-сәдака» дигәнен Нурдидә апа белән аның килененә тапшырдым, «үзегез белгәнчә тиешле авылдашларга өләшерсез, әни белән апа шулай үтенгәннәр иде» дип... Аларның амәнәте иде ләбаса! Һе, карчыклар теленә бер керсәң...

— Үзем дә аптыраган идем. «Себер җирләреннән алтынга баеп кайткан борынгы зимагурмыни ул безнең Госман», дидем. Соңыннан, астыртын гына сорашкалый торгач, аңыштым тагы... Ярар, юк белән баш катырмыйк. Беркем дә гаепләрлек эш түгел. Авылдашларыңның күңелен күреп бик әйбәт иткәнсең, мактыйм... Я, әйтмисең дә, данлы Ленинград каласыннан ничек йөреп кайттың соң?

— Әйбәт, бик әйбәт! — Госман карт укытучыны беләгеннән култыклап алды.— Әйдәле, Сабир абый, тамак ялгар чак та җитте, ресторанга кереп иркенләп утырыйк әле бер...— Шунда анысы хакында да сөйләрмен, бүтәнен дә сорашырмын-кинәшермен...

— Юк, Госман, вакытым бик тә чикле! Әле менә роного кереп мөдир белән якага-яка ябышасым бар, банк ябылганчы банкка өлгерәсе, аннан чыккач, җитешсәм, почтаның радиоузел башлыгын эләктерәсе... Икенче бер чакны инде, үпкәләмә. Аяк өсли генә капкалап, чәйләп алырдай җир булса иде менә! Эх, термосны да ватып әрәм иттем, чәнчелгере!

— Нәрсә, термос кыстырып йөри торган идегезме әллә?

— Пәрмәскә. Тәмам картайдым, ахрысы: чәйсез тора алмыйм, валлаһи! Ә монда Акбалыкка килдең исә, аптыраш: рестораннарында чәй көтеп, булмаган чәчең коела, ашханәләрендә тоттырганнары ни... лыбыр-лыбыр казанда кайнаган болганчык су... Ә инде хәмер дисәң, пожалуйста, чат саен, кибет саен! Бүлеп тә бирәләр, бүлмичә дә суза-

лар. Нибары ярты сәгать эчендә ләх була аласың, ипидер! Минем нше аек башлар хакында бөтенләй кайгырта белмиләр шул.

Госман янә хөрмәтле авылдашынын җиңенә ябышты.

— Әллә ниме. Сабир абый, безгә әлдертәбезме? Машина хәзер килеп җитәр... Юк, кафега да, чәйханәгә дә түгел, үземә дим, кунак булып, дим. Бер көнгә мондагы эшләрегезне калдырып торасыз да... Урыс әйтмешли, эш дигәнебез — аю түгел — урманга качмас әле. Әйе, үзем авылга кайткач, завуч Мәрьям апага вәгъдә иткән нәрсәләрне дә алып китәр идегез... Ул сезгә җиткердеме?

— Җиткермичә... Чын, булыр дисеңме?

— Булмыйча соң? Мәктәпнең химия кабинетын чын-чынлап баета алырбыздыр. Микроскоп бирә алам, аналитик үлчәүләр, гади үлчәүләр, фотопроектлар, сепаратор... Безнең өчен искергән, гамәлдән чыккан бүтән нәрсәләр складта тагы да бардыр әле. Савыт-саба ишесен, төрле реактивларны әйтмим дә инде.... Сабир абый, барсына төкерегез дә, киттек, әйдә!

— О, безнең кабинетның да бер байыйсы көне җитәр икән. Күңел ышанмый.

— Ышансын. Миннән соң, ичмаса, бер генә химик та чыгара белмәдегез бит. Бәлкем, файдасы тияр, дим.

— Аның каравы, энекәш, азмы укытучысыдыр, врачыдыр, инженеры-механизаторыдыр чыкты бездән, ә? Әнә, әлерәк кенә ишеттек, Мәскәү каласының үзендә Инеш арты Ибрай малае Зәйтүн, атаклы математик башыбыз, диссертация якларга җыенып йөри, ди. Түбәләребез янә күккә тия язды.

— Булдырган егет! Менә бит, Сабир абый, тормышлар хакында бер иркенләп сөйләшеп утыру өчен дә бик матур орлык та бар икән. Өйдәгеләр дә куаныр гына иде... Һади Такташ әйтмешли, «галстугыгыз белән билегезне буып аласыз да...»

— Бик рәхмәт, Госман! Тик, зинһар, авыл кешесе икәнеңне оныт әле — сыткый сагызы булма! Күрәсең бит, эшләремне һич чигерер чамам юк.— Сабир абыйсы, моңарчы кулында асып торкан юка гына күн портфелен күтәреп, култык астына кыстырды да кабаланып сәгатенә күз төшереп алды.— Син, зинһар, үпкәләмә инде. Бигайбә, яме! Шушы араларда ук ничек тә үз җаем белән барып чыгарга тырышырмын. Бәлкем, куна да калырмын әле.

— Ярый, мин анысына да риза.

— Ә хәзергә хуш, яме! Ашыгыйм әле...

— Көтәм, Сабир абый!

Башына киң тирәле эшләпә, аягына хром итек өстеннән эр-яңа галошлар киеп алган карт директор, юеш асфальтка җәһәт-җәһәт баскалап, бераз гына китте дә борынгы йортларның берсенә, роно мөдире белән «якага-яка ябышыр» өчен, ашкынып кереп тә югалды. Госман исә, үз борчуларына чумган килеш, чат башында басып калды.

Исенә төште. Шәһәр комитетына сугылмаса да, политмәгариф кабинетына кермичә кайту ярамас. Чулман заводында кичке университетның филиалы ачылган иде, заводтан атнаның һәр дүшәмбесендә боларга микроавтобус җибәреп торалар, ләкин мондагылар, күбесенчә пединститут лекторлары, расписание белән бик үк исәпләшергә теләмиләр. Менә шуны ничектер ныклы бер юлга саласы иде.

Чат башыннан әкрен генә купты.

Сәер... «Изге җан», имеш. Сөенүдән бигрәк, көенерсең. Ләкин телләренә чуан чыккыры дип тиргәнергә дә хакың юк: үз итүләре, яратулары... Ә ул Инеш арты Ибрай малае Зәйтүнне, ата казларны муеныннан эләктереп, бөтереп, яр астына мәтәлдерүче, билен этисенең киң каешы белән буып йөргән китек иренле малай итеп кенә хәтерли Госман. Кай арада үскән-укыган да, кай араларда аспирант булып, инде

диссертация дә өлгерткән, диген. Кем уйлаган анардан... Хәер, Госман үзе сон...

Ә Сабир абыйсы килеп чыкса, ах, шәп тә булыр иде. Менә кем Госманның күңеленә бөялгәннәрне ерып җибәрә белер иде. Теге чакны, унынчы классны тәмамлагач, үзе үк авыл хуҗалыгы институтына керергә димләгән булса да, Госман аның каршысына студент-химик булып килеп баскач, Сабир абыйсы: «Шәп иткәнсең, энем! Авылны аны, агрономнар белән кулга-кул тотышып, химиклар да күтәрәчәк. Менә күрерсең!» — дигән иде. Гомере буена тарих укытып, тормышны бик күп күргән, үтә ярдәмчел, киң күңелле һәм төпле акыллы кеше белән киңәшеп, анык бер карарга килсә, Госман партком җитәкчесе Вероника Борисовна белән дә, кирәк икән, шәһәр комитетының беренче секретаре алдында да, күкрәк киереп сөйләшә алыр иде сыман...

Ике-өч көн үткәч, Морт мәктәбеннән Чулман заводына яшьрәк кенә ханым — химия укытучысы белән завхозлары килеп төште. Сабир абыйлары бик ымсынган икән дә аны тагы нидер тоткарлаган. Нишлисең, ана үпкәләрлек урын да юк: тормыш дигәнең, мәктәп директоры кебек бик мәшәкатьле эш кешеләрен иярләп алып, әле тегеләйгә, әле болайга йөгертә шул.

## 14

Тышта, тәрәзә яктысында, җепшек кар күбәләкләре бөтерелә.

Яңгыр булса, менә шушындый йомшак җилле, талгын гына сибәләп торса, монсу шыбырдавы белән күңелне сызландырыр иде. Ә бу ап-ак, сап-салкын күбәләк болытның тавышы-өне бөтенләй юк. Ул җанны бөртек тә сызландырмый, киресенчә, күңелгә үткәннең шаян, тиле-миле хатирәләрен җилпи сыман. Күз кабакларыңны шытырдатып йомсаң да, күз алдында бу көмеш канатлар, нәфислектә берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, өзлексез биешеп, бөтергәләнеп торалар...

— Беренче кар!..— дип пышылдады Зөлфә һәм, өстәлендәге калын белешмә китабына таянган көенчә, күзләрен яңа йомып торды. Аннары суырткыч шкаф янында анализ-синтез ише нәрсәләр белән сихерләнеп, дөньясын оныткан Ривага тавышын күтәрә төшеп эндәште: — Рива, кара әле: тагы да куера төште. Инде ябалак-ябалак ява...

— Электр плиткасын гына тоташтырчы, Зөлфә: чәебез суынып беткәндер инде...

— Карны әйтәм... Кичен тәрәзә яктысында бигрәк тә матур инде!..

Рива да, суырткыч шкафыннан аерылып, билен турайтмыйча булдыра алмады.

— Гаҗәеп икән шул. Мондыйны безнең әбкәй мәрхүм, күктәге фәрештәләр йон-мамыкларын кагып, яңаралар, сафланалар, дияр иде... Бер айдан авылда чана юлы төшәр инде, алайсам.

— Фәрештәләр мамыгы дисеңме? Чынлап та охшаган бит, неме?

Зөлфә электр плитасын розеткага тоташтырды да тышта дөм караңгы фонда уйнашкан ап-ак тылсымга төбәлеп торды. Тирән иттереп бер тын алгач, көлемсерәп исенә төшерә башлады.— Минем беренче гыйшкым да фәрештәләр канат каккангa туры килгән иң... һе-һе... Алтынчы класста укый идем бугай, әллә җиденчедәме? Бер мәлне мәктәптән кайтып килабез. Менә шушылай ук ябалак-ябалак кар ява. Әкәмәт матур! Урам буйлап кар атыша-атыша кайтабыз. Куллар кызарып, күшегеп бетте. Шул чак Фәнил атлы бер малаебыз, мин өйгә керер китим дигәндә генә, мине эләктереп алды да шәл арасына якама җепшек кар тутыра башлады. Үзем — акырам, бакырам, әнине чакырам...

— Шуннан, шуннан? — диде Рива, колба-шешәләр белән тулган стеллаждан үзенә кирәклесен эзләп. Тапкач, янә суырткыч шкафы каршысына басты.

— Шуннан муеннан гашыйк булдым үзенә... Дәресләрдә запискалар ыргытышабыз. Шуның өчен кара тактаның беребез бер башында, икенчебез икенче башында әллә ничә тапкыр басып торгаладык. Хәзер кайларда йөри, кем булды микән ул Фәнилкәй? Үзе кире беткән усал бер нәрсә иде, әмма бик тә башлы... Барысы да минә шушылай тәңкәтәңкә кар явудан китте.

— Туктале, кызый, син бер көнне генә беренче мәхәббәтеңне тугызынчы класста укыганда дигән идең, инде менә, ни ишетим, алтынчыда ук дөрли башлагансың икән...

— Көлмәсәнә, Рива! Мәхәббәт дигәч тә... Юк, аның чын-чыны миңа бик соңгарып килде. Хәер соңгарып килсә дә... Эх, кадалсын ла иде!.. — Зөлфә янә бер мизгелгә күз кабакларын кысып тотты, әмма күз алдында, кар кубәләкләре өермәсен аралап, Зәбир сурәте пәйда булды. Кыз, калтыранып, башын селкеп җибәрде.

— Сөйләвеңә караганда, синең, Зөлфә, әллә нихәтле булган, ахры?..

— Алай ук түгел лә...

— Ни әйтсәң дә, күпләрнең җанын көйдергәнсең син... Әллә шуңа күрә тәкъдир дигәнебез тегеләрнең үчен кайтара микән хәзер? — Рива шкафы янында тагын да тураеп басты. Әмма хезмәттәше аңа ни дип тә җавап кайтармады. — Ах, язмыш, язмыш... Мин үзем соң? Беренче мәхәббәтемдә үк бер гаепсезгә нигеземә тикле яндым лабаса...

— Уфтанмыйк, Рива.

— Мин дә шулай дим... Әйдә, китаптан эзләгән нәрсәңне таптыңмы әле? Тапсаң, реакцияне икенче төрлерәк сынап карар идек, ичмаса... Югыйсә, монысы тагы чыш да пыш кына булыр сыман.

— Хәзер, тагын бераз гына караштырыйм да...

Зөлфә калын белешмә китапны читкәрәк этеп, икенчесен, юкарагын әкрен генә битләргә кереште. Әмма, озак та үтмәстән, тагын тәрәзә яктысында очынган кар күбәләкләренә төбәлде.

— Туктале, теге бүлмәләрдә ничек икән? Тикшереп керим әле.

Бик җилле генә кубып, чыгып китте дә өч-дүрт минуттан әйләнеп тә керде.

— Рива! Рива апа, дим! — Зөлфә хезмәттәшен кайвакыт үз яшьтәшедәй итеп күрә, кайчакны аны олыгайтып та җибәрә, ара-тирә икесен бергә бутап та куйгалый иде. — Анда безнең җизни дә кабинетында тончыгып утырмый: инде сыпырткан. Аналитикларда да ут күптән сүнгән, ахрысы: Лида Воронцова шушындый кичне түзәме соң!.. Акылы алтын! Әллә без дә җыена башлыйкмы?

— Ә Рәшит белән Марс?

— Алар утырмыймы соң, җүләр! Спектографларының яшел күзенә төртелгәннәр дә чекерәеп катканнар... Их, фәрештәләргә тикле җенләнгән шушындый тылсымлы кичне ят инде таш келәт эчендә сөрсенеп... Җитмәсә, син әллә нинди сасылар чыгарып кына торасың. Суырткыч шкафың да суырып бетерә алмый...

— Әле сизелми шикелле, әмма озакламый таралачак ул хушбуй исләре, — диде Рива, серлерәк мәгънәдә тел чәпелдәтеп. — Очына чыга алмабызмы дим. Һу, әле тугызынчы ярты гына бит.

— Иртә икән!.. Инде атна буе эзләнәбез бит, әле һаман җепнең очына чыга алганыбыз юк, беленми дә әле ул. Туйдырды тәмам! Безгә дә сызарга бик вакыт. Үз ирегебездә ич, беркем көчләми-нитми...

— Җизнәңнән аз гына да уңайсызланмыйсыңмыни?

— Һи, аның каршында минем хакым бер тиен. Бәһасен күтәрер дисеңме? Юк, житте бүтән эзләмим дә, карамыйм да!

Зөлфә шап иттереп белешмә китапларын ябып куйды.

— Ярар, күңдерден, кызый,— диде Рива, уфтанып, һәм әзерләгән колбасын шкаф эчендәге кызган плиткага утырткач, бар нәрсәсен җентекләп күздән кичерде. Ком сәгатен әйләндереп куйды...— Чак кына сабыр итик, Зөлфә. Инде шушысын гына көтик. Аннары ычкынырбыз. Тик иң әүвәл чәй эчеп алырбыз. Баш мингерәүләре таралмасмы, ичмаса.

— Тагы чәй! Ярый, ярый, бәбәкләренне агартмыйча гына... Тегеләрне, Рәшит белән Марсны да, дәшәбезме? Ул мескеннәргә тәмәке пыскытырга булса, җиткән...

— Дәшәрбез. Тик ашыкма әле... Иң башта минем сумканы бушат син: анда бәләкәй генә сюрприз, Зөлфә.

— Сюрприз?! Тагы вареньеңның ниндие икән?

Үзәк лабораториядәге халыкның өчтән бере диярлек читтән торып институтта укый иде. Өч-дүрте инде диплом язарга да тотынган. Кичләрен калып эшләүчеләр, дөресе, үз темасы буенча эзләнүчеләр байтак булгалый. Башлыклары Госман каршы килми, киресенчә, хуплый гына: үзләренә дә, заводка да файда... Әмма кичләрен иң нык бирелгәннәре югары катта Рива белән Зөлфә, түбәндә Рәшит белән Марс булыр иде. Болар, тикшеренү эшләрендә башлары катыбрак киткән чакларда, еш кына бергәләп гөрләшә-шаярыша чәй эчәләр, хәл яңартып җибәрәләр иде.

Зөлфә күн букчадан иң әүвәл кәгазь төргәк белән эре-эре алмалар чыгарды — бусына әллә ни исе китмәстән, берсен, арада иң матур күренгәнен, энҗе тешләре белән шундук кертләп тә карады, аннары, икенче төргәкне алгач, кычкырып ук җибәрде:

— Мандарин! Менә, ичмасам, сюрприз! Каян бу?

— Син сорама, мин әйтмим,— диде Рива. Бу минутта ул суырткыч шкафына арты белән борылган да, кулларын күкрәгенә кушырып, мөлаем бер кыяфәт белән Зөлфәгә карап тора иде.

— Юк, син иң башта әйт: каян? Бу вакытта бездә исе дә булмый мондый нәрсәнең... Тегеннәнме әллә?

— Әйе... Нефте-чаладан җибәргәннәр.

— Кем?

— Берәү...

Риваның йөзенә кус кызыллык йөгерде. Алай да сер бирмәскә теләп, кеткелдәгән булды.

— Дөньяда азмыни изге җанлы кешеләр. Дуслык хакын онытмаган.

— И Рива апа, мин синнән бер нине дә яшермим, барын да мәрҗән урынына тезеп кенә торам, ә син? Исеме ничек?

— Исемеме? Әни дә, кичә посылка килгәч, шулай төпченгән иде, инде син. Ярый, әнидән яшермәгәнне, синнән генә яшереп булмас, ахры. Исеме — Җәвад.

— Җәвад? О, Рива апа! — Зөлфә аны иңбашларыннан кочып ук алды.— Сөйлә әле, ничек булды? Тик, зинһар, бөртеген дә калдырмыйча сөйлә. Минем күк...

Нефте-чаладагы бром заводына баргач танышкан булган икән. Болар кебек үк, заводның үзәк лабораториясендә эшли, инженер-тикшерүче, ди. Утыз тирәләрендә, ди. Әнә шуның ярдәмендә Рива ул заводның барлык нечкә эшләренә хәтле сөзеп алган да икән. Үзе гыйльми эзләнүләргә нык лап ябышырга ниятли, инде кандидатлык минимумын тапшырып, диссертация өстендә баш вата икән.

— Чибәрме соң? Фотосы юкмы?

— Юк. Фотолар алышуга ук барып җитмәдек. Ә болай ярыйсы гына. Аларны беләсең инде. Чем-кара мыеклы, кылычрак борынлы...

Рива, бер вазеннәргә керешкәч, Нефте-чалада үткәргән соңгы икеөч көне-киче хакында тәмле генә иттереп сөйләп алды. Киного барган-

нар, паркларында йолдыз санап йөргәннәр, гостиница ишеген сакл ганнар...

— Аның әтисе ягыннан әбисе дә безнең кеше икән. Арчадан, д Әүвәл-әүвәлдән үк әзербәйҗаннар белән кыз алыш, кыз биреш сир булмаган бит ул бездә. Әнисе белән бик таныштырасы, сөйләштерә килгән иде үзенең. Мин аңа: «Арчада минем әтинең сеңлесе яши, ан булгалаганым бар»,— дигән идем. Җавад: «О, алайса, бигрәк тә ша әбкәебезнең куанычы чиктән ашар!» — дип, бөтенләй җенләнде. Әмм оялмыйча ничек барасың, ди?! Дөрес бит, Зөлфә?

— Әлбәттә.

— Озаткан чагында хат алышу турында сүз куешкан идек куешуы әмма посылка турында ләм-мим, сиздермәде... Аптырадым. Әни бигр тә... Кире җибәрер идең, әллә ничек тагы...

— Җүләр! Миңа килсен иде әле!.. Ә син соң үзең хакында ни д булса...

— Әйттем, Зөлфә, барын да... Кияүдә булганымны иң баштук, бил геле. Ә ул... ә ул... Ни, ишеткәч, кашларын җыергандай итте, аннары кулын җилкәмә салды да көлеп куйды: «Аңа карап кына гел әң чәч кәсе шиңмәгән»,— диде.

— Егетнең асылы икән, чын, Рива апа!

— Алдан кычкырмыйк, башыбыз авыртмагае,— диде Рива тыенкы гына.— Әле үзе дә командировка алып бу якларга килеп чыкмакчы Хатында шулайрак язган. Ул да бит, безнең кебек үк, җир астыны тозлы сулары белән шөгыльләнә.

— О, килсен иде тизрәк! Бер күрер идек, ичмаса... Ә сине, Рива апакаем, котлыйм, чын күңелемнән котлыйм! Синең бәхет кояшың күр дә тор, шул Нефте-чала тарафыннан чыгар да куяр әле, ипидер!

Электр плиткасында утырган чәйнекләре чыжлап кайнап чыкты. Шул гына өннәренә кайтарды. Күз салсалар, суырткыч шкаф эчендәге колбадагы сыекча да әллә кайчаннан бирле кайный икән инде. Рива шундук ухылдарга тотынды.

— Тагын булмады... Эх!..

— Төкер башына! Иртәгә дә көн бетмәгән... Мондый да куанычлы кичне ыңгырашмыйк! Әйдә, ул нәрсәләреңне сыпырып ат та чәеңне әзер лә, ә мин тегеләрне дәшәм... Тәмләп сыйлыйк әле үзләрен!

Рива бармагын иренәнә куйды.

— Тик син, Зөлфә, мин сөйләгәннәрне... бераүгә дә...

Кыз үпкәли язды:

— Син бигрәк инде...

## 15

Көн җепшек: өстән бервзлексез кар катыш яңгыр сибәләп тора.

Бала тудыру йортының икенче катындагы киң тәрәзә өлгесендә, ниһаять, башына ап-ак яулык бәйләгән, авыз тирәсен дә марля белән каплаган медсестра күренде, аның сонында Эмма үзе... Биләүле бәбиләрнең әүвәл берсен, аннары икенчесен күрсәттеләр. Бер генә мизгелгә... Нәниләрнең йөзләре уч төбе кадәр генә, аз гына кызгылт, борыннары уймак чаклы гына, күзләре йомык. И нарасыйлар, и дөнья ямьнәре!..

Әниләре Эмманың йөзе аксыл-саргылт иде, шундук тагы, нәниләренең йөзеннән дә болайрак булып, бурлат төсләренә керде. Оялып, башы аска иде, әмма шулай да, куанычын яшерә алмыйча, бәхетле бер төс белән елмайды. Аннары ябык ак кулын селеккәләде дә юк булды.

Госман баскан җирендә таптангалап алды, кулына тотып болган торган кепкасын кире үз урынына, баш түбәсенә ябыштырып куйды,

эмма шулай да кузгалырга ашыкмыйча, яшь хатын тагын күренмәсме дип, бер мәл көтеп торды.

О, Эмма тагын күренде. Нәзек бармагы белән тәрәзә пыяласына нидер язгандай итте, тагын кызарынды, тагын оялчан гына елмайды да кул селтәп тагын юк булды.

Госман, кирза итеге белән сукмактагы ләҗбердек карны изә-изә, кайтыр ягына таба атлады. «Шулай инде, кешене куандырыр өчен күп кирәкмени соң!»

* * *

Автобус тукталышына якынлашып килгән чагында, аптека болдырыннан төшеп килгән Вероника Борисовнаны — партком секретарен — күреп алды. Ханымның әтисе нинди дер яман хаста белән ята, шул сәбәпле ана аптека юлын шактый еш таптарга туры килә иде.

Вероника Борисовна көзге пальтога күчәргә өлгермәгән, өстендә әле һаман да көрәнсу төстәге юка плащ. Эмма шулай да көн салкынына бирешептер, башына саргылт мамык яулык бөркәнеп алган. Менә ул култык астыннан зонтигын суырып чыгарды һәм аны баш өстендә җәеп җибәрде. Шул мизгелдә үткен күз карашы белән Госманны элеп алды һәм, бусы якынлашкач, күн перчаткасын салып, кул сузды, саран гына көлемсерәде.

— Ничек, Борис Михайловичның хәле юньлегә таба түгелме? — дип сорады Госман.

— Кая инде... Даруның да файдасы әллә ни сизелми башлады. Инде тәмам аптырадык... Ә син, Госман Габдулыч, ни дип йөрисең әле больница тирәсендә? Әллә берәр кемең чирләп киттеме?

— Түгел лә... Безнең бер кызыбыз, дөресе, яшь киленебез Эмма Сәмитова бала тапкан иде. Игезәкләр! Малай белән кыз!.. Тырыша безнең үзәк лаборатория бу юнәлештә дә, Вероника Борисовна: өченче елны дүртәү туган иде, былтыр алтау, ә бу елны инде менә җиде җанга житте, әле тагын бер яшь хатыныбыз көмәнле... Сынатмыйбыз! Химиклар ыруын арттырабыз!..

— Котлыйм, котлыйм! Әнә нинди куаныч артыннан йөрисең икән әле... Әлбәттә, күчтәнәчтер-нидер?

— Ансыз ярыймы соң? Кагорның иң куесы, алманың иң матурлары... Тик бик тә кызганыч, чәчәк булмады, чәчәк!..

— Һәр нәрсәнең үз вакыты бар шул, Госман Габдулыч.

— Үз вакыты. Алай да, менә шушындый көнне, тышта җепшек кар катыш яңгыр явып торганда, тумбочка өсләренә купшы чәчәкләр утыртып куйсаң, ай-яй, бөтен палата эчләре ямьләнеп китәр иде. Бик тә кызганыч...

— Чәчәк дисең...— Ханым, тукталып, Госманга баштанаяк сөзеп карады.— Соң, Госман Габдулыч, синең менә болай, олы башыңны кече итеп дигәндәй, кул астында эшләүче берәүнең шатлыгын уртаклашып, хәл белешеп килүең чәчәк бүләк итүдән әллә кимме? Аның өчен, бәлкем, кадерлерәктәдер әле...

Шулай сөйләшә-сөйләшә, алар автобус тукталышына килделәр. Стеналарындагы тишек-тошыклардан җил өреп торган иске будкага кереп сыендылар. Монда дүрт-биш кеше автобус килгәнен көтеп тора иде. Озакламый түбәннән үргә каршы авыр гүләп менгән автобус үзе дә күренде. Ул тегеочтан әйләнеп килгәнче, байтак вакыт үтәчәк иде әле.

Бер мәл, аска, аяк очларына төбәлгән килеш, уйчанланып торганнан соң:

— Иртәгә гипосульфитныйда отчет җыелышы,— диде партком секретаре.

Госман сагая калды. Вероника Борисовна цехлардагы отчет-сайлау җыелышларына, берсен дә калдырмыйча, үзе йөри һәм партком члennарыннан да берәрсен иярткергә дә тырыша иде. Моңарчы Госманны дәшкәне булмады, чөнки ул аның әле күптән түгел политмәгариф системасындагы укуларны башлап җибәргәндә шактый гына вакыт һәм энергия сарыф иткәнлеген яхшы аңлый иде. Әлбәттә, Госманга гипосульфит цехының партия җыелышына катнашып алу зыян итмәс иде дә итүен, эх, вакыт юк шул, вакыт...

— Озакламый үзебезгә дә хисап тотасы. Октябрь бәйрәмен генә әйбәтләп үткәрик тә...

Госман җинел сулап куйды.

— Аңарчы әле егетләрне армиягә озатасы бар, Вероника Борисовна. Аны да шәп бер традициягә әвереледермәкче идек бит, онытмыйк.

— Әйе, әйе... Сугыш ветераннарын кабат кузгатмыйча булмас. Пионерларны да... Яздагы шикелле үк шәп үтсен, солдат күңеленнән мәңге чыкмаслык булсын, дөрес бит?

— Әлбәттә. Ә үзебезнең отчетны ничек тә үткәрербез инде аңысы. Болай начар эшләмәдек, аз тырышмадык кебек. Ник пошынырга? Ел да кабатлана торган хәл.

— Алда зур юбилей, Госман Габдулыч.

— Беләм. Үтә җаваплы ел булачак.

— Димәк ки, шул хакта бүгеннән үк кайгырта башларга кирәк безгә. Сайланачак парткомга үзебезнең уй-теләкләребезне, киңәшебезне җиткермичә, ничек инде? Янә үзебезне үк сайлап куюлары да ихтимал. Шулайрак сизелә.

Госман сигаретына ут алды.

Кар хәзер куерак һәм ешрак төшә, ләкин җылымса җиргә төшү белән эри бара иде.

Автобус көтүчеләрнең беришесе аякларына юкарак кигәннәр иде, күрәсең, табан асларына таракан кергәнлеген тоеп сукрана-тиргәнә, таптангаларга кереште. Вероника Борисовна да резин итекләрен берберсенә бәргәләп алды. Бер-ике мәртәбә бөтен гәүдәсе белән калтыранып та куйды шикелле. Югыйсә, парткомның үз микроавтобусы да бар. Әле һаман начальниклыкка күнегеп бетә алмый, ахры, ыспай җан...

Госман кинәт сигаретын тиз-тиз суыргаларга кереште. Суырып бетермәде, төпчекне каты чиртеп читкә ыргытты... Тукта, партком секретаре белән төптәнрәк сөйләшү өчен бик тә җай чыгып тора түгелме? Әйе, ни пычагыма куркып, шөбһәләнеп торырга соң? Барыбер якын арада бер аңлашмыйча котылып булмаячак...

— Шулай, уйлашуларны сузмабыз, аннары ныклап киңәшербез,— диде ул, баягы сүзне әле һаман хәтерендә тоткандай. Үзләре янәшәсендәге кысык иренле бер хатынның ике арадагы гәпкә колак салырга тырышуын сизеп, Вероника Борисовнага будкадан читкәрәк тайпылырга ымлады. Биш-алты адым читкәрәк атладылар. Госман уч төбенә йөткергәләп алды, аннары сәер ашыгучанлык белән, сүзләрен әвәләп пышылдый башлады:

— Тик ни... Вероника Борисовна, мин ни... сезне алдан ук кисәтмичә булдыра алмыйм, парткомнан читләшергә уйладым әле мин. Кабаттан сайлануга кул-аягым белән каршы!

Ханым зонтигын җәеп җибәрергә итенгән хәрәкәтеннән бүленеп, башын капыл күтәрде дә гаҗәпләнеп Госманга төбәлде:

— Ничек? Ничек?

— Шулай, кул-аягым белән каршы! Ике көймә койрыгын тотудан туйдым инде. Ныклап берсенә утырырга да каерып-каерып ишәргә кирәк мина! Аңлыйсызмы: заводта мин — иң әүвәл фән кешесе, фән!..

— Нәрсә, партия эше зыян итәмени сина? — Вероника Борисовнаның болай да салкыннан күгәренгән йөзе бөтенләй караңгыланып кит-

те. Ә Госман, әйбер урлап тотылган малай шикелле, колак яфракларының кызышып яна башлавын тойды.

— Партия эшеннән димим, партком составыннан китәм, дим... Бер генә чанага җигеләм! Инде сез дә хәлне аңламагач, Вероника Борисовна...

Госман, гәүдәсенең җинелчә калтырануын басарга тырышып, ныграк тавыш белән үз туксанын тукырга кереште. Менә ул инженер кеше, техник фәннәр кандидаты, әмма көн тәүлегендә ул үзенең төп хезмәте белән күпме генә шөгыльләнә ала соң? Бик күп вакыты жыен вак-төяк артыннан чабып, төрле утырыш-киңәшмәләрдә утырып уза. Ярый әле, кичләрен калгалап, хәлне аз-маз төзәткәли... Әнә бит министр кулы белән расланган инструкциядә дә үзәк лаборатория житәкчесе турында бик тә ачык итеп «баш химик» диелгән... Заводта хәл ителәсе проблемалар, тикшерәсе-табасы нәрсәләр азмыни әле? «Җегәре бар, ничек тә өстерәр» дип, бик күп нәрсәне бер кеше жилкәсенә аудару дөресме, гаделме? Заводта алмаш беткәнмени, колачны нигә киңрәк җәймәскә? Партком бу хакта да төптән кайгыртырга тиеш ләбаса...

— Съездданмы син мондый каты, усал уйлар белән кайттың, Госман Габдулыч?

— Съездан... Искә төшерикче, күптән түгел генә генеральный секретаребыз да ничегрәк дигән иде әле? «Хәзерге заманда һәр коммунист үзен зур иҗатчы дип аңларга тиешле, үзенең бөтен сәләтен, акыл һәм рухи жегәрен иң кулай, иң оптималь юнәлештә, ягъни һәркем үз урынында, җигә белергә тиешле!» — дигән иде түгелме?

— Бөек Ленин фикере...

— Әйе, чишмә башы...— Госман тирән-тирән сулап бер мәлгә тукталып торды. Бая очрашып юл алгач та сөйләшкәннәре хәзер аңа бөтенләй вак һәм әһәмиятсез кебек тоелды. Ә бусы.... Әйе, хәзер инде ерганак юл алган, аны кабатлап буу мөмкин түгел.— Съезд бик нык уйландырды, рухландырды, әлбәттә. Канатлар үсеп чыкканлыгын аермачык тойдым... Ләкин, Вероника Борисовна, әйтсәм әйтим инде, күңелгә юшкын да кунмады түгел. Ни өченме? Безнең ише завод җиреннән вәкилләр өч бөртек кенә иде анда. Өч бөртек! ВХОда демократия дигән нәрсә белән дә бик үк исәпләшмәгәннәрдер кебек тоелды хәтта. Бәлкем, юбилей съезды булганга күрә шулайдыр. Ярый, бу ягын калдырып торыйк. Элек-электән бер күңелсезрәк тенденция сизелә: югарыда, бигрәк тә үзебезнең ВХОда фәннең түбәнге катламына бармак аша гына карыйлар сыман, һаман да күләгәдә тотмакчылар кебек. Ә бит чынлыкта түбәндә чиксез потенциаль мөмкинлекләр бар лабаса. Мисалга үзебезнең заводны гына алыйк, ә? Күктә кояш бер. Ул үзенең нурларын һәркемгә тигез өләшә. Фән үзе кояш, аның тирәсендә дә меңләгән, миллионлаган йолдызлар бар. Төрлесе-төрле яктылыкта җемелли. Без дә үзебезнең таләпләребезне куя белергә тиешле! Югарыда бераз айный төшсеннәр, дим. Хәер, аның өчен генә дә түгел... Шулай, Вероника Борисовна, безгә дә акыллы, нурлы йөзләребезне күләгәдән яктыга чыгарып күрсәтергә бик вакыттыр ич?!

— Бәхәссез аңысы. Замана сулышы...

— Әйе, замана сулышы... Ләкин парткомнан читләшсәм дә, партком үзе миннән читләшмәстер, шәт...— Госман авызына янә сигарет капты. Бармаклары калтыранганга мы, шырпысы тиз генә кабынып китә алмады.— Нигәме? Турысын әйтим: мин үзебездә ВХОның дилбегәсен үз кулыма алмакчымын. Властька кызыгудан-нитүдән түгел, билгеле... Ни өчен завод җирендә ВХО советы баш инженерга буйсынырга тиеш? Кайсы «акыллы баш» уйлап тапкан канун ул? ВХОның Бөтенсоюз Правлениесы Президиумының махсус күрсәтмәсе, имеш. Дүрт-биш ел әүвәлге күрсәтмә... Нилектән? Ул заманда эшләрне юньле оештыра белмәгәнлектән ул шулай. Бик тә уңай, әлбәттә: техсо-

веттамы анда, янсә бүтән берәр утырыш-киңәшмәдәме берәр әйбәт чара каралса, шалт, ВХОга да бер «карга» утыртып куябыз. Эшләр шуңа күрә ал да гөл булып күренә. Ә чынлыкта? Мин үзем ВХОда совет члены — пычак та кырмыйбыз без чынлыкта, валлаһи... Ә бит замана, дибез, нык үзгәрде, дибез. Заводта инженер-техник работниклардан йөзләгән кеше ВХОда исәпләнә, аз көчме бу? Йокымсыраганнарны уятып, чын иҗат эшенә тарта алсак, начар булырмы? Мондыйны партия дә читкә какмый, киресенчә, үз эше, үз вазифасы кебек карый шикелле, дөресме?

— Ай-яй, тирәнгә кереп киттең, Госман Габдулыч!

— Тирәнгә кермичә булмый, ярамый. Аннан килеп, тәкъдим дигәннән...

Автобусның якынлашуын икесе дә абайламады: алгы тәгәрмәч күлләвеккә басып үткәнгә, боларның плащ-пальто итәкләренә пычрак чәчрәде. Ләкин бу хәлдән бигрәк, сүзләренең капыл гына өзелүенә кәефе кырылды Госманның. Ул усал иттереп шоферга бармак янады.

Автобуска кергәч, гәпләре, әлбәттә, яңартылмады. Буш урыннар булса да, икесе дә басып бардылар. Вероника Борисовнаның какча йөзе үтә җитди, хәтта чыраендагы баягы караңгылык тагы да куера төшкән сыман иде. Кресло тоткасына ябышкан көенчә, вак сикәлтәләрдә тирбәлә-селкенә, мыштым гына бара бирде. Госман да шулай... Әмма монысының гәүдәсеннән дә болайрак җаны кымыр-чымыр сикәлтәләнә иде. Кызганыч, күңелдәгене әйтеп бетерә алмады. Ә бит... Әйе, ни өчен, әйтик, партком каршысына, бүтәннәренә өстәп, тагы фән прогрессы белән шөгыльләнүче махсус комиссия төземәскә? Инде аны артык санасалар, парткомның үзендәге производство секторын бик әйбәтләп икегә бүләргә мөмкин ич. Берсе агымдагы, көндәлек мәсьәләләрне кайгыртса, икенчесе алдагы көн проблемалары, фән-техника прогрессы белән җитәкчелек итәр иде. Соңгысы өчен бик тә кулай белгечләр дә юк түгел бит: әнә Васил Землянов янсә гипосульфит башлыгы Галиуллин...

Ә Вероника Борисовнага, әлбәттә, җиңел булмаячак: ни дисәң дә, килешеп эшләделәр, тиктомалга тешләшмәделәр. Госман бик әйбәт белә иде: оештыру эшләрендә секретарьның уң кулы — Герой Белобородов булса, сул кулы — Госман иде. Вероника Борисовнаның кабаттан сайланачагына шикләнмәскә мөмкин, аның яңа таянычы кем булыр, һәм ул ана тиз генә күнегеп, ияләшеп китә алырмы?

Үзәк лаборатория турысында Госманга төшеп калырга кирәк иде. Шунда җитеп килгәндә, Вероника Борисовна уйчанлыгын басып, моңсу гына көлемсерәде дә:

— Кешене шулай бик якыннан беләм дип йөргән буласың, ә ул... Бая син, больницадан чыгып килгән чагында, бер төсле ялтыраган идең, ә соңыннан бөтенләй бүтәнчә... Ярый, хәерлегә юрыйк,— дип пышылдады.

* * *

Лабораториядә эш көне тәмамланганга күрә күпчелек халык кайтып киткән, тик кайбер бүлмәләрдә, җыештыручы Мөстәкыймә апалары әйтмешли, «төн күбәләкләре» генә кыштыр-мыштыр килә иде. Шул «күбәләкләрнең» атасы — Госман үзе...

Кабинетына кергәч, ул пальтосын урындык артына элеп, аның пычраган итәген батарея җылысына борыбрак куйды да уйга калды... Аклап җиткердеме икән Вероника Борисовна? Ул да якламаса, конференциядә самоотвод бирүләре, һай, ансат булмаячак. Бәлкем, шәһәр комитеты секретаре белән алдан ук аңлашып куюю хәерлерәк булыр? Чынлап та, нигә куркырга? Завод эше өчен ләбаса...

Юк, хәзергә барын да онытып торырга!.. Тегендә Рива белән Зөлфә чәйнекләрен инде куйганнардыр. Бик шәплән, куе итеп чәй эчеп алырга да ике-өч сәгатькә эшкә чумарга кирәк — иң татлы минутлары шул аның...

Телефон янына килеп басты. Лабораториядә тоткарлануын өйдәгеләргә әйтмәкче булды. Трубканы улы Рөстәм алды:

— Әниме? Өйдә-ә... Ә син озак торасыңмы соң? Бүген, әтием, «В мире животных!» Хи, кайтмыйсың икән... Әниме? Безгә бер хат килгән иде, шуны укыды да диванга сузылып ятты.

— Нинди хат? Әбиеңнәнме? Ни язганнар?

— Әбидән түгел лә... Бер ападан бугай... Әниме? Телефонгамы? Килми бит. «Кирәк булса, үзе кайтыр әле», ди... Юк, авырмый да үзе...

«Минә сина... Бу ни хикмәт тагы? Нинди хат, нинди хәбәр икән?» — дип, тәмам аптырашта калды Госман.

## 16

Зөбәрҗәт баш астына ак мендәр салып, өстенә кërән шакмаклы кызгылт одеялны бөркәнгән дә диванда бөгәрләнеп ята иде. Йөзе-кыяфәте күренми. Госманның йомшак кына эндәшүенә җавап кайтармады.

Рөстәм өстәлдә яткан зәңгәр конвертны алып әтисенә сузды:

— Менә ул хат, әтием. Почтальон апа тапшырганда ук ачылган иде...

Урталай бөкләнгән гап-гади дәфтәр бите. Зәңгәр кара белән шома һәм бик матур итеп язылган. Беренче сүзләре ук Госманның йөрәгенә кыздырган без булып кадалды: «Сөеклем, кадерлем Госман!..»

Хат бик кыска иде, ярты биттән аз гына артып киткән иде, Госман калган хәтлесенә бер тын эчендә күз йөртеп чыкты:

«Нишләвең инде бу синең, кадерлем! Ленинградларга барып кайткансың икән. Барганда Казанда тукталгансың икән. Нигә инде миңа сугылмадың, нигә күренмичә киттең? Мин бит сине, бәгырь кисәгем, һаман да зарыгып көтеп ятам. Әллә онытгыңмы инде зәңгәр күзле сары чәчкәңне? Әллә башка берәүне таптыңмы? Казан каласы зур бит. Юк-юк, ышанмыйм!.. Син моннан болай кайчан киләсеңне алдан хәбәр ит, мин әзерләнеп, көтеп торгалармын. Эшемә язсаң да, өемә язсаң да ярый, гаеп итүчем юклыгын беләсең ич... Бик-бик сагынып калучы сөекле Фаягөлең дип белерсең...»

Госман берара аңгы-миңге булып торды... Хатны ертып ташламакчы иде, ертмады, зәһәр ачу белән бөгәрләп идәнгә атты. Ачы сыкрануы кысык, кансыз иреннәре арасыннан сытылып чыкты:

— Кабахәт җан!.. Ниткән Фаягөл? Кем эше булыр бу? Тфү!..

Диван авыр кымшанудан шыгырдап куйды. Гүя Зөбәрҗәт үзе түгел, яткан диванының пружинасы теш шыгырдатты:

— Җил исми яфрак селкенми, акыллым!

— Яфрак? Җил?.. Эх, Зөбәрҗәт!

— Бәрәңге белән колбаса кыздырган идек. Кофе да кайнаган. Инде суынгандыр. Җылыт...

Башын ике кулы белән дә кысып, өстәл янына утырды Госман. Былтыр да шулай исемсез-нисез бер открытка килгән иде. Анонимка. Әмма штемпеленә карaганда, анысы да Казаннан җибәрелгән иде. Анысына да Зөбәрҗәтне башта бик нык үпкәләп, кырлы-мырлы кыланган, тик соңга табарак, иренең гөнаһсыз икәнлегенә, кемнеңдер усал, мәкерле ният белән кыланганлыгына тәмам ышангач кына, йомшарган иде. Ә бит бусы... Госман, нелеп, идәндә йомарланып яткан конвертны алды, төзәтеп, күз салды. Исемен генә түгел, зәңгәр конверт тышына төп-төгәл адресын да, хәтта фамилиясен дә куйган бит, кабахәт.

Кинэт Госманның зиһене яктырып киткәндәй булды, һәм ул урыннан купты да, иренен тешләп, телефон янына килде. Телефонист кыз Казан белән сөйләшергә заказны шундук алды...

Кухняда җылымса кофены бокалга салмыйча, кастрюль кырыеннан гына чөмергән чагында, миендә икенче төрлерәк уй кайнап алды. Әйе, нигә җебергә, нигә сабырлык күрсәтмәскә соң? Үч итеп!

Кире олы якка чыккач, өйләрендәге пошаманлы, явыз тынлыкны ярып, тиле кешедәй шаркылдап көлеп җибәрде:

— Ай-яй, зәһәр шаярту булды бу! Кара борыч чәйнәгәннән дә яманрак!..

— Синһа көлке дә... Ярый әле, әнкәй кайтканчы килде ул нәмәстәкәй, югыйсә, бик күңелсез булыр иде,— диде Зөбәрҗәт, юрганын башына ук каплап.

— Ә хәзер бик күңелләмә?

Телефон чылтырады. Казан линиясенең бушрак сәгате иде, ахрысы. Бәхетенә, Зыя үзе туры килде. Җиңелчә генә хәл-әхвәл белешкәләп алгач, Госман, тавышындагы пошаманлык төсмерен басарга тырышып, мондагы хәлне аңлатырга кереште.

— Нинди хат? Нинди Фаягөл? — дип гөрләде чыбыкның теге очы, хәлне бик үк аңламыйча.

— Алайса, тыңла, укып күрсәтәм.— Госман, кулындагы кәгазь битен җәеп, утка табан тотты.— Иң башта: «Сөеклем, кадерлем Госман» дигән...

Диван янә бик яман шыгырдап куйды. Зөбәрҗәт атылып килеп тә җитте, хатны ире кулыннан тартып та алды.

— Син нәрсә?! Телефонисткалар колак торгызып тыңласын, дисеңме? Инде болай да китергәндә үк ачык иде хатың...

Госман, нишләсен, тамак кыргалый-кыргалый, буылып калгандай итте, аннары, ихтыярсыздан, беравык кеткелдәп торды, тик шуннан соң гына, сүзләрен җыя төшебрәк, Зыяга төп максатын аңлатып бирде.

— Эһе, сезнең Казан каласында йөгәнсез, азгын хатыннар юк түгел, дисең, алайса... Әйе, әйбәтләп белеш әле: Фаягөл дигән кәнтәй кем икән ул? Адресымы? Бар. Язып ал: Комлев урамы, йорт 83, квартирасы тугыз... Ә фамилиясе эт эчәгесе кебек озын: Минсәхибгәрәева... Пожалуйста, Зыя, сузмасаң иде...

Кызлары Ләйләнең олыларда әллә ни гаме юк иде. Ул үз почмагында, авыз эченнән генә көйли-көйли, курчакларын йокларга әзерләп матавыклана иде. Ә уллары Рөстәм исә, әтисе белән әнисенең сәер сүз алышкалауларына, әкәмәт кыланышларына аптырап, колак сагайткан иде. Телефоннан сүз өзелүгә үк, ул ыңгыр-шыңгыр килебрәк торды да каш астыннан гына әнисенә текәлеп:

— Әни дим, ә кем ул кәнтәй? — дип сорады.

Ирле-хатынлы бер-берсенә гаҗәпсенеп карашып алдылар. Зөбәрҗәт улының башыннан сыйпаштыргалады.

— Улым!.. Барын да белергә башың яшь әле синең!.. Аны әтиең болай гына, сүз арасында гына әйтте... Чүп сүз, яман сүз... Ярар, улым, телевизорыңны йоклап калма тагы.

Телевизордан бик кызыклы фильм күрсәтәләр иде. Инглиз фильмы. Африка урманнарында Җуди кушаматлы маймыл маҗаралары... Карт арыслан, авыр койрыгын селтәштергәләп һәм ара-тирә үкергәләп, җинел диварлардан торгызылган җәйге йорт алдында ыспай гына ята бирә. Хуҗалар кыргый хайваннарны, төрле киекләрне күзәтү һәм дәвалау белән матавыкланып йөргән аулак бер сәгатьтә, әлеге йортка маймыл көтүе һөҗүм итә... Көлке артыннан көлке! Рөстәм белән Ләйлә чыркчырык көлешәләр — идәндәге келәмгә берсе сузылып яткан, икенчесе аяк бөкләп утырган,— әниләре Зөбәрҗәт тә, инде хәзер диван почмагында бөрешкән хәлендә, «кһе-кһе» итеп өн сиздергәли иде. Госман

үзе дә онытылырга тырышып карады. Әмма күңеле зәңгәр экрандагы кызыкларга ияреп китә алмый иде. Теге яман хат аның моңарчы тыныч яшәгән җанын әледән-әле йолыккалап, чәнчеп куйгалый иде... Госман Казандагы таныш-белешләрен күңел иләге аша үткәзеп азапланды. Дуслары, яхшылык күргән яисә үзе күрсәткән адәмнәре бар, әмма дошман диярлеге арада бөтенләй юк иде сыман... Кайчан, кемнең юлына киртә торгызганы, кемнең койрыгына басып үткәне булды соң? Ә бәлкем, бөтенләй Казанда да түгелдер, бәлкем, мондадыр? Әйе, хатны шушында язып, аны Казандагы почта ящигына ташлатуы кыен эшмени?

Үзәк лабораториядә эшли башлагач та: «Ул тиклем хатын-кыз арасында чуалуның ни икәнен чамалыйсыңмы, егет? Акылыңны җуйма»,— дип, дусларча искәртеп куючылар булгалаган иде. Госманга кадәр аның урынында Бабич дигән берәү утырган иде. Олы кеше, карт кеше... Бабичка кадәр үзәк лабораториягә гел диярлек хатын-кыз җитәкчелек иткән. Ул чакларда лабораториядә хатын-кыз унбиш-егермедән арткаган, ә хәзер бит алтмыштан ашып китте ләбаса. Анысы да хак: Госманның дәрт-дәрманы ташып торган чагы. Әмма аның моңарчы берсе белән дә əвеш-түеш кыланганы булмады.

Юк, Госманның үз кулы астында эшләүче хатын-кызларның берсе турында да яман уйлыйсы килми иде. Әмма дөньяда аның лабораториясе генәмени, әнә әйләнәсендә завод бар, зур булмаса да, кала бар бит әле. Арада кемнәр юктыр, дисең...

Телевизорда кинофильм бетеп килгәндә, Госман Зөбәрҗәтнең боек, хәлсезрәк тавыш белән:

— Ә кем булыр дип уйлыйсың, чамалыйсыңмы? — дип пышылдавын ишетте.

— Белсәмме?! Агулы тешләрен эскәк белән умыртып чыгарыр идем! Юк, судка бирер идем! Бүтән бәдбәхетләргә дә сабак булыр иде, ичмаса!..

— Инде дә калай этәч син, Госман!..

Балаларны йокларга яткыргач, Зөбәрҗәт ике мамык мендәрне дә бер-бер артлы һәйбәт кенә кабарткалап, үз ятаклары түренә сөяп куйды да моңсу һәм нәүмиз төстә иренә эндәште:

— Ятасыңмы? Әллә тагы утырасыңмы?

— Ятармын... Утырсаң да, барыбер башка берни кермәс. Бер кичне әрәм иттерделәр, кабахәтләр...

Бер кичне генә микән? Дөрес, өйләрендә Сафура бураны купмады кубуын, әмма шулай да әшәке җил кузгаткан кара тузан күңелләренә ачы юшкын булып куначагын ир дә, хатын да аермачык сизә иде.

## 17

Соңгы вакытларда Мирыч әллә нишләп китте әле. Төнлә тыныч кына яткан җиреннән кинәт сикереп тора да, ап-ак күлмәк-ыштаннан өрәктәй калкынып, уң кулын алга таба хәтәр сузып:

— Бей гадов! Огонь, ребятки, огонь! За Родину, за Сталина!..— дип, ачы аваз белән кычкырып җибәрә, аннары капыл идәнгә сузылып ята да: — Воздух! Ложись...— ди.

Сугыш беткәненә инде чирек гасыр...

Ул анда минометчы булган...

Беренче мәртәбәсендә хатыны Рабига да, үги улы Фуат та йокыларыннан котлары алынып уяндылар һәм, ни кылырга белмәстән, аңгыминге хәлдә катып калдылар. Әмма Мирычның бу тиле халәте алай озакка сузылмады, болар ут яндырганда инде ул, акылына килеп, идән уртасында күлмәк изүен шытырдатып кыскан килеш, үтә нәүмиз, үтә

мескен кыяфәттә туңкаеп утыра иде. Калтыранган тавыш белән ынгырашып эндәште:

— Фуат, салкын су бирче... Ә син, Рабига, маңгайга...

Су эчеп, маңгаен яулык белән бәйләгәч, мыштым гына караватка барып ятты. Мирычка, әлбәттә, оят иде, бик тә оят иде. Ә болар, аналы-уллы, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнүләре аркасында, аны-моны сорашырга да кыймадылар, кешене тизрәк тынычландыру ягын карадылар. Тик иртәгәсен генә аз-маз аңыштылар.

Элгәре Березникида яшәгән һәм эшләгән чагында да булгалаган икән. Бигрәк тә берәзлексез аракы эчеп таушалган көннәрендә еш җәфаланган... Монда килеп, тол хатын Рабигага йортка кергәнче, Мирыч өч тапкыр өйләнеп, өч тапкыр хатыннарыннан колак каккан кеше иде. Шул өчнең берсе, иң азаккысы бу ирдән бала булмаганлыгына аның әнә шулай җиде төн уртасында бер-ике мәртәбә «җенләнүеннән» соң: «Контужный гына түгел, шыр дивана да икән әле. Ходаем сакласын, төнлә буып үтерер. Тол яшәсәм яшәрмен, иллә мәгәр, ялгыз башым, тыныч колагым булыр!» дип, чыгып сызган. Тыныч кына, шыпырт кына чыгып сызса бер хәл, юк бит, ул пумала баш, үзен яклау нияте белән, ирен яманлап, аның төнге «хикмәтләренә» тагын әллә ниләр өсти-өсти, бөтен Березники каласына рисвай итеп йөргән, имеш. Рабига ханым да, улы Фуат та моңарчы берни шәйләмичә яшәгәннәр иде, инде белделәр: Мирычның тегендә Березники химкомбинатындагы әйбәт кенә эшен, квартирын калдырып, Чулман ярларына килеп чыгуының төп сәбәбе әнә шул икән.

Инде менә монда да өч-дүрт мәртәбә кабатланды. Югыйсә, аракы дигән иблис эчемлеген авызына алмаганына да бишбылтыр — инде аның тәмен дә онытты шикелле, чөлем тартуын ташлаганына да өченче елы китте — хәзер ютәл азабын бөтенләй белмичә, рәхәтләнеп сулап йөри. Әйе, сугышта җәрәхәтләнгән уң аягының ара-тирә, бигрәк тә көзязларын, ачы сызлаштыргалаулары́н искә кертмәгәндә, ярыйсы гына әйбәт, хәтта шәп диярлек иде сыман. Эшеннән дә канәгать; цехта хөрмәт ителүчеләр арасында йөри. Әмма барыннан да бигрәк, Текә Ярның аулак бер урамында утырган йортка керүеннән галәмәт уңды: бу хатыны Рабига һәм аның улы Фуат белән, хәтта ул үзе көтмәгән дәрәҗәдә, бик тынышып, бик тә ипле тору бәхетенә иреште. Тагын ни җитмәгән? Шулай, тамагы тук, өсте бөтен, җаны тыныч иде Мирычның. Ләкин бары да килешле, бары да уңай һәм кулай булып, дөнья рәхәтен татып яшәргә ирешкәч кенә... каян сытылып чыга соң бу каһәр суккан сугыш зәхмәте?

Әлбәттә, кеше-карага сиздермәскә сүз куештылар. Рабига ханым ризыкны тагы да төрләндерә һәм тәмләндерә төште, ирен юк-бар белән артык йөдәтмәскә, борчымаска тырышты.

Җылы сүз — җан азыгы, диләр. Тәгаен, шулайдыр, халык белмичә әйтмәгәндер. Ләкин сугыш кырында бомба шартлавы белән бергә Мирычның җанын да, зиһенен дә җимереп-сытып кергән ул кара җен кайдадыр бик тирәндә, бик төптә оялап алган иде, ахрысы. Бер дә бер төнне ул яман җен янә хәрәкәткә килеп һәм бусында абзыйны тагын да тупасрак, ямьсезрәк кыландыртып, барын да зур хафага салды. Ире, тынычланып, әүвәлге сәламәт хәленә кайткач, Рабига ханым бик хафаланып:

— Тагы да тирәнгәрәк китмәгәе, врачка күренмичә булдыра алмассың. Нигә сузарга? — дип киңәш итте. — Сугыш инвалиды ич син, барыбыз өчен дә кан койган кеше, ниеннән оялырга, ди?

Фуат та әнисе сүзен куәтләде:

— Шаярма, Мирыч: уеннан уймак чыгып куймагае...

— Сез бигрәк инде, — дип кеткелдәгән итенде Мирыч, аларның менә шушылай бик тә ярдәмчел булуларына һәм чын-чынлап үз, якын иту-

ләренә җаны тәмам эреп: — Вакыты җитеп, үз җае белән генә үтмәсме дип өметләнгән идем. Ярар, көндердегез: күренергә кирәк, күренербез... Тик невропатологка эләгүе генә бәла булмагае.

Заводның үз поликлиникасында невропатолог юк иде. Мирычны терапевт ханым карады. Аннары, лабораториядә тиешле анализларны алдырткач-ниткәч, Акбалыктагы район поликлиникасына барып, психоневрологка күренер өчен махсус кәгазь язып бирде.

Андагы врач Мирычны әйбәтләп карады, мондый авыруы белән врачка күренми йөрүе өчен шелтәләп тә алды, аңа ике-өч төрле дару язып бирде, ахырда завкомга барып, санаторийга путевка юлларга кушты, курорт картасы тутырып бирербез, диде.

Цех башлыгы Белобородов — үзе дә сугышны уртасыннан ерып узган, анда тән һәм җан җәрәхәтен аз алмаган кеше — Мирычның врачларга нилектән күренеп йөрүләрен бик әйбәт сизенгән иде, агай эшкә килүгә үк, аны кабинетына дәшеп, барын да бәйнә-бәйнә төпченергә кереште. Мирыч та тел яшереп торуны кирәксенмәде, бу өлкән иптәшенә үз халәтен дә, психоневролог киңәшләрен дә ипле генә аңлатып бирде. Моның соңында Белобородов өстәл тактасында бер мәл бармак биеткәләп торгач:

— Ярар, җылы колак булмыйк, мә кәгазь, менә авторучка, утыр, яз! — дип боерды һәм үзе үк әйтә-әйтә, үткен генә сүзләр дә кыстыргалап, Мирычтан завком исеменә гариза яздырырга тотынды.— Инде тиз арада гына юнь чыгара алмыйлар икән, үзем профсоюзларның өлкә комитетын дыңгырдатырга керешермен. Табарбыз, булыр ул путевка, Мирыч!..— диде.

Моңа кадәр Мирычның үз гомерендә бер-ике мәртәбә ял йортында гына булып кайтканы бар иде, ә монда бит санаторий!..

Гаризасы завкомда — инде көтәсе генә калды...

Врач-психоневролог тәкъдим иткән «препарат»ларның файдасы булды микән, әллә, алардан да бигрәк, Мирычның үз дару-әмәле: көн аралаш хатыны Рабига ханым яккалаган кызу мунчада бик шәплән чабынып чыгуларның шифасы тиде микән, атна-ун көн үтүгә, абзагыз гәүдәсендә сәер яңару, дәртле җиңеллек тоеп йөри башлады. Ах, бу адәм баласының миһербанлылыгы!..

## 18

Заводның агач тара цехы каланың үзәк урамы белән түбән төшкән чагында урталыктарак, текә генә яр итәге белән Туймә елгасы арасындагы уйсу бер төшкә урнашкан иде. Әле сәүдәгәр һәм эшкуар Ушков хәзрәтләре тарафыннан ук билгеләнеп, теге заман өчен уңай да, кулай да дип табылган урын: бердән, ышыкта, икенчедән, ут-күз чыга калса, сүндерергә суы да янәшәдә генә...

Менә шунда, бер катлы таш бинаның ярыйсы гына иркен һәм якты бер почмагында үз эшенә керешкәч, Мирыч даң-доң чүкеч тавышлары һәм цехның алдагы өлешләреннән өзлексез яңгыраган пычкы авазлары, машина гөрелтесе астында да, күңелен иртәдән үк биләгән шатлыклы хәбәр тәэсиреннән котыла алмыйча, һаман да кияүләре Васил белән кызлары — яшь хатын Сәриянс һәм аларның әле яңа гына дөньяга килгән нарасыйларын уйлады. Аннан килеп Фуатны... Моңысы кайчан инде яшь кәләшен өенә алып кайтыр да сөйгән кызы Асияңеке шикелле үк чем-кара күзле бәбиләрен боларның җылы кулларына тоттыра белер? Әнисенең сүзенә карамасын, ашыксын иде, ичмаса, оешмаган бәндә кисәге...

Мирыч үзенең маркасын бик тә югары тота. Һич кабатламас, кирәкмәгәнгә тузынмас, таркалмас, тик үзе генә белгән ипле бер җай, бер

ритм белән таза кулларында чүкечне уйната бирер. Биш-алты минут саен төбе җиренә җиткерелеп төпләнгән, ырмаулары һәйбәтләп ныгытылган һәм эченә капкачы да салынган шома ак мичкә зал уртасына тәгәрәп китәр. Әйе, тәгәрәтеп җибәргәнче, күнегелгән бер хәрәкәт белән мичкә төбенә авыр чүкечен орып ала: һавада шул мизгелдә, һәйбәт тартылган барабан шикелле, шома һәм тыгыз аваз яңгырап куя: шап!..

Менә ул янә бер мичкәне урталыкка этәреп җибәрә дә, уч төбенә төкереп алгач, авыр чүкечен кулында салмак кына уйнаткалап, икенче мичкәне дыңгырдата башлады. Димәк ки, кыз бала... Бәхете дә үзе белән бергә үк туган булса ярый инде. Әнисе ни хәлдә икән, инде торып йөри башлады микән? Тик ул нәнигә ни дип исем кушарлар икән? Кияү белән Сәрия инде уйлашканнардыр уйлашуын да... Әйе, үзебезчә да бик матур, колакка бик ятышлы булсын, урысча да бозылмыйча, шап яңгырардай булсын иде. Әйтик: Нурия, Айзирәк, Мәдинә... Беткәнмени дөньяда матур исемнәр?

Читтән кызыксынып күзәтеп торучы булса, хәйран аптырап колак артын кашыр иде, мөгаен: карт оста Андрей Павлыч та, Мирыч та әнә шулай каударланмыйча гына эшли бирәләр, әмма смена азагында, бактың исә, нормада билгеләнгәннән шактый артык мичкә тәгәрәткән булалар. Акрын киткән, морадына тизрәк җиткән, дигәндәйрәк кыланалар. Әмма иң әһәмиятлесе: алар кул астыннан тәгәрәшеп чыккан мичкәләр һәркайсы да җырлап тора лабаса! Агайлар үзләре дә бик белә: гидраттамы яисә реактив тозлар цехындамы, нәкъ менә алар әзерләгән шәп тарага продукциянең дә иң һәйбәте тутырылып, экспортка озатыла ич...

## 19

Төшке ялга туктадылар. Цех тынып калды.

Гадәттә, яшь-җилкенчәк тамак ялгарга ашханәгә чаба. Өлкәнрәкләр исә үзләре алып килгән ризык белән канәгатьләнә. Кызыл почмакның аулаграк өлешенә берничә өстәл тезеп куелган иде, шулар тирәсенә утырышалар да артель-артель берләшәләр. Кем ни китергән — рәхим ит, сыйлан! Техничка Бәдәр түтиләре аларга галәмәт олы алюмин чәйнеккә тутырып титанда кайнатылган хуш исле чәй кертә, теләгән кешеләр, үзара укмашып, шул ук түтидән шар кызуына көйләнгән махсус казанда чикмәнле бәрәңге пешертеп ала. Мирыч та, гадәттә, үз артеленнән бүленмичә, шунда гына туклана торган иде.

Ләкин бүген, кабарга тәгам алган булса да, аерылды. Аның күңеле бүген изгерәк нияттә: эшеннән бушагач та, яследән оныгы Альбертны алып, бала тудыру йортына Сәриянең дә, дөньяга әлерәк кенә килгән нәнечнең дә хәлен белергә барачак ул.

Бу вакытта ашханәдә чират зур булганлыктан, ул кафеда аяк өсле генә өчпочмак һәм кайнар кофе белән тамак ялгап алды. Аннары азык-төлек кибетенә сугылды. Сатучы ханымнан да, кибеткә кергән бүтән хатын-кыздан да Мирыч киңәш сорарга кыюлык итмәде, беравык киштәләрдәге ризык-нигъмәтләргә күз йөрткәләп, уйчанланып торды. Әйе, бүген таңда гына дөньяга бала китергән яшь анага иң әйбәте, иң ярардае ни булыр икән? Авызга тәм бирү өчен дә, сихәтләнү өчен дә иң шәбе шул булыр дип, ахырда Мирыч бер банка чия вареньесы белән бер шешә йөзем ширбәте, тагы бер-ике пачка кыйммәтле печенье сатып алды.

Тиз әйләнгән, ахры: цех эче әле һаман тып-тын иде. Ләкин озакламас, тагы ун-унбиш минуттан, бары да хәрәкәткә килеп, чыж-чыж, дыңгыр-даңгыр шауларга тотынырлар. Әлегә хатын-кыз кызыл почмакта тамак ялгап алганнан соң, тәмләп ләчтит сата торганнардыр, ир-атның беришесе «курилка»да тәмәке төтәтәдер.

Мирыч «курилка» бусагасыннан атлап, эче төтен эчендә чумуына, мондагыларның гәбе капыл киселгәндәй булды.

— О, Мирыч, әйдүк, әйдүк! — дип, кинәт гөрләп җибәрде тел бистәсе Гыйрфан, утырган җирендә авыр гына кымшангалап.— Синең монда кермәгәненә биш былтыр бит! Әллә ниме... бер сыйлыйммы үзеңне? Әйдә, бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй, зиһенеңне уйнат әле бер!

— Тәмәке беләнме? Фу, сезнең монда үзең тартмасаң да, тәгәрәп китәрлек инде!

— Әллә ниткән әүлия булдың әле син, Мирыч, аракыдан качасың, тәмәкедән дә...

— Акылы алтын,— дип кыстырды Бучкар Гарифы басынкы гына.

— Алтынмы-көмешме — анысын, туган, кеше үзе исән чагында әйтүе кыен... Туктале, Мирыч, мин сиңа бик әйбәт бер киңәш бирим әле, ипләп кенә тыңла. Утыр, дим, утыр! Теге чакны Ярыслауда шушылай ук тарныйда эшләгәндә күреп, гыйбрәт алдым мин. Безнең белән бергә Кирилл атлы бер агай эшләгән иде. Менә синең кебек, Мирыч, кул остасы, галәмәт тырыш бәндә. Шул Кирилл дәдәбез нишләр иде, дисең? Иртүк, смена башланганчы ук, безнең белән курилкага керә дә бик һәйбәтләп, бик тәмләп кенә бер папирос тартып ала. Шуннан, төпчеген сүндергәч тә, куен кесәсеннән бер чәки сөт чыгара да шунын төп-төгәл өчтән бер өлешен йотып куя... Ни өченме? «Тартуын тарттык, никотинның зарарын инде сөт белән каплап куйыйк» дип... Төш турында әбәт ашагач, аннары смена беткәч, тагын шулай. Көне буена өчне генә тарта! Кесәсендәге чәкие әнә шул папиросның агуын басарлык итеп чамаланган да... Әллә дим, Мирыч, син дә шулай итәсеңме? Тик шунысы жәл...— Гыйрфан кара төкләр баскан ияген кәрәктәй кулы белән сыпырып алды да, бәбәкләрен агартып, кисәк тирән һәм авыр иттереп ухылдап куйды.— Ул дәдәебез, озак та үтмәстән, һич уйламаганда гүр иясе булды шул. Ни сәбәптәнме? Алла белә. Сөтне азрак эчкәләгәнгә күрәдер, ахрысы...

— Синнән дә акыллы сүз, юньле киңәш-табыш чыгармы, дисәм...

— Адәм баласы нидән еш кына харап була? Әнә шул һаман да акыл дип, фәлән дип шашканга күрә... хе-хе!

— Житте, шыңгырдама, зинһар,— диде Бучкар Гарифы, тамагын усал гына кыргалап.— Мирыч кереп бүлдерде, сез миңа әйтмәдегез бит әле: нишләргә икән, Яр-Чулманга автозавод төзелешенә китсәм, минем шикелле кул остасына эш табылыр бит? Ишетүемчә, андыйлар үлеп кирәк, ди. Аннан инде, малай таза-сау килеш, акылына утырып кайтса, аны ничек тә үз яныма сыендыра белер идем. Я, ник дәшмисез? Сездән кеше киңәш сорый.

— Белмим, төрмәдән котылып кайткан кешене андый зур төзелешкә кертергә теләрләр микән? Булмастыр, ярамастыр. Алар бит, нихәтле генә акылга утырып кайтмасыннар, барыбер... көне житсә, бер ялтырамыйча түзмиләр,— дип, тубал башын селеккәләде Гыйрфан.

Хезмәттәше Сергей Мирычка бер-ике сүз белән төшендереп бирде: Бучкар Гарифының малае Марсель тегендә төрмәдә утырган җирендә дә Чулман ярларындагы зур төзелеш хакында ишетеп, кызыксына башлаган икән!

— Аның бит, шулай ипле генә эш күрсәтә белсә, утыру срогы кыскартылып, бер-ике елдан кайтып төшүе дә ихтимал... Шәт, дуңгыз булмастыр инде,— дип, моңсу гына кыяфәт белән иренен чәйнәде хәсрәтле ата.

— Ярый, малаең хакында ышандырдың, ди... Әмма син үзең, Гариф абый, монда семьяңны калдырып, йортың-бакчаңны ташлап китә алырсыңмы икән соң? Анда бару өчен, ай-һай, йөрәк тә кирәк бит әле. Синдә бар микән андый йөрәк? — дип шик белдерде Сергей.

— Шулай, тәвәккәллек кирәк! — дип, секундында ук күтәреп алды аны Гыйрфан.— Әй синең белән, Бучкар туган, тәвәккәллек, ичмаса, бер төнен дә янәшә кунып карамагандыр, үпкәләмә — турысын әйтәм... Ә малаең, ие, бәлкем, чынында да төзәлеп, адәм кыяфәтенә кереп кайтыр...— Гыйрфан калын кашларын кушып Мирычка сәер генә иттереп күз төшереп алды.— Ә теге кем... Мәрдәнев малае тагы да катырак режимлысына эләккән, имеш, тагын нидер кылган, ахрысы. Бу елны бердәнбер хаты килгән, анысы да: «Исән-сау гына әйләнеп кайттым, мин анда кара йөрәк Бөдрәшне — ягъни мәсәлән, сезнең Фуат Шайморатовны була инде — нишләтәсен үзем белермен, безнең башларны ул гына ашады» — дип әйтеп, бик тә хәтәр янаган, ди.

— Ә кем гаепле? — дип, аваз салды моңарчы дәшмичәрәк утырган Матвей Горбачев, почмактан Гыйрфан ягына кырыс, утлы карашын төбәп. Алар сиңа кеше талау, кибет басып йөрүләре өстенә, инде үтерешкә барып җитә язсыннар да...

— Бөдрәшкә Мәрдәнов малае Мәргән атканмыни? Аның теге Железняк дигән бандитына җиде кат сак, җиде кат йозак астында яту бик яраган да үзе, ә бу бит... Бөдрәш белән яшьләй үк бергә тәгәрәшеп диярлек үскәннәр ләбаса!

Мирыч ишек ягына күз ташлап алды, әмма чыгып китмәде, кызыша башлаган тамак төбен төкереге белән чылаткалап, баскан-сөялгән җирендә кымшанмыйча, мыштым гына тора бирде. Төкле танау Гыйрфан аңа төбәлеп:

— Бик тә ыспай гына, бик тә кәпрәеп кенә йөргән була да, бер дә бер заман, теге әшнәкәйләре белән исәп-хисап тотар көне җиткәч, бөтенләй туарылып, чәчелеп калмагае әле сезнең Фуатыгыз! — диюенә, Мирыч кинәт үз сүзләренә үзе буылгандай итте:

— Безнең Фуатмы? Безнең Фуат... бик... бик...

Шул мизгелдә ишектә техничкалары Бәдәр башы калыкты һәм түти, Мирычның җиңеннән тартып, аны цех җитәкчесе Белобородов үз кабинетына дәшүен әйтте. Мирыч беравык аңышмыйча торды, аннары ишек тоткасына ябышты. Ләкин бу килеш, ачы мәсхәрәләнгән хәлдә, чыгып китәргә ярамый иде. Ниһаять, аның сулышы ачылып киткәндәй булды, һәм абзый, сүзләрен кайнар ачу белән укмаштырып:

— Бик теләсә, Мәрдән-Мәргән ишеләрнең генә түгел, менә синең кебек, Гыйрфан, әзмәвер бәндәләрнең дә азау тешләрен коеп, кулларына тоттырырдай егет ул безнең Фуат! — диде дә ишекне шапылдатып ябып чыгып китте...

Цех башлыгы Герой Белобородов кабинетында Мирычның җанын телгәли башлаган әлеге ярсу чаткылары сүрелә төште, алар урынына күңелендә бөтенләй икенче хис-тойгы дулкыннары кузгалды...

Белобородов, дустанә, йомшак тавыш белән дәшеп, аны өстәле янындагы бердәнбер урындыгына утыртты һәм, елмаеп, Мирычка өчкә бөкләнгән озынчарак, шома кәгазь кисәге сузды.

— Менә сиңа, Мирыч, путевка! Завкомнан үзем алып чыктым... Өчдүрт көннән юлга кузгаласы булыр. Курортның да шәбе: Кавказның үзенә бит, ә!

Агайның иреннәре капыл җәелде:

— Шул арада диген! Тәки дуылдата белгәнсез икән, Аркадий Мефодич! Тик ни... миңа бирәр нәмәрсәгә кул куясы-нитәсе юкмы соң?

— Завкомга сугылырсың. Әйе, тагы бер тамга саласың булыр әле: юл чыгымнарыңны аз-маз күтәрешер өчен, сиңа утыз сум яздырган идем, монысын үзебезнең кассирдан гына аласы.

— Ничек инде? — Мирыч, нягин учлап, сәерсенү аша цех башлыгына текәлде.— Мин бит, Аркадий Мефодич, алай ук нужалы түгел...

*Дәвамы бар.*

## Фәннур Сафин

### Чулман

Утсыз төтен булмый, диләр,— хактыр,
ә төтенсез янгын буламы?
Таң атканда, алсу нурга төренеп,
дөрләп яна «Яшьлек» урамы!..

Ә дулкыннар биек ярга сикерә,
теләмичә аста калырга...
Яшь каланы дулкыннары белән
тели Чулман кочып алырга!..

Чал дулкыннар сары комны ялмый,
күбекләнә Чулман, агара...
Кайларгадыр дәшкән шикелле ул
көймәләрне бәрә ярларга!

### Романтиклар

Иркен далаларда булсак та,
грузовикларга тулсак та,
сорасалар бездән шул чакта:
— Юл тотабыз болай кай якка? —
— Без юлда!
Без юлда...
Без мәңгелек юлда!

Бераз гына сәер кеше без.
Бөек хыял белән көчлебез.
Палаткада — дала йортында
җылынабыз өмет утында:
— Без юлда!
Без юлда...
Без мәңгелек юлда!

Матурлыкка барган юлларның
иге-чиге мәңге юк аның.
Һәр матурлык,
бөтен зур эшләр
башланалар гади төзелештән!
— Без юлда!
Без юлда...
Без мәңгелек юлда!..

## Буранга йөз куеп...

Күз ачырмый торган
Тын алгысыз буран.
Буранга йөз куеп,
Мин юлларга чыгам.
Әй, буран!
Кар белән
Юлымны каплыйсың.
Тик язны көтмичә,
мин алга атлыймын!

Буранга йөз куеп
киткәннәр хәтердә:
Хакыйкать юлында —
билгесез кабердә,
Өши һәм калтырый
күк алар хәзер дә...

...Күз ачырмый торган
тын алгысыз буран.
Буранга йөз куеп,
мин юлларга чыгам...

## Яшьлек каласы

Әй, дусларым, хәзер Камада
нинди матур булып таң ата!
Җил, кызларның чәчен сүткәндәй,
дулкыннарны назлап тарата...

Бу җирләргә шундый биектән
таң нурлары төшкән уйнарга!
Ах, таң нуры, дисәм, яшь кала
шулай чагыла икән суларда...

Гашыйк җаннар аны төзиләр,
чын яшьләрчә шәһәр бу, җаным!
Алма кебек тора кызарып,
чыклар юа чорлар тузанын.

Яшь йөрәкләр мәңге ашкына,
романтика дәшә, ил дәшә.
Ярларына дулкын ыргытып,
дала белән Кама серләшә...

## Кама

Минем исемем Чулман иде,
хәзер — Кама,
Үзгәрә дә тора заман —
барсы яңа!

Моңсу идем, хәзер инде
башка көйләр.

Кырда икмәк үсә иде,
хәзер — өйләр!..

Элек ярлы, бай бар иде,
хәзер тигез.
Әйтерсең лә бертуганнар,—
игез-игез.

Ялкауланып саллар ага
иде элек...
Дулкыннарым ярга кага
хәзер көлеп!

Кеше суны буып ГЭСлар
төзи хәзер.
Арта гына бара бит, әй,
безнең кадер!

Яшьләр килә...
Бер-берсенә
гашыйк алар.
Тик бу ни хәл: кая һаман
ашыгалар?

Сирәк килеп, тиз китәләр
мине ташлап.
Дулкыннарым туймый кала
үбеп-назлап...

Минем исемем Чулман иде,
хәзер — Кама!
Үзгәрә дә тора заман —
бар да яңа!..

## Ялвару

Кама суларыдай дулкынланам
сине уйлап таңга кадәрле...
Бер айлы кич миңа тынгы бирми,
үзе жанга шундый кадерле...

Үткән-киткән, диләр,
беткән!.. диләр,
ә кем өчен яши үткәннәр?
Алар безнең йөрәкләрне сүнмәс
ялкыннарга салып киткәннәр.

— Янам, бәгърем!
Кил син, коткар мине?! —
дип кулларым сиңа сузылган.
Мәңгелеккә мәллә арабызда
чикләр булып офык сызылган?..

## Ник елмаймыйсың?

Жырлыйм дисәм, моңым бар,
сөйлим дисәм, серем бар.
Тик син генә елмаймыйсың,
әллә инде күңелең тар,
әллә берәр кайгың бар?

Мең кайгыңа мең жырым
әзер минем, күз нурым.
Кайгылардан саргайганда
жыр белән юатырмын.

Салкыннарда, буранда
син юлларда булганда,
җаныңа моң тулганда,
каршы чыгып алырмын.

Җырлыйм дисәм, моңым бар,
сөйлим дисәм, серем бар.
Ник син миңа елмаймыйсың?
Әллә синең күңелең тар,
әллә...
сөйгән ярың бар?!.

## Бир кулыңны!

Моңа кадәр, сылу,
кайда булдың,
әллә инде качып
айда тордың?..
Йолдызлардан гына
төштең мәллә?
Шундый самими син,
шундый садә.
Бер агачның ике
тамыры без,
бер үк кайгы белән
кайгырырбыз.
Бир кулыңны, бергә
китик әле,
бер бәхетне ике
итик әле!

Ямиль Мостафин

# ҮЗЕМНӘН ДӘ АРТЫК ЯРАТАМ

хикәя



Мин дөньяда аз тордым, ләкин намус белән яшәдем. Инде соңгы сәгатьләрем житте. Шуңар күрә үземнән дә артык яраткан бер дустым турында сөйләп калырга ашыгам. Кайберәүләргә ул сәер тоелыр. Үзеннән дә артык яратып буламыни дип әйтерләр. Ул дустым турында сөйләп бирсәм, сез, мөгаен, бу хәлнең мөмкин булуына һәм бу хиснең чын бәхет бирүенә ышанырсыз.

Ул көнне мин гомерем буена истә тотам. Аның белән без апрель аенда, Восстания мәйданыннан ерак түгел бер урында очрашкан идек. Мәскәүлеләр бу ыгы-зыгылы урынны яхшы беләләр: яр читендә мыжлаган тукмакбашлар кебек, машиналар әрле-бирле чаба, ә кешеләр мәйдан аша үтеп китәргә ашыгып чәбәләнәләр һәм уттан качкан тараканнарны хәтерләтәләр. Алар берберенә игътибар да итмиләр — һәркайсының үз эше.

Мәйданда күкләргә ашкан бер йорт тора. Мәскәүдә алар жидәү. Жидесе дә солдатлар шикелле бер-береннән аерып алгысыз. Караңгы көннәрдә ул йортның түбәсен болыт каплый, шуңар күрә йорт, башын кисеп алган шикелле, тәбәнәк булып күренә. Түбә астында таштан ясалган кеше сыннары утыра һәм алар кулларындагы скрипкаларга, китапларга, җәзбәләргә аптырап карыйлар сыман. Әйтерсең лә боларны безгә ни өчен бирделәр икән дип гаҗәпләнәләр алар. Боларның барсы турында да җентекләп сөйләгәнгә аптырамагыз, еллар үткән саен кешеләр аларга әһәмият бирми башлыйлар, иләнәләр, оныталар, үзләреннән башка берни дә күрми торган булалар.

Ул көнне апрельнең салкын бер иртәсе иде. Әйтерсең күктә кояш түгел, ай йөзә. Юкәләрдәге бөреләр бодай башагындагы бөртекләр кебек бүрткәннәр. Топольләр, борын төртергә торган яфракларын көн яктысына чыгарырга курыккандай, сагызлы яшьләрен түгәләр.

Бераздан мин дустымның хәле авыр икәнен белдем. Әледән-әле кулын күкрәгенә куып, авырлык белән генә йөри ул. Төннәрен бер дә йокламый икән. Ә ул искиткеч авыр хәл: төннәр озын һәм куркыныч булып тоела. Андый сәгатьләрдә кеше үзен галәм киңлегендәге бер тузан бөр-

теге итеп сизә һәм үз-үзен кая куярга белми. Ул аңлашылмаган бер тәшвишкә, караңгылыкның серле тынлыгына бирелә, җаны өши. Шул вакыт минем дустым таң атуына бар кешедән дә ныграк шатлангандыр, бәлки. Диңгез һәлакәтенә очраган кешенең җиргә аяк басарга теләве шикелле, көн тууын көткәндер ул. Әйтерсең лә таң белән аның хәле җиңеләячәк иде.

Борын заманнардан ук безнең ерак бабаларыбызны караңгы төн куркуга салган кебек, хәзерге заман кешесен дә караңгылык шөбһәгә сала.

Чыннан да, көн тууга дустым тамырларга кайнар канының каты бәреп агуын да, арган йөрәгенең туктап-туктап тибүен дә сизмәс булды. Аның күңеле яктырды. Шатлык, бәхет, газап белән тулы тормышы тынычланып киткәндәй булды, төне буе газапланып чыккан җанын балаларча соклану биләп алды. Төнлә коточкыч бер төш күрдем дип, ул үз-үзен ышандырырга да әзер иде инде. Ә хәзер хәтта үлемгә дә ышанмый башлады. Ничек шулай булсын инде ул: җир өстен мәңгелек караңгылык каплап алсынмы, кешеләрнең көлүләре, шау-шулары, тормыш ыгы-зыгылары инде бүтән кабатланмасынмы, табигатьнең мең төрле төсләре сүнсенме...

Бер вакыт, ул үзе сәламәтләнеп җиткәч, балалар кызамык чире кичергән кебек, барлык кешеләр дә ни белән булса да авырып алырга тиеш дип әйтеп куйды. Авыру кичермәгән, шуның газабын башыннан үткәрмәгән кеше сукыр кешегә охшый, тирә-ягындагы дөньяны ул бары бер төсле генә итеп күрә башлый...

Аның шулай уйларга хакы бар иде, күрәсең. Чөнки авырган чагында нервлары табигатьтәге кечкенә генә хәрәкәтне дә сизә торган катлаулы приборларга охшап калган иде.

Бер көнне авыр уйларыннан арынырга һәм кешеләр күрергә теләп, минем дустым Горький урамына чыкты. Иртәнге сәгать уннар тирәсендә биредә әле бернинди ыгы-зыгы юк. Анысы аның соңыннанрак, шәһәргә килгән кешеләр, сумка тоткан хатыннар һәм пенсионерлар йөри башлагач булачак.

Тимер юл вокзалы өстенә атланып торган Белорус күпере аша узганда, күперне ул бик зур китнең кара аркасына охшатты. Ә күпер өстендәге фонарьлар кит тәненә кадалган гарпуннарны хәтерләтә иде. Түбәндә вокзал мәйданындагы кешеләр кырмыскалар кебек йөгерешәләр. Метро янында эрекмән яфрагыдай зур кепкалы кавказлылар чәчәк сатып торалар. Эссе июнь көннәре булса да, өсләрендә яхшы кара костюм, күлмәкләренә янган ... коянган муеннарына, сәер булып, ак алъяпкычлары эленеп тора. Үзләре алтын тешләрен ялтыратып, тамак төпләре белән кычкыралар: «Яңа китергән розалар, әле яңа гына китергән розалар! Алыгыз, үкенмәссез! Өч кенә тәңкә! Алыгыз!»

Шунда ук ак яулык япкан озын күлмәкле хатыннар зәңгәр чәчәкләр, кыр ромашкалары һәм хуш исле миләүшә чәчәкләре сатып торалар. Алар чәчәкләрен күкрәкләренә кысканнар, ә кипкән ирennәре кыюсыз гына пышылдый:

— Букеты унбиш тиен, унбиш тиен букеты...

Үзләре милиционер узып киткән саен, шикләнеп, аңа карыйлар. Узып йөрүчеләр аларны ишетми дә.

Юлүткәргеч янындагы юкә куләгәсенә, яшел үлән өстенә, чегәннәр туктаган. Мәскәү урамнарында алар май аенда күренә башладылар һәм шуннан бирле Белорус вокзалында үзләрен туган таборларындагы кебек хис итәләр иде. Битләре пычранып беткән чегән малайлары, алсу уч төпләрен сузып, узып барган кешеләргә бәйләнәләр:

— Абзый, бер тиен бир әле! Апа, акча бир инде!

Әгәр «абзый» я «апа» акча бирми узып китсә, артларыннан:

— У-у, саран,— дип кычкырып калалар.

Ләкин бу сәгатьтә бала-чага яшел чирәмдә изелеп йоклый әле. Шунда ук япь-яшь һәм сакаллы карт чегәннәр сузылып ята. Алар, күзләрен йомган көе, иренеп кенә сүз катышып алалар. Ике яшь чегән хатыны чуар яулыкларга төрелгән ябык балаларын имезә. Тротуар читендә алтын алкалы чибәр чегән хатыны утыра. Карменга охшаган бу хатынның күкрәгендә куллары белән имчәккә чытырдап ябышкан бала йоклый. Ә ул баласының башы салынып төшүгә дә игътибар итмичә, тузып беткән карталарын бутый-бутый, үткән бер кешегә бәйләнеп кала.

— Багыйм әле, бәхетеңне кайда табарсың, кайчан югалтырсың, тормышыңда ниләр булган, ниләр булмаган, казна йортында үзеңне ни көтә — барын да әйтеп бирермен...

Шунда ук сөттән, кефирдан бушаган кәгазь каплар, булка кыерчыклары, колбаса кисәкләре аунап ята... Папирос капкан чегән карчыклары егермешәр тиенгә һава шарлары сатып торалар. Алар аны чәчәкле итәкләренең сырлары арасыннан алалар да шунда ук өреп кабарталар.

Менә алар янына алсу яңаклы яшь милиционер-сержант килде. Үзе тыныч сөйли, ләкин эчтә ачуы барлыгы сизелеп тора.

— Гражданнар! Шарлар белән сату итәргә ярамый. Газоннарда яту да тыела. Гражданнар, газоннардан торыгыз...

— Урлаганны сатабызмы әллә? Без аларны ни белән туйдырырга тиеш? — диделәр карчыклар, балаларга күрсәтеп.— Кара син аны? Әллә үзең туйдырасыңмы? Я, ал, алып кит, ашат!

Юан бер чегән хатыны милиционерның каршына ул килеп басты. Аның чуар яулыгы җилкәсенә шуып төште һәм аркасына чал чәчләре таралды.

— Таралыгыз, гражданнар, таралыгыз. Җәмәгать урыннарында йокларга ярамый,— сержант уңайсызланып кызарынды, тавышын күтәрә төште, ярдәм эзләгәндәй, үтеп баручыларга карады. Ләкин тегеләр туктап тормадылар, читкә борылып уза бирделәр.— Карагыз инде, ничек чүпләп бетергәнсез.— Бу сүз инде йоклаганга салынып дәшми яткан чегәннәргә кагыла иде. Көрән эшләпәсен сыңар күзенә каплап яткан карт чегән генә, итегенә чыпчык килеп кунгач һәм ул сикергәләп йөри-йөри ак тап калдырып очып киткәч, күзен ачып карады, сукранып куйды, ләкин урыныннан кузгалмады.

Үз эшен эшләгән чыпчык икмәк кыерчыгын чукып торган күгәрченнәр янына очып килде. Шырпыдай нечкә аяклары белән сикерә-сикерә чибәр күгәрчен янына килеп туктады да аның тирәсендә бер әйләнеп чыкты, аннары, җаен туры китереп, кыска каты томшыгы белән икмәкне чукып алды һәм канатларын җилпеп, юкәнең түбәнге ботагына килеп кунды. Күгәрчен аптырап аның артыннан карап калды.

— Торыгыз! Сезгә әйтәләр бит,— дип шелтәләвен белде милиционер.— Монда ятарга ярамый. Табор кормагыз.— Аннары юри күкрәген япмыйча утырган чибәр чегән хатынын күреп алды.— Синең оятың бармы, юкмы? Япь-яшь башың белән! Кыяфәтеңә кара!

— Нәрсә булган? Я, ни булган? — диде хатын, урыныннан торып. Шунда аның баласы елап җибәрде һәм каядыр култык астына кереп тә югалды.— Имчәк күргәнең юкмы әллә? Мә, кара! — дип, ул күкрәген киереп милиционерга таба бара башлады. Аның тавышында шаянлык һәм котыртасы килү сизелә иде.

Милиционер кызарып артка чигенде. Чегән картлары кычкырып көлеп калды, узып баручылар аларны әйләнеп үтә бирделәр.

Сәгать унберләр тулып килә инде. Пенсионерлар магазиннан магазинга йөри башладылар. Кай яклары беләндер алар бер-берсенә бик охшыйлар иде. Язмышлары беләндер, ахры, һәркайсының сумкасында берәр шешә сөт я кефир, йөз граммлап май, берәр пачка эремчек, яңа пешкән булка һәм иртәнге газеталар булыр... Танышларын очратсалар, бәхетле минутларын озайтырга теләгәндәй, ашыкмыйча, озаклап сөйлә-

шәләр. Яшь чакларында бер үк йортта торсалар да, эш дәрәҗәләре төрле булганга, бер-берсен әлегә хәтле танымый яшәгәннәре дә хәзер очраша. Еллар инде үзенекен иткән,— ул аларны таныштырган, тигезләгән. Һәм алар тормышның асылын, ниһаять, аңлаганнарына шатланганнар. Вак-төяк үпкәләшүләр, йөрәкне туктаусыз кимереп торган көнләшүләр инде онытылган, инде күңелле картлык тынычлыгы биләп алган, һәм алар шушы вак борчулардан башка тормышның тулырак, күңеллерәк барганын аңлап алганнар. Ләкин шунысы кызганыч, гомернең иң шәп чаклары шул ваклыклар белән үткән.

Минем дустым кандай кызыл хәрефләр белән «Ит» дип язган магазин янында илле яшьләр чамасындагы таза гына бер ир кешене еш очрата. Ул һәр вакыт төсе уңган кепкадан булыр һәм сырма өстеннән күк зәңгәр халат киеп йөрер. Ул гомере буе пычаклар кайрады. Карт шарманчыга охшаган бу кеше ун ел элек кайракларын аяк белән әйләндерә иде. Ул чагында аркасын бөгеп, пычак җуылдаган көйгә туктаусыз чайкала иде, аның күзләрендә бетмәс хәсрәт бар сыман тоела иде. Хәзер ул кайрагына электр моторы көйләгән. Хәзер аның станогы үкереп эшли. Ә үзе элеккечә караңгы йөзле, аз сүзле. Аның кулыннан мал суя торган меңнәрчә зур пычаклар, ит чаба торган балталар, сакал кыра торган пәкеләр, кайчылар үткән. Аның каралып беткән юан бармакларында гел яра булыр, шушы тупас бармакларның шулай оста эшләвенә гаҗәпкә каласың. Ул үзе бик аз сөйләшә һәм эшен мактаучыларны тыныч кына тыңлый. Ләкин эченнән шатланганы сизелеп тора.

Шул ук сәгатьләрдә минем дустым тагын бер кешене очрата. Анысы да илле яшьләрдә булыр. Ике аяксыз бу кеше кечкенә арбасын еш-еш эткәләп, тротуардан шалтырап килә. Аның чандыр йөзе имәннән шомартып эшләнгән сынны хәтерләтә. Матур иреннәре, гомергә ачылып карамагандай, нык йомылган. Хәтта тротуарда кеше күп булып, аяк астыннан үтәргә кыен чакларда да ул коры гына әйтеп куя: «Рөхсәт итегез! Юл бирегез!» Шул чакта да аның иреннәре каты кысылган булыр, әйтерсең лә ул кеше үзе түгел, ә аның эчендә утырган башка берәү тавыш бирә. Үтеп баручылар, үзләренең сәламәт булуларына читенсенгәндәй, уңайсызнып аңа юл бирәләр. Гарип кеше аны күреп тора. Шуңар ул аларның аяк астыннан тыныч һәм салкын бер ваемсызлык белән үтеп китә. Кешеләр ялгыш кына башына сумка белән бәргән өчен кыенсынып аннан гафу үтенгәндә дә күтәрелеп карамый.

Бу кеше өчен дөнья тормышның башка принципларыннан, әлеге ыгы-зыгылардан әһәмиятлерәк принциплардан тора диярлек. Бу кешенең тормыш белән үз исәп-хисабы бар, ул, күрәсең, аңа үзенчә бәя бирә. Аның моңар хакы да бар. Башкаларның бәхете өчен ул сәламәтлеген бирде шул.

Минем дустым бу кешене очраткан саен кайда яралануы турында сорашмакчы була. Ләкин аның кырыс карашын очратып һәр чак югалып кала.

Күз карашларында дөньяга булган мәхәббәт һәм тормышны сөю яшеренеп яткан ул кешеләр инде көннән-көн азая бара. Йөзәр ел яшәргә хаклары булса да, ул кешеләр, илле яшькә дә җитә алмыйча, тын һәм тыныч кына дөньядан китеп баралар. Алар тиз янып сүнгән метеорны хәтерләтәләр.

Бу сәгатьләрдә минем дустым тагын бер кешене — егерме яшьләр тирәсендәге егетне очрата. Ул гарипләрне йөртә торган кул арбасында утыра, аны талчыккан йөзле чал хатын этеп бара. Егетнең аякларын зәңгәр одеял белән төргәннәр. Алар үзара бик аз сөйләшәләр. Дустым бары тик бер генә тапкыр егетнен әкрен һәм серле тавыш белән әнисеннән:

— Әнием, йөргәндә кешеләр арыйлармы? — дип сораганын ишетте.

— Арыйлар, улым, арыйлар...— диде әнисе.

— Алай булгач синең дә аякларың арыйдыр?

Хатын улының йомшак чәчләрен сыйпап алды да:

— Минемме? Ни сөйлисең? Мин бер вакытта да арымыйм. Мин бит синең белән йөрим...

— Ә-ә-ә,— диде егет һәм, урамның икенче ягыннан йөгереп үткән ике малайны күргәч, өмет белән сорап куйды:

— Аякларым йөрсә, мин дә шулар күк көне буе йөгереп йөри алыр идемме икән?

— Йөрер идең, билгеле...

Егетнең түгәрәк йөзе елмаюдан яктырып китте, ул кәкрәеп каткан бармаклары белән алдындагы одеялын төзәтеп куйды һәм күк йөзедәй зәңгәр күзләрен алга төбәде. Аның күзләре ялтырап китте һәм үз аяклары белән йөрүчеләргә ашардай булып карады.

— Әни, тизрәк узып китик аларны! — диде егет, балаларча бер шаянлык белән.— Тизрәк инде! — аның тавышы түземсез иде.

— Хәзер, улым, хәзер,— диде хатын һәм арбаны кызу-кызу этеп китте. Зур тәгәрмәчнең ялтыравык чыбыклары асфальтта нур булып уйнады, ананың йөзе алсуланды, агарынган маңгаена тир бәреп чыкты, чигәләренә зәңгәр тамырлар бүртте. Биек үкчәләре асфальтта шак-шок килде. Барган саен кызулыгын арттырган тәгәрмәчләр артыннан ул хәзер көчкә житешә иде.

— Тизрәк, тизрәк! — диде улы.

Егет үзе дә алга омтылып утыра, менә-менә ул сикереп төшәр дә аяк астындагы жирнең катылыгыннан рәхәтләнеп, йөгереп китәр сыман... Үтеп баручыларның берәрсе кояш нурында кызган бу соры асфальтны шул чагында ике кеше кадәр үк көчле ярата алыр иде микән!

— Шәп, улым, шәп...— ди хатын, ә үзенең тыны кысылган, әмма үзе улының рухлануына сөенә. Ул хәзер рикшага охшый. Ләкин ул бәхетле. Улының шатлыклы бер елмаюы, бәхетле бер тавышы хакына йөгерергә дә йөгерергә һәм аналар өлешенә тигән авыр йөкне гомере буе алып барырга әзер ул... Хатын инде тирә-ягында беркемне дә күрми башлады, чал чәчләре таралып төште. Ул бары тик бәхетле улының балаларча куанып кычкыруын гына ишетә иде...

Ул көнне алар әлегә бүтәннәр шикелле кызу йөри алмый торган дустымны да узып киттеләр. Ләкин хатын белән аның улы бу кеше турында берни белмиләр. Аларның икесенең дә күңеле шатлык белән тулган: хатын әле үзенең карт булмавын, улына күп ярдәм итә алачагын, аның авырудан йөдәгән җанына шатлык бирәчәген аңлады, ә егет тизлекнең матурлыгын, кешеләр белән янәшә бара алуның рәхәтен тойды.

— Узып киттеләр! Узып киттеләр.! — дип кычкырды егет һәм әнисенә борылып карады. Шул вакыт арба кыңгыраеп китте һәм бер тәгәрмәче тротуардан чыкты. Хатын кычкырып жибәрде, арбаны тотып калырга тырышты.

Алар янына кешеләр йөгереп килде, хатынны күтәреп торгыздылар, арбаны тротуарга куйдылар. Хатын үз-үзен онытып, улына ташланды:

— Бәгърем минем, улым...— диде ул, күз яшьләрен чак-чак тыеп, тирә-ягында кешеләр барлыгын да онытып, улының кулларын, йөзен үбә башлады.

— Бәрелмәдеңме, улым?

— Шәп төштек бит, әйеме, әни? — диде егет.

Ул сокланып тирә-яктагыларга карады һәм шатлыктан кычкырып жибәрде. Әнисе түзмәде, елап жибәрде. Кешеләр борылып китә башладылар. Ә егет әнисенә кулының сыдырылган жирләрен күрсәтергә тотынды.— Кара, ничек күгәреп чыкты! Үзе бер дә авыртмый... Ә син каты төштеңме? Нигә елыйсың? — дип сорады ул борчылып.

— Юк, шатлыктан гына елыйм...

Мондый очрашулардан соң минем дустым үз-үзенә ныграк ышана,

соңгы вакытта еш кына башына килгән күңелсез уйлары өчен ояла торган булды.

— Үзегездән башка берни дә күрмисез, бары тик авыруыгызны гына сөйлисез, әйтерсең лә иң бәхетсез һәм кыерсытылган кешеләр инде,— дип, тормыштан канәгать булмаганнарны шелтәләп торганын еш кына ишеткәнем бар.

Андый чакта тегеләр кызып үз-үзләрен акларга, уңышсызлыкларын, хәсрәтләрен, башларына төшкән авырлыкларны санарга тотыналар.

Әйтерсең лә алар, чыннан да, бәхеттән өлешсез калганнар. Кемнеңдер хатыны явыз, йортны начар карый, икенчесенең эштә начальнигы холыксыз, артык акыллы түгел, мәкаләләрне, докладларны аңар язып бирәләр, ә ул бары тик кул гына куя һәм талантлы җитәкче дигән исем алып йөри. Моны бары да белеп тора, ләкин ләм-мим дәшмиләр, чөнки күбесе шулай эшли... Өченчесенең балалары телевизор яныннан китми, дүртенчесенең бакчадагы агачларын корт ашаган...

Язмыш андый кешеләрне кыерсытмаса да, алар сәламәт булсалар һәм җитешлек белән яшәсәләр дә, бәхет үзләрен читләтеп үтмәсә дә, тормышның кайсыдыр бер ягын тоя алмыйлар иде.

Бу очрашулардан соң дустым күңелсезләнеп кала, аның кешеләргә ярдәм итә алмавыннан, гомумән, дәшмәс була. Дөрес, күңеленнән ул һәр кешенең үз намусы алдында үзе хисап бирер көне җитәр, шуннан соң алар анадан тугандай сафланып калырлар, дип ышанып йөри. Мин дустымны яхшы аңлыйм. Чөнки үзем дә ярамаган берәр нәрсә эшләсәм, соңыннан борчылып йөрим, намусым шул кадәр газаплана, кеше күзенә күтәрелеп карарга оят була.

Авырудан сәламәтләнеп киткәч, дустымның күңел күзе ачылып, җаны тынычланып калгандай булды. Тайгада озак адашып йөргәннән соң кешеләр яши торган җиргә килеп чыкканда шундый хәлне кичерәсең.

Бер вакыт мин төнлә, барысы да йокыга талгач, аның елаган тавышын ишеттем. Дустым хат яза иде. Күземне дә алмыйча аңа карап торам, ә ул моны сизми... Мин аның хисләрендәге һәрбер үзгәрешне кичереп утырам. Ул үзенең бала вакытын, әнисен һәм шул чакларга бәйле булган башка вакытларны хәтеренә төшерә.

Хәтердә искә алырлык хәлләр калу яхшыдыр ул. Ә менә мин әниемне дә, балалык елларымны да белмим...

Кешеләр бездән бәхетлерәк.

Менә минем дустым абыйсының ишле семьясында үсте. Икенче класска гына йөри иде әле ул. Ләкин олы кешегә хисаплап, башкалар белән беррәттән ана да өй эшләрен эшләргә кушалар иде. Суыктан агачлар шартлаган кышкы төннәрдә, кар өстенә көмеш ай нуры төшкәндә ул сыерга һәм сарыкларга печән бирергә чыга иде. Караңгы сарайда аңар бик куркыныч була. Ул, як-ягына карана-карана, капшанып, тагарак янына килә һәм ашыгып печән сала. Юеш борыны белән шаулатып мышнаган һәм җилененнән сөт исе килеп торган сыерга килеп төртелгәч кенә ул бераз тынычлана. Караңгы почмакта сарыклар ята. Алар нидәндер өркеп сикереп торалар һәм бер җиргә җыелалар. Бу хәрәкәттән курыккан малай сыерга тагын да ныграк сыена.

Дүртенче класска житкәч, абыйлары аңа кыска чалбарлы яңа костюм сатып алдылар. Бу аның гомерендә беренче тапкыр яңа костюмга тиенүе иде. Мәктәпкә киеп барган беренче көнне үк иптәшләре мыскыллап көлделәр, чалбар кигән иркә малай, дип үртәделәр. Дустым аларга каршы торып карады, мин иркә малай түгел диде, кыска балаклы бу чалбарны абыйлар көчләп киертте, дип алдады, мин аны бер дә кызганып кимим, диде. Шунда бер малай:

— Кызганыч булмаса ерт! — дип куйды.— Ә, куркасыңмы?

Дустым, кыйналган эт баласы шикелле, кызганыч итеп иптәшләренә карады һәм мәктәп ишегалдындагы эрбет агачына менә башлады.

— Кызганыр дип уйлыйсызмы? — диде ул, корсагы белән агачның кытыршы кабыгыннан өскә шуышып. — Менә карагыз, хәзер ертам.

Ул бик югары менде, ләкин шул чак астан укытучының тавышы ишетелде:

— Хәзер үк төш. Муеныңны сындырырга телисеңме әллә? Туганнарың сиңа яңа костюм алганнар, ә син... Оятың кая?

Малай чалбарын ертырга теләп ботакларга элэгэ-элэгэ аска шуа башлады. Җиргә баскач ул өс-башына карап алды — бер җире дә ертылмаган, берничә җирендә генә ялтырап сагыз күренә.

Дәрестә аңар, бу бит кызлар ыштаны, син аны кызганасың, абыйларың көчләп кидермәгәндер әле, үзең мактанып йөрергә уйлагансыңдыр, диделәр. Шул чак нишләргә белмәгән дустым кара савытын алды да карасын чалбарына түкте. Чалбар балагы буйлап шәмәхә кара агып төште. Малайлар тыннарын да алмыйча аңа карап калдылар. Ә дустым, андый чалбар киеп йөрергә мин кемнән артык, мин әле үземне җитәрлек җәзаламадым, малайлар ни кушсалар, шуны эшләргә тиешмен, дип уйлый иде. Ул чалбар бавын йолкый башлады. Шытырдап материя ертылган тавыш классны сискәндереп җибәрде. Идәнгә зәңгәр төймә тәгәрәп төште, берничә кат сикерде дә, парта астына кереп китте. Дустыма ертылган чалбарыннан бигрәк тә төймә кызганыч булды.

Өенә ул чалбарын кулы белән күтәреп, шыңшый-шыңшый, бер ялгызы кайтты. Шул чакта кечкенә генә бер яхшы сүз дә аның сызланган йөрәген тынычландырган булыр иде. Ләкин янында беркем юк — һәркайсы үз эше белән мәшгуль иде.

Кич белән абыйлары эштән кайтты, хатыннарының сөйләгәннәрен тыңлап тордылар да дүртенче класс баласын зурларны җәзалаган кук җәзаладылар. Дустым төне буе йоклый алмады — иптәшләренә, олыларга аның бик каты хәтере калган иде. Ул карага буялып беткән ертык чалбарын мендәр астыннан алып карый һәм гомерендә беренче кат эшәке көнчелекнең корбаны булганын төшенмичә, кайнар күз яшьләрен түгә бирде.

Шуннан сугыш башланды. Әле унбиш яше генә тулса да, минем дустым башкалар кебек үк уникешәр сәгать эшләде. Ул елларда үзе ач булса да, әнисе улын тәрбияләргә тырышты: ул аңар я зуррак икмәк кыерчыгы биреп җибәрә, я ашның куерагын бүләргә тырыша, ә үзе син аша, мин тук инде, дигән була. Табигатьнең үзе шикелле үк юмарт булган аналар мәхәббәте иде ул.

Соңыннан анасы үзенең кышкы пальтосын һәм итеген сатып билетлык акча юнәтте дә улын зур шәһәргә укырга җибәрде. Дустым аны белмәде дә, күрмәде дә. Дөнья минем өчен генә яратылган дип йөргән чагы иде. Аның яшендә, мөгаен, барысы да шулай уйлыйдыр...

Намусы газаплаган бер төндә әнкәсенә булган җылы хисләрен ак кәгазьгә генә булса да төшерергә утырганда, аның алдында булган гаебен соңга калып булса да танырга теләгән вакытта, аңар барысын да сөйләп бирергә теләгәндә инде ул бик соңга калуын белми иде әле. Кеше гомере мәңгелек түгел шул. Ул, һәр вакыттагыча, бу юлы да соңга калды. Мәңгегә соңарды. Шул төннән элек кенә, зур шәһәрдән ерак урында аның әнисен җирләгәннәр иде. Әнисе үләрен улына белдермәскә кушты. Шуның белән тагын бер тапкыр, соңгы кат улын борчудан саклап калды...

...Мин инде дустым турындагы хикәямне тәмамлыйм. Мин бәхетле яшәдем. Хәтта бик бәхетле. Тормыштан үндым мин — менә дигән дустым булды. Мин аны түгел, ул мине тапкан иде. Бала чагында ул мине бик яратты, тик мин үзем генә аңар бәя бирә белмәдем, шулай булырга тиештер дип уйладым. Бервакытта да яратуыбыз турында әйтешми идек без, аның кирәге дә юк иде. Дустымның кулы башыма орынган чагында һәм аның:

— Нәрсә, дускай, моңаябызмы? — дигән сүзен ишеткәндә кәефем килә, рәхәтлектән башым әйләнеп, күзләрем йомам. Мондый бәхетле минутларымда йөрәгемне ярып дустыма бирерлек булам. Ул мине аңлый һәм:

— Я, нигә дип хискә биреләсез? — дип сорый.— Берәр нәрсә әйтер иден...— ди.

Мин бәхетемнән буылып дәшми калам, дустымның чиксез кадерле булуын гына тоям.

— Дәшмәвең, бәлки, яхшыдыр,— дип әйтә ул,— сөйли белсәң алай ук яратмас идең.

Бу сүзгә хәтерем кала, әйтерсең лә мине типкәләп кыйныйлар, йөрәгем әрнеп, бөтен тәнеп куырылып килә. Дустым хәлемне аңлый, аркамнан сөя һәм гаепле кеше сыман:

— Ялгыш әйттем, ялгыш,— ди.— Кешеләр тормышка һәркайсы үз күзлегеннән карый. Үзләрен хаклы һәм һич гөнаһсыз дип исәплиләр. Бөтен явызлык шуннан киләдер, мөгаен.

Шундый сүзләреннән соң дустымны кызганып куям, аңар карата да көчлерәк ярату хисе тоям. Кешеләрнең йомшак яклары турында ул шундый борчылып сөйли, әйтерсең лә бу борчылудан ул кешеләрнең үзгәреп китүе мөмкин. Һәркемнең тормышка үз күзлегеннән генә каравы күп бәлаләргә китермиме икән? Дустым да, үзе белә торып, ялгыш бара сыман тоела һәм ул миңа бик кызганыч булып китә.

Мин борыным белән аның куенына тыгылам, ырлыйм һәм аның хәлен аңлавымны белдерергә телим.

Бервакыт ул муенымнан кочып алды да күзләремә төбәп карады һәм гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде:

— Дускаем! Син бит сөйләшә беләсең! Күзләрең сөйли синең, җаның, һәрбер күзәнәгең сөйли! Кичер, дустым, мин бит моны белми идем.

Мин дустымны ялап алдым. Кешеләр моны үбү диләр. Рәхмәт әйткәндәй, җилкәсенә башымны салдым. Ниһаять, ул мине аңлады! Ул ялгышмый иде — мин чынлап та сөйли беләм, иң тугры, иң ихлас тел — хисләрем теле белән сөйлим мин.

Мин инде үләм. Бәхетле булып үләм. Чөнки җир йөзендә дустым — минем ачышым, намусым кала. Мин аны үземнән дә артык яратам, барлык йомшак яклары белән яратам. Чөнки ул хисләр телен, башкаларның хәсрәтен, газапларын аңлый белә торган кеше.

Үзбәк Саттаров

# КЫЗЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

## «Түү»



Кече кызымның теле ачылып килә. Инде әллә ничә сүз белә. Белмәсә дә аптырап тормый — үзе ясый, әйберләргә үзенчә исем куша. Сүзе житмәгән җирдә кулларын, аякларын да ярдәмгә чакыра, кирәк нәрсәсен кыланып та аңлата. Аңлыйбыз тагы үзен.

— Бу сүзне французча әйтте кебек, әллә французча ачыла инде кызыбызның теле,— ди әнисе.

— Юк, балалар теле — интернациональ тел, аларның телен өлкәннәр, нинди милләт кешесе булуына карамастан, аңлый ала,— дим мин.

Шулай макташып торганда, кызым миннән «түү» сорый башлады. Аңладым, янәсе:

— Әнисе, кызыма су бир, су сорый бит кызыбыз,— дим.

Кызым стаканга салып биргән суны төртеп кенә җибәрде. Ә үзе һаман «түү...» сорый. Суга охшаган, я булмаса, «түелди» торган нинди генә нәрсәне бирмәдек, барысын да кире кага кызым.

Сеңелесенең телен апасы бездән яхшырак аңлый икән:

— Кичә без әби белән йон эрләдек, ул орчык сорый бит,— ди.

Орчыкны күргәч, кызымның йөзләре ачылып китте. Ул орчыкны кулына алды да барыбызга да күрсәтеп чыкты. Күрсәтә дә, «түү», ди. Янәсе, без өлкәннәр шуны да белмибез, орчык «түү» итеп әйләнә, шулай булгач, ул — «түү» була бит!

## «Абзыйлар урамда йөри...»

Кызым белән бакчадан кайтабыз. Күзенә күренгән һәр нәрсә турында сорашып кайта бу. Йортлар, кибетләр, агачлар турында балага аңлату җиңел әле, ә менә кешеләр очрагач: «Болар кемнәр?» дип соравы теңкәгә тия. Ни дип җавап бирәсең аңа. «Болар абзыйлар, кызым»,— дип котылам.

Бала һаман үзенекен итә — яңадан кешеләр очрый, тагын шул ук сорау кабатлана:

— Болар кемнәр? Кая баралар? — ди.

— Алар да абзыйлар, урамда йөриләр,— дим.

Кичен безгә Хәйрулла абзый килде. Шулай инде, яшьтән «Хәйрулла

абый» дип түгел, «Хәйрулла абзый» дип өйрәнелгән. Үзенә дә шулай дип дәшәбез. Кызларымны аның белән таныштырдым:

— Бу инде Хәйрулла абзыегыз була,— дим.

Гүзәл:

— Абзыйлар алар урамда йөриләр, безнең өйгә кергәч, ул абзый булмый инде,— дип, борылып, Хәйрулла абзыйсы яныннан китеп тә барды.

Минем урамда аңлатканнарны яхшы үзләштергән икән кызым!

## «Дежурный» сарыклар

Машинага утырып авылга барабыз. Автобусның тәрәзәләре ачык. Кырлар, урманнар, болыннарны карап, күзге табигатьнең матурлыгына, байлыгына сокланып, гәп сугабыз.

Кич кырын. Көтү кайткан чак. Бездән ерак түгел, сарык көтүе авылга якынлашып килә.

Балаларның сарыкларны берәм-берәм күргәннәрне булса да, көтүдә күргәннәре юк иде әле.

— Кызлар, әнә сарык көтүе! — дим.

Балалар бик озак көтүгә карап торалар.

— Нәрсә ул көтү? Монда бит сарыклар гына, ә көтүне күрмим мин,— ди бәләкәе.

Аңа көтүнең нәрсә икәнен аңлата башладым, әмма аңлатып бетерерп булмады, олысы сүзне бүлде:

— Әти, дим, әти! Әнә, дежурный сарыклар!

«Дежурный» сарыклар дигәне тамга итеп муеннарына кызыл тасма бәйләгән ике сарык булып чыкты.

## Яңа костюм алгач

Гүзәлгә яңа кофта алдык. Бик ярата ул аны, ләкин әнисе аны бәйрәм көннәрендә генә бирә, әгәр кызым үзен бик әдәпле тотса, сүзен тыңласа, якшәмбе көннәрне дә яңа кофта эләгә.

Бервакыт шулай миңа да яңа костюм алдык. Өйгә кайткач, яңадан иркенләп карыйм дип, көзге алдында торам. Әнисе дә, балалар да «әйбәт» диешәләр. Гүзәл:

— Әти, әнигә үпкәләмә, яме. Ул сиңа бу костюмны бәйрәм көннәрендә генә кидерер,— диде.

Безнең аптырашып калу баланы шиккә төшерде. Бераз уйланып торганнан соң:

— Ял көннәрендә дә! — дип өстәде.

## Күршеләр шакый

Гүзәл, икенче көн инде, «колагым авырта» ди, әмма әнисе дә, мин дә аның сүзенә игътибар итмибез. Еламагач, борчылмагач, «яраттырыр өчен генә кыланадыр» дип, уен сүзләр белән аны юатып йөрибез.

Беркөн шулай кич утырабыз. Тынлык. Кызым минем янымa килде дә:

— Әти, күршеләр ни эшлиләр? — ди.

Мин тыңлыйм, әмма берни дә ишетмим, аптырап:

— Ник алай дисең, кызым? — дим.

— Әнә бит, шакыйлар,— ди.

Тагын тыңлыйм — берни ишетелми. Шунда келт итеп баланың колагым авырта дип зарлануы исемә төшә.

Шуннан соң гына аны врачка алып барырга кирәк икәненә ышанабыз.

## «Әти, син телевизорга ничек кердең?»

Әнисенең сүзләренә караганда, балалар минем телевизордан сөйләгәнне тын да алмый тыңлаганнар. Ә инде:

— Хәзер әтиегез үзе кайтыр,— дигәч, ишек төбеннән китмичә, кайтканымны көтеп торганнар.

Кайтып керүгә, җавабын да көтеп тормастан, сорау арты сорау яудыралар:

— Әти, күрдеңме, син телевизорда идең?!

— Әти, син безне күрдеңме, без сине күрдек!

— Әти, без сиңа кычкырдык, син ишеттеңме?

— Әти, син телевизорга ничек кердең?

Кечкенәсе мине телевизор янына өстери:

— Әйдә, әти, янадан телевизорга керәбез! — дип, экран янына түгел, телевизорның артына таба тарта.

Гүзәле өлкәнлеген итә:

— Анда балаларны кертмиләр, әти үзе генә керсен,— ди.

Кечкенәсе килешә алмый:

— Бер көнне мин телевизорда ясле балаларын да, детсад балаларын да күрдем, телевизорга балаларга да керергә ярый! — дип каршы төшә.

## «Чеби чыгарабыз...»

Кинодан кайтып керсәк, ни күзебез белән күрик, казларыбыз йомырка сарысына буялып беткәннәр, идән тулы ватык йомырка. Безнең кергәнне дә абайламыйча, һаман бәхәсләшәләр:

— Анысында түгел, монысында ул чеби!

— Ват тизрәк, тыны бетеп үләр бит!

— Ни эшләвегез бу? — дип, балалар янына киләбез.

— Чеби чыгарабыз,— ди кызларның кечесе.

Олысы аның сүзен куәтли.

— Әби йомыркадан чеби чыгарды бит.

Идән тулы ватык йомырканы җыйганда, әнисе көлеп:

— Авылның файдасы тиде. Белемнәре артты кызларның. Киләсе елга да авылга илтербез инде,— диде.

## «Балдыз» түгел, «кызым» ул!

Безгә Сәрия килеп керде. Гүзәл аны күрү белән:

— Сәрия килде, Сәрия килде! — дип сикерә дә башлады.

— Сәрия апа дип әйт, апа бит ул сиңа,— дип, әнисе кызны шелтәләп алды.

Гөлнара:

— Нишләп ул Сәрия булсын, ул — «балдыз» бит! — дип каршы төште.

Ә Гүзәл сеңелесе белән килешмәскә тырыша:

— «Балдыз» түгел, «кызым» ул, әби аңа «кызым» дип әйтә.

Сәрия Гүзәлнең әнисенә «апа» дип дәште. Бу Гүзәлгә ошамады:

— Минем әнием «апа» түгел! — диде һәм бераздан ачу белән өстәп куйды:

— Син үзең «апа»!

## «Азатик Гөлнара буламыни?»

Һәр кечкенә баланың сеңелесе булырга тиеш дип уйлый иде Гүзәл. Бервакыт күрше кызы Фәридәгә энекәш алып кайттылар. Бу хәл Гүзәлгә бик сәер тоелды. Һәм аны уйга калдырды. Нинди генә сораулар бирмәде ул яңа туган Азат турында! Мин аңа сеңел генә түгел, ә энекәш тә була икәнен аңлаттым. Шуннан соң кызым көлеп җибәрде:

— Аңладым инде, аңладым, Азатик Гөлнара була икән! — диде.

## «Мин йонлымыни?»

Кече кызымны алдыма утыртып иркәлим:

— Бәбкәем! — дим.

Бала көлүеннән туктап:

— Мин йонлымыни? — ди.

Ник алай дигәнен аңламыйм әле. Ул да мин җавап бирмәгәнгә аптырап тора:

— Мин дә сарымыни? — ди.

Шуннан соң гына «бәбкәем»нең сүз буларак «бәбкә»гә охшаш икәнлеген аңладым.

— Син бит каз бәбкәсе түгел, минем бәбкәем,— дим.

— Мин дә бәбкә кебек йомшакмыни? — ди.

— Әййе шул, син дә каз бәбкәсе кебек, йомшак та, матур да! — дим.

Гөлнара чын күңеленнән шатланып, балаларга гына хас сафлык белән елмая һәм мине яратып кочаклый, чөнки ул үзе бәбкәләрне ярата, шулай булгач, минем аны ничек нык яратуымны күз алдына китерә ала.

## «Шарик, әниеңә әйтермен...»

Һәр көнне диярлек кичкырын безнең күрше Клавдия Петровна Шарик кушаматлы этен ишегалдына уйнатырга алып чыга. Һич кенә тик тора белми ул Шарик, һәр вакыт йөгерә, койрыгын болгап, балалар янында әйләнә, күп вакыт аларның итәгеннән кабып тарта, кайберәүләрнең кулын, битен ялап алырга омтыла. Гадәттә, балалар аларны көтеп алалар, чөнки ул шаян этне бик яраталар.

Ә Гөлнара бүген урамга яңа күлмәк киеп чыккан. Шарик та аның янында бөтерелә: өстенә сикерә, борынын сузып битенә үрелә. Гөлнараның да уйныйсы бик килә, тик күлмәк пычранудан курка. Ул Шарикны куа, ә Шарик аның кууын уенга ала, китәргә уйламый да. Гөлнара аңа яный:

— Шарик, кит! — ди.

Шарик бераз койрыгын болгап, аңа карап тора да, тагын сикерә. Гөлнара житди кыяфәт белән:

— Шарик, тукта, әниеңә әйтермен! — дип, аңа Клавдия Петровнаны күрсәтә.

## «Җир әйләнми...»

Телевизор карап утырабыз. Мәскәүдән тапшыру бара. «Вакыт» программасы башлана. Экранда шар. Шар әйләнә. Балалар бер генә минут та сорау бирмичә тора алмыйлар бит. Гөлнара һаман сораша:

— Әти, бу нәрсә?

— Җир шары...
— Ник ул әйләнә? Җир әйләнәмени?
— Әйе, кызым, Җир әйләнә...
Бер-бер артлы яуган мең дә бер сорауның кайсына нинди җавап биргәнне кайчакта искәрми дә каласың, ә бала күңеле аны сендерә, саклый икән. Икенче көнне бакчадан кайтканда, кызым минем белән сөйләшми дә!
— Ни булды, кызым, сиңа, ник сөйләшмисең? — дим.
Бик җитди кылана бала:
— Син балаларны алдыйсың! — ди. Менә сиңа — мә! Аптырап киттем.
— Мин сине кайчан алдадым? — дим.
— Кичә кич, телевизор караганда.
— Нәрсә дип?
— Җир әйләнә, дип.
Эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач, эчкә җылы кергәндәй булды.
— Мин сиңа дөресен әйттем, кызым, Җир әйләнә,— дим, шик калдырмаслык итеп!
— Җир әйләнми, бакчада без кызлар белән эзләдек инде, әйләнгән төшен тапмадык,— ди.

## «Егерме ун»

Апасы өйрәткәндер инде, кечкенә кызым егермегә кадәр теттереп саный. Хәзер инде егермедән өстә санарга исәбе бар.
— Өйрәт әле, әти, егермедән соң ничек саныйлар? — ди.
Өйрәттем. Башлап, мин әйтәм, егерме дип әйт, аннан соң бердән унга чаклы саннарны берсе артыннан икенчесен кабатла.
Икенче көнне олысы минем янга:
— «Егерме ун» буламыни? — дип килгән.
— Кем әйтте сиңа алай дип?
— Син үзең бит Гөлнараны «егерме тугыз», «егерме ун» дип санарга өйрәткәнсең.
Бик озак вакытлар нәкъ мин өйрәткәнчә санады бала, аңа «егерме ун»ның утыз икәнен аңлату безнең өчен шактый кыен эш булды.

## «Картлар бетәләр икән...»

Кызларым белән һава алырга чыктык. Урам буйлап барабыз. Каршыга, җеназа күтәреп, бер төркем кеше килә. Бала — бала инде, ни күрсә, шул турыда очсыз-кырыйсыз сораулар яудыра.
— Әти, кая баралар алар?
— Каберлеккә.
— Ник?
— Әнә, күрәсеңме, аларның әтиләре үлгән, шуны күмәргә алып баралар.
— Ник үлгән ул?
— Карт булган.
— Картлар үләләрмени?
— Әйе, кызым, картлар үләләр.
Нишләптер сораулар өзелде. Бераз араны сөйләшмичә, тыныч кына уздык. Бала уйланып, ишеткән сүзләреннән нәтиҗә ясап бара икән. Бераздан ул:
— Болай булгач, картлар бетәләр икән,— диде.

## «Әйдә, автобустан төшеп калыйк...»

Әнисенә шкафны ачарга кирәк, әмма шкаф ишегенә урындыгын терәп, кулына курчагын тотып Гөлнара утырган. Аны урыныннан һич торгызып булмый, курчагы белән автобуска утырып, әбиләренә кунакка бара, янәсе. Әнисе ачуланып та, янап та карый, ә баланың кузгалырга исәбе дә юк. Шундый ихлас күңел белән уйнаган баланың кәефен кырасы килмичә, без дә уенга кушылдык.

— Кызым, автобус бик селкетмиме соң? — дим.

— Селкетә шул, әнә, Айсылу йокысыннан уянды инде, дип, курчагын көйли башлады кызым.

— Кызым, автобус туктады бит, әйдә автобустан төшеп калыйк тизрәк,— дим бераздан.

Бала урындыктан торды,— автобустан төшә, янәсе. Әнисе балага сиздерми генә елмаеп шкаф ишеген ачты.

## «Гөлшатның бабасы— минем әбием икән!»

Үзенең сеңелесе, әбисе булгач, Гүзәл башка барлык кызларның да сеңелесе дә, әбисе дә булырга тиеш дип уйлый. Тик менә аңлап бетереп булмый, күрше кызы Гөлшатның сеңелесе бар барын, әмма әбисе юк. Аның каравы, Гөлшатның бабасы бар.

Гүзәл бик еш сораша:

— Ә Гөлшатның әбисе кайда соң? — ди.

— Гөлшатның әбисе үлгән,— дим мин.

— Ә минем бабай кайда?

— Синең бабаң да үлгән.

— Гөлшатның бабасы кем соң ул?

Эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алып, тырыша-тырыша, балалар телендә Гөлшатның бабасы кем икәнен аңлатам. Сорашулар кимегәч:

— Аңладыңмы инде, кызым? — дим.

Ул бик яхшы аңлаган кыяфәт белән:

— Аңладым, Гөлшатның бабасы — минем әбием икән!— ди.

**Сәгыйт Закиров,**
инженер

# ТОРМЫШКА АШКАН ХЫЯЛ

Безнең танышып китү уйламаганда булды. Яңа технология процессларына өйрәнергә, бер үк вакытта ремонт эшләренә дә катнашырга дип, мине изопрен-каучук җитештерү цехына практикага җибәрделәр.

Күкләргә ашардай булып, парларын бөркеп торган мәһабәт ак колонналар янында үзеңне бер мәлгә диңгез корабле палубасында, я булмаса ерак космик очышларга әзерләнгән старт мәйданында итеп хис итәсең. Аларны йөгәнли, зур эшләргә җигә алган кешеләргә карата үзеннән-үзе соклану туа, шулар кебек булырга омтылыш арта. Йөрәкләргә дәрт, беләкләргә көч өстәлгәнен тоясың.

Шундый кичерешләр белән аппаратларны күздән үткәргәннән соң, приборларның ничек күрсәткәнен карарга дип, операторныйга кердем. Беренче реактордагы басымны күрсәтү приборы янына шактый кеше җыелган. Нигәдер басым артканнан-арта бара. Сәбәбен белүче юк. Әгәр ул чикләнгән нормадан узып китә икән, шартлау куркынычы туа. Вакыт бик аз калган. Нәрсәдер эшләргә, аны булдырмас өчен берләнбер дөрес юл сайларга кирәк.

Уртача буйлы, зәңгәр күзле, коңгырт бөдрә чәчле егет регенератордан реакторга катализатор килүне азайтырга кирәклеген әйтте. Һәм үзе үк аны эшләр өчен аппаратлар янына йөгерде.

Тиздән басым азайды. Приборлар технологик режим саннарын күрсәтә башладылар. Хәлне ишетеп, ашыгып килеп житкән цех начальнигы Лев Давыдович Котлер, тынычланып, эчке бер горурлану белән:

— Сменада Шамил эшләгәндә дүрт күзем бар кебек дигән идем бит мин сезгә,— дип куйды.

Шунда «Нефтехимик» газетасында укыганым искә төште. Анда: «СССР Верховный Советы Президиумының 1971 ел 20 апрельдәге Указы белән, сигезенче бишьеллык заданиеләрен уңышлы үтәгәне өчен комбинатның 4 нче цех өлкән аппаратчысы Имаметдинов Шамил Имаметдин улы Ленин ордены белән бүләкләнә»,— дип язылган иде.

Әллә шул, әллә Шамилнең ачык йөзе, сабыр карашы, тыйнаклыгы тәэсир итте, үзем дә сизмәстән, аңа тартыла, күбрәк аның янында булырга тырыша башладым...

Татарстанның гүзәл почмакларыннан берсе — Мамадышта туып-үскән Шамил. Бөек Ватан сугышы еллары бала чакларының тәүге хатирәсе булып әле дә хәтерендә саклана аның.

Үзәкләрне езеп авыл өстендә җыр агыла:

Кояш чыга әйләнеп лә,
Алмагачка бәйләнеп шул.
Җиңү белән, әй туганнар,
Без кайтырбыз әйләнеп.

Җыр зәңгәр тәрәзәләрнең челтәр пәрдәләрен кагып, тыныч өйләргә керә, якты урамнарга сибелә, кояшлы киң тугайларга тарала. Илнең типсә тимер өзәрдәй арыслан ир-егетләре сугышка китәләр. Аларны озата чыккан авылның аксакаллары соңгы киңәшләрен әйтәләр, газиз аналар җиңү көннәре телиләр. Бераз арырак яшь киленнәр моңсу гына басып калганнар. Ә сылу кызлар сөйгән ярларына истәлек ядкарьләрен — төннәр утырып, күз нурларын түгеп, чиккән бизәкле кулъяулыклар бүләк итәләр.

Әнисенең күлмәк итәгенә чытырдап ябышкан кечкенә Шамил абыйларыннан күзләрен ала алмый. Әнә алар утырып барган кыңгыраулы атлар авыл башындагы калкулык артына кереп күздән дә югалдылар инде. Бары җиз кыңгырау моңнары гына бик озак чыңладылар...

...Якшәмбе көн, Казан радиосыннан ял концерты бара.

Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары.
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары.

Иркен, тыныч өйдә улы Айратны рәсем ясарга өйрәтеп утырган җиреннән Шамил кинәт туктап калды. Кайда ишеткән иде соң әле ул күңелгә шундый якын, таныш бу моңнарны. Эфир дулкыннары аны бала чак хатирәләренә, үткән елларга алып киттеләр...

...Җиңү көнен якынайту өчен якташларының тылдагы хезмәт фронтында көне-төне барган көрәше. Хезмәтнең олылыгын, икмәкнең кадерен кечкенәдән күреп, татып үсте Шамил. Менә илне шатлыкка төреп, якты нурларга күмеп зарыгып көткән Җиңү көне килде. Күрешүләр, шатлыклы һәм кайгылы күз яшьләре. Нәни Шамил абыйлары чыгып киткән юлларга, басу капкасы баганасына басып, бик күп мәртәбәләр каерылып-каерылып, күз керфекләре талганчы караса да, алар күренмәделәр. Таныш җиз кыңгырау моңнары ишетелмәде...

Әллә семьяда төпчек бала булганга, әллә спортны кечкенәдән бик тә яратканга, яшьтән үк төп кебек нык, таза булып үсте ул. Районда гы спорт ярышларының аның катнашыннан башка үткәне сирәк булгандыр.

Мамадыш җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң — техник училище. Аннан соң хезмәттәге тәүге адымнар. Мамадыш промбазасының тимерче егете Шамилнең осталыгы турындагы хәбәр якташлары арасында тиз таралды. Ләкин егет үзе генә калган чакларда кулындагы тимергә карап озак-озак уйлана торган иде. Нигә ул тутыга? Нәрсәдән кислоталарга тиз бирешә? Бәлки, аларга бирешми торган яңа материал эшләп карарга кирәктер? Моны бары тик химия генә булдыра ала. Ләкин ничек? Гади бер тимерчелек алачыгында бу хыялны тормышка ашыру мәмкин түгел. Дөньяны яңа танып белә башлаган авыл егете өчен болар катлаулы сораулар иде әле.

Менә Шамил — Хәрби Диңгез Флоты хезмәтендә. Еракларга җәелгән диңгез офыкларына карап дулкыннар тавышын тыңлаганда талъян

гармунда уйнап авыл урамнарыннан узган чаклары, күкрәк киереп печән чапкан болыннары сагындыра, туган якның сызылып аткан алсу таңнары өздереп искә төшә иде.

Ә корабль механизмнары жай гына әйләнәләр. Ягулыкның төрле булуына карап, аларның йөреше, корабльнең тизлеге дә төрлечә. Аны сынап карау эшләрендә кече сержант Шамил Имаметдинов та катнаша. Химиянең чыннан да тылсымлы көчкә ия икәнлегенә көннән-көн ышанычы ныгый, аңа мәхәббәте арта.

Менә флот хезмәтенең соңгы елы. Шул елларда партиябез, халык хужалыгының башка тармаклары белән бергә, химия промышленностен үстерүнең дә яңа үрләрен билгеләде.

Шуны раслагандай республикабызның башкаласы Казанда химия гиганты — органик синтез заводы төзелеп ятуы бөтен илне шаулатып. Шамилгә дә барып ирешә. Бу хәбәр аның яшьлек хыялларын кабат уятты.

Хәрби хезмәт һәм политик хәзерлек отличнигы Шамилнең кая кайту мәсьәләсендә командирларына җавабы әзер иде инде. Бары туган ягына.

Абыйлары, апалары кайсы экономист, кайсы укытучы, кайсы Совет Армиясе офицеры булдылар. Ә ул химияне сайлады.

Казан. Органик синтез заводы. Ул аның беренче нигез ташларын салуга катнашты. Беренче продукциясе аның кулыннан да үтте. Йөзләрчә аппаратларның язмышы аңа ышанып тапшырылды. Алар катлаулы. Алар өчен һәрбер очракта нык ихтыяр көче, салкын канлылык, сәламәт акыл сорала. Шундый техниканың, зур көчнең чын хуҗасы булыр өчен Шамилгә тимерче ныклыгы һәм оста спортчы өлгерлеге генә җитмәгәнлеге, белем кирәклеге адым саен сиздерә килде.

Һәм менә ул химия-технология техникумының кичке бүлеге студенты. Китаплар, исәп-хисап, сызымнар белән төннәр буе утыруның нәтиҗәсе үзен озак көттермәде. Тиздән ул өлкән аппаратчылыкка имтихан бирде. Үзе эшләп чыгара торган продукциянең сыйфаты да яхшырганнан-яхшыра барды.

Завод коммунистлары Шамилне үз сафларына кабул иттеләр. Ә ул күрсәтелгән олы ышанычка тырыш хезмәте белән җавап бирде. Хөкүмәтебез аның җиденче бишьеллыкта ирешкән уңышларын Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән билгеләп үтте.

Бер көнне аны завод парткомына чакырып алдылар. Хөкүмәтебез республикабызга зур ышаныч күрсәткән — чорыбыз химиясенең иң олы гигантларыннан берсен Татарстан җирендә, Түбән Камада төзергә карар ителгән. Бөтенсоюз удар төзелешенә — хезмәтнең алгы сызыгына тәҗрибәле, тирән белемле коммунист-белгечләр кирәк икән.

Менә 1968 елдан бирле ул Түбән Кама нефтехимия комбинатын төзүдә. Комбинатның беренче продукциясе — сыйфаты ягыннан натураль каучукка тиң синтетик изопрен-каучук алуга да аның турыдан-туры катнашы бар.

Шамил үзе дә, тормыш иптәше Флера да коммунистик хезмәт ударниклары. Татарстанның 50 һәм В. И. Ленинның 100 еллык юбилейлары хөрмәтенә алган социалистик йөкләмәләрен уңышлы үтәүләре өчен икесе дә «В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә» медале белән бүләкләнде. Флера комбинат лабораториясендә химик анализлар ясый. Ә Шамил эшли торган цехтан каучук алу производствосы башлана. Продукциянең нинди сыйфат белән алынуы аның осталыгына да нык бәйле.

Ә кичен — техникум. Быел бишенче курс. Флераның да аннан калышасы килмәгән. Икесе дә бер курста укыйлар. Бер-беренә ярдәмләшеп яшәү, игътибарлы булу аларны тагын да якынайткан, кыенлыкларны җиңәргә ярдәм иткән. Улларының матур булып үсеп килүе семья түрендәге ямьгә нур өстәгән.

Чыннан да тынгысыз кеше ул Шамил. Цехны эшләтә башлауларына күп вакыт үтмәгән әле, ә аның рационализаторлык тәкъдимнәре белән шактый экономия ясалган инде. Өстәвенә, комбинатның партком члены буларак, ул зур җәмәгать эшләре алып барырга да вакыт таба.

Күптән түгел генә цех коллективы матур башлангыч белән чыкты. Коллектив, комбинатның эшли башлаячак яңа цехларына үз кадрларын җибәреп, практик ярдәм күрсәтергә карар кабул итте. Бу эштә дә беренче адымны Шамил ясады. Ул узган ел эшли башлаган каучук производствосы цехына килде. Аңа монда цех сменасын җитәкләү эше тапшырылды.

Яңа производство куәтләрен үз вакытында үзләштерү өчен цех коллективы шулай ук шактый эшләр башкарды инде. Инструкцияләр алдан ук әзерләнеп куелды. Техник минимумнар да тапшырылды. Һәр эшче илебезнең Ярославль, Тольятти, Ангарск һ. б. шәһәрләрендәге химия предприятиеләренә җибәрелеп алдынгы тәҗрибә алды, хезмәт алымнарын камилләштерде. Технологик процессларда кайбер төгәлсезлекләр, хисаплаулар белән расланып бетмәгән җитешсезлекләр бар иде. Аларны төгәл хәлгә китерүдә Шамилгә дә цехның технологы Ю. Ризванов белән шактый тир түгәргә туры килде. Ләкин продукция алыну аппаратындагы җылылыкның аз булуы сәбәпләре һаман билгесез кала килде. Фәннең соңгы казанышындагы яңалыкларны кулланып, исәп-хисаплаулар, сынап карау эшләре үткәргәч, нык1ы бер карарга килделәр: җылылыкның аз булуы пар трубаларының кирәгеннән артык озын булуында икән. Эшләрнең нәтиҗәсе белән уртаклашырга дип комбинатның баш инженеры П. А. Вернов янында да булдылар. Ул аларның эшенә уңай бәя бирде, киләчәктә дә яңа инженерлык тәкъдимнәре көтеп калачагын әйтте. Олы белгечнең якты сүзләре Шамилгә дә үз көченә ышаныч өстәде.

Күптән түгел СССР Министрлар Советы Председателе А. Н. Косыгин нефтехимкомбинат эшчеләре һәм җитәкчеләре янында булып китте. Коллективның эшләре, бүгенгесе һәм киләчәге белән якыннан кызыксынды. Хөкүмәтебезнең комбинат язмышы хакында аталарча кайгыртуы, бер яктан, коллективка зур бурычлар йөкләсә, икенчедән, партия куйган планнарны уңышлы үтәүдә олы ышаныч күрсәтү билгесе иде.

Комбинат коллективы ул ышанычка фидакарь хезмәте белән җавап бирде: еллык план срогыннан ай ярымга алда үтәлде. Туган илебезгә планнан тыш меңнәрчә тонна Татарстан каучугы озатылды. Ә Нефтехимия һәм нефть эшкәртү промышленносте министрлыгы, предприятиеләр арасындагы еллык социалистик ярышка йомгак ясагач, Түбән Кама нефтехимия комбинатының икенче урынга чыкканлыгын, аның бүләкләнүен билгеләп үтте.

Уфа шәһәрендә Союз күләмендә үткәрелгән нефтехимикларның иҗади киңәшмәсенә җибәрелгән делегация составында Шамил Имаметдинов та бар иде. Илебезнең башка алдынгы химиклары белән тәҗрибә уртаклашу, яңа фән казанышлары белән танышу Шамилгә үз һөнәренең серләрен тагын да аңлый төшәргә ярдәм итте. Бигрәк тә нефтехимия промышленносте министры В. Федоровның делегатларга сөйләгән сүзләре аеруча хәтерендә калды. Ул илебез химиясенең бүгенгесе һәм киләчәге, аның халык хуҗалыгы өчен тагын да зур әһәмияткә ия булачагы хакында сөйләде. Шулай ук Түбән Кама нефтехимкомбинатының киләчәгенә дә киң тукталды.

Ә аның бүгенгесе матур булса, киләчәге тагын да гүзәлрәк. Партиябезнең XXIV съезды карарларында: «Түбән Кама нефтехимия предприятиеләре төзелешен тизләтергә»,— дип аерым әйтеп үтелгән. Шуннан чыгып тугызынчы бишьеллыкта гына да һәр ел саен икешәр завод сафка кереп барачак. Димәк, бик күп яңа продукцияләр дә артачак. Ә ун ел

эчендә комбинат үзенең масштаблары буенча Европада гына түгел, дөнья күләмендә иң зур химия гигантларының берсенә әвереләчәк. Бу — Шамил кебек гади совет кешеләренең хезмәт нәтиҗәсе, милләтләр дуслыгының тантанасы, ленинчыл политикабызның дөреслек көче дә булып тора.

Түбән Кама шәһәре белән янәшәдә генә үсеп килгән икенче бер индустрия гиганты — Кама автомобиль заводының шиннары да алар чыгарган каучуктан эшләнәчәгеннән ишетү Шамилнең үз коллективы белән горурлану хисләрен тагын да арттырды. Кама буендагы киләчәк буыннарга олы бер тарих булып калачак шанлы хезмәт мәйданнарында үз эшенең дә нәтиҗәсен күрү үзе бер зур шатлык бит ул. Ул кинәшмәдән яңа дәрт, яңа рух белән, киләчәк зур эшләргә канатланып кайтты.

Ә тиздән шәһәр күләмендә җиңел атлетика буенча спорт ярышлары икән. Аңа да әзерләнәсе бар. Комбинатның спорт данын яклауда һәр вакыттагыча Шамил тыныч кала алмый. Күп ярышларда җиңеп тә чыга. Бәлки, бусында да иптәшләренең ышанычын аклар...

...Менә көн дә кичкә авышты. Смена эш тәмамлады. Шамил дә, цехның бер төркем эшчеләре белән, кайтыр юлга чыкты.

Кама-Чулман ягыннан кешеләрне матур эшләргә дәртләндереп талгын җилләр исеп узды.

Ә аяз күктә балкыган меңләгән йолдызлар, комбинатның бик еракларда балкып күренгән якты утларына кушылып, тагын да нурландылар. Җирдәге күркәм эшләргә, хезмәт йолдызларына сокланып алар да яктырак яндылар.

IIIIIIIIIIIIIII

Гариф Ахунов

# СӘХНӘДӘ — АЙРАТ АРСЛАНОВ

Безгә, бер төркем татар язучыларына, Татарстанның эстрада осталары белән бергәләп, Донбасс якларында булырга туры килде. Гадәттә халык белән очрашуларда язучыларның игелекле юлдашлары актерлар була, андый очрашуларга, җилкәсендә мең төрле эш, мәшәкать булуга карамастан, Айрат Арсланов та бик теләп катнаша.

1972 елгы яз аендагы сәяхәтебез, СССР төзелүгә илле ел тулу уңае белән Украинаның Ворошиловград өлкәсендә үткәрелгән татар әдәбияты атналыгы көннәре, минем үземдә Айрат Арсланов иҗаты хакында мәкалә язып чыгу теләген уятты.

Бу — әлбәттә — беренче сызмалар. Мин һич кенә дә тулылыкка, нәфис сүз сөйләүнең барлык нечкәлекләренә төшеп язуга дәгъва кылмыйм. Максатым тыйнаграк: Айрат Арсланов иҗатының берничә төп моментына сәнгать белгечләребезнең һәм сәнгать сөючеләребезнең игътибарын юнәлтү.


**Халык улы булуыңны аңлау.** Атналыкка без унике язучы, биш җырчы, бер нәфис сүз остасы һәм берничә журналист барган идек. Ворошиловград предприятиеләрендә чыгышлар ясаганнан соң, безне төркемнәргә бүлеп, районнарга чыгарып җибәрделәр.

Дүрт-биш кешелек безнең төркемдә Айрат Арсланов та бар иде. Безгә Кременное, Рубежное кебек шахтерлар шәһәрләрендә дә, ТЭЦ төзүчеләр янында да, терлекчеләр җәйләүләрендә дә булырга туры килде. Юллар һәр урында да асфальт түгел, басу юллары бар, тузаны бар, баш өстендә утлы шар кебек кыздырып торган кайнар кояшы бар, көн саен шундый юллардан йөзәр чакрым җир узарга туры килә. Табигыйдер ки, эсселектән, юлдан, тузаннан шактый ук арыган язучының, актерның, шушы хәлләргә җайлашып, җәйләүләрдә җиңелчәрәк киемнән, өс-башын сәхнә киеменә алмаштырмыйча сөйләргә дә омтылуы мөмкин. Әмма бу очракта безнең барыбызга да мисал булып Айрат Арсланов килеп чыга иде. Йөзәр чакрымлы юлга ул кунак йортыннан дәү бер чемодан да күтәреп чыга. Бактың исә анда шыплап тутырган нәрсә дә юк, бик һәйбәтләп үтүкләп салынган сәхнә костюмы. Безнең Айратыбыз шул зур чемоданны, кайда гына бармыйк, һәр вакыт үзе белән йөртә, иң кыен урыннарда, мәсәлән, төзелеп яткан ТЭЦның таш-кирпеч өемнәре арасына, яки берәр будкага барып киенә һәм... халык алдына һәркайчан ялт итеп торган киемнән, пөхтә булып, матур булып, гаять тәз һәм зифа булып килеп чыга.

Пөхтә киенү, чибәр күренергә тырышу — кешенең тумыштан ук килгән табигый бер гадәте булырга мөмкин. Һәм бу, шулай ук, сәнгать кешесенең үз урынын, дәрәҗәсен белеп, аңлы рәвештә эшләгән эше дә булырга мөмкин.

Айрат Арслановта боларның һәр икесе бергә кушылган. Әмма аңлы рәвештә алып барганы көчлерәк булса кирәк. Без аңардан үзара, якын итеп, ничек син һәрбер очрашуга шул хәтле дә пөхтә киенергә, иң кыен шартларда да тышкы кыяфәтеңне сакларга иренмисең? — дип сорагач, ул, гади генә итеп, болай дип җавап бирде:

— Без бит Татарстаннан килдек. Безне татар халкының уллары итеп кабул итәләр. Ничек инде үз халкыңны, Максим Горькийлар, Чеховлар патша Россиясенең иң авыр елларында да пөхтәлек һәм хезмәт сөю ягыннан зурлап телгә алган халкыңны, бүген, чиста-пөхтә киенү өчен бөтен шартлар булган заманда, ким итеп күрсәтәсең?!



Әйе, Айрат Арсланов белән бер атна йөргән чакта без, язучылар, аңарда үз халкының улы булу тойгысы ифрат зур икәнне күрдек. Минемчә, бу тойгы һәркемнең канына сеңгән булырга тиеш.

**Җаваплылык тойгысы.** Актердагы бу сыйфат турыдан-туры аның беренче сыйфатына килеп тоташа, алай гына да түгел, аның шул сыйфатыннан үсеп тә чыга. Үз халкының улы булуны аңлау тойгысы ул үз халкының нәрсәгә сәләтле икәнен башка халыкларга мөмкин хәтле тулырак итеп китереп җиткерү дигән сүз түгелме?

Әгәр бу шулай икән, актер үзен һәр җәһәттән камил югарылыкка күтәрергә тиеш. Иҗаттагы җаваплылык тойгысы программа төзүдән башлана.

Айрат Арсланов, артистларның үз терминнары белән әйтсәк, сөйләү жанрында егерме ел буена эшләп килә. (Башка жанрлардагы хезмәте хакында соңыннанрак сөйләрбез.) Егерме ел вакыт эчендә ул дистәдән артык программа төзеде, һәр программасын нык уйлап төзеде, гражданлык позициясе белән югары сәнгать законын бергә куша алуынраслады. Һәм шул сәбәпле ул иң таләпчән тамашачы, башкалабыз Мәскәү тамашачылары алдында да югары бәя алды. Программаларга күз салыйк:

Туган ягым Татарстан.
Татар совет поэзиясе.
Шагыйрьнең гомере (Г. Тукай поэзиясе).
Герой шагыйрь Муса Җәлил.
Бетен тавышка (В. Маяковский поэзиясе).
Мәхәббәт лирикасы.
Кыска хикәя кичәсе.
Антон Чехов хикәяләре.
Чит ил поэзиясе кичәсе.
Мин — Советлар иле гражданины.
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Бу программаларда беренче карауга ук тирән идеялелек, җаваплылык күзгә ташлана. Татар совет поэзиясенең, татар классик поэзиясенең югары үрнәкләре сайланып, ныклы бер композициягә корылган. Аннары — рус шагыйрьләре, рус язучылары, илебезнең барлык якларында яшәүче тугандаш халыкларның әдипләре тупланган. Әгәр актерның һәр программасын җентекләп күздән үткәрсәгез, аларның нинди зур җитдилек һәм киң диапазон белән төзелгәненә игътибар итми кала алмассыз.

Иң элек бер нәрсәне онытмыйк: сәнгать иҗатчыдан чама хисе, такт һәм югары зәвыклы булуны таләп итә. Хәтеремдә, Айрат бер мәртәбә шигырь бәйрәмендә урта кул бер шагыйрьнең Тукайга багышлап язган йомшак шигырен сөйләде, ә шуның өчен халыктан, язучылардан күпме шелтә ишетте. Бу аңа гомерлек сабак булды.

Айрат Арсланов төзегән программаларда чын мәгънәсендәге талантлы зур язучылар, зур шагыйрьләр генә түгел, аларның да үз гомерләрендә иҗат иткән иң көчле әсәрләре, өстәвенә, актерның үзе иҗат иткән программага, үзе халыкка тәкъдим итәчәк образга туры килә торган әсәрләре алына.

Дистәдән артык программаның эзелү принципларын сөйләп чыгар өчен генә да нәфис сүз сәнгате хакында зур бер китап язарга кирәк булыр иде һәм мин Айрат Арслановның эш үрнәгендә андый китап әле язылыр дип бик нык ышанам! Ә хәзергә программаның бары тик икесенә — «Күңелем Ленин белән сөйләшә»гә һәм Ворошиловград программасына гына тукталам. Шушы ике программа А. Арслановның сәхнә почеркын, актерның йөзен һәм зәвыгын беркадәр ачып бирә алыр дип уйлыйм.

Иң элек Ворошиловград программасы турында. «Дуслыкның көче океан» дигән программаның унбиш минутлык бер кисәге иде бу.

Айрат Арсланов — ялт итеп киенгән, озын буйлы, искиткеч ягымлы йөзле актер — халык алдына чыгып баса. Сәхнә ягымлылыгы актерның ярты уңышы, дигән К. Станиславский. Безнең Айратыбыз белән зал арасында шундук үзара ягымлы аңлашу, бер-берсенә ышану тойгысы уяна. «Здравствуйте!» — дип, русчалап дәшә Арсланов. Бу — аның, Татарстан вәкиленең, Донбасс шахтерлары белән исәнләшүе дә, шул ук вакытта рус шагыйре Владимир Солоухин шигыренең исемен әйтүе дә.

Актерның йомшак, матур тембрлы тавышы зал өстенә агыла башлый. Бар иде бит безнең матур бер гадәтебез, без бер-беребезгә «Исәнмесез!» дип дәшә идек, юл чите тездән кар булса да, хәтта ләпек булса да читкә чыгып юл бирә идек. Без ул гадәтләребезне шау-шулы шәһәрләрдә югалта башладык түгелме? Чыннан да, халык ташкыны агылып торган Горький урамында яки ГУМда һәр кеше белән берәмберәм исәнләшеп йөрмәссең бит. Ә «Исәнмесез»! — нинди олы сүз, нинди ягымлы сүз, сәламәтлегегез әйбәтме, исән-сау яшисезме дигән сүз бит инде. Ә менә хәзер мин сезгә зур бер шатлык хисе белән күңел тойгымны әйтеп бирә алам: «Здравствуйте!» — Исәнмесез!

Зал өстеннән янә бер мәртәбә ягымлы, эчкерсез елмаю, дустанә хис уза. Актер белән халык арасы тагын да якыная, тагы да җылына төшә кебек. Менә шуннан инде Арсланов украин шагыйре Рядченконың Муса Җәлилгә багышланган шигырен укый. Ни өчен татар шагыйренең яки башка халык шагыйренең түгел?

Беренчедән, без тугандаш украин халкы җирендә, икенчедән, Рядченко Муса батырлыгының төп мәгънәсен башка шагыйрьләргә караганда кыскарак та, остарак та итеп әйтеп бирә алган. Игътибар итик, «Исәнмесез!»не укыган чактагы Айрат тавышындагы лирик җылылык, дуслар белән күрешү сөенече инде бу юлы җир өстеннән үзган трагедияне аңлату, фашист палачларына карата аяусыз нәфрәт хисе — Айрат тавышындагы интонацияләр — залны электрлаштыра, гүя халык йөрәгеннән кайнар ток уза. Салават күперендәге төрле төсләр кебек, Айрат тавышындагы интонацияләр үтә дә табигый рәвештә үсә, үзгәрә, байый бара, совет поэзиясенең йөз аклыгы булган Җәлилгә, шагыйрьне тудырган һәм үстергән Татарстан җиренә карата рәхмәт хисе булып тулышып җитә. Әнә шундый табигый җирлекне тудырганнан соң гына актер Муса Җәлилнең үз шигырьләрен укуга күчә. «Ышанма» шигыре белән ул аны барыннан да бигрәк туган-үскән җиреннән, гаиләсеннән еракта газап чигүче тоткын шагыйрь итеп, кеше итеп бирә. Аннары герой шагыйрьнең «таш капчыкта» рухы сынмавын аның шаян шигыре аша җиткереп, оптимистлыгын раслый, «Татарлар елмаеп үлделәр!» дип Мусалар үлемен күргән шаһитләр әйткән сүзне сәнгать теле белән исбат итеп бирә, тик шуннан соң гына туган халкына, Совет ватанына, совет поэзиясенә васыять итеп әйткән «Җырларым» шигырен сөйли. Юк, сөйли дип әйтү аз, ул драматик актер булып, әйе, әйе, нәкъ менә драматик актер булып, Муса батыр монологын залга әйтеп бирә. Менә кайчан аңар Татар дәүләт академия театрында эшләп, драматик актер булып җыйган тәҗрибәсе ярдәмгә килә. Дөресен әйтергә кирәк, Айрат Арслановка актерлык әллә ни шөһрәт китерә алмады, академтеатр аның бушка уздырган вакыты диебрәк караучылар да булмады түгел. Тик актер үзе моның белән һич тә килешә алмый, сөйләү жанрына өстәлгән нyклык, җитдилек аның сәнгатенә академтеатрдан башлап салынды, ә ул үзе шул ныклыкны, чынлыкны, үз-үзен тотуда, халык белән уртак тел табуда булган ышанычын театрда таптым дип, «академга» күңелендә рәхмәт хисе саклап йөри. Нәфис сүз осталары, дөресрәге, сөйләү жанрында эшләүчеләр өчен драматик театр әйләнеп узылмаска тиешле зур бер мәктәп дип карыйм.

Безнеңчә, бу шулай ук Айрат Арслановның үз иҗатына булган таләпчәнлегенең халык алдында җаваплылык хисе тоеп эшләвенең тагын бер әйбәт мисалы.

Айрат Арслановның талантын халык та, Татарстан хөкүмәте дә аның иҗатының ренче дәверендә ук күрделәр. 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты м сәнгате декадасыннан соң ук аңар Татарстанның атказанган артисты дигән мак-улы исем бирелде.

Әнә шул исемне әле алга таба аклыйсы, үстерәсе, сәнгатьтә беркетәсе бар иде.

Сәнгатьтә барлык художниклар омтылган һәм барлык җан җылылыгын салып шләгән бер тема бар. Ул — Ленин темасы.

Айрат Арслановның да дистәдән артык программасы арасында Ленин темасы рым бер югарылыкта тора.

Моңа ул гаять зур әзләнүләр, иҗат газаплары аша килде.

Беренчедән, Айрат программасы башка сүз осталары программасын кабатламас-, аның Ленин темасына үз мөнәсәбәтен, үз карашын белдереп торырга, кыскасы, на бер ачыш булырга тиеш иде.

Айрат эшне Ленин мирасыннан, юлбашчы турындагы әсәрләрне, истәлекләрне кудан башлый. Казанның театр училищесында һәм Мәскәүдә читтән торып театр нститутында укыган дәверендә, институтларда өйрәнелгән Ленин тәгълиматының, арксизм тәгълиматының төп нигезләрен янә бер мәртәбә барлап чыга һәм аның үз алдына: ни өчен Ленинны барлык изелгән халыклар да бердәй тигез итеп күрә-әр, ни өчен алар аны үзләренең юлбашчысы, изелүдән чыгу юлын табып бирүче теп таныйлар? — дигән сорау куя. Айратка мәсьәлә ачыклана башлый. Ленинны үз халкың язмышы белән бәйләп күрсәтә алган сурәттә генә максатыңа ирешеп булачак.

Актерны шагыйрь Сибгат Хәкимнең Ленин турындагы әсәрләре байтактан дулкын-ландырып йөри иде. Менә хәзер ул моның нигә шулай икәнен аңлый. Ленинны Сибгат Хәким беренче чиратта кеше итеп, гаять дәрәҗәдә кешелекле итеп биргән, Ленин акылы аркылы татар халкының язмышын үткәргән, татар крестьянының атлы булу ниятын үткәргән. Бөек Октябрь революциясе булганга илле ел, ярты гасыр тулган өннәрдә, бу хыялларның инде тормышка аша баруын, инде Ленинның титаник план-нары меңләгән тракторлар, «электр елгалары» булып әверелүен, Татарстан җирена бәхет килүен күреп тору — Ленинны иллюстрация итеп кенә калдырмаган, әдәби әсәрнең тулы канлы, тере образы иткән.

Үз уйларыңның дөреслеген башкалар уе белән чагыштырып караганда хакыйкать табыла, диләр. Бүгенге заманның зур шагыйре һәм акыл иясе Пабло Неруданың Ленин турында әйткән сүзләре Айратка канат биргәндәй була.

«Минем өчен Ленин, барыннан да элек, гадилекнең бөек үрнәге, — дип яза Пабло Неруда. — Аның бик күп әйбәт сыйфатлары бар, ул даһи теоретик һәм практик, әмма мин аның гадилеген аеруча үз итәм.

Гомер буе тәҗрибә җыйган, барлык сәгатьләрне тәртипкә китереп, вакытны төгәл күрсәтергә мәҗбүр иткән сәгать остасы кебек, Ленин җир йөзенә дөньяны сүтеп җыярга килгәндер төсле тоела миңа. Аның карашы зурайткыч пыяла аша механизм-ның иң вак кисәкләрен күрә алган зирәк сәгатьче карашы кебек үткен. Шундый ук үткен караш белән ул тарихны өйрәнә, әйберләр, кешеләр хәрәкәткә килә, җанлана. Аналык чаңы суга, аннары тормыш үзе аны чолгап ала. Һәм ул әнә шул иксез-чик-сез дөньяда гади бер оста киемендә зирәк акыллы, олы җанлы кеше булып йөри.

Үзен тотуы белән ул бик күп кешеләр төсле гади, эшләгән эше белән дөнья та-рихын үзгәртеп җибәргән даһи — әнә шул контраст — мине гел үзенә тартып, мавык-тырып тора, һәм мин Бөеклекнең кешечә гади бер остасын, барлык олы һәм кечә эшләрне башкарган гади дә, куәтле дә иптәшне күңелемдә тергезәм...»

Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле шигыре нәкъ менә Пабло Неруданың Ленинга биргән бәясе белән авазлаш иде. Шигырь актер өчен программаның лейтмотивына, нык нигезенә әйләнде. Галәмнең ифрат дәрәҗәдә гади һәм бөек» кешесе белән бүгенге заман кешесенең әңгәмәсе — менә нәрсә зирәк тамашачыга — эшчегә, колхозчыга, интеллигентка.

Димәк, яңа программа ачыкланды. Хәзер шуның шигырьләрен туплап, ныклы бер композициягә салырга һәм... айлар буена, ярты шар елга сузылган зур эшкә — үзне халыкка җиткерү, сүзгә көч-җегәр салу сәнгатенә керешергә кирәк.

Әңгәмәдә Бүгенге Кеше һәм Ленин катнашырга тиеш. Бирердә сиңа янә дә югары дәрәҗәдәге чама хисен, тактны һәм зәвыкны югалтмаска кирәк. Туган телнең бизәк-

ләрен, тирәнлеген, югары идеал, бөек сәнгать хакына, халыктан армый-талмый эзлә табарга кирәк...

Без халыкның яраткан артисты, җитди уйланучан артисты Айрат Арслановның хезмәтендәге бер-ике моментын гына сөйләп бирдек. Һәр шигырьнең үз аһәңен табу, аны цезураларга бүлеп чыгып, логик басымын, яңгыраш басымнарын билгеләү, ягъни шигырьне буынтыклап сүтеп чыгып, яңадан җыю кенә-төнә эшләүне, армый-талмый эшләүне сорый. Шуннан соң аны укучыга җиткерү — үзе зур бер хезмәт таләп итә.

Илһам Шакировның табигый моңына сокланган кебек, Айрат Арслановның да сәхнәдән әдәби әсәр укуына, кыланмыйча, кулларын бутамыйча, нәфислекнең хакый-кать дигән югары дәрәҗәсенә ирешә алуына, камиллекнең югары дәрәҗәсенә ireшә алуына без сокланабыз.

Әмма без аның нинди титаник хезмәт белән ирешелүен күз алдына китермидер идек әлә.

Татарстанның атказанган артисты Айрат Арслановка «Күңелем Ленин белән сөйлә-шә» исемле концерт программасы өчен 1969 елны республикабызның иң зур бүләге— Габдулла Тукай премиясе лауреаты исеме бирелде. Бу — эстрадада сөйләү жанрының югары бәя алуы иде.

Ә шагыйрь Сибгат Хәкимгә Ленин поэмалары өчен РСФСРның Максим Горький исемендәге премиясе бирелде.

Димәк, актерның репертуар сайлаудагы җаваплылыгын тормыш тагын бер мәр-тәбә раслады.

Моңарчы без Айрат Арслановның иҗат алымына, иҗаттагы үсешенә тукталдык. Ләкин иҗаттагы үсеш художникның җәмгыятьтәге урыныннан беркайчан да аерым була алмый. Моны инде безнең Тукаебыз моннан алтмыш еллар элек үк әйтеп кал-дырган. Айрат Арсланов егерме елдан артык дәвам итеп килгән иҗатында илебез-нең бик күп калаларында — Мәскәүдә һәм Ленинградта, Ульяновскида һәм Волго-градта, Свердловскида һәм Чиләбедә, Оренбургта һәм Уфада, Төмәндә һәм Томскида Ташкентта һәм Сәмәркандта, тагын бик күп, бик күп калаларда булып, татар һәм рус телләрендә совет әдәбиятын пропагандалады, Татарстанның нәфис сүз сәнгатен кү-тәрде. Язучылар бригадалары, әдәби атналыклар, Мәскәүдә үткәрелгән Тукай һәм Такташ бәйрәмнәрендә татар совет әдәбиятының, татар классик әдәбиятының җәүһәрен һәм нәфислеген, илебез халыклары әдәбиятлары белән тугандаш гаиләдә гөрлә-үсеп килүен күрсәтеп бирде.

Бөтенроссия конкурсларында ул ике мәртәбә лауреат булып дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр алды. Татарстан радиосында һәм телевидениесендә тамашачыла-рыбыз аның тавышын ишетеп, йөзен күреп тордылар.

Кабатлап әйтәбез, Айрат Арслановның сөйләү җанрында ирешкән уңышлары безне канәгатьләндерә һәм, күңелдәгесен яшермичә әйткән чакта, бераз хәвефкә дә төшерә. Безнең менә дигән җырчыларыбыз бар. Ул өлкәдә өлкән җырчылар тәҗри-бәсе тупланды, урта буын халык ихтирамын казанды, яшь җырчыларыбыз үсеп килә.

Ә менә сөйләү жанрында инде ветераннар булган Фәйзи Юсупов, Әзәл Яһудин кебек эстрадачыларга алмаш килмәгән кебек, Айрат Арсланов артыннан ялтыра-үсеп килүче нәфис сүз остасы да юк. Казанның театр училищесында, культура инсти-туты филиалында һәм Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә нәфис сүз осталарының яңа буынын тәрбияләү, татар әдәбиятын пропагандалау мәсьәләләре кон тәртибенә җитди итеп куелырга тиештер.

Без, язучылар, Айрат Арслановның югары сәнгать законнары буенча башкарга-зур хезмәте Ворошиловград өлкәсе хезмәт ияләрендә тирән ихтирам һәм зур соклан-уятуын күреп кайттык.

Без Айрат Арсланов кебек җитди зур актерның филармониядә партоешма секре-таре булып олы җәмгать эше алып баруына да ихтирам белән карыйбыз, шул ук вакытта язучыларның иң зур дусты итеп, иптәшләрчә әйтер сүзебез дә бар.

— Хөрмәтле дустыбыз Айрат, актер буларак та, партоешма секретаре буларак та нәфис сүз осталарыбызның җырчылардан калышмавын кайгырту, сөйләү жанрында эшләүчеләрнең яңа буынын тәрбияләү синең шәхси җаваплылыкка да кагыла. Безнең сиңа, синең зур һәм күп яклы иҗатыңа булган изге теләкләребезнең тагын берсе әнә шул!

Светлана Червонная

# ТУГАННАРЧА ДУСЛЫК ШАРТЛАРЫНДА

Җәмгыятебез алга барган саен совет кешеләренең дөньяга карашын, коммунизм төзүченең әхлак сыйфатларын һәм, гомумән, халыкның югары рухи культурасын формалаштыруда сәнгатьнең әһәмияте һәм тоткан рыны үсә. КПССның XXIV съездында фәнни нигезләнгән менә шушы хәл рәссам-ардан үз әсәрләренең сәнгатьчә эшләнешенә, коммунистик партиялелекнең югары ринципларына турылыклы булуына аеруча зур игътибар таләп итә. Халыкны ком-унистик рухта тәрбияләүнең иң мөһим чараларыннан берсе булган сәнгатькә җә-мәгатьчелек игътибарының көннән-көн арта баруы совет сәнгатенең хәзерге хәлен итди анализлауны, тарихи тәҗрибәне өйрәнүне һәм сәнгатьтә чорыбызның милли оциалистик культуралары ирешкән уңышларны гомумиләштерүне сорый. Моның улай кирәклеге КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы махсус карарында аеруча басым ясап әйтелде. Бу хәл күп яклы, катлаулы, гел үсеш-ә булган Совет Татарстаны сынлы сәнгатенә дә тулысынча кагыла.

Быел илебез җәмәгатьчелеге зур күтәренкелек белән билгеләп үткән мил-әтләр дуслыгы бәйрәме — СССРның төзелүенә 50 ел тулу тантанасы татар халкы әм республика сәнгате тарихында мөһим тарихи вакыйга булды.

Совет Татарстанының рәссамнар коллективы элек-электән күп милләтле, СССР-агы төрле сәнгать мәктәпләрендә һәм төрле югары уку йортларында тәрбияләнгән әссамнарны берләштергән коллектив булып килде һәм хәзер дә шулай булып кала. еспубликаның сәнгать культурасы беркайчан да үз эченә генә бикләнеп калмады, з милли чыганаклары нигезендә генә үсмәде, бәлки барлык совет сәнгатенең җат тәҗрибәсенә таянып эш итте.

Татар халкы культурасының Россиядәге башка халыклар культуралары белән емтәсе бик күптәннән килә. Дөрес, бу процесс күбрәк әдәбият һәм театрга карый. экин бу хәл сынлы сәнгатькә бөтенләй кагылмаган дип уйлау да дөрес булмас де. Сүз дә юк, татар халкының сынлы сәнгате башка халыкларның, бигрәк тә ус халкының, сынлы сәнгатеннән элек бик нык аерылып торган. Әмма бу мәсьәләдә ернинди дә милли чикләнгәнлек булмаган.

Беренчедән, культура бәйләнешләре, үзара мөнәсәбәтләр һәм тәэсир итешүләр эрьяклы гына булмыйча, күп кенә бүтән халыкларның культуралары белән һәр ва-ыт бәйләнештә үскән. Бу җәһәттән караганда, татар сынлы сәнгать культурасы күрше ашкорт халкының сынлы сәнгать культурасы белән аеруча тыгыз элемтәдә торган. тар сәнгате истәлекләренең кайбер төрләре белән (әйтик, эпиграфика, XVI—XIX сырлардагы кабер ташларына язылган язулар һ. б.) Төньяк Кавказ халыклары нгате арасында да шактый гына охшашлыклар күрергә мөмкин. 1800 елда Казанда ылган «Азиатская типография»нең бай продукциясе шулай ук Татарстанга һәм

Башкортстанга гына түгел, бәлки Урта Азиягә дә таралган. Шул рәвешле Россияда яшәүче татар халкының китап сәнгате формалары Көнчыгыш халыкларына да үтеп кергән.

Икенчедән, рус демократик сәнгать культурасының үсүе татар халкында шулай ук эзсез калмаган. XIX гасырда Казанның заманына күрә зур культура үзәге булып әверелүе, аның шактый алга киткән сәнгате, театр тормышы, архитектура-төзелеше һәм нәшрияты булган университетлы шәһәр булып китүе, ниһаять, 1895 елда сынлы сәнгать мәктәбе ачылуы татар рәссамнарының иҗади талантларын уятып җибәрүгә дә уңай йогынты ясамыйча калмаган, әлбәттә. Мәсәлән, XIX гасырның мәгълүм милли рәссамы Гали Мәхмүдов профессиональ рәссам һәм культура эшлеклесе булып Казан университетында формалаша. Ул күп еллар буена (1842—1855 елларда) элеге университетта орнамент һәм каллиграфия укыта.

Әйе, татар халкының башка милләт халыклары белән культура багланышы элек-тән килгән. Ләкин Бөек Октябрь революциясенә кадәрге бәйләнеш белән революция-дән соңгы бәйләнешне бер киштәгә куеп тикшерү методологик яктан һич тә дөрес булмас иде. Чөнки революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы культура элем-тәләре характерлары ягыннан да, сыйфатлары ягыннан да бер-береннән бик нык аерылалар. Революциягә кадәр реакцион көчләр төрле милләтләрнең культураларын вакларга, чикләргә, хәтта бер-беренә каршы куярга тырышкан булса, революциядән соң мондый ясалма киртәләр җимереп ташланды. Халыклар арасында культура тигезсезлеге бетерелде. Шуның белән бергә, меселманнарга тере җан ияләренең сурәтләрен ясарга ярамый, дип өркетеп килгән ислам дине догмаларына да чик куелды. Революциягә кадәр меселман халыклары өчен ябык булган сәнгать мәктә-бенең ишекләре талантлы татар яшьләре өчен дә киң итеп ачылды. Татарстан АССРда культура төзелеше башланган көннәрдән алып бер-беренә бик тыгыз бәй-ләнгән түбәндәге ике бурычны хәл итү өчен эш алып барыла башлады: бер яктан, талантлы кешеләрдән эзлекле рәвештә милли кадрлар хәзерләүгә, аларны профес-сиональ сәнгатьне үстерүгә юнәлтүгә зур әһәмият бирелде, икенче яктан, республика рәссамнарының күп милләтле коллективын ныгытуга, Татарстан АССРның социали-стик культурасын күтәрү буенча алда торган гомуми бурычларны хәл итү өчен төрле милләт рәссамнарын ориентацияләүгә курс тотылды. Бу җәһәттән караганда шунысы игътибарга лаек: Казан сәнгать мәктәбенең өлкән буын укытучы-осталары — элек татар халык сәнгатенең искиткеч бай хәзинәсенә, аның көнкүреш, традиция һәм тор-мыш үзенчәлекләренә бөтенләй әһәмият бирмәгән кешеләр — яңа, социалистик Татарстан шартларында татар халкында үзләре өчен гаҗәп бай сәнгать мирасы тап-тылар һәм бу табыш аларның иҗатын баетып, дөньяга карашларын киңәйтеп җи-бәрде. Революциягә кадәр Казан рәссамнарының тематик картиналарында һәм порт-ретларында (гәрчә бу жанрлар шактый нык үскән булса да) татар халкының тормы-шы бернинди дә чагылыш тапмаган, бер генә татар хезмәт иясе дә күрсәтелмәгән булса, егерменче елларда хәл бөтенләй үзгәреп китте. Нәкъ менә шул милли җирлектә татар авылы поэтикасын оста итеп һәм белеп чагылдырган (П. Радимов пейзажлары), шәхеснең рухи байлыгын, ихтыяр көчен, татар эшче сыйныфы, крестьяны һәм интеллигенциясе вәкилләрен сурәтләгән (П. Беньков сурәтләре, бигрәк тә аның «Галимҗан Ибраһимов портреты»; Г. Медведев, В. Тимофеев һәм башка рәссамнарның хезмәтләре) әсәрләр барлыкка килде.

Татар совет сәнгатендә милли һәм интернациональ башлангыч аерылмас бер-бөтен булып формалаша. Республикада яшәгән рус рәссамнары бик мавыгып Та-тарстан пейзажын сурәтлиләр, милли геройларның портретларын ясыйлар, республи-каның революцион тарихын һәм кайнап торган бүгенге тормышын чагылдырган кар-тиналар тудыралар. Егерменче елларда формалашкан бу традиция сугыштан соңгы елларда эзлекле рәвештә үсә бара (С. Ратницкий картиналары һәм аның театр өчен ясаган декорацияләре). Бүгенге сынлы сәнгатьтә бу матур традициянең тагын да киңәеп һәм баеп дәвам итүе Н. Кузнецов, С. Лывин, Н. Сокольский, А. Прокопьев пейзажларында; В. Кузелькинның тарихи картиналарында һәм портретларында; В. Карамышев, И. Колмогорцева, И. Язынин, В. Поповларның график образларында һәм Е. Киселеваның металлга чүкеп эшләгән әсәрләрендә бик ачык күренә. Бу рәссамнарның иҗат дөньясы татар халкы тормышы белән, Татарстан республикасы

сбрвзы белән, аның зур төзелешләр пейзажы белән, онытылмас тарихы һәм алда торган бурычлары белән аерылгысыз булып бәйләнгән.

Икенче яктан, революциягә кадәр иҗат формалары чикләнгән (чигү, аппликация, ювелир сәнгате, ташка язу, орнамент һәм каллиграфиянең сәнгатьчә формаларын куллану), зур сәнгать белән кызыксынудан ерак торган караңгы авылларда, бистәләрдә һәм сурәт ясауга каршы булган мәдрәсәләрдә генә иҗат иткән, әсәрләрен күргәзмәләргә кую һәм профессиональ сәнгать мәктәпләрендә уку мөмкинлегеннән мәхрүм булган татар рәссамнары, революциядән соң үзләре дә зур дәрт белән иҗат итәргә керешеп, сынлы сәнгать культурасының яңа формаларын тудыралар: алар реалистик графиканы, скульптураны, портрет ясауны өйрәнәләр һәм иҗади үстереп җибәрәләр; фигуралы композиция һәм натурадан ясау серләренә төшенәләр; политик плакат, китап графикасы, театр декорациясе өлкәсендә күп эш эшлиләр, монументаль пропаганданың ленинчыл планын гамәлгә ашыруда актив катнашалар. Мәсәлән, башта Казан сәнгать мәктәбендә, аннары Мәскәүдә ВХУТЕМАСта укыган (1919—1926) елларында ук яшь рәссам Бакый Урманче үзен күп яклы сәләт иясе итеп танытып өлгерә. Ә инде укып чыгып Казанда эшли башлагач исә, ул татар сынлы сәнгате өчен яңа булган көнкүреш әйберләре һәм портрет жанрын үстереп җибәрә. 1922 елда Казанда Госман Арсланов та иҗат эшенә керешә һәм ул чордагы татар культурасы өчен әле яңа булган иҗат формаларын — политик плакат, газета рәсеме, китап һәм журналларга иллюстрация өлкәсендә бик күп һәм нәтиҗәле эшләр башкара. Театр декорациясен җайга салуда да катнашып, 1923 елда татар театры сәхнәсендә барган «Принцесса Турандот» спектакленә декорация эшли. Шул ук егерменче елларда татар язучыларының китапларын сәнгатьчә формалаштыру, аларга сюжетлы иллюстрацияләр ясау өлкәсендә рәссам Фаик Таһиров та бик күп иҗади эш башкара. 1923 елда чыга башлаган «Чаян» журналында рәссамнардан Г. Арсланов, И. Сөләйманов, Ш. Мөхәммәтҗанов үзләренең сатирик рәсемнәре белән катнашалар һәм, шулай итеп, милли сатирик рәсем жанры да бик тиз үсеп китә. Ә инде егерменче елларның ахырында исә татар рәссамнары үзләре рәсем сәнгате укытучылары булып (Бакый Урманче) житешәләр һәм Казан сәнгать техникумында системалы рәвештә милли рәссамнар әзерләп чыгарыла башлый. Мәсәлән, 1927—29 елларда әлеге мәктәпнең графика бүлегендә яшь талантлардан А. Кәримов, Ш. Гарифуллин, В. Хөснетдинов, Г. Кәримуллин, Ш. Мөхәммәтҗанов һәм Юсуповлар рәсем, гравюра, литография осталыгына өйрәнәләр, полиграфия эшен эшлитерәләр. Кыскасы, рәсем сәнгатенең барлык өлкәләрендә дә татар рәссамнары, рус рәссамнары белән кулга-кул тотынышып, бер-берсенә ярдәм итешеп эшлиләр. Һәм бу иҗади дуслык елдан-ел ныгый бара.

Ленинградтагы пролетар сынлы сәнгать институтын тәмамлап, 1931 елны Садри Ахун Казанга кайта һәм, башка жанрларда да уңышлы иҗат итүе белән берраттан, портрет һәм монументаль скульптура жанрларын да сизелерлек үстереп җибәрә, Хади Такташ, Нәҗип Җиһанов, Муса Җәлил портретларын ясый. Аннары ул Габдулла Тукай һәйкәлен иҗат итәргә тотына һәм аны уңышлы башкарып чыга. Казандагы Тукай һәйкәле — әнә шул берничә елларга сузылган хезмәтнең нәтиҗәсе инде. 1958 елда ачылган бу һәйкәлне Садри Ахун, Мәскәү скульпторлары Л. Кербель, Л. Писаревский һәм архитектор Л. Павловлар белән бергәләп гамәлгә ашыра һәм аның бу хезмәте Татарстанда милли геройны чагылдырган монументаль скульптураның уңышлы хәл ителүенә җанлы шаһит булып тора.

Ленинградтагы рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтын тәмамлап, 1933 елда яшь рәссам Мортаза Абдуллин Казанга кайта, татар театрына декорацияләр эшли башлый. Татар драматургларының спектакльләренә — К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр»енә, Ш. Камалның «Томан артында»сына декорацияләр ясау белән бергә, М. Абдуллин рус һәм дөнья әдәбияты классиклары әсәрләреннән куелган спектакльләргә дә декорацияләр эшли. Шул рәвешле, ике милләт арасындагы интернациональ дуслыкны ныгытуга билгеле бер өлеш кертә. А. С. Пушкинның йөз еллыгына багышлап, 1937 елда Татар академия театрында куелган һәм зур уңыш белән барып, совет сәхнәләрендә күрсәтелгән Пушкин спектакльләре арасында иң гыйбәтләренең берсе буларак дан казанган «Таш кунак» спектакленә эшләнгән декорациясендә Мортаза Абдуллин театр рәссамы буларак аеруча зур иҗади уңышка

ирешә һәм үзен югары профессиональ культуралы, киң карашлы, лирик характерлы, образлы гомумиләштерүләр ясый ала торган рәссам итеп танытты.

1935 елда Пенза сәнгать училищесын тәмамлап, Казанга тагын бер яшь һәм сәләтле рәссам — Байназар Альменов килә, җиң сызганып Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. Б. Альменов тиз арада Габдулла Тукай һәм Шәриф Камал әсәрләренә ясаган иллюстрацияләре белән танылып китә. Һәм шунысы куанычлы: ул ирешкән уңышлары белән канәгатьләнеп, бер урында тукталып калмады, киресенчә, профессиональ осталыгын елдан-ел камилләштерә барып, балалар китапларына иллюстрацияләр иҗат итүдә аеруча зур уңышка иреште.

Еллар үтә барган саен республикада милли рәссамнар да арта. 1938 елда Ленинград рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтын тәмам итеп Нәбиулла Вәлиуллин да Казанга кайта һәм сәнгать училищесында укыта башлый. Булачак рәссамнарны укыту белән бер үк вакытта ул үзе дә иҗат эше белән шөгыльләнә: татар авылында Октябрь революциясе ничек булганлыгын чагылдырган тарихи картинасын яза, бик оста эшләнгән портретлар, пейзаж этюдлары, күп фигуралы композицияләр иҗат итә. Сугыштан соңгы елларда рәсем сәнгате өлкәсендә әйдәп баручыларга әйләнгән атаклы рәссамнардан Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Әнәс Тумашевлар — барысы да заманында Нәбиулла Вәлиуллинның шәкертләре булган кешеләр. Бүгенге татар рәсем сәнгате үзенең көче, нык реалистик нигезе, социаль проблематикасының киңлеге белән шулай ук укытучы һәм рәссам Нәбиулла Вәлиуллинга бурычлы. Нәбиулла ага Вәлиуллин татар сынлы сәнгатен үстерүгә тагын да зуррак өлеш керткән булыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, ул 1943 елда туган илебезне яклап фашистларга каршы көрәшкәндә яшьләй вафат булып калды.

Совет властеның беренче елларыннан ук милли рәссамнар тәрбияләүгә игътибар бирелү нәтиҗәсендә хәзер республика сәнгать культурасында милли кадрлар булмаган бер генә өлкә дә юк. Тематик картина яки портрет жанрын аласыңмы, пейзаж жанрына күз саласыңмы — Х. Якупов, Л. Фәттахов, М. Хәйретдинов, И. Халиуллов, М. Усманов, И. Зарипов, Х. Хәйдәров кебек рәссамнарның һәр яктан җиренә җиткереп эшләнгән хезмәтләрен бик еш очратырга мөмкин. Скульптура өлкәсендә дә уңышлар зур. Б. Урманче, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина, Н. Адыловларның хезмәтләрендә скульптура жанрының барлык төрләрен (портрет, аллегория, көнкүреш һәм тарихи жанр, символик характердагы һәм портрет характерындагы монументаль пластика) дә табып була. Татар рәссамнарының хезмәтләрендә графиканың барлык жанрлары һәм техник төрләре дә киң чагылыш тапты. Бу өлкәдә Г. Рахманкулова, Р. Госманов (акварель), Р. Килдебеков (рәсем), Э. Ситдиков, Т. Хаҗиәхмәтов (гравюра, тематик эстамп), И. Әхмәдиев, Л. Насыйров, С. Әбдрәшитова (карикатура) иптәшләр шактый актив иҗат итеп киләләр. Театр декорациясе, агитплакат, монументаль-декоратив рәсем һәм башка, һәм башка жанрларның барысында да милли рәссамнарның хезмәтләре бар һәм алар елдан-ел арта бара.

Шулай итеп, татар рәссамнары социалистик реализм сәнгатенең гомуми үсеш процессында аның барлык төрләрендә һәм жанрларында да катнашып, күп милләтле совет сәнгате культурасына үзләренең дә өлешләрен кертәләр, ә ул культураның кайбер өлкәләрендә аларның тавышы аеруча нык яңгырый. Алай гына да түгел, хәтта кайбер моментларда аларның таланты, аларның иҗаты әлеге культураның чикләрен формалаштыру хезмәтен дә үти. Мәсәлән, Харис Якуповның татар авылы хезмәт ияләре турындагы картиналарыннан, замандашларыбызны сурәтләгән портретларыннан һәм зур тарихи полотноларыннан башка, бүгенге совет рәсем сәнгатен күз алдына китереп тә булмас шикелле. Хәзерге совет рәсем ленинианасын Х. Якупов «Пролог»ыннан башка күз алдына китерү мөмкин дә түгел, чөнки аның ул картинасы, уңышлы иҗат ителгән әсәр буларак, бу өлкәдә үзенә аерым урын биләп тора. Һәм моның шулай булуы табигый да. Ни өчен дигәндә, Владимир Ильич Ленинның революцион эшчәнлеге Казанда университетта укыган чорда башланып киткән. Күтәренке рухлы, героик-романтик яңгырашлы, дәртле омтылыш һәм ачык колорит белән иҗат ителгән бу картинада рәссам Ильичның әнә шул революцион яшьлеген уңышлы сурәтләгән. Шунлыктан ул рәсем лениниана сы әсәрләре арасында аерылып, игътибарны җәлеп итеп тора. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: соңгы

егерме ел эчендә оештырылган бөтенроссия һәм бөтенсоюз күргәзмәләренең берсендә дә Якупов картиналары куелмыйча калганы юк.

Илебездәге барлык сәнгать югары уку йортларында укучы студентларга да дәреслек булып хезмәт итә торган «Совет сәнгате тарихы» китабында сынлы сәнгатьнең иң яхшы үрнәкләре буларак китерелгән әсәрләр арасында Харис Якупов портретлары да бар. Республиканың Питрәч районы Вахитов исемендәге колхоз алдынгыларының сурәтләрен чагылдырган ул портретларында рәссам татар совет халкының көчен, рухи матурлыгын, эшчәнлеген һәм югары мораль сыйфатларын бик дөрес һәм оста итеп ачып бирә алган. Совет Татарстаны рәссамнарының күп милләтле совет сәнгатен үстерүдә актив катнашуларын бик ачык күрсәтеп торган мондый мисалларны тагын да китерергә булыр иде. Ләкин без, аларның барысын да санап тормастан, түбәндәге ике фактны искәртеп үтү дә җитәр дип уйлыйбыз: 1967 елда РСФСР рәссамнарының Ростов-на-Дону шәһәрендә үткәрелгән плакат күргәзмәсендә һәм 1970 елда «Политик сатира тынычлык өчен көрәштә» дигән девиз белән Мәскәүдә үткәрелгән халыкара күргәзмәдә Казан «Агитплакат» коллективы һәм «Чаян» журналы рәссамнарының хезмәтләренә югары бәя бирелде. Бу — куанычлы хәл. Бу — татар рәссамнарының профессиональ осталыклары һаман үсә баруын, аларның хәзер теләсә кайсы милләт рәссамнары белән ярышып эшли алганлыкларын раслый торган бик матур дәлил.

Татар рәссамнары республикадагы бүтән милләт рәссамнары белән иңгә-иң торып иҗат итәләр, алда торган интернациональ бурычларны бергәләп тормышка ашыралар. Моның шулай булуына беркемдә дә шик калмасын өчен, Татарстан АССРның иң зур милли бүләге — Габдулла Тукай исемендәге премиянең татар рәссамнары белән бәрабәрдән Татарстанда яшәп иҗат итүче һәм иҗатлары лаек дип табылган бүтән милләт рәссамнарына да бирелеп килүен искә алып китү дә җитәр дип уйлыйбыз. Бүгенгә көндә әлеге зур бүләккә лаек булган рәссамнар барысы бишәү булып, шуларның өчесе — татар, икесе — бүтән милләт вәкилләре. Алар: Бакый Урманче, Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Николай Кузнецов һәм Эрнест Гельмс.

Совет Татарстаны сәнгатенең үсеш процессындагы төп сыйфат шул — ул барлык күп милләтле совет сәнгате белән үзара бәйләнештә торып алга бара. Татар совет сынлы сәнгатенең көче республика рәссамнары коллективындагы әлеге үзенчәлектә генә түгел, бәлки ул коллектив членнарының сәләтенә, ничек иҗат итүләренә дә бик нык бәйле. Ә Татарстанда сәләтле рәссамнар күп һәм алар уңышлы гына иҗат итеп, илебез рәссамнары сафында бер аяктан атлап, үз тазышларын ишеттереп киләләр.

Илебезнең төрле шәһәрләрендә белем алып Казанда иҗат иткән һәм укыткан татар һәм рус рәссамнары хакында сүз алда булды инде. Хәзер шунысын искәртеп китәргә кирәк: үз чиратында, Татарстан да бурычлы булып калмады. Татарстаннан чыккан рәссамнар да бүтән республикалар сәнгатен үстерүгә шактый өлеш керттеләр. Мәсәлән, 1928 елда Үзбәкстанга киткән П. Беньков үз иҗаты белән үзбәк рәсем сәнгатендә Казан сәнгать мәктәбенең реалистик традицияләрен гамәлгә кертүгә булышлык итте. Байтак еллар дәвамында Урта Азия республикаларында яшәгән һәм иҗат иткән Бакый ага Урманче да татар сәнгате белән әлеге республикалар сәнгатен үзара якынайтуга, әлбәттә, ярдәм итте. 20—30 елларда системалы рәвештә Идел буендагы күрше республикаларга барып, иҗат итеп һәм ул республикаларның рәссамнарына шефлык күрсәтеп, Казан рәссамнары Г. Медведев, П. Радимов, В. Тимофеев, П. Байбарышевлар Мари, Чуваш һәм Мордва Автономияле Совет Социалистик Республикаларының милли сәнгате культураларын күтәрү өчен шактый эш башкардылар. Казан сәнгать училищесы профессиональ рәссамнар әзерләп чыгару буенча Идел буе республикалары өчен дә, Советлар Союзының бүтән культура үзәкләре өчен дә үзенә бер төрле милли үзәк булып хезмәт итте. Удмуртиянең күренекле рәссамы Н. Косолапов, Ярославль рәссамы А. Мәҗитов, мари Б. Пушков, мордва В. Попков, тувалы С. Ланза һәм башкалар барысы да Казан сәнгать училищесында профессиональ белем алган рәссамнар. Шул ук вакытта сугыштан соң, бигрәк тә бу соңгы елларда, Татарстан АССРда югары квалификацияле рәссамнарга ихтыяҗ да артты. Рәссамнар коллективында Советлар Союзының югары сәнгать уку йортларында белем алган югары квалификацияле кадрлар күбрәк булган саен респуб-

ликаның сәнгать культурасы да сыйфаты ягыннан камилләшә, үсә бара. Анңары тагын шунысы да бик әһәмиятле: тәҗрибәле һәм югары белемле рәссамнар яшь талантларны укыту һәм тәрбияләү эшендә дә зур файда китерәләр. Мәсәлән, башта Харьков сәнгать институтында укыган, аннары үзе шунда укытучы булып эшләгән Мәснәви Хәйретдиновның 1960 елда Лениногорскига кайтуы һәм шунда эшли башлавы нефть якларында рәсем сәнгатенең торышын җанландырып җибәрде һәм татар культурасы белән украин культурасы арасындагы бәйләнешне ныгытуга китерде. Шул ук алтмышынчы елларда Львов сәнгать институтында укып чыккан И. Колмогорцева, Г. Зяблицев иптәшләр дә Казанга килеп зур активлык белән эшкә тотындылар. һәм Татарстан сынлы сәнгатенең төрле өлкәләрен (китап графикасы, керамика) Украина совет сәнгатенең Львов мәктәбенә хас булган үзенчәлекле декоративлылык, матурлык белән баетуга булышлык иттеләр. Ленинградның «Боевой карандаш» («Сугышчан карандаш») мәктәбендә укыган Л. Елькович сатирик графика өлкәсендә, Эстония ССРның дәүләт сәнгать институтын тәмамлаган И. Язынин, Л. Потягунин, Ю. Лысогорский, Л. Кальюрандлар эстамп, рәсем, графика өлкәсендә, Латвия ССРның дәүләт сәнгать академиясендә белем алган И. Рафиков тематик зур картиналар иҗат итү һәм катлаулы композицияләр төзү өлкәсендә шулай ук күп эш башкаралар.

Зур илебезнең географик үзәгендә диярлек урнашкан һәм башкалабыз Мәскәүгә чагыштырмача якын булган, Идел һәм Урал буйларындагы автономияле республикаларның тыгыз боҗрасы белән уратып алынган Татарстан көнчыгышка һәм көнбатышка, Мәскәүгә, Ленинградка, Балтик буена, Украинага, Урта Азиягә, Уралга һәм Себергә баручы күп санлы культура контактларын һәм элемтәләрне ныгытуда роль уйнады һәм хәзер дә шул хәл дәвам итә.

Милли культураларның тәэсир итешүенә рәссамнарның үзара очрашып яшәүләре, вакытлыча бергә эшләүләре, съездлар һәм күргәзмәләр дә шактый йогынты ясый. Мәсәлән, Мәскәү скульпторы В. Цигаль белән Мәскәү архитекторы Л. Голубовскийның вакытлыча Казанда торып эшләүләре нәтиҗәсендә 1967 елда Казан Кремле каршындагы Муса Җәлил һәйкәле дөньяга килде. Татарстан рәссамнары Идел буе республикалары рәссамнарының «Зур Идел» зона күргәзмәләрендә, бөтенроссия һәм бөтенсоюз күргәзмәләрендә әледән-әле үзләренең әсәрләре белән катнашып киләләр.

Милли сынлы сәнгать культураларының, шул исәптән Татарстан культурасының да, үзара керешеп һәм тәэсир итешеп тору процессы, бер яктан, культура бәйләнешләренең сан ягыннан һаман үсә баруына китерсә, икенчедән, яңа сыйфатка — күп милләтле совет сәнгатенең бердәмлеген формалаштыруга да бик нык ярдәм итә. Әлеге үзара аралашу, тәэсир итешү нәтиҗәсендә бер халыкның эстетик ачышы һәм сәнгать өлкәсендәге тәҗрибәсе бүтән халыкларга да мәгълүм була. Шулай итеп, күп милләтле совет сәнгатенең катлаулы һәм бердәм организмындагы гомуми закончалыклары татар сәнгать культурасына тәэсир итеп, аның иҗади мөмкинлекләрен киңәйтүгә, гомуми күтәрелешенә дә этәреш ясый. Мәсәлән, гражданнар сугышы һәм совет власте өчен көрәш елларында совет сәнгатендә политик плакат жанрының активлашып китүе 1919—1922 елларда Казанда плакат сәнгатенең чын мәгънәсендә үсеп, чәчәк атуына китерде. Революциянең беренче елларында Казан рәссамнары тарафыннан эшләнгән плакатларны алып карагач, әле бүген дә, революцион агитация эшен шулай киң итеп күтәрү өчен шул хәтле көч, кадрлар, иҗади тәҗрибә аларга каян килде икән, дип аптырап куясың. Ни өчен дигәндә, революциягә кадәр Казанда мондый хәл беркайчан да булмаган бит. Димәк, бу өлкәдә тәҗрибә дә булмаган. Революция елларында һәм революциядән соңгы гражданнар сугышы елларында Казанда яңа рәссамнар да өстәлмәгән, материаль һәм полиграфия базалары да артмыйча, гел шул элекке хәлендә кала килгән. Ләкин, шулай булуга да карамастан, Казан рәссамнары политик плакат жанрын бик нык үстереп җибәргәннәр. Безнеңчә, моның сәбәбе ул елларда бөтен Россия күләмендә атаклы булган В. Дени, Д. Моор, М. Черемных, А. Апсит кебек политик плакат осталарының барлыкка килүе һәм В. Маяковскийның «Окна РосТА»сы чыгарыла башлау белән аңлатылырга тиештер.

Моңа охшашлы хәл Бөек Ватан сугышы чорында тагын кабатланды: 1941—1945 елларда республикада плакат жанры яңадан бик нык үсеп китте. Моның сәбәбен

гэчке ситуация» белән генә дә, Татарстан графикларының бу өлкәдә осталыгы үсеп, кызыксынулары артып китү белән генә дә аңлатып бетерү мөмкин булмас иде. Сугыш елларында политик плакат жанры бөтен ил күләмендә бик нык үсеп, активлашып китте. Кукрыниксларның, Б. Ефимовның, В. Корецкийның, В. Серовның, К. Елесеевның сугышчан политик плакатлары илебезнең бүтән рәсемнәрендә дә бу жанрга карата кызыксыну уятты. Татарстан рәссамнары да сугыш елларында җиң сызганып политик плакат иҗат итәргә керештеләр. Б. Альменов, И. Бобровицкий, Э. Гельмс, Р. Сәйфуллиннар бу өлкәдә аеруча күп көч куйдылар. Монда шуны ачык итеп әйтергә кирәк: атаклы рус рәссамнарыннан үрнәк алып эшләсәләр дә, Татарстан рәссамнары аларның хезмәтләрен һич тә кабатламадылар, бәлки үз темаларын табып, мөстәкыйль рәвештә иҗат иттеләр.

Менә шулай үзара тәэсир итешеп, үрнәк алышып эш итүгә мисалларны сәнгатьнең башка төрләреннән дә китерергә булыр иде. Ләкин безнең максат ул түгел һәм бу хакта артык сүз озайтып торуның хаҗәте дә юк — мәсьәлә болай да аңлашыла дип уйлыйбыз.

Алда без егерменче елларда Казан рәссамнарының татар халкының көнкүреше, җирле этнографик материал белән кызыксынулары арту хакында искәртеп киткән идек инде. Бу мәсьәләдә Казан рәссамнарының уңышы чыннан да зур булды. Ләкин шуны онытырга ярамый: аларда мондый кызыксыну туу әлеге шул совет реалистик сынлы сәнгатендә барган гомуми процесс белән турыдан-туры бәйләнгән иде. СССР халыкларына, аларның милли культураларына революция тарафыннан гомуми кызыксыну уятылмаган булса, Казан рәссамнары П. Беньков, П. Радимов, Г. Медведев, В. Тимофеевларның һәм сәнгать белгече П. Дульскийның татар халкы тормышына, аның культурасына багышланган хезмәтләре дә дөньяга килмәс иде.

Сугыштан соңгы елларда Татарстанда тематик сынлы сәнгать бик нык үсеп китте. Катлаулы драматик картина, атап әйткәндә, Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» (1954) дөньяга килде. Татар сынлы сәнгате өчен зур үсеш иде бу. Милли сәнгатьнең сугышка кадәрге һәм сугыш елларындагы торышы белән чагыштырганда зур алга китеш иде. Чөнки моңарчы татар сынлы сәнгате тарихында халыкның героик характерын, милли тарихның мөһим катламнарын сәнгатьчә шушылай тирән итеп ачкан әсәрләр юк иде әле. Зур совет энциклопедиясенең 1946 елгы беренче басмасында бик хаклы рәвештә әйтелгәнчә, татар сынлы сәнгате әле үзенең милли осталарын тиешенчә ачып җиткерә алмаган иде. Ә менә шуннан соң дүрт ел үтү белән СССР Дәүләт премиясенә лаек булган һәм татар рәссамнары Харис Якупов белән Лотфулла Фәттаховның исемнәрен бөтен Советлар Союзына танытк<br>ан «Татарстан АССР төзелү турындагы декретка В. И. Ленинның кул куюы» исемле картина дөньяга килде. Шуннан соң татар тематик сынлы сәнгате тагын да ныграк үсеп китте һәм татар рәссамнары татар халкының милли горурлыгы булып саналырлык картиналарны байтак иҗат иттеләр.

Бу — татар рәссамнарының зур уңышы иде, әлбәттә. Ләкин бу зур үсешне Казан сәнгать мәктәбе традицияләренә генә кайтарып калдыру бик үк дөрес булмас иде. Моны утызынчы елларда ук үсә башлаган Б. Иогансон, А. Дейнека, С. Герасимовларның тарихи картиналары һәм сугыштан соңгы елларда интенсив рәвештә алга киткән А. Пластов, В. Серов, Т. Яблонская, Э. Калнынь, О. Зардарян кебек күренекле рәссамнарның хезмәтләре, ягъни бөтен милли совет тематик сынлы сәнгатенең гомуми уңышлары белән бәйләп аңлатырга кирәк. Татар сынлы сәнгать осталары үзләренең эш барышында нәкъ әнә шул ил күләмендә ирешелгән тәҗрибәгә таяндылар һәм шуның нигезендә беренче карашка искиткеч булып тоелган уңышларны яулап алдылар. Кукрыниксларның «Һәлакәт», Б. Иогансонның «Коммунистлардан сорау алу» кебек әсәрләре булмаса, ихтимал, Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» дигән картинасы да дөньяга килмәгән булыр иде. Кабатлап әйтәбез: монда сүз һич тә кемнәндер, нәрсәнедер күчерү, иҗади үзенчәлек булмау турында түгел, бәлки культураларның үзара бер-беренә уңай тәэсире, татар сынлы сәнгатенең рус совет сәнгате тәҗрибәсе белән баетылуы хакында бара.

Тәэсир итешү бер яклы гына процесс түгел, әлбәттә. Үз чиратында, татар сәнгате дә башка милли культураларга йогынты ясый. Х. Якупов белән Л. Фәттаховның «Татарстан АССР төзелү турындагы декретка В. И. Ленинның кул куюы» иҗат ител-

мәсә, күп кенә автономияле республикалар рәссамнарының (Чувашиядә Н. Овчинников, Мари АССРда Б. Козьмин, Дагстанда М. Джемал һәм башкалар) үзләрендә автономияле республика туу тарихын сурәтләгән картиналары да, мөгаен, булмас иде. И. Зарипов иҗатына хас булган заманча милли декоративлык тенденциясе белән шулай ук бүтән республикаларның рәссамнары да кызыксына һәм аның иҗатындагы колоритлы, ритмик матурлыкның чагылышын үз әсәрләрендә дә иҗади рәвештә кулланырга омтылалар.

Ләкин менә шушындый уңышлы тәэсир итешүне беркайчан да гади бер охшашлык һәм бер-береңнән күчерергә тырышу белән бутарга кирәкми. Әгәр рәссам үз башыннан иҗат итүдән туктап, милли үзенчәлеген югалта һәм билгеле бер штамп буенча гына эш итүгә күчә икән — бу рәссам буларак бетү дигән сүз. Мондый хәл иҗатта пассивлыкка, теләсә нинди модага ияреп китүгә китерә. Мондый куркыныч элек тә бар иде, хәзер дә бетмәгән әле. Мисал эзләп ерак барасы түгел. Илленче елларның беренче яртысындагы «Чаян» журналын гына хәтерлик. Эчтәлеге белән дә, формасы белән дә «милли булмаган», баналь карикатуралар, «тешсез», кызыксыз материаллар урнаштырып бара торган һәм «Крокодил»ның провинция вариантына әйләнә башлаган журнал түгел иде микән ул?

Милләтнең рухи көчен, дәрәҗәсен һәм культура байлыгын билгели торган иҗади үзенчәлекнең булмавы сынлы сәнгатьнең кайбер төрләрендә хәзер дә сизелгәләп куя әле. Монументаль сынлы сәнгатьтәге кайбер штамплар (фигураларның схематик бертөрлелеге, сурәтләү «иероглифлары»: кран ясап куеп — төзелеш барганын, колба рәсеме белән — химия промышленностен, вышка белән — нефть чыгаруны, хатын-кыз башына калфак кидерү белән — милли үзенчәлекне аңлатырга тырышу) — болар барысы да мәсьәләгә тиешенчә иҗади карамауның, әзер, тапталган юлдан ансат кына атлап барырга тырышуның бәласе инде.

«Татар хатыннарыча: дөнья бер ефәк кулмәктер. Кояш илә ай икесе дә ике книтсльле калфаклардыр. Татар хатыннарының һәрберсе шул калфакларны кимәк арзусындадырлар».

Прогрессив дөнья культурасыннан аерылып, үз җирлегендә йомылып яшәгән шартларда татар хатын-кызларының эстетик карашы чикләнгән булуга борчылып, «Дөньяны төрлечә тану» дигән мәкаләсендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукай 1908 елда әнә шулай дип язган иде.

Халык иҗатының үзенчәлекле формаларында декоратив-көнкүреш сәнгатендә татар халкының дөньяны эстетик танып белүе һәм сынлы сәнгать өлкәсендәге сәләте нибары калфак чигүгә генә кайтып калган әнә шул заманнан соң үткән тарих өчен бик аз булган 60—70 ел эчендә Татарстан АССРның сынлы сәнгате искиткеч зур үзгәреш кичерде һәм чагыштыргысыз дәрәҗәдә алга китте. Бу татар халкының рухи дөньясы баеганлыгын, идея-эстетик карашы киңәйгәнлеген, бай иҗади тәҗрибәсе тупланууын, культурасы үскәнлеген Єик ачык күрсәтә торган матур күренеш. Татар совет сынлы сәнгать культурасының бөтен үткән юлы һәм бүгенге хәле КПСС Үзәк Комитетының «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүгә 50 ел тулуга әзерлек турында»гы карарында язылган: «Күпьеллык тормыш тәҗрибәсендә илебезнең барлык халыклары Совет Социалистик Республикалар Союзында туплануның нинди мул җимешләр бирүенә, аның киләчәктә нинди киң мөмкинлекләр ачуына ышандылар... Совет дәүләтендәге барлык милләт һәм халыкларның иҗади энергиясе, иҗат сәләтләре, талантлары туганнарча бердәмлектә тиңдәшсез тулылык белән ачылды», дигән мөһим тарихи нәтиҗәне тулысынча раслап тора.

Ясир Нурлыгаянов

# МОҢНАР ЧИШМӘСЕ

Ачык тәрәзәләрдән урамга моң агыла. Бу моң күңелләрне дулкынландыра, йөрәкнең иң яшерен почмакларына үтеп керә, тормыш мәшәкатьләрен оныттырып, гүзәллек дөньясына чакыра. Хыялың белән, кардан яңа гына ачылып, яшел хәтфәгә төренеп килгән киң басуларда, ярларына сыеша алмый аккан елга буйларында, сайрар кошлар белән тулы урманнарда, болыннарда, әрәмәләрдә йөрисең. Ә моң агыла да агыла. Әйе, таныш моң бу — Татарстанның атказанган артисткасы, композитор Сара Садыйкова иҗат иткән моңнар.

Җыр остасы, композитор С. Садыйкованың талантын югары бәяләп, филология фәннәре докторы, профессор М. Гайнуллин 1965 елда «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә болай дип язып чыккан иде: «Күп кырлы иҗат эшчәнлеге алып барган С. Садыйкова турында сөйләве кыен да, җиңел дә. Кыен: чөнки опера сәнгатенең беренче карлыгачы, үзенчәлекле артистка, сандугачтай моңлы җырчы, сәләтле композитор турында сөйләү өчен үзеңә күп нәрсәне белергә кирәк. Җиңел: бәхеткә каршы, аның күп кырлы иҗат байлыгын халык күптәннән белә».

Берсеннән-берсе гүзәл җырлары белән халык мәхәббәтен казанган С. Садыйкова иҗаты татар музыкасы тарихында лаеклы урын алып тора. Ул ярты гасырга якын гомерен татар сәнгатен үстерүгә багышлый һәм әле бүген дә, дәртләнеп, илһамланып, яңа көйләр яза, тормышның матурлыгын, хезмәт кешеләренең уй-фикерләрен, тойгыларын дөньядагы барлык халыкларга да аңлаешлы телгә — музыка теленә сала.

Җырга, музыкага мәхәббәт Сара күңелендә кечкенәдән үк уяна. Аның беренче җыр укытучысы үз әнисе була. Дин китапларында, шәригать законнарында җыр, музыка ярату гөнаһ саналса да, хөр фикерле, яңалыкка омтылучы Гайшә апа тальян гармунында татар халык көйләрен бик оста итеп сайрата, яшьли сукыр калган әбисенең узып-сузып мөнәҗәтләр әйтүен, бәетләр көйләвен, әкиятләр сөйләвен Сара зур игътибар белән, чын күңелдән бирелеп тыңлый. Һәм үзе дә, нәни бармаклары белән гармун какмаларына тырыша-тырыша басып, төрле көйләр чыгара башлый. Зирәклеге, күп белергә тырышуы белән башка балалардан аерылып торган Сара үзлегеннән укырга, язарга өйрәнә. Ул бигрәк тә прогрессив идеяләр белән сугарылган «Аң» журналын яратып укый. Бу журнал аша Сара татар әдипләреннән Тукай, Дәрдмәнд, Ф. Әмирхан, рус әдипләреннән Пушкин, Лермонтов, Купринның татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләре белән таныша.

Бераз үсә төшкәч, белемгә сусаган Сараны әтисе заманы өчен алдынгы карашлы кешеләр тәрбияли торган Аитов мәктәбенә укырга бирә. Бу мәктәптә шул чорның



Күренекле тарихчысы Г. Гобәйдуллин, педагоглардан М. Гобәйдуллина, Мөштәриевалар укыта. Аларның тирән һәм нигезле белем бирүләре нәтиҗәсендә Сараның дөньяга карашы киңәя.

Менә Бөек Октябрь социалистик революциясенең давыллы җилләре Сара укый торган Аитов мәктәбенә дә үтеп керә. Азатлык, тигезлек, хакыйкать дигән сүзләр үсмер кыз Сараны канатландырып җибәрә; Совет власте аңа бәхет алып килә, күкрәк киереп, тирән сулыш алып җырларга юл ача, яшьтән хыялланган матур уйларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Сара 1919 елда Казан педагогия техникумына укырга керә. Техникумда укыган чагында чын-чынлап җыр сәнгате белән мавыга башлый. Аның музыкаль сәләтен үстерүдә талантлы композитор һәм педагог Солтан Габәшинең ярдәме зур була.

...Татар дәүләт академия театрында 1920 елда күренекле драматург Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» исемле әсәре сәхнәгә куела. С. Габәши үзенең шәкертләрен җариялар хорында җырлау өчен спектакльгә алып килә. Беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баскан Сарага, әлбәттә, монда һәрнәрсә яңа булып тоела. Аңа аеруча Зөһрә ролен башкаручы танылган артистка Әшрәф ханым Синаева уйнавы ошый. Бу спектакльне карагач, Сараның бөтен күңелен артистка булу теләге биләп ала.

1921 елда С. Габәши җитәкли торган үзешчән сәнгать коллективы, ачларга ярдәм итү максаты белән, кыска гына вакыт эчендә «Бүз егет» пьесасын хәзерләп сәхнәгә куя. Яшь артистлар үз рольләрен зур тырышлык белән уйныйлар. Сәхипҗамал ролен башкаручы Сараның йомшак, саф, моңлы тавышы тамашачылар күңеленә аеруча хуш килә. С. Габәши Сараның сәхнәдәге һәр хәрәкәтен җентекләп күзәтә һәм соңыннан аны бәйрәм белән тәбрикләп, болай дип яза: «Яшь Татарстанның яшь таланты, сөекле шәкертем Сара! Күптән түгел генә синең исемең игъланнарда язылмый, газеталарда басылмый, телдән-телгә йөртелми иде. 1921 елның декабрендә син беренче мәртәбә Сәхипҗамал ролендә татар сәхнәсенә чыктың. Казан халкының мәхәббәтен, татар матбугатының дикъкатен җәлеп иттең»...

Техникум җитәкчеләре С. Садыйковадан киләчәктә өметле генә опера җырчысы чыгарга мөмкин дигән фикергә киләләр һәм аны Татарстан мәгариф комиссариаты аша Мәскәү дәүләт консерваториясенә укырга җибәрәләр. Ул керү имтиханнарында татар халкының борынгы көйләреннән «Уел»ны пианинода үзе уйнап, үзе җырлап күрсәтә. Бала чактан ук җаны-тәне белән җырны, музыканы яраткан Сара имтиханнарны уңышлы бирә, консерваториягә берсүзсез кабул ителә.

1925 елда Татарстанның бишьеллык бәйрәме уңае белән С. Габәши, Г. Әльмөхәммәтов, В. Виноградов «Сания», соңрак «Эшче» операларын иҗат итәләр. Татар сәнгате тарихында беренче тапкыр опера куелуы гаҗәеп зур вакыйга була. Бу турыда татар халкының классик язучысы Ф. Әмирхан болай дип яза: «Татар-башкорт музыкасын сөючеләр барсы берлектә без аның сәхнәгә куелу көнен сабырсызлык белән көтәбез. «Сания» операсындагы төп рольне С. Габәши С. Садыйкованың чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышын күздә тотып иҗат итә. Яшь җырчы Сара Казан тамашачылары алдында зур сынауны бик уңышлы үтә, ул үзен сәләтле җырчы итеп күрсәтә, сәнгать сөючеләрнең күңелендә истә калырлык гүзәл кыз Сания ролен тудыра».

1922 елда төрле вузларда укучы яшь талантлар көче белән Мәскәү дәүләт үзәк эшче татар театры ачылу хәбәрен Сара шатланып каршы ала. Һәм аны оештыруда үзе

дә актив катнаша. С. Садыйкова консерваториядә укуын дәвам иттерү белән бергә, җәйге ял вакытларында театр коллективына кушылып, гастрольләргә чыга. Татар артистлары илебезнең төрле почмакларында булалар. Донбасс, Урал, Себер якларында эшләүче якташларыбыз аларны түземсезлек белән көтеп ала һәм рәхмәт сүзләре әйтеп озатып кала. Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасында Донбасс шахтерларының татар артистларын тәбриклəп җибәргән котлау хатлары да басылып чыга. «Сара иптәш Садыйкованың уйнавын һәм җырлавын бертуктамыйча кул чабып каршы алдылар. Бигрәк тә матур җырлый, сандугач шикелле. Без әле беренче мәртәбә татар артистларының оста итеп уйнаганын күрәбез. Алар безне онытмасыннар, ешрак килсеннәр»,— дип язалар шахтерлар.

Ниһаять, музыка дөньясына Салих Сәйдәшев килә. Ул берсеннән-берсе гүзәл җырлар, маршлар иҗат итә. «Наемщик», «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар» кебек драмаларга музыка яза. Татар дәүләт академия театрында куелу белән бергә, Мәскәүдә дә зур уңыш белән барган бу драмаларда төп рольләрне һәр вакыт диярлек С. Садыйкова башкара.

Талантлы артистка С. Садыйкова 1930 елда Казанга кайтып, музыкаль спектакльләрдә уйный башлый һәм тиз арада халыкның яраткан җырчысы булып китә. Шул елларда аның турында «Азат хатын» журналында «Татарстанның сандугачы» дип исемләнгән мәкалә дә басылып чыга. Аның үзенчәлекле тавышына С. Сәйдәшев «Сандугач», М. Мозаффаров «Сайра, сандугач» җырларын язалар. Бу җырларны Сара әерым бер дәрт, эчке ягымлылык белән җырлый.

1931елда Татар дәүләт академия театры С. Сәйдәшев һәм К. Тинчурин тарафыннан иҗат ителгән «Кандыр буе» музыкаль драмасын сәхнәләштерергә керешә. Бу драмада С. Садыйкова мәхәббәт хисләре белән әчтән гена янучы кыюсыз кыз Фәридә ролен башкарырга тиеш була. Әсәрне сәхнәгә куярга инде санаулы көннәр генә калып бара, әмма Сара җырлый торган Фәридә ариясенә музыка язарга С. Сәйдәшев һаман да өлгерә алмый. Сара Фәридә җырын үзе язып карарга була.

Бер көнне ул ашыгып театрдан чыгып баручы Сәйдәшевне туктата да аны музыка бүлмәсенә алып керә һәм үзе язган көйне уйнап күрсәтә. Бу көй С. Сәйдәшевкә бик ошый, ул чын күңеленнән Сараны тәбрик итә, аңа иҗади эшкә ныклап керешергә киңәш бирә.

1934 елда Татарстан хөкүмәтенең опера-балет театры оештыру турындагы карары чыккач, бер төркем сәләтле музыкантларны Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында оештырылган студиягә укырга җибәрәләр. С. Садыйкова да шул студиядә укып кайта.

Татарстанда опера-балет театры Н. Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла. Бу операда төп рольләрнең берсе Рәйхәнәне уйнауны инде халык арасында танылган, шактый гына сәхнә тәҗрибәсе туплап өлгергән С. Садыйковага тапшыралар. Ул сәхнәдә эмоциональ яктан көчле яңгырашлы образ тудыра һәм Рәйханәнең эчке кичерешләрен, уй-тойгыларын бөтен тулылыгы белән тамашачыга җиткерә. Яшь артистканың талантына халык чын күңелдән баш ия. Сара Садыйкова хәзер ул вакыйганы: «Татар сәнгатендә опера яңа булганга, мине һәр вакыт «халык аңлый алырмы?» дигән сорау борчып торды һәм бары тик опера бетеп, халык дәррәү кул чапкач кына өстемнән авыр йөк төшкәндәй хис иттем»,— дип, зур дулкынлану белән искә ала. Опера сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Сара Садыйкова, татар җырчыларыннан беренче булып, республикабызның атказанган артисткасы дигән мактаулы исемгә лаек була. Ул үзенә тапшырылган рольләрне көннән-көн ялкынланыбрак башкара, берсеннән-берсе кызыклы, характерлары ягыннан төрле булган, истә калырлык образлар иҗат итә. Алар арасында Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендәге чая кыз Сәрвәр, әзербәйҗан халкының күренекле композиторы Газизбековның «Аршин мал алан» әсәрендәге кыю табигатьле Асия, М. Мозаффаровның «Галиябану» операсындагы мөлаем һәм саф күңелле Галиябану кебек образлар бар.

Татар дәүләт опера-балет театры Н. Җиһановның икенче зур күләмле әсәре «Алтынчәч» операсын сәхнәләштергәндә С. Садыйкова бөтен көчен, бөтен тырышлыгын биреп «Алтынчәч» ролен әзерли: әзләнә, уйлана, үзенчәлекле яңа образ иҗат итү уе белән янып яши. Ләкин көтмәгәндә барлык уйлар, матур хыяллар җимерелә.

Сугыш башлана. «Алтынчәч» операсы ярты юлда бүленеп кала, ир артистлар сугышка китә.

Сугыш вакытында Сара ханым, опера-балет театрында эшләү белән бергә, госпитальләрдә, хәрби частьләрдә яралы сугышчылар алдында концертлар белән чыгыш ясый.

1948 елда С. Садыйкова татар дәүләт опера-балет театрыннан Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенә күчә, аерым бер эстрада бригадасы оештырып, концертлар бирә башлый. Ул үзенең программасына халык көйләре белән бергә татар, рус композиторларының романсларын, операларыннан арияләрне дә кертә. Халык С. Садыйкова башкаруында күренекле рус композиторы Алябьевның «Сандугач» романсын бигрәк тә яратып тыңлый. С. Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасыннан Гөлйөзем ариясен дә халык беренче мәртәбә С. Садыйкова башкаруында ишетә. Аның репертуарында М. Мозаффаровның тирән мәгънәле, хискә бай җырлары, Н. Җиһановның операларыннан арияләр, Җ. Фәйзи, А. Ключаревның берсеннән-берсе дәртле көйләре көннән-көн киңрәк урын ала. Ул татар халык көйләрен дә үз тавышына яраклаштырып эшкәртә. Аның тарафыннан колоратура элементлары кертеп эшкәртелгән татар халык көйләреннән «Сакмарсу», «Һаваларда йолдыз», «Илче бага», башкорт халкының борынгы җырларыннан «Зөлхиҗә», «Ашказар» һәм башкалар музыка сөючеләр арасында бик тиз популярлашып китә.

Бала чактан ук халык көйләрен җырлап үсү, аларны яхшы аңлау, үзенчәлекле якларын тиз төшенү, консерваториядә уйнаган чакта Европа һәм рус композиторларының әсәрләре белән танышу, ә иң мөһиме — музыкаль фантазиягә бай булу аның үзенә дә җырлар язарга этәргеч бирә.

Вакытында Сараның көйләр язарга сәләте булуын әйтеп, С. Сәйдәшев ялгышмый. Аның Бөек Ватан сугышы елларында меңнәрчә җыр сөючеләр күңеленә җан азыгы биргән «Көтәм сине» җыры моны бик ачык раслый. Бу җыр яшь композиторга көтелмәгән зур уңыш алып килә. «Көтәм сине» татар музыкасында моңарчы күрелмәгән үзенчәлекле бер көй, төзелеше белән ул башка җырлардан аерылыбрак тора. Композитор бу җырда рус һәм татар халык көйләрендәге музыкаль алымнарны оста итеп үреп бирә.

Беренче уңышыннан соң С. Садыйкова тагын да илһамланыбрак язу эшенә керешә. Җырлар иҗат итү белән бергә, үзешчән сәнгатьтә дә актив эшләп килә. Казанның М. Горький исемендәге культура йорты каршында татар хоры оештырып, егерме елга якын яшьләргә сәхнә культурасын өйрәтә, хормейстер буларак, җыр күнекмәләре бирә. Бу хор һәр вакыт диярлек смотрларда катнашып килә һәм татар композиторларының яңа әсәрләрен пропагандалауда зур роль уйный. Аның хорында тәрбияләнгән яшьләрнең күбесе консерваториядә, театр училищеларында укый, үзешчән сәнгать белән җитәкчелек итә. Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең яшь җырчылары Ш. Әхмәтҗанов, Ф. Ишморатов, Р. Сибгатуллина, Ф. Сөләйманова һәм башкалар җыр күнекмәләрен беренче тапкыр Сара ханымнан алалар.

С. Садыйкова һәрбер яңа әсәрендә гади хезмәт кешеләренең хисләрен, уй-теләкләрен чагылдырырга тырыша. Аның халык арасында киң популярлык казанган «Өченче көн тоташ кар ява» (М. Кәрим сүзләре), «Дөнья матур, дөнья киң» (Г. Афзал сүзләре), «Язгы сулар акканда» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Кайтам инде» (И. Юзеев сүзләре), «Йөрәк сере» (И. Ганиева сүзләре) һәм башка җырлары еллар үтү белән искермиләр, ә бәлки ничектер яңача, тагын да моңлырак, тагын да дәртлерәк булып яңгырыйлар, җыр сөючеләргә чын мәгънәсендә эстетик ләззәт бирәләр.

С. Садыйкованың халыкчан җырлары әкренләп сәнгать мастерларының репертуарларында ныклырак урын ала бара. Халкыбызның яраткан җырчылары Ф. Насретдинов, И. Шакиров, Ә. Афзалова, Р. Билалова, Г. Рәхимкулов һәм башка артистлар С. Садыйкова җырларын башкарып зур уңыш казаналар.

С. Садыйкова — күп еллар сәхнәдә җырлаган җырчы-композитор, шуңа күрә ул һәрбер әсәрен җырчыларның тавышларын, башкару үзенчәлекләрен күздә тотып иҗат итә. Аның талантының тагын бер матур ягы бар — композиторның көйләре мәктәп балаларына да, яшьләргә дә, чачләренә чал кергән олы кешеләргә дә якын һәм аңлаешлы. «Беренче мәхәббәт» (Ә. Рәшитов сүзләре), «Ак пароход» (Г. Зәйнашева сүзләре), «Солдатым» (М. Ногман сүзләре) — әнә шундый җырлар.

Композиторның иҗатында тынычлык, туган илне саклау, сугышка каршы көрәш темасы аерым урын алып тора. Башкорстанның халык шагыйре М. Кәрим сүзләренә язылган «Өченче көн тоташ кар ява» җыры күңелләрдә дошманнарга карата тирән нәфрәт уятса, «Һәйкәл җыры» (Г. Зәйнәшева сүзләре), «Шәймәрданов комиссар», «Кайтырсың бит» (М. Ногман сүзләре) туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияләләр.

Эстрада музыкасын үстерүгә С. Садыйкова үзеннән күп өлеш керткән композиторларның берсе. Аның бүгенге яшьләрнең матур тормышы, тырыш хезмәте турында язылган җырлары лирик җылылык белән сугарылган. Аларны халык яратып тыңлый һәм яратып җырлый.

Бүгенге тормыш эчендә кайнау, халык белән аралашып яшәү, композиторны халыкчан әсәрләр язарга рухландыра. Көйләрен йөрәк аша үткәреп иҗат иткәнгә күрә, халык С. Садыйкова җырларын үз җыры кебек кабул итә.

С. Садыйкова музыкаль драмаларга һәм комедияләргә көйләр язучы буларак та үзен сәләтле композитор итеп танытты. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында зур уңыш белән барган «Ак калфак» (М. Фәйзи), «Күк капусы ачылса» (Х. Вахит) спектакльләрендә С. Садыйкова тарафыннан иҗат ителгән җырларны кемнәр генә рәхәтләнеп тыңламаган да шул җырлардан кемнәр генә рухи ләззәт алмаган.

Республика күчмә театрында «Шомырт чәчәк атканда» (А. Гыйләҗев), «Бәркетләр кыяга оялый» (И. Юзеев) комедияләре берничә сезон рәттән куелып килә. Бу әсәрләрнең озак еллар буена сәхнәдән төшмичә уйналуында, әлбәттә, С. Садыйкова тарафыннан иҗат ителгән җырлар да зур роль уйный. С. Садыйкованың драматург Х. Вахит белән бергә иҗади дуслыкта язылган «Мәхәббәт җыры» музыкаль комедиясен дә тамашачылар җылы каршыладылар. Яшьлек романтикасы белән сугарылган бу комедия турында язучы Г. Минский «Социалистик Татарстан» газетасында: «Мәхәббәт җыры» — профессиональ музыкаль комедия жанры традициясе һәм формасында эшләнгән спектакль. «Башмагым», «Алтын көз», «Курай моңы» кебек музыкаль комедияләрдән соң эшләнгән дүртенче спектакль ул».— дип язып чыккан иде.

Талантлы композитор С. Садыйкованың дөньяга карашы киң, аның белән бер утырып сөйләшүе нинди генә кәефсез чакларыңда да күңелләрне канатландырып, күз алларыңны яктыртып җибәрә. Аның сәхнәдәш дуслары инде күбесе лаеклы ялда, ә С. Садыйкова һаман эзләнә, яңа иҗат планнары кора, бүгенге тормышыбызга лаек әсәрләр иҗат итү өчен ялкынланып яши.

Зәет Мәҗитов

# ТИМЕРЧЕ СУГЫШТА

*Ф. Кәрим поэзиясендә солдат образы*

## 1

Фронт каһарманнарының җанлы образларын сурәтләү — Ватан сугышы чоры татар поэзиясенең зур казанышларыннан берсе. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ш. Мөдәррис, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Г. Хуҗиев, С. Хәким, Ә. Ерикәй, М. Садри кебек шагыйрьләребезнең сугыш чоры иҗатында, лирик герой белән рәттән, психологик тирәнлек белән сурәтләнгән совет солдаты образы үзәктә тора дип икеләнмичә әйтергә мөмкин.

Туган илебезнең азатлыгы өчен сугышып йөргән солдатның фронттагы батырлыкларын конкрет эпизодларда ачу белән бергә, шагыйрьләр аны берьяклы итеп, бары тик сугышчы итеп кенә күрсәтүдән сакландылар. Алай гына да түгел, алар совет сугышчысы йөзендә бөтен җаны-тәне белән тормышка, туган җиргә, кояш чыгуына, тын күлләрдә йөзгән аккошларга гашыйк нечкә күңелле, әмма шул ук вакытта, кирәк чагында ир йөрәкле һәм сабыр табигатьле дә була белүче олы җанлы кешенең реаль, табигый образын сурәтләделәр. Аның фикерләү һәм кичерү дөньясын конкрет детальләрдә һәм моңарчы татар поэзиясендә кеше образын сурәтләүдә күрелмәгән тематик колачы белән ачуга ирешелде. Бөек Ватан сугышы чорында татар совет поэзиясе ирешкән иң зур казанышларның, новаторлыкның төп моментларыннан берсе нәкъ шушы реалистик сурәтләү көченең үсүе дә инде.

Сугыш совет кешеләренең мораль һәм рухи көченә, кешелеклелек сыйфатларына хәлиткеч сынау булды. Совет кешеләре каушап калмадылар, үлемнең күзенә карап, батырларча көрәш алып бардылар. Барлык совет халыклары поэзиясендәге кебек, татар поэзиясендә дә солдат шушы сыйфатлары белән гәүдәләнде. Фатих Кәрим, мәсәлән, әле 1942 елның яз айларында ук «Дусларга» шигырендә: «Сугыш — сугыш инде, рәхимсезлек ия булып йөри күңелгә»,— дип язды. Әмма бу рәхимсезлек совет солдатының тупаслануы, кыргыйлануы дигән сүз түгел иде. Киресенчә, бу хис солдатның, көн саен, сәгать саен үлем белән күзгә-күз очрашып торуына карамастан, каушамавын, ил каршындагы бурычын үтәүдә нык торуын күрсәтү белән бәйле иде. Икенчедән, бу рәхимсезлек фашистларга карата булган иң гадел, иң кешелекле, иң тирән нәфрәттән туган иде. Ерткычларга карата йомшак күңелле булу үлем белән бер иде. Поэзиядә баштарак публицистик формада белдерелгән нәфрәт тойгысы алга таба солдат йөрәгендәге кичереш буларак сурәтләнә башлый.

Шәрәф Мөдәрриснең 1942 елгы «Парчалар» циклыннан бер шигырьгә күз салыйк:

Күп булса да йөрәк ялкыннарым,
Чит-ят җиргә чәчәр җылым юк.
Үтсәм дә мин кургаш яңгырларын,
Сыкранырга туган җырым юк![1]

Биредә лирик геройның шагыйрь икәнлеге күренеп тора. Ләкин лирик герой шагыйрь генә түгел, солдат та. Ул да, башкалар белән бергә, кургаш яңгырлары астында йөри, көрәш дәрте белән ярсый. «Сыкранырга туган җырым юк» — бу инде шагыйрьнең эстетик кредосы. Шагыйрь-солдат көрәшнең бөтен авырлыкларын иңенә ала. Җырның да вазифасы сыкрану түгел, ә көрәш. Дошманга нәфрәт белән тулы күңел бу көрәш ярсуын көчәйтә. Мәхәббәт һәм нәфрәт җыры шулай бергә үрелә:

Күп гаять тә йөрәк түрләремдә
Дус-ишемә рәхим-шәфкатем,—
Ялкын булып ярсый күкрәгемдә
Дошманнарга каршы нәфрәтем.

Бу юллар «күңеленә рәхимсезлек ия булып йөргән» солдатның нәкъ менә «гаять тә күп рәхим-шәфкатьле» кеше икәнлеген ача да. Татар шагыйрьләренең бу елларда язылган нинди генә шигырен алма — совет кешесенең шушы олы сугышчан гуманизм хисенә ия булуын гәүдәләндерү белән очрашабыз. Бу чор поэзиясенең төп герое — солдатның кешелек сыйфатларын ачуда беренче урынны нәкъ менә анык бөек кешелеклелеген күрсәтү алып тора. Әмма солдат рәхимлелек һәм нәфрәт хисләрен йөртүче генә түгел. Поэзия солдатның рухи дөньясын ачу юлыннан бара. Солдатны без дошманга каршы һөҗүмгә ташланганда да, авыр сугыштан соң землянкада ял иткәндә дә, туган җирен, анда калган сөекле кешеләрен сагынып җырлаганда да, моңайганда һәм шатланганда да күрәбез.

Солдат образы Фатих Кәрим поэзиясендә аеруча тулы ачылды.

«Хәзер фронтларда авыр һәм хәлиткеч сугышлар бара. Кызыл Армия искиткеч батырлыклар күрсәтә, зур уңышларга ирешә бара. Ничек кенә булса да вакыт табып шуны иҗат итәргә тиеш мин»,— дип яза Фатих Кәрим сугыш чорындагы бер хатында[2]. Ничек, нинди чаралар белән сугыш баһадирларының образларын ача соң шагыйрь?

Менә «Иптәш» шигыре. Әсәр соң чиккәчә җыйнак, кыска гына бер хикәяләүгә охшый. Хикәяләү шигырьгә гадилек һәм ышандыру көче бирә:

Канлы башын салып пулеметка
Үлде иптәш...
Үләр алдыннан,
Ялкынлы күз карашлары белән,
Чакырып алды мине янына.

Бу юллардан күренгәнчә, шагыйрь булган хәлне бизәми-нитми генә сөйли. Шигырь юлы белән җөмлә арасындагы симметрия шул максаттан чыгып «бозыла» (җөмләнең бер өлеше, шигырь юлы ахырында була торган гадәттәге тынышны бетереп, икенче юлга күчә). Рифманың да үтә төгәл булуы, үтә күзгә күренеп «ялтыравы» кирәк түгел (үләр алдыннан — мине янына). Аннары «иптәш» дип алуга да игътибар итмичә мөмкин түгел. Иптәш — күпләрдән берәү, гади солдатларның берсе. Ләкин ул меңнәр шикелле үк батыр сугышчы, меңнәр шикелле үк (һәм бигрәк тә шагыйрьнең үзе шикелле үк) үлемнең күзенә туры карый белә торган кеше. Шуңа күрә шагыйрь зур кайгыны ирләрчә сабыр тонда белдергән хикәяләү интонациясен сайлый да. Биредә лирик геройның үзенең дә ирләрчә нык, олы йөрәкле булуы ачылып китә.

Аның кулларында минем кул,
Кулларымны сыйпап әйтте ул.

Бу — икенче строфа. Ул бик урынлы рәвештә ике юллыкка әйләндерелгән. Ныклы ихтыярлы кешеләр хушлашканда артык сүзгә урын юк.

---

[1] Ш. Мөдәррис. Җыр үткән юл. Казан. 1947 ел. 23—24 битләр.
[2] Шагыйрьнең семья архивыннан.— З. М.

Шигырьнең соңгы строфасы — якын иптәшнең үләр алдыннан әйткән сүзләре:

**Башың түбән имә, әгәр минем**
**Тыныч үлүемне теләсәң;**
**Илле фашист**
**исән йөрер иде әле,**
**Мин бирегә килеп үлмәсәм.**

Бу сүзләрдә бөтенесе дә гади, ирләрчә тыйнак. Сурәтләр бөтенләй «бизәксез». «Бизәксезлек» бирегә үзе сурәтләү чарасы хезмәтен үти, илле фашистны кырып сугыш кырында калган нык ихтыярлы, үлгәндә дә әрнү-сызлануны җиңеп үлгән совет кешесе образы йөрәккә уелып, онытылмас образ булып кала.

Ф. Кәримнең батыр сугышчы образын сурәтләвендә күренгән беренче үзенчәлек әнә шул. Әмма Ф. Кәрим сугышчы батырлыгын сурәтләүдә күп төрле алымнарга мөрәҗәгать итә һәм һәр вакыт тиешле тонны, тиешле сурәтләрне таба белә. «Шәкүров турында җыр» шигырендә, әсәрнең исеменнән үк аңлашылганча, Ф. Кәрим батыр сугышчыга дан җырлый. Интонация дә, ритмика да шуңа бәйле рәвештә сайлана. Менә беренче строфа:

**Корыч канатлы яшь лачын**
**Сыкратты фрицларны;**
**Каныкты безнең лачынга**
**Кипкән йөзле, бүре күзле**
**Дошман зенитчылары.**

Бу инде бүтән стиль, бүтән ритм. Батыр егет образы «корыч канатлы яшь лачын» итеп алынса, дошман зенитчылары — кипкән йөзле, бүре күзле». Бер карауга бирегә сәрәтләүләрдә схематиклык бар шикелле. Ләкин әсәрне укый барган саен, анда җыр стиленең өстенлек итүен, җырга хас булганча, шигырьдә буяуларның ачык төсләре генә салынуын күрәбез:

**Меңләгән тупларның берсе**
**Тигәч самолетына,**
**Туган илне, киң Иделне**
**Искә алды егет, ләкин**
**Борылмады артына.**

Җыр да сюжетлы хикәяләү төсен алды. Бер яктан, күтәренке, романтик яңгыраш, икенче яктан, сюжет-хикәяләү үстерелә. Шунлыктан җыр предметсыз-образсыз тантаналы мактауга әйләнеп китми, киресенчә, гади, табигый хикәяләүгә күтәренкелек өстәлә. Табигыйлек тә бар, күтәренке пафос та. Шәкүровның батырлыгы җырга лаек. Ул, капитан Гастелло шикелле, «янган самолеты белән «атылган йолдыз сыман, бик биектән, зәңгәр күктән» дошман зениткасына ташлана. Җырның соңгы куплетында Ф. Кәрим уңышлы гомумиләштерү ясый:

**Шулай үлде ватан улы**
**Сугыш барган кырларда;**
**Сагынган саен, без аны**
**Бик биеккә, зәңгәр күккә**
**Күтәрербез җырларда.**

Бирегә гипербола ярдәмендә хикәяләүгә күтәренке пафос салына.

Җырның төзелешенә һәм ритмикасына килсәк, монда ике момент игътибарга лаек: беренчедән, эре сызыклар белән генә сюжет-вакыйга үсеше бирелә. Икенчедән, һәр куплет, җыр яңгырашы алып, бишәр юллы итеп төзелә: һәр строфаның 3 яки 4 юлы эчке рифма белән янсә янәшә рифмалар белән каймаланып, көчәйтеп барыла. Беренче строфада — «кипкән йөзле, бүре күзле», икенчесендә — «туган илне, киң Иделне», өченчесендә — «бик биектән, зәңгәр күктән», дүртенчесендә — «бу чокыр калганнарына, немец-фин еланнарына», бишенче строфада «бик биеккә, зәңгәр күккә» дип алына.

Ниһаять, тагын бер кызыклы моментны әйтик: батыр очучы Шәкүров — яшь лачын итеп, ә дошманнар немец-фин еланнары итеп бирелә. Лачын янып торган

молеты белән, йолдыз сыман, күктән шул еланнарга ташлана һәм җиңеп улә. Горькийның «Лачын турындагы җыр» әсәрен искә төшермичә мөмкин түгел бу ракта. Шагыйрь шигырьдә Горькийның онытылмас образларын уңышлы файдала. М. Горькийның революцион романтизмы шагыйрьгә сугышта күрсәткән бөек тырлык романтикасын бирүдә ярдәм итә.

Ф. Кәримнең башка әсәрләрендә дә сугышчы образы гаҗәп уңышлы ачыла. Сапер», «Связной» шигырьләрендә, мәсәлән, иң авыр һәм иң мактаулы хәрби проессия кешеләренең типик образлары бирелә.

## 2

Фатих Кәрим шигырьләрендә сурәтләнгән солдат фронт тормышының төрле ксыйгаларына катнаша; без аны яңа гына тылдан кайтып кабат окоп тормышына ушылып киткән хәлдә дә, землянкада ял иткәндә дә, разведкада да, мина кырында л яргалда да күрәбез. Ләкин нинди генә очракта да Ф. Кәрим солдатның рухи ньясын тулы ачуны беренче планга куя. Солдатның сагышларын, моңнарын, кайгырын да, үч һәм нәфрәтен дә, мәхәббәт һәм хөрмәтен дә, һәм, иң мөһиме, авыр рда көр һәм җор күңелле була белүен дә күрәбез без анда.

«Окоп» (1942 ел) шигыренә күз салыйк. Көзнең күк томанлы таңында солдат бат фронтка кайткан.

> **Мылтык яңа, дуслар да яңа,**
> **Окоп иске, таныш мин аңа.**

Әйе. Солдат инде күпне күргән. Окоп шартлары аның өчен яңа нәрсә түгел. негелгән. Әле күптән түгел генә («Дусларга». 1942 елның кышы), беренче тапкыр ронтка килгәндә, шагыйрь окопны:

> **Төтәп торган кырның окоплары**
> **Серле генә каршы алдылар,—**

п, «серле» эпитеты белән сурәтләгән иде. Хәзер исә окоп гап-гади, иске, күнегел и урын булып калган. Алай гына да түгел, лирик герой аңа, иске танышын очраткан й, ярым юмористик елмаю белән карый:

> **Сержант та дус булып өлгерде,**
> **Консерв һәм граната бирде:**
> **«Консервысын үзең ашарсың,**
> **Бусын... немецларга ташларсың».**

Шул рәвешчә, окоп тормышының солдат өчен искиткеч бер шарт түгел, ә көрәш артларында көндәлек яшәү урыны булып әверелүе күрсәтелә. Ләкин бу хәл солдат әргендә дошманга булган ачу давылының сүрелүе дә, солдатның инде тормыштагы ге нәрсәләргә мөнәсәбәте тупаслана төшү дә түгел. Киресенчә, сугыш сузылган ен, фашистларның ерткычлыклары ишәйгән саен, шагыйрь-солдатның дошманга рата ачуы арта, совет кешесе өчен изге нәрсәләргә олы һәм нечкә мәхәббәте ранәя генә бара. Ф. Кәрим шигырьләрендә мәхәббәт һәм нәфрәт аерылгысыз лып әвереләләр. Ф. Кәримнең сугыш елларында чыккан беренче җыентыгы Мәхәббәт һәм нәфрәт» (1943 ел) дип аталу очраклы түгел. Җыентык туган илгә, дерле кешеләргә, тормышка мәхәббәт, дошманга ачы нәфрәт хисләре белән тулы игырьләрне эченә алган.

«Совет солдаты» (1943) һәм «Сапер» (1943) кебек шигырьләрендә Ф. Кәримнең лдат образын сурәтләүдәге тагын бер үзенчәлеге — монументальлеккә омтылу лык күренә. Образның монументальлегә детальләрнең искиткеч конкретлыгы һәм бигыйлеге белән бирелә. «Совет солдаты» шигырендә без иң элек сугышчының туандәге портретын күрәбез:

> **Канатларын кагып сызгыра җил,**
> **Тузып-тузып оча күк болыт;**

Тамчыларын коя көзге яңгыр,
Җыела су юлга күп булып.

Башны саклый торган каскалардан
Җилкәләргә салкын су ага;
Манчып алган кебек шинельләрнең
Салмак итәкләрен җил кага.

Гранаталар биндә, капчык индә,
Анда патрон, анда запаллар;
Иңбашларын кисә капчык бавы,
Тирле аркалардан калка пар.

Бу сурәтләүдә детальләр капшап карыйсы килерлек дәрәҗәдә конкрет. Конкретлаштыруда төп рольне эпитетлар үтәве дә бәхәссез: «күк болыт», «көзге яңгыр» «башны саклый торган каскалар», «җилкәләргә агучы салкын су», «манчып алга кебек шинельләр», «шинельләрнең салмак итәкләре», «тирле аркалардан калк пар».

Бу — шигырьнең беренче өлеше. Монда шагыйрь аңлы рәвештә конкретлык бир торган буяуларны актив куллана. Солдатның табигый-конкрет образы тудырыла. Болай эшләү шигырьнең икенче яртысында әйтеләчәк фикерләрнең көчен арттыру, сурәтләүгә монументаль яңгыраш бирү өчен кирәк:

Ә тамырлар бүрткән: кан күп бездә,
Көч күп бездә — әйди ашкыну;
Совет солдатының йөрәгендә
Шаулап бара һөҗүм ташкыны.

Бу строфаның беренче ике юлы белән соңгы ике юлы арасында бер «ярашмау» бар. Беренче ике юлда лирик герой «без» исеменнән сөйли. Соңгы ике юлда солдат берлектә алына. «Мин»не дә, «без»не дә бер үзенә туплаган, эрелəндерелгән солдат — совет солдаты образы төсмерләнә. Аның «каны күп, көче күп, әйди ашкыну» Аның йөрәгендә «шаулап бара һөҗүм ташкыны». Гиперболик сурәтләү биредә эреләндереп гомумиләштерү өчен килә. Солдатның тышкы портреты эчке портрет белә тулыландырыла:

һәр солдатның күкрәк кесәсендә
Туганнардан килгән хаты бар;
һәр солдатның гадел вөжданында
Ватанына биргән анты бар.

Әгәр шигырьнең беренче өлешендә эпитетлар конкретлаштыру, индивидуальләштерү өчен хезмәт иткән булса, биредә алар гомумиләштерү, монументальләштерү өчен киләләр. «һәр солдатның күкрәк кесәсе», «туганнардан килгән хат», «һәр солдатның гадел вөжданы» һәм «Ватанына биргән ант». Нәкъ менә «күкрәк кесәсе», нәкъ менә «гадел вөждан», нәкъ менә «Ватанга биргән ант!».

Шигырьнең соңгы строфасы бөтенләе белән «без» исеменнән әйтелү дә бик әһәмиятле:

Кызганмыйбыз көчне... Яшь гомерне
Кызганмыйбыз кирәк урында;
Ут давылын ерып үтәбез без
Илне азат итү юлында.

Күплек куллану совет солдатының конкрет образын томалап калдырмый, бәлки аны эреләндерү, мәһабәт монументка әверелдерү өчен хезмәт итә. Бу монументта шагыйрь игътибары барыннан да элек солдатның ихтыяр көчен, җиңүгә омтылышын күрсәтүгә юнәлә.

«Сапер» шигырендә дә конкретлык белән монументальлек бергә бирелә. Моны эпизод-портрет дип тә атарга мөмкин булыр иде. Пулемет уты. Сапер — яшь солдат

шуыша. Ракеталар оча. Сапер өстендә кар кебек халат. Икенче строфада шагыйрь портрет сурәтләүдән солдатның рухын, көчен сурәтләүгә күчә. Сурәтләүдә солдатның арысланлык сыйфаты, зур йөрәге, җиңү һәм яшәү хисе тулы киң күкрәге очраклы гына бергә китерелми. Дошманга каршы күкрәгендә олы ачу саклаучы, зур рухи көчкә ия булган саперның мәһабәт портреты тудырыла. Шагыйрь табигыйлекне саклар өчен алдагы строфаны яңадан конкрет детальләр белән бирә:

**Килеп җитә. Ул-бу юкмы!**
**Шаулап җил исә,**
**Җил дә аны сакласын:**
**Сапер чәнечке чыбыкны**
**Тын алмый кисә,**
**Ача һөҗүм капкасын.**

Строфаның вакыйганы хикәяләү рәвешендә төзелүе күз алдында. Инде соңгы строфа килә. Соңгы строфа сапер батырлыгының әһәмияте турында сөйли:

**Кабына һөҗүм ялкыны,**
**Ашкына күңел,**
**Һәркем хәнҗәрен тоткан,—**
**Коела фашистлар каны.—**
**Кызганыч түгел**
**Тире суы төсле кан.**

Бу строфада инде саперның үзе турында сүз юк төсле. Сүз берлеккә алып сурәтләнгән сапердан күплеккә — һөҗүм итеп баручы солдатларга күчә. «Совет солдаты» шигырендә дә нәкъ шушы алым кулланылуын һәм аның образны монументальләштерүдә роль уйнавын күрдек.

## 3

Шушы рәвешчә, Ф. Кәрим солдат образын гәүдәләндерүдә табигый-конкрет сурәтләүне гомумиләштерү, эреләндерү белән берләштерә. Бу да Ф. Кәримнең солдатны, бер яктан, конкрет, гади кеше итеп, икенче яктан, Ватан язмышы өчен көрәштә олы батырлык эшләүче каһарман итеп күрүеннән килә. Менә шуңа күрә дә кайбер хезмәтләрдә, Ф. Кәримнең образ тудыру принциплары турында сөйләгәндә, кайбер төгәлсезлекләр җибәрелүгә игътибар итми мөмкин түгел.

«Ф. Кәримдә героизм,— дип яза В. Г. Воздвиженский,— реаль кыяфәттә күрсәтелә. Ул гадәти һәм гади, чөнки батырларча көрәш солдатның көндәлек тормышына әйләнгән. Югары тойгыларны һәм данлы эшләрне шигъриләштергәндә Ф. Кәрим үз лирикасында зурайтылган образларга һәм күтәренке интонацияләргә мөрәҗәгать итми, үз героен «җирләштерә» (ләкин түбән төшерми)»[1].

«Геройлык Ф. Кәрим поэзиясендә реаль кыяфәттә бирелә» дигән фикергә каршы килеп булмый. Әмма шагыйрь күтәренке образлар һәм югары интонацияләрдән файдаланмый, геройны «җирләштерә» дию белән килешүе кыен. Әле генә караган шигырьләр Ф. Кәримдә солдат образын сурәтләүдә «җирләштерелгән» очраклар да, күтәренке-эреләндерелгән очраклар да, ягъни төрле алымнар куллану барлыгы турында сөйлиләр. Әле 1942 ел уртасында ук ул, «Шәкүров турында җыр» белән рәттән, «Тимер һәм тимерче» балладасын язган иде.

Баллада жанрына мөрәҗәгать итү үзе үк инде сугышның драматик вакыйгалары эчендә романтик-күтәренке эпизодлар күрү белән бәйле иде. Сугыш кырында ике көч: колхоз тимерчесе Саттар белән тимер тавы — үлем алып килгән дошман танкысы бәрелешә. Баллада алымы шагыйрьгә барлык буяуларны калку итеп бирергә, Саттар образын гомумиләштерүне көчәйтергә, конфликтны кискен итеп сурәтләргә, сугыш эпизодының драматизмын калку күрсәтергә мөмкинлек бирә. Баллада

---

[1] В. Г. Воздвиженский. Моабитские тетради М. Джалиля и их место в советской литературе военных лет. Кандидатлык диссертациясе. Казан. 1969 ел. 269 бит.

сугышның зур гомумиләштерү белән сурәтләнгән тулы бер эпизодына, яшәү һәм үлем арасындагы, тимер табы һәм кеше арасындагы көрәш эпизодына әверелеп китә. Әсәрдә Саттарның тимер тавын җиңеп чыгуы аша тормышның үлемне җиңеп чыгуы җанландырыла.

Тимер тавын туктатырлык көчкә ия булган тимерче Саттар, бер яктан, совет халкының искиткеч табигыйлек белән сурәтләнгән гади бер вәкиле, икенче яктан, гаять гомумиләштерелгән образы булып күз алдына баса. Икенче төрле әйткәндә, конкретлык, табигыйлек гомумиләштерүне, гомумиләштерү-эреләндерү реальлекне тутырып торалар, образга мәгънәви тирәнлек өстиләр. Шунлыктан балладада сурәтләнгән бөтен эпизод, сугышның җанлы эпизоды булуын югалтмастан, фәлсәфи мәгънәгә ия булган гомумиләштерелгән эпизодка әверелә.

Баллада һәркайсы өч катрен һәм бер дистихтан[1] гыйбарәт булган 14 әр юллы 7 кисәктән тора һәм абба+вггв+дд+ежже рәвешендә рифмалашкан катлаулы строфага охшый. Балладаның буеннан-буена шушы форма саклана. Бу исә әсәрнең тышкы төзелешенә үк мәгълүм бер төзеклек, монументальлек төсмере бирә. Шигъри форма сурәтләүнең эчке табигатенә гаять төгәл туры килерлек итеп сайланган. «Тимер һәм тимерче» балладасына шактый кызыклы анализ ясаган Г. Кашшаф бу хакта түбәндәге юлларны яза:

«Бу батырлыкны бирү ысулы турында шагыйрь шактый озак уйланган булырга тиеш. һәм ул, безнеңчә, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып эш иткән: танкны кем ясый? Аны кеше ясый. һәм танк кешедән дә көчле була алмый, аны тимерче үк үтерә ала һәм соңыннан аның ватыкларын сандалга салып, теләсә нәрсә ясый ала. Шагыйрь исә киләчәктә тимерче шул танк ватыкларыннан вандалга богау ясар дигән уй белән поэманы тәмамлый»[2].

Г. Кашшаф Саттар образын иҗат итүдә Ф. Кәрим «аны үлемнән курыкмаучы, тимер тавын әйләндереп ташлый торган әкият батыры итеп сурәтләмәгән», аның «реалистик сыйфатларын поэтик тукыма га кертеп барган» дигән караштан чыга. Шунлыктан тәнкыйтьче Саттар образының башлыча бер ягын — «Ватан сугышының рядовой солдаты» булу ягын гына күрсәтә. Әмма Саттар образының җыелма образ итеп сурәтләнүе тәнкыйтьче игътибарыннан читтә кала.

Ф. Кәрим «Тимер һәм тимерче» балладасын, тәнкыйтьче әйкәнчә, чыннан да озак уйланып язган. Шагыйрьнең фронт блокнотларында[3] балладаның 4—5 варианты язылуын раслый торган караламалар бар. Мисал өчен берничә строфаның ничек табылуын гына күзәтеп үтик.

Балладаның экспозиция өлешендә Саттарның сугышта булуы, бервакыт дошман танкысы белән күзгә-күз очрашырга туры килүе хәбәр ителә:

**Колхоз тимерчесе Саттарга,**
**Яше үрләгәндә иллегә,**
**Гранаталар тагып биленә,**
**Туры килде илен сакларга,—**

дип башлана ул. Моннан соң окопта булган конкрет эпизод сурәтләнергә тиеш. Беренче вариантта түбәндәге юллар языла:

**Саттар бүген сугыш кырында.**
**Тимер ауный, тимер һәр җирдә.**
**Тимерченең күзе тимердә,**
**Нинди генә тимер юк монда!**
**Күпме тимер булыр бер түпта,**
**Яңгыр булып күктән түп ява,**
**Гөрселдәп таш кыялар ава,**
**Карый Саттар тирән окоптан.**

---

[1] Дүрт юллы һәм ике юллы строфа исемнәре.
[2] Г. Кашшаф. Муса Җәлил. Казан. 1961 ел. 268 бит.
[3] Блокнотлар шагыйрьнең семья архивында саклана.— З. М.

Ачык ки, бу вариантта ук шагыйрь Саттар һәм тимер мәсьәләсен әләктереп алган һәм «тимерченең күзе тимердә» дип юкка гына әйтми. «Бу тимерләр үлемгә түгел, төзелешкә киткәндә никадәр файдалы булыр иде» дигән төсләрәк фикернең шагыйрь күңелендә ятуы ачык сизелә. (Бер вариантта тимерченең исемен Гарәфи дип алуны да искәртеп үтик.) Әмма бу фикер бик турыдан-туры әйтелгән сай фәлсәфә булып аңлашылуданмы, сугыш эпизодының кырыс фонында табигый яңгырамауданмы, шагыйрь аны бөтенләе белән сызып ташлый һәм строфаны яңабаштан яза башлый:

Киләләр, тәреле танклар...

Бу да сызыла. Чөнки Саттар берәү, танклар күплектә. «Танклар» дип алганда шагыйрьнең бергә-бер баскан тимер һәм тимерчене калку итеп эчке мәгънә белән сурәтләү мөмкинлеге югалыр, сугыш эпизоды гадәти сурәтләүгә әверелеп китәр иде. Яңа юллар языла:

**Танк килә — кара тәреле,**
**Танк килә безне таптарга;**
**Һәркем карый аңа үрелеп,**
**Һәр кешегә яшәү кадерле.**

Кайбер төзәтүләр ясала:

**Танк килә — кара тәреле,**
**Үтерергә килә, таптарга,—**
**Саттар карый аңа үрелеп,**
**Үлем килә күзгә күренеп.**

«Танк килә — кара тәреле» эзләгән сыйфат. Дошман танкысы берлектә алына һәм «кара тәреле» дип көчәйтелә. Әмма «безне таптарга», «һәркем карый аңа үрелеп» дигән формада бирү уңышсыз. Бердән, дошманның бер танкысына «без» каршы куела. Танкка каршы торучы көчне кечерәйтү төсле килеп чыга. Шунлыктан «безне таптарга» урынына, «үтерергә килә, таптарга» дип, куплектә «һәркем» дип алынган урынга Саттар дип кенә калдырыла. Әмма әле дә строфа табылып җитмәде. Бердән, ул тәзек түгел (рифмовкада), икенчедән, «үтерергә килә, таптарга» дип алу тачк алып килгән куркынычны артык күпертә. Ниһаять, эпизод түбәндәге рәвешне ала:

**Карый Саттар, карый үрелеп,**
**Үлем килә күзгә күренеп;**
**Танк килә — кара тәреле,**
**Улап килә Саттар янына;**
**Тимерчеме тимер таавына,**
**Таумы тимерчегә бәрелер.**

Әүвәлге вариантта ахырда килгән юллар алга күчерелде (дистих) һәм тулы катрен төзелде. «Тимерчеме тимер тавына, таумы тимерчегә бәрелер?» дигән риторик сорау, сюжетның төенен тәшкил итү белән бергә, зур фәлсәфи мәсьәлә кую булып та тора. Бөтен әсәр нәкъ менә шушы фәлсәфи сорауны чишүгә юнәлдерелгән эпизод итеп төзелергә тиеш икәне шагыйрь өчен ачык. Һәм ул, караламалардан күренгәнчә, күп вариантлар язу юлы белән тәгәл, күп сыйдырышлы шигъри сурәтне эзли. Балладаның без белгән вариантында ул аны сокландыргыч шигъри тәгәллек һәм тирәнлек белән кәгазьгә төшерүгә ирешкән.

Балладаның иң әһәмиятле казанышы — тимерче Саттар образы. Моны югарыда телгә алган хезмәтендә тәнкыйтьче Г. Кашшаф та билгеләп үтә, башка хезмәтләрдә дә ул зур уңыш буларак телгә алына. «Ул (Саттар),— дип яза Г. Кашшаф,— җанлы һәм тәгәлләнгән әдәби образ булып, бөтен эчке дөньясы белән күз алдына баса»[1].

Ф. Кәрим Саттарның нинди сыйфатларын күрсәтергә теләгән соң?

Саттар — колхоз тимерчесе. Яше илләгә үрләп бара, димәк, инде өлкән кеше. Менә ул сугышта, дошман танкысы белән бергә-бер очраша. Саттарның да, лирик

[1] Шунда ук, 268 бит.

геройның да уйларын бергә кушып (эчке монолог алымы белән), Ф. Кәрим шигырьнең икенче кисәгендә түбәндәге юлларны китерә:

Үлем үрләмәсен терегә,
Тере тәгәрәтсен үлемне!
Моның өчен уйны, күңелне
Кирәк броняга төрергә.
Җан кадерле, дуслар, сугышта,
Сугышырга чөнки җан кирәк,
Үлә калсаң, әйдә, бу йөрәк
Сер бирмәсен соңгы сулышта.

Бу строфаларның да төгәл бирелешен Ф. Кәрим шактый күп вариантлар аша эзләп таба. Башта мондый юллар табыла:

Бу дөньяда яшәү кадерле,
Сине җиргә салып изәргә
Танк килә — кара тәреле.

Аннары ул үзгәртелә:

Җан кадерле, дуслар, сугышта,
Кадерлегә күрә туган ил;
Сугышырга чөнки җан кирәк,
Вөҗдан кирәк, кайнар кан кирәк.

«Йөрәк» сызыла һәм «вөҗдан» сүзе белән алыштырыла.

Йөрәк кирәк соңгы сулышта.

Юк, әле шагыйрь канәгать түгел. Тагын эзләнү:

Җан кадерле, дуслар, кадерле,
Үлем торса басып янында.

«Үлем торса басып янында» юлы «үлем йөрсә тирә-ягында» дип алыштырыла. Ахырда хәзер безгә билгеле булган югарыдагы ике строфа туа. Беренче варианттагы «бу дөньяда яшәү кадерле» диган сүзләр ни өчен кире кагыла соң? Безнеңчә, моның ике сәбәбе бар: беренчедән, бу — бик билгеле хакыйкать, икенчедән, сугыш эпизоды белән бәйләнешсез әйтелә. Өченче вариант та төгәл түгел. «Үлем тирә-ягында йөрсә генә җан кадерле» дигәндәй абсурд фикер кала.

Икенче вариантның беренче ике юлы безнең утызынчы еллар поэзиясендәге традицияbезгә туры килә, тышкы патриотик бизәк тә бар төсле: «җан кадерле, дуслар, кадерлегә күрә туган ил». Ләкин бит туган ил һәр вакыт кадерле. Бирәдә логик эзлеклелек, фикер төгәллеге җитми. Ф. Кәрим, хаклы рәвештә, ул вариантларның бәрысын да кире кага һәм гади, ачык, мәгънәле итеп әйтелгән:

Җан кадерле, дуслар, сугышта,
Сугышырга чөнки җан кирәк,
Үлә калсаң, әйдә, бу йөрәк
Сер бирмәсен соңгы сулышта,—

дигән вариантка туктала. Ә нәрсәгә ирешелде соң?

Шушы эчке монологта без Ф. Кәримнең образны сурәтләүгә эстетик яктан ничек якын килүен дә, балладада әйтергә теләгән төп фикерен дә төсмерлибез төсле. Сүзне беренче строфадан башлыйк. Беренче ике юлда, риторик эндәш формасында «үлем үрләмәсен терегә, тере тәгәрәтсен үлемне» дигән ритмик фигура белән бирелгән антитеза ясала. Канатлы сүзләр, публицистик пафослы тәгъбир барлыкка килә. Аннары «моның өчен уйны, күңелне кирәк броняга төрергә» дигән фәлсәфи фикер. Тимерче Саттарның броня тавы каршындагы калканы — броняга төрелгән күңел! Шулай итеп, без тимерче Саттарның корыч ихтыярга ия булган кеше икәнен күрәбез. Ләкин бу кабарынкы сурәт Ф. Кәримдә һич тә плакатка әйләнеп китми, чөнки моның артыннан ук бу сурәтләүне табигый тасвир белән тулыландыра торган

юллар килә. Бередә «дуслар»га мөрәҗәгать итеп, ачыктан-ачык сөйләшү рәвешендә «җан кадерле, дуслар, сугышта» дию бик урынлы. Ф. Кәрим өчен «бу дөньяда яшәү кадерле» дип әйтү төгәл булмаса, «сугышта» (нәкъ менә сугышта!) итеп алу бик отышлы. Сугышта да кеше яшәү турында уйлый. Ләкин моны да Ф. Кәрим башкача әйтә: «сугышырга чөнки җан кирәк». Аннары «үлә калсаң» диган шартлы форма Ф. Кәримнең яшәү һәм үлем турындагы гомуми концепциясенә дә туры килә. Әйе, сугышта үлемгә дучар булуың да ихтимал. Шулай итеп, Ф. Кәрим, бер яктан, Саттарның тимер тавына каршы торырлык рухи көче барын, каһарманлыгын калкыта, икенче яктан, аның гади сугышчы, солдат һәм үлүе дә ихтимал, гадәти кеше булуын ассызымлый. Шушы яше иллегә үрләп килгән тимерче каршына «танк килә — кара тәреле», «тимерчеме тимер тавына, таумы тимерчегә бәрелер». Беренче кисәк ахырындагы бу төенләнеш икенче кисәк ахырында да килә һәм вакыйгаларны кульминациягә таба үстерә торган үзенчәлекле рефрен рәвешен ала.

Балладаның өченче һәм дүртенче кисәкләрендә Саттарның яңа бер сыйфаты ачыла: бу аның үлем каршында куркып калуга мөнәсәбәте. Кара тәреле танк улап килүдән куркып бер шәүлә артка йөгерә.

> **Бу йөгергән куркак гәүдәгә**
> **Саттар мылтык төзәп өлгерә.**

Белүебезчә, М. Ю. Лермонтов үзенең «Беглец» поэмасында куркакның классик образын иҗат итеп калдыра. Куркакны сөйгәне дә, туганнары да, хәтта анасы да кабул итми. Ф. Кәримнең фронт поэзиясендә дә куркакны шушы планда гәүдәләндерү берничә тапкыр кабатлана. Куркакка мондый мөнәсәбәтне без башка шагыйрьләребез поэзиясендә дә күрә алабыз. «Тимер һәм тимерче» балладасында куркакны тимерче Саттар атып үтерә, чөнки «вөҗдан рөхсәт итә атарга».

Дүртенче бүлекчәдә Саттарның куркакларга, илгә биргән антын бозучыларга мөнәсәбәте тагын да тулырак ачыла:

> **Саттар әзер аның гомерен**
> **Яшәү дәфтәреннән сызарга.**

Куркакны Саттар дошманга Ватан капкасын ачучы итеп, Ватанын ташлап качучы итеп карый.

Куркусыз тимерче Саттарның морале әнә шундый. Ул бүген җаваплы постта, ул бүген Ватаны өчен үлемгә каршы гранит кыя булып баскан. Күрәңә ки, Ф. Кәрим каһарман образын эзлекле рәвештә үстерә бара, аның сугышчы буларак батырлыгын тимер ихтыяр белән бәйләп, образны калкулата, эреләндерә килә.

Балладаның бишенче бүлекчәсендә, куркак образына бәйләнешле эпизодны сөйләп бетергәннән соң, шагыйрь кабат каршына улап килгән дошман танкысын Саттарның ничек каршы алуын сурәтләүгә күчә.

> **Яшереп булмый, курка тимерче:**
> **«Ычкынмасын кулдан бу «үлем»,**
> **Үзем үлсәм, бәхил бул, илем»,—**
> **Дип тимерче җыйный бар көчен.—**

диган строфа уңае белән Г. Кашшаф, Саттар образын характерлап: «Ләкин никадәр ул җимерә алмаслык мораль броняга төренмәсен — ул кеше, аңарга каушау, курку да хас нәрсә»[1],— диган нәтиҗә ясый. Ягъни тәнкыйтьче бередә шагыйрь образны батырлык, куркусызлык сыйфатын гына йөртүче итеп сурәтләми, аны күпьяклы итеп аңарга тели, диган фикер әйтә. Ф. Кәримнең образны төрле яктан ачарга омтылуы дөрес билгеләнә, әмма бу очракта Саттарның куркуын сөйләү урынлы булыр идеме? Дошман танкысына каршы күтәрелү куркаклыктан гына эшләнгән батырлык булып чыкмас идеме? Шигырьдән Саттарның дошман танкысын җимертүе турындагы юлларны укыйк:

> **Ул кулына граната тоткан,**
> **Ул үрмәләп чыга окоптан;**

[1] Г. Кашшаф. Муса Җәлил. Казан. 1961. 267 бит.

**Ул үрмәләп каршы бара да:**
**Танк боргаланган арада,**
**Бәрә төзәп бензин багына.**

Биредә Саттарның куркуына ишарә булырдай бер генә сүз дә юк. Соң моннан алдагы строфада ни өчен «яшереп булмый, курка тимерче» диелде? Җавап бик гади: «Ычкынмасын кулдан бу «үлем». Димәк, Саттар танкка тигезми кала күрмим, дип курка. Бу — табигый сурәтләү, сугышта була торган табигый курку. Ләкин моның дошман каршында куркып калу шикелле нәрсә булмавы да бик ачык. Димәк, Саттарга «курку, каушау хас» дип нәтиҗә чыгару дөрес үк булмас. Сугышның бу киеренке-драматик моментында Саттарга курку турында уйлап торыр вакыт юк. Аннары «Саттар каушады» дигән хәрактерда искәрмә ясау Ф. Кәримнең образ (каһарман) сурәтләү принцибына ятышмас иде, чөнки шагыйрь үз каһарманын бу очракта нәкъ менә калку сынлы, мәһабәт-монументаль планда сурәтләргә омтыла. Балладаның алтынчы бүлекчәсенә игътибар юнәлтик:

**Тимерченең тимер йөрәге**
**Ачу уты белән тулышкан,**
**Күрек кебек калка сулыштан,**
**Колачка чак сыяр күкрәге.**
**Сулый Саттар танк янында,**
**Гүя аны ерып яндыра.**

«Тимерченең тимер йөрәге», «күрек кебек калкучы колачка чак сыяр күкрәк» кебек сурәтләр, «гүя танкны ерып яндыра» дигән чагыштыру Саттарның зурайтылган-мәһабәт портретын ачык күрсәтсә кирәк.

Ниһаять, балладаның җиденче йомгаклау кисәгенә күчәбез. Ул түбәндәге строфадан башлана:

**Яна дөрләп ләгънәт утында,**
**Яна танк — кара тәреле;**
**Тимерчегә килеп бәрелде**
**Тимер тавы сугыш судында.**

Бу — балладаның «тимерчеме тимер тавына, таумы тимерчегә бәрелер» дигән төенләнешенә, ягъни әсәрдә куелган төп проблемага җавап булып килә торган чишелеше. Тимерче тимердән көчлерәк булып чыкты. Тимер белән тимерче мәсьәләсен балладаның буеннан-буена үстерә килү дә «тимер» сүзен стиль чарасы буларак куллануны күрү читен түгелдер. «Тимерче», «тимер тавы», «тимер бикле капка», «тимерченең тимер йөрәге» һ. б. тәгъбирләр һәм аларның әледән-әле кабатланып градацияләнеп килүләре, сурәтләнгән сугыш эпизодының мәгънәсен тирәнәйтә барып, аңа эчке мәгънә — фәлсәфи фикер сала киләләр һәм без балладаның үзәгендә зур фәлсәфи фикер ятуын төшенәбез: дошман никадәр генә көчле булмасын, ничек кенә үлем кораллары белән ябырылмасын, хаклык каршында, Ватан намусы өчен көрәшүче броня ихтыярлы (нәкъ менә броня, чөнки ул тимердән ныклырак: «моның өчен уйны, күңелне кирәк броняга төрергә», дигән юллар юкка гына килмәде) совет кешесе каршында көчсез. Хәзер инде Саттар образының җыелма образ булуы, аның сугышучы совет халкын сынландыруы, кара тәреле танкның да фашизм символы итеп алынуы ачык аңлашыла. (Кара тәреле танк та балладада стиль чарасы буларак еш телгә алына.)

Балладаның йомгаклаучы юллары нәкъ шушы фикерне раслыйлар:

**...Җиңү җәелер тиздән һәр якка,**
**Тимерченең туган иленнән**
**Мәгърур тавыш яңгырар. «Суд килә!»**
**Юлбасарлар басар аякка.**

**Җинаятьләр тавы чишелер,**
**Өсләренә килеп ишелер.**

Күренә ки, тимерче биредә аңлы рәвештә берләктә алына һәм юлбасарга суд ясаучы, җинаятьләр тавын дошманның үз өстенә ишүче итеп сурәтләнә. Соңгы строфа балладаның бөтен фәлсәфи фикерен йомгаклап, бер йодрыкка йомып әйтеп бирә:

**Танк ватыкларын сандалга**
**Салыр бу көн безнең тимерче,**
**Чүкеч үтә йөртеп бар көчен**
**Богау ясар һәрбер вандалга.**

Тимерче образының җыелмалылык сыйфаты биредә югары дәрәҗәгә җиткерелә. Дошманның сугыш машинасы җимерелер һәм ватыклары сандалга салынып — фашизмның үзенә богау ясалыр.

Бу фикерләрнең еракка карап әйтелгән булуын күрү читен түгел.

Җыеп әйткәндә, тимер тавын туктату көченә ия булган тимерче Саттар образы — совет халкының зур осталык белән индивидуальләштерелгән, табигый буяулар белән бирелгән җыелма образы, халку итеп сурәтләнгән оригиналь тибы. Шулай итеп, азатлык көрәшенең романтик гәүдәләнеше барлыкка килде. Романтик күтәренкелек белән гомумиләштерү Ф. Кәримдә реализмны көчәйтүгә хезмәт итте. Менә ни өчен соңгы чор тәнкыйтендә Ф. Кәрим поэзиясенең төп үзенчәлеге итеп «җирләштерелгән реализмны» гына күрсәтү тенденциясе белән килешәсе килми. Образ сурәтләүдә тегеяки бу сыйфатның активлашуы Ф. Кәримдә теманың характерыннан, әйтәсе фикер, гәүдәләндерәсе хиснең табигатеннән килеп чыга.

Шулай итеп, Фатих Кәрим поэзиясе сугыш чоры вакыйгаларын, сугыш кешеләрен җанлы һәм тулы итеп гәүдәләндергән, югары сәнгать дәрәҗәсенә ирешкән поэзиянең үрнәге булды.

Фатих Хөсни

# БЕЗ КИТМӘСКӘ КИЛДЕК!

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

## 1. КАРАШ КИҢЛЕГЕ

Бүгенге татар прозасы турында башланган сүз ничек, кай якка таба дәвам итәр, кызыклы һәм күңелгә ятышлы фикерләр булырмы? Аныы безнең бу мәсьәлә белән ни дәрәҗәдә кызыксынуыбызга бәйле, дөресрәге, бу чаклысын киләчәктә күрербез. Хәтта, бик кызып китеп, игътибар казанырдай зур фикерләр кузгатылса да, бу сөйләшү генә әле безнең проза жанрын берьюлы яңа үрләргә күтәрер дип уйларга ярамый. Яхшы әсәрләр алай бер сөйләшеп алу нәтиҗәсендә генә тумыйлар. Әмма туң яту, яхшысы турында да, яманы турында да ләм-мим дәшмәү шулай ук эш түгел.

Сүзне башлап җибәргән Рафаэль Мостафин, төрлечәрәк таләптән чыгып карагандa, прозабызның бүгенге торышын тегеләй дә, болай да бәяләргә була дип куя мәсьәләне. Ишетү өчен күңелле, хәтта оригиналь яңгыраучы бу куелыш асылда буталчыклыкка алып бара. Аңлашылып җитми, ник әле без югары таләп, урта таләп, хәтта кай очракта уртадан да түбән таләпләрне искә алып сөйләшергә тиешбез икән?

Р. Мостафинның күп кенә кызыклы һәм тәфсилле күзәтүләрне эченә алган «Тема, идея, әдәби осталык» дигән мәкаләсе тик бер елны, аны да элеккерәк еллар тезмәсеннән аерып алып тикшерүе һәм, җитмәсә тагын, «әгәр узган елгы әдәби әсәрләргә партия куйган таләпләр югарылыгыннан торып якын килсәк, ...1971 ел проза өлкәсендәге **иң төссез һәм чырайсыз** елларның берсе булды» дип үтә кистереп куйган нәтиҗәсе миндә берьяклырак тәэсир калдырды. Вәхаләнки, шул «төссез һәм чырайсыз» ел прозасында да «алдынгы замандашыбыз образын гәүдәләндерүнең уңышлы бер мисалы» була алырлык Халикъ Саматов (Г. Ахунов. «Чикләвек төше»), Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» повестеның төп герое булган, эшлекле, принципиаль, кирәк чакта рәхимсез һәм каты куллы да була белүче чын коммунист Хафиз Кадергулов кебек образлар да иҗат ителгән икән ләбаса! (Әлбәттә, тәнкыйтьче аларның да кимчелекле якларын күрсәтә, йа хода, алайга китсә, быелгы чиктән ашкан кызу җәй кайбер тиз калтыраучан кешеләрне хәтта кояшка да шомлаыбрак карый башлауга китереп җиткерде бит!) Мин инде «мәктәп штангасын күтәреп җыйган мускуллары һәм батыр калырга чамалаган исәпләре белән бер якка чәчрәп барып төшкән» һәм үзен шулай шәп итеп атып бәргән Таш елга егетенә соңыннан ничек рәхмәт әйтергә белмичә аптырап йөргән колхоз председателе Ахунҗанов турында әйтеп тә тормыйм. «Кичәге көн председателе» башы белән бүгенге көн эшләренә тыкшынып йөрмәсен! Шулай да, уйлабрак карыйк әле, Рафаэль туган, шул «төссез һәм чырайсыз» ел прозасында да кемнәрдер булган ич! Дөрес, син аларны соңыннан үзең дә күрәсең, ләкин мәкаләнең беренче бүлеге азагында ук, булган барлы-юклы байлыкларны анализлаудан элек, бөтен бер елның башына «төссез һәм чырайсыз ел!» дип имән казык кагып куярга бераз ашыгa төшмисеңме, дип кенә әйтүем. Аннары тагын шуны да онытмаска кирәк, аннан элеккеге елда гына бездә «Этил суы ака то-

рур» (Н. Фәттах) кебек зур тарихи роман, «Күршеләр» (Б. Камалов), «Күпер чыккан-да» (Э. Нуруллин) кебек игътибарга лаек повестьлар, күзгә чалынырдай байтак кына хикәяләр дөнья күрде. Инде килеп, шул «төссез һәм чырайсыз» 1971 елны алыш-тырган быелгы елда шактый киң диапазон-лы, кешеләре төрле һәм кызыклы булган ике романны — Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ын, Шамил Бикчуринның нефтьчеләр тормышын сурәтләгән һәм күп кенә гыйбрәтле хәлләрне, үзенчәлекле характерларны эченә алган «Каты токым» романын һәм дүрт-биш яңа повесть укы-дык. Шуның өстенә, журнал редакциясенең, нәшриятның киштәләрендә «Якын килмә-гез! Юкса, шартлыйбыз!» дип торган ка-лын-калын портфельләр бар — аларда яңа романнар, повестьлар, хикәяләр чират (?) көтеп ятмакта. Игътибар иттегезме икән, Ш. Бикчурин романының азагында «Ле-ниногорск, 1968—1972» дигән тамгасы бар. Мин моның шаһиты була алам, чынлап та, 1968 елда, Малеевка иҗат йортында ул моның башлангыч бүлекләрен миңа укып күрсәткән иде. Аннары бер елны Ибраһим Гази мәрхүмнең, Әлмәткә барып кайткач, ул «салам чәчле» егетнең өметләндергеч әйбер өстендә эшләвен куанып хәбәр ит-кәнлеге хәтеремдә. Шул «төссез һәм чы-райсыз» елда, бу авторның әлеге шул каты токымны: «Менә! Менә очына чыгам!» дип тирләп-пешеп утырган чагы булгандыр. Ни өчен әйтәм мин бу сүзләрне? Проза-быздагы кимчелекле якларны ничек тә каплап калдыру яки акларга тырышу өчен түгел — аллам сакласын! Озак сузып азап-лануымның сере шунда: проза жанры кебек җитди һәм озак утырып эшләүне сорый торган жанр турында сүз ачканда, еллар тезмәсеннән яки чәр каскадыннан аерым бер генә буынны өзеп алып, кисеп әйтелгән нәтиҗәләр ясарга ашыкмыйк.

Тулаем алганда, прозабызда соңгы ун еллар дәвамында искә алырдай уңай як-лар (күп кенә өметле яшь каләмнәр өстәлде. Кеше-герой психологиясенә ти-рәнгәрәк керә барабыз. Тематик диапазон-ның киңәя төшүе күз алдында: нефтьче-ләр, тезүчеләр, укытучылар, партия эшлек-леләре, художество интеллигенциясе вә-килләре, диңгез сәяхәтчеләре һ. б.) булуга да карамастан, уйландыра, хәтта борчый торган кимчелекләр дә үзләрен сиздерә киләләр. Мин хәзергә әле Р. Мостафин мә-каләсен генә укыдым, фикер алышу бары-шында иптәшләр төрле якка кагылырлар дип өмет итәм, хәтта берсенә берсе охша-ган фикерләр дә булыр. Булсын! Бары тик ханжалык, юкны бар итеп күрсәтергә мата-шу, ярашырга-хәтер саклашырга тырышу гына булмасын.

Мине соңгы еллар прозасында иң бор-чыган нәрсә: караш киңлегенең җитенкерә-мәве. Моннан берничә ел элек мин, шушы юнәлештәге борчылуларымны белдереп: «Кайда сез, олы язмышлар?» дип язып та чыккан идем инде. Аннан бирле калын-ка-лын романнар, бер-бер артлы повестьлар чыкты, чыга тора. Әмма «Менә бу безнең чорның колоритлы фигурасы!» дип төртеп күрсәтерлек катлаулы язмышлы әдәби образның әлегә күренгәне юк. Күрәсең, бу — әсәрдәге персонажның хәрәкәт итү «платформасы»ның киңлеге, аның, әйтик, атаклы зур төзелештә эшләве белән генә тәэмин ителми торгандыр. Югыйсә, соңгы елларда әдәбиятыбызда андый төзелеш-ләрдә эшләүчеләрне күргәләдек, ләкин алар зур төзелештә эшләүче вак кешеләр, шомартыбрак әйтсәк, урта кул «работник-лар» булып чыктылар. Ник алай? Барыннан да әүвәл, заманны дип әйтмибез дә инде, хәтта шул үзләре эшли торган зур завод-ның яки зур төзелешнең зурлыгын, нилек-тән зурлыгын, гомуми халык хуҗалыгы системасында аның нинди урын тотканлы-гын тиешенчә төшенү, шуны төшенүдән туган иманның ныклыгы җитми. Алар бары тик үзләре эшли торган участокны гына беләләр, уңай дигәндә, шул участокны алга җибәрү өчен пыр тузып чапкан була-лар, шул процесста я хатыны белән, я күр-ше участок кешеләре белән, күпкә китсә, заводның (төзелешнең) җитәкчеләре белән конфликтка керәләр. Әле тегесе дә, бусы да уңай кеше булып, ышанычларының-ка-рашларының төрле булуы нәтиҗәсендә туа торган конфликт булса бер хәер иде, ул чагында, кешеләр буларак, аларның караш-лары, офыклары, эчке дөньялары ачыла төшәр иде. Еш кына очракта консерватор-лыгы турыдан-туры өстә чекереп яткан бакча карачкысы белән көрәшәләр. Ә уку-чы «уңай герой»ның юлына язучы үзе уй-лап, үзе корып куйган ясалма киртәләрне, берсе артыннан икенчесен, сикереп үткә-нен түземлеге җитеп укып утырырга тиеш.

Р. Мостафин, татар әдәбиятының совет власте елларында барлыкка килгән бай традицияләрен сүз арасында гына булса да искә төшереп, кайбер исемнәрне атап та үтә. Әйе, бу шулай. Гадәттән тыш әдәби вакыйга булганлыктан түгел, ләкин шул

уңай иҗади эшләребез тезмәсеннән берсе итеп һәм, әлбәттә, хәтердә нык сакланганлыгы өчен Гомәр Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә образын искә төшерик. Фронт һәм тыл, тылдагы халыкны, аерым алганда, үз бригадасындагы кешеләрне зур эшкә рухландыра алуы, кәкре куллы Сәйфи ишеләр белән конфликтка керүе — болары аның эшчәнлегенең, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, тышкы гәүдәләнеше. Шулар белән аралашып ук аның эчке драмасы үрелеп бара — ире Газизнең фронтта үлеп калуы, гармунчы Зиннәт йөзендә «иске романтика»ның яңадан терелеп, Нәфисәгә тагылырга йөрүе, Хәйдәргә мөнәсәбәтенә ачык караш билгеләү, төрле имеш-мимеш хәбәрләрдән килененә карата күңеленә шом кергән кайнананы тынычландырырга кирәклек — өстән-өстән генә санаганда да, яшь кенә бу авыл хатыны җилкәсендә, ай-һай ла, нихәтле йөк! Һәм ул шуларны, һич кыланусыз, көчә җиткәнчә тартып бара. Әлбәттә, ялгыз үзе генә түгел, үз тирәсендәге коллектив белән. Ләкин Нәфисә уртак тел таба алган коллектив белән. Бусы — бер. Икенчедән — бусы, бәлки, иң әһәмиятлесеңдер — Нәфисәнең, шул гади генә авыл хатынының, чорга, ахыр чиктә безнең барыбер җиңеп чыгачагыбызга, авылдашларына, үзенә, үзе алып бара торган эшкә бетмәс-төкәнмәс ышанычы. Менә шулар инде Нәфисәне, ул алып барган эшләрне, аның башыннан кичкәннәрне татар хатынының Бөек Ватан сугышы елларындагы олы язмышы дәрәҗәсенә күтәрә дә.

Соңгы ун-унбиш еллар эчендә иҗат иткән эшләребезне, шул җөмләдән, «Гыйлмениса»ны бер яктарак калдырып, үзем язганнарны да, күз алдымнан үткәрдем. Әйтеп карагыз, бүгенге совет хатын-кызлары арасыннан Нәфисә язмышы накалына күтәрелгән хатын-кыз язмышы биргәнебез бармы? Әлбәттә, иренең үлеп калуы һич шарт түгел, ире һәм балалары белән тигез гомер итсеннәр, бәхетле булсыннар. Нәфисә кебек гел кирза итек киеп йөрү дә шарт түгел, иң соңгы модадагы ялтыравык туфли киеп йөрсен. Ләкин иҗтимагый аңы-иманы ягыннан, ягъни гражданка буларак, андый дәрәҗәгә җиткән хатын-кыз образын мин күрсәтә алмыйм.

Шундый уңай традицияләр рәтеннән Р. Мостафин Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен дә күрсәтеп үтә. Совет властеның беренче ун елларындагы комсомол-яшьләр тормышыннан гыйбрәтле хәл-әхвәлләрне сурәтләү ягыннан «Агыйдел» дә, әлбәтта игътибарга лаек әсәр. Ләкин шул ук Мирсәй Әмирнең иң авыр сугыш елларында иң артта калган колхозга җитәкчелек итү гә үзе теләп керешкән фидакарь йөрәкл Миңлекамалы да бар ич. «Саф күңел» романындагы Сания Ибраһимова да яхшы у зур масштаблы персонаж. Инде килеп шушы М. Әмиребез, сугыштан соң егерм биш ел вакыт узгач, акылы һәм талантын тәмам камилләшеп җиткән бер вакытында «Балыкчы ялганнары»н бирде. Мин аны бу әсәрен кимсетү ягында тормыйм, анда кызыксыну белән укыла торган аерым бүлекләр, эпизодлар бар. Әгәр «Балыкчы ялганнары»н тәнкыйть итәргә уйласам, мин, барыннан да әүвәл, авторны мавыктыргыч итеп ялганлый белмәүдә тәнкыйтьләр идем. Шулай да әйтми булмый, гражданлык накалы ягыннан килеп карый башласак, бу әсәр «Миңлекамал» да, «Саф күңел» дә түгел. Моңарга охшаш мисалларны барыбыздан да китерергә мөмкин. Ярый, картлар картайганнар, чишмәләре саеккан ди. Кызганычка каршы, киң карашлы, зур эрудицияле, хәрәкәт-алымнары ягыннан истә калырдай колоритлы образлар яшьрәкләр каләменнән дә сикереп кенә төшми ләбаса. Кыскасы, язучыларыбызның саннары үсә, ә дөньяга карашлары тарая бара. Мондый нәтиҗәнең кайберәүләрне сискәндерүе дә мөмкин, ләкин әдәби хәрәкәтебезгә җитди карарга һәм аны алга җибәрергә уйласак (ә без бу турыда уйлыйбыз да уйлыйбыз!), дөреслекне, гәрчә ул ачы булса да, әйтми мөмкин түгел.

## 2. ИХЛАС КҮҢЕЛЛЕЛЕК

Л. Н. Толстой әдәбият турындагы язмаларының берсендә әйтә: «Әсәр чын сәнгать әсәр булсын өчен, өч шарт кирәк: 1) әсәрнең эчтәлеге алып килә торган яңалык кешеләр өчен әһәмиятле булсын; 2) бу эчтәлекнең сәнгатьчә чагылышы кешеләр аңларлык ачык булсын һәм 3) авторны бу әсәрне иҗат итәргә кузгаткан этәргеч аның эчке таләбеннән килеп тусын, ә тышкы этәргечләр нәтиҗәсендә генә булмасын».

Бу шартларның бигрәк тә өченчесенә ныграк тукталасым килә. Чөнки беренче икесе бездә азмы-күпме саклана дип әйтергә мөмкин. Менә өченчесенә килгәндә, билләһи дип әйтәм, минем үземдә һәр вакыт шик туа. Үзенекеме, үз җырымы? Җаныңда, йөрәгеңдә кайнап туганмы? Әллә заман шуны сораганлыктан, бу теманың

актуальрак ... торгынлыктан, әллә ни зур кыенлыкларга дучар булмыйча әсәрнең дөнья күрәчәгенә ышанудан гына автор бу эшкә керешкәнме? Заман сораганга колак салмаска дигән сүз түгел бу. Һәр художник, һәр зур художник, иҗатында барыннан да элек үз заманының ничек тә эзен калдырырга омтыла. Дөресен әйткәндә, бу — художникның чын бәһасен билгеләүче критерийларнең берсе. Ләкин, шуның белән бергә үк, ул үз күңеленә дә колак салырга тиеш. Мин соң бу зур теманы әле тиешенчә үзләштереп өлгердемме? Тагын да җитдирәге: яратып өлгердемме? Бу — минем үз җырыма, үз моңыма әйләндеме? Матур сүз булганы өчен әйтелми бу. Ахыр чиктә, әнә шуннан, теманың һәм тормыш материалының язучыда аның чын мәгънәсендә үз җыры булып өлгерүеннән яки өлгереп җитмичә дөнья күрүеннән әсәрнең самимилеге, авторның ихлас күңеллелеге, яки, ширпотребка исәп тотып, аннан-моннан гына «ябыштырып куйганлыгы» ачыла да инде. Язучының ихлас күңеллелеге әсәрнең укучы тарафыннан яратып кабул ителүенең, эмоциональ йогынтылы булуының төп билгесе. Авторның кайвакыт заман кушканча дөрес кенә уйлап җиткермәве дә, икеләнүләре дә, эчке каршылыклары булуы да мөмкин — бу тозәтеп булмаслык бәла түгел. Безнең укучы акны карадан аера белә хәзер. Кирәк икән, ул аерым мәсьәләләрдә автор белән бәхәскә кереп, тегенең кайбер төгәл булмаган раслауларын кире дә кага ала. Иң әшәкесе: авторның үз җаны белән тиешенчә исәпләшмичә, бары тик «товар»ның үтемле булачагын күздә тотып кына теге яки бу темага тотынуы. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: соңгы елларда бездә язылган һәм күз нярмәстәй тизлек белән басылып чыккан калын-калын романнарның һәм урта калынлыктагы повестьларның йөздән сиксәне әнә шул принципта дөнья күргән әсәрләр. КамАЗ төзелешеме? Нинди сүз булуы мөмкин, яшел юл аңарга! Зәй ГРЭСына багышланганмы? Халыклар дуслыгы темасынамы? Сөйләшеп тә тормыйбыз, кульязмаң ярты елдан китапка әверелеп өстәлеңә менеп кунаклаячак. Әнәдән дөя ясарга яратучы һәртөрле демагогларга, тема базарында алу-сату белән шөгыльләнүче спекулянтларга тел чайкарга урын калдырмас өчен алдан ук әйтеп куям: политик әһәмиятле бу зур темаларга кем каршы килер икән? Җитди художник, Ватанның чын гражданины андый әһәмиятле темаларга язуны үзенең төп бурычы итеп саный. Ләкин тема җитдирәк һәм әһәмиятлерәк булган саен, аңарга мөнәсәбәт, аны сәнгатьчә чишә белү дә җитдирәк булырга тиеш. Аннан кала әлеге Лев Толстой куйган таләп: аны тасвирлау инде язучының эчке таләбенә, күңел җырына әверелгән булырга тиеш.

Әйтик, нефть турында бездә китаплар язылмады түгел. Беришеләре укышлырак; икенчеләре тәссезрәк — әмма нефтьчеләрнең, язучылар безне күрмиләр, дип әйтергә хаклары юк, алар турында китаплар бар. Әмма шулар арасыннан миңа иң ошаганы Шамил Бикчуринның былтыр журналда басылып чыккан «Каты токым» романы булды. Бигрәк тә кай ягы белән? Язучының күңел җылысы салып, шатланасы урында чын-чынлап шатланып, көләсе килгәндә чын ихластан көлеп, әйтә торган сүзен җырга — нәкъ үз җырына әйләндереп әйтә белүе белән ошады. Кешеләре дә җанлы кешеләр, төрле характердагы кешеләр, эшләренә дә ышанасың. Тин-Тиньчның Валя дигән кызны каңгырып эзләү юлында нефть эзләүчеләргә кушылып китүе һәм ярым шуклык рәвешендә тасвирланган бу лейтмотивның соңыннан коллективны тагын бер кат җанландыручы гомуми «хәсрәткә» әйләнеп китүе, авыл белән нефтьчеләр арасындагы элемтәләрнең җанлылыгы, табигыйлеге, кызлар белән нефтьче егетләр арасындагы шуклыклар — кавышулар һәм аерылышулар, чын сүзләр һәм хәйләкәр мутлыклар — бөтенесе дә, бөтенесе дә үз урыннарында. Һәм бөтенесе дә язучының үз җыры, самими җыры булып яңгырый.

Шулай да бу авторның бер «саташып» китүен әйтмичә булмый. Әсәрдә күп кенә кызыклы һәм үзенчәлекле геройлар арасында Мотгәрәй дигән шәп бер егет бар. Кашларыннан алып аяк тырнакларына хәтле дияр идем мин — авыл егете. Авылны җаны-тәне белән сөя, авыл эшен белә, шуннан башка тора алмый. Хәтта бораулаучылар бригадасына кушылып, үз кеше булып киткәч тә, сменадан бушаган сәгатьләрендә якындагы колхоз кырына барып, элекке яраткан эшен — комбайнчылык эшен «татып карый» — рәхәт тә соң комбайнга утырып иген дыңгезендә чайкалу (үземнең «чайкалып» караганым юк, Мотгәрәй шатлыгын бүлешеп әйтүем!). Менә шул колхоз кырына бара-кайта йөргән араларда Мотгәрәй кырчылык бригадасында пешекче булып эшләүче Фәридә

атлы яшь кенә бер тол хатынны күреп ала. Монысы — мут, тегесе — тол,— уртак тел табалар болар. Һәм чынлап табалар. Мотгәрәйнең кулыннан килмәгән эше юк, шуның өстенә, ихлас күңелдән ярата да белә икән. Бергә кушылалар, язылышалар, ирле-хатынлы булып яши башлыйлар һәм сизеп торасың: бәхетле кавышу булды бу, ястык-түшәкләре түземле булсын! Ләкин юк, бораулаучылар бригадасы бу төбәктә эшен бетереп, икенче төбәккә китәргә тиеш һәм шулар белән (ходай язмаганны, кул күтәреп язучы язып утырган) янәсе: безнең патриот нефтьчебез Мотгәрәй дә китә. Сау бул, Фәридә җаным, югалма, яңа гына табылган бәхет! Йа алла, «нефтекярь» лыкның моннан да югарырак ноктасы булырмы? Нефть эзләү һәм нефть чыгару бик зур һәм әһәмиятле эштер, бәлкем, минем үземнең чыгарып караганым юк. Әмма да кеше дигәнең бер нефть белән генә дә туенып тормый бит. Авылны ярата, авыл эшен белә торган комбайнчы Мотгәрәйне, шуның да өстенә тагын, бәлки, бусы барысына караганда да өстенрәгедер — әле яңа гына үзенең Фәридәсен — бәхетен табып, матур гаилә корып җибәргән Мотгәрәйне, яшь кәләшеннән аерып, бригадага тагып җибәрү нигә кирәк булгандыр? Ул бит колхозда эшләп калса да шушы ил өчен үк файда китерәчәк. Ихтимал, бу да шул караш киңлеге җитешеп бетмәүдән, нефтьне фетишка әйләндерүдән килгәндер!

Ихлас күңеллелек дигәннән, тегe яки бу әсәрдә тасвир ителгән социаль вакыйгалардан, аларда катнашучы геройлардан тыш, дөресрәге, шулар арасында кысылып, вакыты белән яңгырап, вакыты белән иңрәп, үзен сиздереп торучы һәм асылда язучы өчен үтә газиз булган икенче лейтмотив булуы да мөмкин. Р. Мостафин тарафыннан чамача «тере классиклар» рәтеннән саналган исемнәр арасында минем «Җәяүле кеше сукмагы» дигән романым да бар. Мин үзем әйтә алмыйм, ничә мәртәбә татарча, ничә мәртәбә русча бастырып, бастырган саен корректурасын гына булса да укып, бу әсәрдә гадәттән тыш шаккаттыргыч нәрсә таба алганым юк, шул ук вакытта, аңардан туя алганым да юк. Бу урында ул әсәрне шуның өчен телгә алам: анда минем: «Кеше нинди генә йөгерек акыллы, авызы белән кош тотучы булмасын, дөньяны, кояшны, кызларны, бигрәк тә кызларны ничек кенә диваналарча кайнар яратмасын, әгәр ул, шул булдыклылыгына мәсаеп, башкалардан үзгә сукмак салырга, бәхеткә җиңел юл белән ирешергә маташса, соңыннан үзенә үпкәләсен, аның ул юлы догалы юл түгел. Бәхеткә барыр юлны кешеләр бергәләп табарга тиешләр!» дигән җырым бар. Минем өчен ул җыр газиз, ул — минем иманыма әверелгән, шул җырдан башка мин ул әсәрне яза алмаган булыр идем. Һәм әнә шуның булуы, шул җырның әсәрдә буйдан-буйга, кешеләр язмышы аркылы, әле сизелерлек шаулап, әле үзен сиздермичә генә иңрәпелап килүе мине башка вакыйгаларны сурәтләгәндә дә илһамландырып торды.

Кыскасы, объектив дөньяны танып-белү дә, кешеләрне һәм иҗтимагый барышны дөрес аңлау да художник өчен бик кирәк, ләкин шуның өстенә художникның эчке иманы, үз җыры булу да зарури. Шуннан башка зур әсәрнең булуы мөмкин түгел. Калынлыкка калын, әмма иманы зәгыйфь китапларның булуы бик мөмкин. Безгә, ниһаять, бу ике төр китапны аера белә башларга бик вакыт.

## 3. СӘНГАТЬЧӘ ТӨГӘЛЛЕК

Сәнгатьчә төгәллек — әйтеп бетергесез зур нәрсә. Һәм ул бездә — әдәбият белемендә булсын, тәнкыйть фикерендә булсын, иҗат практикабызда дип тә өстик — иң «онытыла» торган якларның берсе. Хәтта «онытыла» дип әйтү генә аз, гомумән, безнең тешебез үтми булса кирәк бу «чикләвеккә». Кайбер кагылган очракларда да әсәрдә форма белән эчтәлекнең тәңгәл туры килергә тиешлеге турында өстән-өстән берничә декларатив фраза ташлап китүдән узмыйбыз. Хәтта тәңгәллекнең нидән гыйбарәт булырга тиешлеге, аларның диалектик бердәмлеге, берсенең икенчесенә сәнгатьчә йогынтысы турында нинди дә булса махсус сөйләшү булганын, яки нинди дә булса бер әсәрне нәкъ әнә шул аспекттан чыгып тикшергән гыйльми хезмәтне мин хәтерләмим. Проза буенча да, драматургия һәм шигырь өлкәсендә дә. Хәлбуки, сәнгатьчә төгәллек — сәнгать әсәренең иң катлаулы состав өлеше. Һәм ул күп кенә аспектларны эченә ала. Әсәрдә эчтәлек белән форманың бер-берсен тутырып, тулыландырып торуы шуның нәтиҗәсендә ирешелгән камиллек. Әсәрдәге персонажларны, «уйнаган рольләренә» карап, урыннарына куя белү — берсен дә кимсетмәү, берсенә дә «территориаль» өстенлек бирмәү. Артык кисәкләрне кирәк-

ледән аерып ташлый белү. Әсәрнең эчтәлегенә һәм тасвирлана торган тормыш материалына хас аһәңен (интонациясен) табу. һәм аны әсәрнең азагынача тигез саклау. Җитдилек белән уен-көлкене, юмор элементларын аралаштыру, аларны урынлы-урынсыз бутамау, шулай ук берсенә генә үтә өстенлек биреп, икенчесен онытып калдырмау. Ниһаять, әсәрне башлый белү (беренче дөрес аккорд) һәм нәкъ үз урынында, үз вакытында нокта куя белү. Дөньяда үз урынына куелган ноктадан да көчле нәрсә юк, дип раслый мәгълүм хикәя остасы И. Бабель.

Менә шушы саналып үтелгәннәр һәм баш җитмәү аркасында саналмый калган бүтән бик күп компонентлар — бөтенесе бергә сәнгатьчә төгәллек дигән төшенчәне тәшкил итәләр дә инде. Кызганычка каршы, безнең прозадан сәнгатьчә төгәллекнең түгел, сәнгатьчә төгәлсезлекнең мисалларын күпләп-күпләп китерергә мөмкин. Әлеге шул, күңел кушуы буенча булудан бигрәк, заман кушуы буенча, шаушулы зур төзелешләргә барып, кулдан блокнотны төшермичә, бер участоктан икенчесенә сикергәләп, аяк астында буталып йөреп, соңыннан шул блокнотка теркәлгән факт валчыкларын, берсен икенчесенә төкерек белән ябыштырып, ашыкпошык әвәләп чыгарылган романнарны, повестьларны алып карыйк. Уйланып җитмәгән ситуацияләр, артык кисәкләр, метраж артыннан куу, чын белән ялганны, кешеләр белән пластмассадан катырган маникеннарны аера белмәү — мисал китереп торуның кирәге юк — тулып ята болар. Хәлбуки, заман бездән мондый маникеннарны сорамый, алдашып маташуларга юл куймыйк, заман бездән катлаулы чынбарлыгыбызны бөтен катлаулылыгында, каршылыкларыннан курыкмыйча ачып салган һәм художникның ихлас күңеле белән нурландырылган җитди сәнгать әсәрләре сорый.

Тоташ пластмассадан катырган «әсәрләр» турында озак тел чәйкап тору кирәк тә түгелдер, бәлки. Алар турында озаклап сөйли башласаң, алла сакласын, авторлары үзләрен язучылар дип уйлап, соңыннан җыен бетерә алмаслык чүп-чар белән әдәбиятны күмеп ташлаулары мөмкин — талантсыз кешедән барысын да көт! Хәтта игътибарга лаек дип тапкан, зур көч салынып, гомумән, сәнгать әсәре югарылыгына күтәрелгән әсәрләребездә дә сәнгатьчә төгәллек «аксаган» урыннар очрап-очрап куйгалый. Мин үзем, мәсәлән, Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» романын соңгы елларда дөнья күргән проза әсәрләре арасында иң җитдие дип саныйм. Иптәш зур көч салып, архив тузанында күп казынып, кузгаткан тормыш материалын үзе чын ихластан яратып, хәтта мавыгып һәм укучыларны да мавыктырырлык итеп, зур иҗат җимеше тудырган. Ләкин әнә шул җитди казанышта да әсәрнең беренче яртысы белән икенче яртысы арасында сөрлегеп китү үзен сиздерә. Әсәр, ислам кабул ителгәнче Идел, Кама буйларында яшәүче мәҗүси ыруглар, кабиләләр арасындагы үткен социаль мөнәсәбәтләрне, аларның көнкүрешендәге, гадәт-йолаларындагы кызыклы үзенчәлекләрне сурәтләп, киң планда башлана, ахырга тарая-тарая барып, ниһаять, бәк балаларының «башсыз» тәвәккәллекләрен, сөешү-мәхәббәт романтикаларын бик тәфсилле сурәтләү белән очлана. Бу ыруглар арасында социаль наразыйлыклар берьюлы кодрәт белән алынып ташланмаганнардыр лабаса. Шул ук исламны китереп тагу да бер дә каршылыксыз, майлаган кебек кенә узмагандыр. Һич югы, сәнгатьчә төгәллекне саклау зарурлыгыннан чыгып кына да автор мондый «сөрлегүләргә» юл куймаска тиеш иде кебек.

Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» повестенда сурәтләнгән райком секретаре Хафиз Кадергулов образының партия работнигы буларак та, кеше буларак та яхшы ук сөйкемле тәэсир калдырганлыгы әйтелде. Шул җөмләдән, проза турындагы бу бәхәсне ачып җибәргән Рафаэль Мостафин да әлеге әсәргә югары бәһа биреп узды. Гадел хөкем. Әйе, Хафиз Кадергулов күп кенә каршылыклар алдына куелган һәм шуларны хәл кадәренчә дөрес чишә ала торган җанлы, якты образ. Ләкин мин үзем әсәрне беренче кат укыганда да, бу мәкаләне язу уңаеннан яңадан карап чыкканда да бер икеләнүдән һич кенә дә арына алмадым. Бер кеше җилкәсенә артык күп йөк йөкләмибезме икән без? Райком секретаре буларак, райондагы хуҗалыкларны һәм кешеләр-кадрлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне белеп тору да Кадергулов җилкәсендә. Баласын ташлап киткән Магъсумә белән аның егет булып җиткәч кайтып төшкән улы Азат Ишбулдин һәм Магъсуманең хәзерге ире, комсыз һәм кенче Әхтәм белән Магъсумә арасындагы катлаулы коллизияләр... Шушы кыен хәлдә Магъсумә шулай ук райком секретаре

бәттә, аны да тыңларга һәм булдыра алганча булышлык күрсәтергә тиеш. Шуның өстенә Хафизның шәхси тормышы җимерелгән хәлдә. Сөекле хатыны, ике баласын — Ләйсән белән Рафисны ире карамагына калдырып, вакытсыз үлеп киткән. Хафиз яшьләй тол калу аянычын да татырга, балалар үстерү җаваплылыгын да күтәрергә тиеш. Шуның да өстенә тагын җизнәсенә әлек-әлектән гел яхшылык кына теләүче, ниндидер вак гайбәтләр аркасында ире ташлап качкан Гөләндәм балдыз да (син дә тол, мин дә тол, калган ягын белеп тор!) шул тирәдә бик сырпаланып йөри башлый. Кыскасы, мәшәкате баштан ашкан Кадергуловның. Бу хәлләрнең өстенә тагын кайдадыр Одесса өлкәсендә Елена Семеновна Солнцева дигән ханым да бар икән ич әле. Моннан күп еллар элек, Елена бу якларда медсестра булып эшләгәндә, Хафиз белән аның арасында яшьлек романы сыман саф җил дә булып алган. Еллар узган. Сугыш бетеп, еллар тынычлангач, Елена үз якларына кайтып киткән һәм... «Инде менә ничә еллар үткәч, Елена исеме Хафиз колагында кабат яңгырый. Ул аның өчен яңадан туды. Ялгыз гына түгел, улы Владислав белән бергә пәйда булды».

Эшләр хәтәргә китте монда! Бөтен мондагы эшләр өзелә, Хафизны яңа табышмак биләп ала: «Кайдан килгән Владислав тагын?» Яңа тасвир, яңа бүлекләр һәм «Хат алышу озакка китәчәк» дип, безнең хөрмәтле секретаребез, обкомнан рөхсәт алып, уттай эш өстендә Одесса якларына Еленаны эзләп очып китә. Эзли торгач, әлбәттә, таба. Икесендә дә үзгәрешләр. Иске хатирәләр, хәл-әхвәлләр, тәрҗемәи хәлләр. Ә ул Владислав дигәне Елена асрамага алып үстергән бер егет, имеш. Иске романтика, кабул булмаган теләкләр хакына Елена аңа Кадергулов фамилиясен биргән. Әлбәттә, берсүзсез ризалашалар һәм, коньяк кучтәнәчләре төяп, безнең секретаребыз кайту юлына чыга.

Хикәя эчендәге хикәя. Ләкин бик озынга киткән һәм һич акланмаган хикәя. Әлеге дә баягы: бу да шул сәнгатьчә төгәллек дигән җитди хакыйкатьне онытып җибәрүдән.

Югарыда яхшы яктан телгә алынган «Каты токым» романында элекке диңгезче егет Валентин Валентиновичның хат аша танышкан Валя атлы геолог кызны йөгерек фантазиясендә «гарше-көрсиләр»гә күтәреп, дагы нефть якларына килеп чыгуы, бригадага килеп кушылуы, бригада кешеләренең дә ярым ышану, ярым шиклык белән Тин-Тинычның хәлен уртаклашкан булып, аны әкренләп нефть эзләү эшенә кызыктырулары кызыклы табылган оригиналь бер лейтмотив булып романның буеннан-буена сузылып килә. Дөресен әйтергә кирәк, бу сызык укучыны да яхшы ук «котырта»: нәрсә булыр, ни белән бетәр икән? Ләкин ахырда бер нәрсә дә булмый. Яшь нефтьчеләр слетында, бик тә прозаик шартларда егет озак хыялланып эзләгән кызын табып ала һәм кочак җәеп үк кавышмасалар да, эшнең шул... кочакка таба юнәлеш алганлыгын сизеп, укучы күңелсезләнеп кала: «Әй, йөргән булды шашынып. Бактың исә, боларныкы да шул безнеке кебек соры финал белән бетәчәк!». Хәлбуки, нигә кирәк аларны табыштыру? Йөрсен иде Тин-Тиныч шул тиле хыялы белән. Бу тиле хыялы аны, бәлки, тагын да акыллырак эшләргә рухландырыр иде. Классик әдәбиятта шундый тиле хыяллар белән канатланып, кешеләргә файдалы эшләр эшләп йөрүче гуманист диваналар азмы!

Мәхәббәт романтикасын тизрәк «очлап» куярга ашыгу Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романында да үзен сиздергән иде. Ә болар бит барысы да, ахыр чиктә, сәнгатьчә төгәллеккә зарар китерә торган ашыгучанлык.

Аяз Гыйләҗев безнең әдәбиятта — драматургиядә булсын, прозада булсын — үз почеркын тапкан язучы. Бу «почерк» дигәнебез, барыннан да элек, бер яки берничә аерым шәхесне төп фокуска алып, алар тирәсендә үтә төпченеп, нәзакәтле тәфсилләлек белән аларны әсәрнең «кендеге»нә әйләндерү һәм, булдыра алса, хәтта бөтен җир шарын да шул «кендекләр» тирәсендә әйләнә итеп күрсәтергә тырышу. Шул арада язучының урыны белән уйландыра торган, урыны белән буталчык философиясе дә, нечкәртелеп эчкә яшеренгән пессимизмы да кушылып китә. «Өч аршин җир», «Бәрәү», «Зәй энҗеләре» һәм, ниһаять, менә «Урталыкта» повесте. Мин боларны яки болай язуны хөкем итеп әйтмим — яза бирсен күңеле кушканча. Мин хәтта «пессимизм» дигән сүзне дә чиркәнып кулланмадым. Кеше күңелендәге табигый бизәкләр палитрасыннан безнең бер бизәкне дә алып ташларга хакыбыз юк. Әгәр тормыш чынлыгына тугрылыклы калыйк дисәк. Ләкин бер хакыйкатьне онытмаска

кирәк: без кешенең эчке күлмәкләрендә казыну чорында яшәмибез, без гомум халыкның уртак шигаре булган бердәм хәрәкәт, юктан бар итү, гомуми иҗат энтузиазмы, кешеләр һәм халыклар белән кулга-кул тотынып, яңа дөнья төзү юнәлешендә яшибез. Аяз Гыйләҗевнең исенә төшерергә һәм вакытында иптәшләрчә кисәтергә кирәк: әгәр ул чорның кире кагып булмастай бу хакыйкатен тиешенчә төшенергә теләмичә, гел аерым шәхесләр җанында казыну юлы белән китсә, аның иҗатының чор иҗатыннан аерылу куркынычы бар. Бусы инде сәнгать тәгәллегенең җимерелүе генә түгел, бусы — хәвефлерәк.

Хәтеремә сеңеп калган: Тарусада, Ока елгасы ярына ябышып утырган һәм җәйләрен Мәскәүнең иҗат интеллигенциясе белән мыжгып торган сөйкемле Тарусада, Николай Богданов белән бер тәрҗемә өстендә «сугышып» көннәр, атналар уздырганда, колагым авырткач, мине Николайның хатыны, хәзер инде мәрхүмә Вера Дмитриевна, үзенең таныш профессорына алып китте. Заманында Кремль больницасында эшләгән, сабыр холыклы, кай ягы беләндер Чехов заманындагы борынгы интеллигентны хәтерләтүче бик тә укымышлы бу күркәм адәм турында, ныклап тотынсаң, үзенә бер китап язарга мөмкин булыр иде. Мин бу очракта аның үзе турында түгел, аның особнягының зур бер залында, бөтен бер стенаны биләп торган картина турында сөйләмәкче булам. Билгесез бер художник тарафыннан эшләнеп, дөньяның шушы почмагында сакланып калган бу панно «Кояшка табынучылар иртәсе» дип атала иде. Бүгенгедәй күз алдымда: зәңгәр диңгез җәелеп ята. Кайдадыр еракта-еракта әлегә бик үк зәңгәрәергә өлгермәгән күксел офык диңгез белән тоташкан. Һәм әнә шуннан, диңгезнең офык белән тоташкан серле ераклыгыннан, зур булып, тирә-ягына алсу нур чәчеп кояш чыгып килә. Ә бирге якта, алгы планда, диңгез ярында бер төркем олы гәүдәле мәһабәт кешеләр. Басканнар, баскан урыннарында катып калганнар, фани дөньяга ис китү юк, укыну-чукыну шулай ук юк, тынлык, тынлык! Һәм шул тынлык уртасында аларның чыгып килгән кояшка текәлгән күзләре. Олылау да бар ул күзләрдә, сәламләү дә бар, тантана да һәм чак-чак шомлану да бар шикелле. Нәрсә генә булмасын, алар шулай шаккаткан килеш торып калганнар, алар китмиләр, алар китмәскә, инанырга, какшамас иман белән инанырга дип килгәннәр. Һәм югарыда әйтелгәннәр өстенә тагын аларның күз карашларында чак-чак кына фанатизм да бар иде түгелме икән!

Юк, мине аларның фанатизмы куркытмады, була бирсен, әмма ул кешеләрнең кояшка булган бөек ышанычлары ахыр чиктә бөтен нәрсәне җиңәчәк кебек күренә иде. Һәрхәлдә, мин бу картинаны шулай тойдым.

Азмы-күпме игътибар казанырдай әдәби әсәрне, үземнең чордашым иҗат иткән әсәрне укып чыкканнан соң, мин һәр вакыт үземә-үзем бер сорауны куям: мөмкинме бу әсәрнең авторын теге зур гәүдәле кешеләр төркеме янына илтеп бастырырга? Ышанычы, иманы ягыннан шул төркемдә басып торырлык көч вә түземлек бармы монда?

Дөресен әйтим: кайвакытта икеләнебрәк тә калам: әсәр шома язылган, кешеләре дә, хәл-әхвәлләр дә үз урыннарында кебек, ә менә авторның үзе «чыгарган» кояшка теге зур гәүдәле кешеләрдә чагылган иман кебек чын ихластан инанганлыгы сизелми.

Ә бит без кояшның кайсы яктан чыгасын беләбез — безгә моны бөек тәгълимат ияләре әйтеп, язып калдырган.

Без тагын шуны да беләбез: без кояшның чыгышына таң калып, аны сәламләп тору өчен генә килмәдек дөньяга. Без кояшны чыгарышу, аның чыгышына җирне һәм күкне әзерләү, иң әһәмиятлесе, кешеләрне, үзебезне әзерләү өчен килдек. Һәм без үз алдыбызга бөек максат итеп куйган изге эшебезне җиренә җиткермичә, бер адым да чигенмәскә, бер кая да китмәскә дип килдек. Ә безнең алда торган бурычлар, кояшка табынучыларныкына караганда, чагыштыргысыз зуррак һәм җитдирәк. Проза турындагы әңгәмәгә кушылып әйтергә тиеш тапкан бу сүземне мин каламдаш иптәшләремнең барысына да — өлкәннәренә дә, яшьләренә дә — иҗат эшләрендә какшамас иман, зур бурычлар алдында каушап калмастай көч вә гайрәт теләү белән бетерәм.

# ӘЙДӘ КИТТЕК СӘФӘРГӘ...

Локман Бадыйкшан язган хикәяләрнең[1] эмоциональ яңгырашын нәкъ менә шушы чакыру тәшкил итә дисәк, әллә ни хата булмас шикелле. Җыентыктагы һәр хикәя яшь укучыны сәяхәткә өнди, тирә-якны танып белергә димли. Әлбәттә, коры үгет-нәсихәт белән түгел, персонажларны эштә, хәрәкәттә сурәтләү аша. Бер-бер артлы «агып» торган хәрәкәт, гыйбрәтле мавыгу белән автор яшь укучыны үзенә каратырга һәм аңар йогынты ясарга омтыла.

Шул кадәресен дә истән чыгармаска кирәк, әсәрне мавыкулы итеп кору — балалар язучысы алдына куела торган формаль таләп кенә түгел, бәлки яшь укучыга йогынты ясау чарасы да. Чөнки, психологлар күрсәткәнчә, балаларның игътибары агым су кебек үзгәреп торучан. Менә шушы үзенчәлек язучылар алдына таләп куя: балаларга адресланган әсәрләрнең сурәтләү тукымасы хәрәкәткә, динамикага, мавыгуга бай булсын.

Локман Бадыйкшан бу таләпне истән чыгармый: һәр адымда бала табигатен аңлап эш итәргә тырыша. Әмма уңышлы әсәр иҗат итү өчен, бала табигатен белү генә җитми, өстәвенә, әле баланы бала итеп сурәтли дә белергә кирәк. Бу яктан карагандa, Локман Бадыйкшан хикәяләрендә эш ничегрәк тора соң?

Билгеле булганча, тормышта һәр кешенең үз-үзен ничек тотуы ике төрле хискә бәйле. Аларның берсен кешенең табигый теләк һәм омтылышлары дип йөртәләр. Икенчесе — тиеш булу, бурычлы булу хисе. Мәктәп яшендәге укучыларда әлеге ике хиснең беренчесе көчлерәк була, табигый теләк еш кына бурыч хисен күмеп китә. Балалар өлкән яшьтәге кешеләрдән шул яклары белән аерылалар да. Локман Бадыйкшан хикәяләрендәге мавыгулар нәкъ менә шушы җирлектә — мавыгу, һәвәслек аркасында, мәсьәләгә җитди итеп карый белмәү нәтиҗәсендә килеп чыгалар. Автор моны ышандырырлык һәм үтемле итеп сурәтли. Мисалга «Биктимер абыйның дуслары» дип исемләнгән хикәяне алыйк.

Балаларның яраткан укытучылары Биктимер абый гаҗәеп матур кораб моделе ясый һәм аны дружина сборында пионерларга бүләк итәргә була. Шуның өчен өенә Әхмәт исемле малайны чакыра һәм аңа болай ди:

«— Бүген бу модельне сезнең дружинага бүләк итеп бирәм. Сбор башланганчы мәктәпкә илтеп куярга кирәк...»

Әхмәт бу йомышны шатланып кабул итә: «Менә бит ул ничек! Димәк, бүләкне мәктәпкә Әхмәт үзе алып барачак.» (4 бит.) Шул ук вакытта Әхмәттә икенче төрле хис — малайлык шуклыгы, табигый теләк баш калкыта. Мәктәпкә пионер сборына дип чыгып киткән малайны юл елга янына алып килә.

«Әхмәт арба тартасен җиргә куйды да як-ягына каранып алды. Бер кем дә күренми. Сбор башланырга да әле шактый вакыт бар. Өлгерер әле...

— Йөздереп карасам... Агач бит ул, аңа ни булсын?..»

Менә шушы йөздереп карау теләге Әхмәткә кушылган йомышны арткы планга этәрә: теләк бурычны, «тиеш булу»ны күмеп китә. Шуның нәтиҗәсендә малай шактый күңелсез хәлдә кала: Биктимер абыйлары ясаган корабны эштән чыгара яза, дружина сборын өзә.

Бу, шөбһәсез, балаларча эш итү галәмәте. Автор биредә бала табигатен дөрес сурәтли.

---

[1] Л. Бадыйкшан. Атау егете. Казан. 1971 ел.

Ләкин Локман Бадыйкшан [illegible] итеп сурәтләүне бөтен яктан китереп, һәр очракта да уңышлы хәл итеп җиткерә алмый әле. Алыйк диалогларны. Менә Әхмәт белән Хәсән сөйләшә:

«— Әле үзем сезгә барырга тора идем, ник озакладың?..

— Нәрсә борының салынды? Әйттем ич инде, тотабыз да артларыннан китәбез...

— Ничек инде китәбез, җәяүме?

— Анда күз күрер...

— Җәяү йөрисем килеп тормый әле...

— Их, син, сәяхәтче! Әйдә, мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм». (14 бит.)

Югарыда китерелгән өзек буенча сөйләшүчеләрне бер-берләреннән аерырга мөмкинме? Юк. Чөнки сөйләмдә бала холкы чагылмый, индивидуаль сыйфатлар сизелми. Бу — гади информация. Авторга балаларның — Әхмәт белән Хәсәннең — сәфәргә җыенуын хәбәр итәргә кирәк булган һәм әлеге сөйләм ярдәмендә ул моны эшли дә.

Хәлбуки, диалог — ул характер көзгесе. Анда сөйләшүчеләрнең индивидуаль төсмерләре чагылырга тиеш. Ниһаять, җыентыктагы хикәяләрдә сурәтләү тукымасына ятышмый торган тагын бер нәрсә бар. Ул шуннан гыйбарәт: автор еш кына укучыны алдан хәзерләп-нитеп тормыйча, аңар бөтенләй көтелмәгән яңалык китереп тоттыра. Әйтик, менә «Биктимер абыйның дуслары» хикәясендә Сөләйман бабайдан автор мондый сүзләр әйттерә:

«...Шулай да тапкансыз вакыт, явымлы көндә әрәмәгә кадәр кеймә йөздерергә килмәсәгез»... (10 бит.) Моннан чыгып фараз иткәндә, безнең яшь персонажлар яңгыр астында көймә йөздереп йөргән булып чыга. Ләкин бу — укучы өчен көтелмәгән яңалык. Чөнки хикәяләү дәвамында явымлы көн турында ләм-мим сүз булмады.

Шундый ук хәл белән «Җилкәннәр» исемле хикәядә дә очрашабыз. Әйтик, әллә кайда, ерак урман эчендә калган Әхмәт янына эте Актүш килеп чыга. Мөмкинме бу очрашу? Әгәр Актүш эзтабар булса, мөмкин. Ләкин автор бу турыда укучыга үз урынында хәбәр итмәде. Шулай булгач, әлеге очрашу да бөтенләй ясалма килеп чыга. Әйтәсе дә юк, мондый очраклыкларны сәнгать әсәре күтәрә алмый. Чөнки алар сурәтләгән вакыйгаларның табигый агышын бозалар, хәрәкәт логикасын җимерәләр.

Шәүлә төшерә торган кимчелекләр арасында иң җитдие тагын шул: автор кайбер хикәяләрендә сюжет ситуацияләрен мәктәп яшендәге балаларга хас конфликтларны тәгъбир итүгә нигезләми, бәлки аларны теге я бу күренешне, хәлне барлап чыгуга гына кора. «Ташкыялар атавында» — шундый хикәяләрнең берсе. Биредә балаларның эшчәнлеге тирә-якны танып белүгә юнәлтелгән күзәтүчелектән узмый. Нәтиҗәдә автор геройларның эчке дөньясына үтеп керә алмый, хикәя укучыда тышкы кызыксыну гына уята.

Локман Бадыйкшанның иҗат биографиясе күптәннән, атап әйткәндә, 30 еллар азагыннан башлана. Артта калган еллар саны кебек үк, автор язган хикәяләр саны да аз түгел. Аларның кайсылары альманахта басылган, кайберләре өлкә газеталарында, байтагы район газетасы битләрендә. «Атау кызы» Локман Бадыйкшанның 1959 елда басылып чыккан беренче мөстәкыйль җыентыгы иде. Җыентыкны, бигрәк тә анда урнаштырылган легендаларны, укучылар нигездә яратып каршыладылар. «Татарстан яшьләре» газетасының 1960 елгы беренче ноябрь санында басылган рецензиясендә Әнәс Камал болай дип язды: «...автор легендаларны бик бирелеп, бик рухланып яза. Сүз агышы җылы диңгез җиледәй йөрәкләргә үтеп керә һәм җыр булып яңгырый... Легендаларда халыкның, халык уллары, халык кызларының батырлыкларына дан җырлана».

«Атау егете» — авторның икенче җыентыгы. Биредә язучының яшь укучы күңеленә салган сукмагы тагы да киңәя төшкән. Дөрес, әле хәзер дә Локман Бадыйкшан хикәяләре әдәбиятыбыз мәйданында үзләренә «тәхеттән» урын дәгъва итәрлек түгел. Ләкин моңар карап Локман Бадыйкшан хикәяләрен бөтенләй юкка чыгарырга да ярамый. Чөнки дөньяда бер генә әдәбият та тоташ гениаль әсәрләрдән генә тормый.

Шушы караштан чыгып фикер йөрткәндә, Локман Бадыйкшан хикәяләренең дә әдәби процесста үз урыны бар. Алар яшь укучыларны эшкә, дөньяны танып-белергә рухландыралар. Аларда меңләгән эзтабарларга төбәлгән чакыру яңгырый — әйдә киттек сәфәргә!

Шәраф Әхмәдуллин.

# КАРЛЫГАЧ КҮКТӘ ОЧСЫН

1967 елда, шигырь сөючеләрнең гомуми игътибарын җәлеп итеп, поэзия күгенә «Беренче карлыгачлар» күтәрелгән иде. Аннан бирле алты ел вакыт узды. Бүген менә шул карлыгачларны яңадан барлап чыгасы, аларны аерым-аерым күзәтәсе, поэзия күгендә нинди биеклектә икәнлекләрен күрәсе килә.

Ул ел карлыгачларының берсе Тәүфикъ Камалиев иде. Яшь шагыйрьнең беренче китабына кергән күп кенә шигырьләре укучыда авторга карата өмет уятты. Аның «Умырзая» шигыре — әнә шундыйларның берсе. Безнең күңелгә умырзая иртә чыгып, тиз шиңә торган яз чәчәге булып кереп калган. Тәүфикъ Камалиев аны икенче яктан ачарга омтыла.

Ул — шаулы яз,
Апрель хәбәрчесе,
Гомерләре узмый заяга.
Юл буйлап, баш селкә-селкә,
Шулар
Озата бара сине кая да...

Шигырьне укып чыккач, син анда үзеңнең беренче мәхәббәтеңне, яшьлек дусларыңны, зәңгәр күкләргә ашкынган хыялларыңны табасың.

Ә шигырьнең:

Бу якларга тагын килеп җитә
Әйләнеп җир, дөнья тирәли,—

дигән соңгы юллары яшьлекнең мәңгелек, кабатланучан көчен авторның үзенчә раславы булып яңгырый.

Тәүфикъ Камалиевның беренче китабындагы хезмәт темасына багышланган шигырьләреннән «Хатка каршы хат» шигыре кызыклы гына. Байтак кына шагыйрьләрнең әсәрләрендә кешенең эше ул тудырган материаль байлык булып кына гәүдәләнсә, Т. Камалиев шигырендә исә кеше белән хезмәт үзара мөнәсәбәттә, тирәнрәк катламда карала. Шигырьнең герое — төзүче егет — үз эшенең мәгънәсен көн саен күреп тора:

Баракларның кыйшык тәрәзәсеннән
Баш тыга да ирләр, хатыннар
Кул изиләр безгә һәр көн саен...

Шигырь һичбер метафорасыз, патетикасыз, ләкин «барак тәрәзәләреннән кул болгаучылар» эшче егетне тизрәк эшләргә, өйсезләрне өйле итәргә омтылдыруы белән күңелгә кереп кала.

Кызганычка каршы, җыентыкта мондый әйбәт шигырьләр әзрәк. «Закирҗан» шигыре Тәүфикъ Камалиев иҗатындагы байтак характерлы якларны үз эченә ала.

Бөтен авыл купкан икән,
Түгел бит бу уен эш:
Бер Закирҗан өчен менә
Уздыралар җыелыш.

Шигырь шулай башланып китә. Аның герое — авылның уңган балта остасы. Автор Закирҗанның тырышлыгын, тынгысызлыгын гади, аңлаешлы итеп сөйли, геройның эшләгән эшен күрсәтә һәм Закирҗанны партиягә алуларын хәбәр итү белән шигырьне тәмамлый.

Дөньяны да күргән шактый,
Булган ул армиядә.
...Закирҗанны бертавыштан
Алдылар партиягә.

Балта остасының партиягә керүенә шатланып, авторның шигырь язарга утыруы бик аңлашыла. Ләкин бүгенге поэзия югарылыгыннан чыгып караганда, шигырь төссез килеп чыккан. Автор үзенең фикерен сөйләп кенә бирә, әсәрдә көчле поэтик детальләр, балта остасының чын тормышын һәм аның партиягә килү юлын ышандырырдай, шуның белән безне дә нык

тәэсирләндерердәй образлылык юк, шигырь гади бер информация булып кала. Закирҗанның тынгысызлыгын күрсәтү өчен, авторның «утырып ял иткәндә дә кармалый күк балтасын» диюе, герой характерына бер штрих сыза кебек. Ләкин анда да, «кармалый» кебек ямьсез сүз кулланып, автор бу детальнең тәэсирен нык киметә.

«Карлыгачлар» сериясендәге бу беренче китабы яшь шагыйрьнең уңышлы гына адымы кебек булса да, аның икенче елны ук чыккан «Сабыр канатлары сынмый» җыентыгы укучылар күңелендәге өметне сүлпәнәйтте. Китаптагы «Шагыйрь» һәм Мөнирә Булатовага багышланган шигырьләрендә яшь авторның үз хезмәтенә, әдәби әсәр иҗат итүгә шактый өстен һәм салкын каравы күренә.

Ниһаять, кулыбызда Тәүфикъ Камалиевның 1972 елда чыккан «Хәләл көчем белән»[1] җыентыгы.

Кереш сүз бу юлы да китапны «эшчеләр тормышы сурәтләнгән» җыентык дип тәкъдим итә. Андый шигырьләрнең иң әйбәте, мөгаен, «Трофим Назарыч»тыр. Автор һөнәр мәктәбендәге тәрбияче образын истә калырлык итеп сурәтли алган. «Язмыш ачысы» да әйбәт кенә тәэсир калдыра.

Кереш сүздә яңа китаптагы күпчелек әсәрләр хезмәт темасына багышланган дип язылса да, аңа кергән 52 шигырьнең 8 е генә хезмәт турында. Әлбәттә, авторны моның өчен генә гаепләп булмый. Чөнки бүгенге шагыйрьне иҗтимагый тормышның бүтән өлкәләрендә дә әһәмиятле темалар көтә. Һәм шуны аңлаган яшь шагыйрь үзе дә тематик диапазонын киңәйтергә тырыша, ахры. Җыентыкның башында ук урнаштырылган өч шигырь космос һәм кеше хакында. Беренче шигырь «Кеше күңеле» дип атала.

Кораб та бар,
Ул гына да
Җитми икән, тагын кирәк.
Җыйнау менеп утырырга
Айда иркен табын кирәк.
Тагын кирәк! —

дигән юлларны укыгач, Т. Камалиев сурәтләгән «күңелнең» шактый ук ярлы икәнен күрәсең.

[1] Т. Камалиев. Хәләл көчем белән. Шигырьләр. Казан. 1972. 80 бит. Бәясе 11 тиен. Җәмәгать тәртибендә Гәрәй Рәхим редакциялеге.

рендә Т. Камалиев, Айга менгән автомат станцияне арбага охшатып, аның белән крестьян арбасы арасында бәйләнеш урнаштырырга тели. Ләкин аңа бу ниятен тормышка ашырырга эзлексезлеге комачаулый. Автор шигырь уртасында, арбаны онытып, атны мактый башлый.

Әгәр дә җыентыкны рәттән тикшерү принцибына басып, моннан соңгы шигырьләргә күз салсаң — анда Октябрь революциясе турында да, райбашкарма председателе турында да, өч монтер, миччә һ. б. турында да шигырьләр табасың. Яшь шагыйрь аларның барысын да кайнар хис белән тереп җиткерә алмый. «Беренче карлыгачлар»да 1967 елда ук басылган сигез шигырен Т. Камалиевның яңадан бу җыентыкка кертүе дә — китапка хисле шигырьләр җитмәгәнлеген сизеп, аны элекке, «яшь чактагы» әйбәт шигырьләре белән сипләве кебек тоела. Яшь шагыйрьнең бүгенге иҗатына сипләү кирәклеген «Төрле чагым булган» исемле шигырен укыгач, тагын да ышанасың. Бу шигырь — безнең яшь шагыйрьләрнең үзләренең үткән тормышларын тикшерүгә багышланган хиссез, ясалма шигырьләренең тагын бер варианты. Тәүфикъ Камалиев та, үлчәү алып, аңа үзе эшләгән ниндидер ялгышларны, изгелекләрне өя һәм кайсы күбрәк икән дип, озак баш вата. Инде әллә ничә шигырьдә бер үзгәрүсез кулланылган шул ук «адашканмын, хәтта алдашканмын» кебек хиссез сүзләрне кабатлый.

Яшь шагыйрьнең бу китабын укып утырганда, еш кына бүгенге рус шагыйре Д. Самойловның:

Көтәм, забойда күмелеп калгандай,
Тормышыма шигырьнең килеп керүен,—

дигән юллары искә төшә. Алар — әз генә китап чыгарып та укучыларга нык танылган бу шагыйрьнең иҗат девизы кебек. Ул юллардан шагыйрьнең үз күңелендә шигырь туу моментын ничек газапланып, түземсезләнеп көткәнен тоясың, ул минутларның шагыйрь өчен никадәр кадерле, изге икәнен, аңа һава һәм яктылык кебек кирәк икәнен аңлыйсың.

«Хәләл көчем белән» китабында энҗе бөртекләредәй җемелдәп киткән әйбәт шигырьләрне күрми калу гаделсезлек булыр иде. «Кыска бәхәс» шигыре әнә шундыйларның берсе. Бу шаян бәхәс кыз белән егет арасында. Егет сихерне — сүздә,

ә кыз — күздә, ди. Тик кызның күзләренә күтәрелеп бер карау белән егет:

Хәзер инде мин дә сиздем,
Чыннан да бит — күздә сихер! —

диярга мәҗбүр.

Ләкин хәзер кыз аны шаярта:

Әле сөям димәдем бит,
Күздә түгел — сүздә сихер...

Бу шигырь безне җыйнаклыгы, шигъри энҗесе булуы белән җәлеп итә.

Моннан алты ел элек поэзия мәйданына чыгып канат каккан, күтәрелергә талпынган бер карлыгач нигә соң бүген поэзия күгендә иркенләп очмый? Аның янында бөтенләй дә күтәрелеп китә алмаган карлыгачлар күренә. Аларның ни өчен мондый язмышка төшүләрен дә ачыклыйсы килә.

Тормышта һәр кешенең кабатланмас үз юлы, үзенә генә хас кайгы-шатлыклары, күңел кичерешләре, рухи дөньясы бар. Шагыйрь шуларның тәүге сафлыгын, укучыны дулкынландыра алу сәләтен югалтмыйча җиткерә алса гына уңышка ирешә.

60 еллар уртасында Тәүфикъ Камалиевның яшьтәшләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харисов һәм Рөстәм Мингалимовларның поэзиягә килүләрендә дә шуңа охшаган күренеш күрдек. Һәм 70 елларда аларның, «Гадиләргә гимн», «Ак сөлге», «Алкын су» кебек, поэзия өчен вакыйга булган җыентыкларын сөенеп укыдык. Бу мисал шагыйрьнең үз тавышы өчен көрәшүе поэзия өчен дә, үзе өчен дә файда икәнлегенә ышандыра.

Ә Тәүфикъ Камалиевның юл башында ук поэзиябез традицияләрен **үз поэтик дөньясы**, үз шәхесе аша үстермәве аның шәхесенең шигырьдә күренмәвенә китерде. Яшь шагыйрьнең иҗатында К. Кулиевтан, И. Бунинннан, көндәлекләрдән алулар, бик күп төрле кешеләргә багышлаулар һәм газета хәбәрләрен сәбәп итеп шигырь язулар күбәйде. Болар, билгеле, яшь шагыйрьне үсүгә алып бармаячаклар.

Бүгенге көн шагыйре була алу өчен, укучы күңеленә үз сукмагыңны табу өстенә, тагын күңел күзеңнең **заман рухы белән үткенәйтелгән** булуы да кирәктер. Хәзер фән меңнәрчә кат зурайта яки кечерәйтә торган электрон телескоплар, микроскоплар һ. б. катлаулы приборлар ярдәмендә табигатьне тикшерә. Фәннең әнә шундый көчле аналитик методларына күнеккән егерменче гасыр кешесенең күңел таләпләрен поэзиянең тормышны иске ысуллар белән тикшерүе канәгатьләндерә алмый. Шигырьгә фикерле һәм хисле детальләр, тирән гомумиләштерүле образлар кирәк.

Карлыгачның югары күтәрелә алмавына тагын бер сәбәп — аның күп шигырьләрдә ихлас булмавы, ясалмалылык яки кайчагында төчелек. Яшь шагыйрь бер шигырендә Р. Зоргеның дусты, япон кызы Исига:

Күзләреңдә тагын бар бер шәүлә,
Сөйлә, җаным,
Я, әйт, нидән, ну! —

ди. Берәү дә «Җаным» дигән кешесенә шундук «ну!» дип дәшми бит.

Тәүфикъ Камалиев — поэзиягә тормышның үзеннән килгән шагыйрь. Әйе, безнең күз алдында алты ел элек «Беренче карлыгачлар»да канат каккан карлыгачның поэзия күгендә иркенләп очмавы, ягъни поэзиядә барлык көчен, җегәрен салып эшләмәве безне борчый. Бу хакта ул җитди уйланырга тиеш.

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# ЗУР ДУСЛЫКНЫҢ БЕР ИСТӘЛЕГЕ

*А. Н. Толстойның тууына 90 ел тулу уңае белән*

1941 елда, Татарстан язучыларының Габдулла Тукай исемендәге клубында уздырылган бер әдәби кичәдә Алексей Николаевич Толстой: «Казан миңа туган шәһәрем кебек якын. Монда мин беренче мәхәббәтемне таптым. Шушы шәһәрдә беренче тапкыр әдәби чиркәнчек алдым»,— дигән иде.

Дөрестән дә шулай. Әле Октябрь революциясенә кадәр ук А. Н. Толстой берничә мәртәбә Казанда булып китә. Казанда чыга торган «Волжский листок» газетасында үзенең беренче шигырьләрен бастыра.

Язучының Казан белән, татар язучылары белән дуслык элемтәләре совет власте елларында тагын да ныгый, көчәя төшә. А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты архивында шул хакта сөйли торган күп кенә материаллар: хатлар, телеграммалар, көндәлек дәфтәрләре саклана. Әлеге документларның берсе белән без укучыларны да таныштырып узмакчы булабыз.

1938 елның 17 январенда Таттосиздатның ул вакыттагы управляющие З. Тинчурин, «Икмәк» исемле повестен җибәрүен үтенеп, А. Н. Толстойга ашыгыч телеграмма суга. Архив материаллары арасында бу телеграмма да саклана:

> «Хөрмәтле Алексей Николаевич Толстой!
> Ашыгыч тесте татар теленә тәрҗемә итү өчен, Таттосиздат Сездән «Икмәк» исемле соңгы романыгызның бер данәсен түбәндәге адрес белән җибәрүегезне үтенә: Казан. Таттосиздат. Таттосиздат управляющие Тинчуринга».

Үтенеч канәгатьләндерелгән булса кирәк. Телеграмма тексты өстенә кызыл карандаш белән «эшләнде» дип язып куелган.

Нәшриятта «Икмәк» повестен тәрҗемә итү эшен Габдулла Хәбиб белән Бакый Халидкә тапшыралар. Эш процессында күп кенә кыенлыклар килеп чыга. Тәрҗемәчеләр, мәсәлән, оригиналдагы кайбер фразеологик тезмәләрне һәм канатлы сүзләрне аңлый алмый аптырап бетәләр. Ярдәм сорап, яңадан авторның үзенә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу кадәресен язучы Ибраһим Гази эшли.

Билгеле булганча, И. Гази ул елларда Таттосиздатта редактор булып эшли. «Икмәк» повестеның тәрҗемәсен редакцияләүне нәшрият җитәкчеләре аңа йөклиләр. Һәм ул, әсәрдәге аерым җөмләләрне тәрҗемә итү буенча киңәшләр сорап, 1939 елның 13 февралендә А. Н. Толстойга хат яза.

Түбәндә хатның тулы текстын китерәбез.

> «Кадерле Алексей Николаевич!
> Исәнмесез!
> Сезнең «Икмәк» исемле повестегызны тәрҗемә иткәндә, кайбер җөмләләрне һәм сүзләрне аңламадык:
> Мәсәлән, беренче бүлектә (5 бит) штабс-капитан болай сөйли: «Мы три года дрались, как черти. Мы с братом **загнали шпалеры и не пошевелимся.**

Точка». Нинди «шпалерлар» хакында сүз бара, бу очракта «загнали шпалеры» нәрсә аңлата?

9 биттә шундый урын бар: «Кто-то в солдатской шинели покатился сверху на каблуках по **лучевому проходу** к трибуне». «По лучевому проходу»ның нәрсә белдергәнен конкрет кына күз алдына китерә алмадык, шуңа күрә тәрҗемә итәргә кыенсынып торабыз.

38 биттә болай диелә: «Двести тридцать человек, шаг за шагом, по ледяным кочкам, с примерзшей к ним **падалью...**»

Сүз нинди «падаль» хакында бара? Бәлки, чүп-чардыр?

70 биттә: «... он обрастал людьми — энергичный, крепкий, на храпящей **кусающейся лошаденке**». Нәрсә бу — авызын ачкан атмы, әллә, чыннан да, тешли торган атмы?

90 биттә: «— Смирно! Щоб вам на пупе нарвало, товарищи!» Сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә, бу нәрсә дигән сүз һәм аны ничек тәрҗемә итәргә?

Аңлатыгыз, зинһар.

Татар язучысы И. Гази.

Безнең адрес: Казан, Татгосиздат, матур әдәбият секторы.

13/II — 39 ел».

Игътибар иткәнсездер, хат мәрхүм Ибраһим Газига хас стильдә язылган. Ул тыйнаклыгы, конкрет булуы белән аерылып тора. Шул ук вакытта югарыдагы хат аның нечкә зәвыклы редактор булуы, сәнгать әсәрләрен тәрҗемә итүгә ифрат сак килүе, җаваплы эш итеп каравы турында да сөйли.

В. Семенова,
филология фәннәре кандидаты.

# Зэки Нури

## Ут ник сүнде!

Шырпы сыздым. Мичтә кабынды Ут.
Мактанды Ут: «Эшли алам күпне! —
Кирәк икән, янгын була алам,
Төтен булып каплый алам күкне!»
Мактады да шулай шашып үзен,
Өлгермичә әйтеп соңгы сүзен,
Тынды Утым — гүя хуплау көтте...
Ә ник тынды? Чөнки утын бетте.

...Юк, якламыйм, сүнгән Утымны мин,
Мактыйм шырпым, мактыйм утынны мин!

## Күченә

Әләк язды таплап бик күп кешене...
Һәм танылды... үзенең кара исеме...
Инде шуны сизенгәч һәм аңлагач,
Яла ягар өчен кем дә калмагач,
Әнә хәзер, ачу йотып эчендә,
Бүтән йортка тиз-тиз бүген күчендә.
...Күпме торыр, тагын күпме азар икән —
Яңа йортта күпме әләк язар икән?

## Дәвамы булачак кыйсса

Малай берданбер. Исеме: Иркәҗан!
Ана һәм ата иртә торалар:
Кояш төшмәсен, уятмасын, дип,
Караватын каплап пәрдә коралар.

Кояш чыкмаса, көн сүрән булса,
Җил какмасын! дип, чара күрәләр.
Салган ашларын ашаган өчен,
«Шоколадка!» дип акча бирәләр...

Ата-анасы шулай назлагач,
«Бу — әрәмтамак!» дип әйтер кемнәр?
Килмәсме икән «Бушка ашады,
Бушка яшәде...» диясе көннәр?!.

## Рәхмәте булмады...

Кара төндә Төлке әтәч буды.
Өлгермәде ләкин ычкынып —
Эләкте ул хуҗа тозагына!
«Таңда,— диде,— каты кычкырып,
Бүлдермәсен әтәч дип тырыштым
Хуҗасының татлы йокысын...
Рәхмәт кенә әллә әйтешеп,
Китикме без өйгә кайтышып?!»
Көлде хуҗа: — Яка миңа түгел,
Хатын сиңа рәхмәт укысын.

## Әйтеп узды

Күлдән әби бер чиләк су алган.
Хәл җыя ул туктап сукмакта.
Бер чибәр кыз аны куып җитә,
Һәм, тормыйча хәтта туктап та,
Әйтеп уза: — Күп калмаган инде,
Бер сулышта менеп җитәрсең...
Уң кулыңны чиләк бик талдырса,
Сул кулыңа, әби, күтәр син!

## Сәер бер хәл

Тычканнар Мәче күмәләр
Бик күбәүләп җыелып.
Каян килгән игътибар бу,
Каян килгән кыюлык?
Эш шунда: Мәче аларга
Тими яшәгән икән —
Татлырак ризык сайлап, ул
Акмай ашаган икән.

## Төлке уенча

Әтәч белән Будильникны бутый кеше,
Икесе дә эш итә дип вакыт белән.
Гомер буе дус булганга хаклык белән,
Әтәчне мин Будильниктан артык күрәм:
Будильникны чөнки тотып ашап булмый,
Ә әтәчне... аны цехта ясап булмый!

### ИҖАТ СОЮЗЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

29 ноябрьда Кремльнең Зур сараенда СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән илебезнең иҗат союзлары һәм оешмалары идарәләренең берләштерелгән пленумы булды. Күп милләтле совет культурасының үсеше турында сүз барган бу пленумда партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури, Композиторлар союзы председателе Н. Г. Җиһанов, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры Р. А. Җиһаншина, композитор Р. Яхин иптәшләр катнашты.

### КОМПОЗИТОРЛАР СЪЕЗДЫ

13—14 ноябрьда консерваториянең зур залында Татарстан композиторларының III съезды үткәрелде.

Композиторлар союзы правлениесенең отчет докладын Татарстан композиторлар союзы правлениесе председателе, СССР халык артисты Н. Г. Җиһанов ясады. Ревизия комиссиясе докладын композитор И. Г. Шәмсетдинов ясады.

Съезд эшенә республикабыз композиторлары, язучылары, театр работниклары, Казан музыка уку йортлары студентлары, партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары җитәкчеләре катнашты. Съездга РСФСР композиторлар союзының җаваплы секретаре С. В. Стемпневский, Чувашия композиторлар союзы председателе Ф. М. Лукин, Эстония ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе профессор В. М. Рейманн, Башкорт АССРдан музыка белгече Ш. Ә. Мәсәгутов, РСФСР композиторлар союзының Югары Волга оешмасы вәкиле Г. Н. Комраков, Литва ССРдан музыка белгече В. П. Юодпусис, Удмуртиядан композитор Г. А. Корепанов һ. б. кунаклар да килгән иде.

Татарстан композиторларының III съездында соңгы 5 елда иҗат ителгән уңышлар турында сөйләнде, композиторлар һәм музыка белгечләренең эшчәнлегенә анализ ясалды.

Съезд көннәрендә композиторларыбызның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре тыңланды.

Соңыннан Ә. З. Бакиров, И. Н. Бәхтиярова, Н. Г. Җиһанов, Г. Я. Касаткина, А. З. Монасыйпов, Б. Н. Трубин, Җ. Х. Фәйзи, М. З. Яруллин, Р. Х. Яхин иптәшләр составында Татарстан композиторлар союзының яңа правлениесе һәм ревизия комиссиясе сайланды.

Правлениенең оештыру эшләренә багышланган утырышында правление председателе итеп Н. Г. Җиһанов, председатель урынбасарлары итеп Җ. Х. Фәйзи һәм М. З. Яруллиннар сайланды.

### БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

Ноябрь ахырында Саратов шәһәрендә Идел буе автономияле республикалары һәм өлкәләренең балалар язучылары һәм нәшрият хезмәткәрләренең семинары үткәрелде. Аны РСФСР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре Дәүләт комитеты һәм РСФСР язучылар союзы оештырган иде. Ул балалар әдәбиятын үстерү һәм аның сыйфатын тагын да яхшырту мәсьәләләрен тикшерде.

Семинарга республикабыздан вәкилләр булып балалар әдәбияты секциясе җитәкчесе шагыйрь Р. Мингалимов, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире язучы Ш. Рәкыйпов, нәшрият редакторы Л. Жаркова иптәшләр катнашты.

Язучы Ш. Рәкыйпов семинарда «Идел буе автономияле республикаларының балалар әдәбиятында интернациональ тәрбия мәсьәләсе» дигән темага доклад белән чыкты.

«...Татарстан китап нәшриятында башта татар телендә басылып, киң җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршыланган әсәрләрне рус теленә тәрҗемә итү елдан-ел киңрәк колач җәя. Н. Дәүлинең «Җимерелгән бастион» һәм «Яшәү белән үлем

арасында», А. Расихның «Ямашев», Г. Ахуновның «Канатлар кая илтә?», Р. Мостафинның «Патриот-шагыйрь М. Җәлил эзләре буйлап», Л. Ихсанованың «Чаткы», Ш. Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы?» һәм «Кайдан син, Җан?», М. Мәһдиевнең «Атадан бала яшь кала» h. б. лар нәкъ әнә шундыйлардан саналалар»,— дип сөйләде докладчы.

Фикер алышуларда катнашучылар исә республикабыз әдипләреннән Җ. Тәрҗемановның «Лобачевскийның яшьлеге», Х. Сарьянның «Әткәм һөнәре», Г. Паушкинның «Вернитесь, аисты», В. Байдеринның «Володя Ульянов в Казани и Кокушкине», Г. Бикушевның «Самый счастливый ковшик», И. Гольдшмитның «Октябрина и Рысь» китапларына да уңай бәя бирделәр.

## ТАТАРСТАН РӘССАМНАРЫ ЛЕНИНГРАДТА

СССР төзелүгә 50 ел тулу көненә багышлап ноябрь ахырында Ленинградның Рус музеенда Татарстан сынлы сәнгать әсәрләре күргәзмәсе ачылды. «Совет Татарстаны» исемле бу күргәзмәгә республикабызның 82 художнигы 200 гә якын әсәрен куйган иде.

Рус сынлы сәнгатенең гүзәл әсәрләре сакланган бу музейның алты зур залына куелган картиналар — рәссамнарыбызның соңгы ун елда иҗат иткән эшләре. Алар республикабызның революцион үткәне, Бөек Ватан сугышы, бүгенге тыныч тормыш турында сөйлиләр. В. И. Ленин образын ачуга багышланган картиналар, Чаллыдагы КамАЗ темасына эшләнгән әсәрләр аеруча игътибар үзәгендә булдылар. СССР Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Фәттаховның «Сабантуй» әсәрен, РСФСРның атказанган художнигы, Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Б. Урманченың «Сагыш», «Язучы Галимҗан Ибраһимов» исемле скульптураларын, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСР халык художнигы Х. Якуповның «Михаил Девятаевның җиңүе» исемле триптихын, В. Кудelькин, М. Хәйретдиновларның автогигант якларыннан язган әсәрләрен, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина скульптураларын күргәзмәгә килүчеләр аеруча яратып карадылар.

Күргәзмәнең иң беренче тамашачысы Советлар Союзы Герое космонавт Алексей Леонов иде. Шуннан башлап ике ай эчендә республикабыз рәссамнары эшләрен йөз меңләгән ленинградлылар яратып карадылар.

## АКВАРЕЛЬ КҮРГӘЗМӘСЕ

Мәскәүдә 3 нче Бөтенсоюз акварель күргәзмәсе булып узды. Бу күргәзмәдә барлык союздаш республика рәссамнарының 600 дән артык эше куелды. Казан рәссамы Гайшә Рахманкулованың бу күргәзмәгә куелган «Җәй», «Шомырт» акварельләренә башкалабызның сәнгать белгечләре югары бәя бирделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Декабрь аенда Татарстан язучылар союзы каршында эшләүче иҗат секцияләре икееллык эшләре турында отчет бирделәр. Бу җыелышларда төрле жанрлар буенча эшләүче һәр язучының иҗат эшчәнлегенә төпле анализ ясалды. Әдәбиятның үсеш тенденцияләре билгеләнде. Секцияләрнең эшчәнлекләренә бәя бирелде. Соңыннан һәр секциянең яңа бюросы сайланды. Бюро утырышларында проза секциясенең җитәкчесе итеп Барлас Камалов, поэзия секциясендә Хәсән Туфан, балалар әдәбияты секциясендә Рәстәм Мингалимов, тәнкыйть секциясендә Рафаэль Мостафин, тәрҗемәчеләр секциясендә Кыям Миңлебаев, рус язучылары секциясендә Тихон Журавлев һәм чуваш язучылары секциясендә Т. Петтерки итепшләр җитәкче итеп билгеләнде.

Барлык секцияләр дә яңа планнар белән эшләрен дәвам итә башладылар.

## ӘДӘБИ ТҮГӘРӘКЛӘРДӘ

Ноябрь азагында илебезнең бөек төзелешләре булган Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә әдәби түгәрәк утырышлары булды. Чаллы әдәби түгәрәге членнары КамАЗда эшләүче яшь шагыйрь Шәүкәт Сибгатуллин иҗаты турында фикер алыштылар. Ә Түбән Камадагы «Кама таңнары» әдәби түгәрәге утырышы яшь язучыларның вакытлы матбугатта катнашуларына багышланды. Түгәрәк утырышларында Татарстан язучылар союзының әдәби консультанты Гәрәй Рәхим катнашты.

## ЗУР БҮЛӘК

Татарстан язучылар союзы һәм аның әдәбиятны пропагандалау бюросы республикабыз авылларында күп санлы әдәби кичәләр, китап укучылар конференцияләре, урындагы яшь язучыларга консультацияләр оештыра. Шулай итеп, йөз меңләгән китап укучыларны татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштырып бара, аларда югары әдәби зәвык тәрбияләүдә булыша. 1972 елда гына да республикабыз язучылары эшчеләр, колхозчылар, студентлар, мәктәп балалары каршында меңнән артык чыгышлар ясадылар.

Менә шушы мактаулы эше өчен ноябрь аенда Татарстан язучылар союзына ВЦСПС һәм СССР Культура министрлыгының Күчмә кызыл байрагы бирелде. Шушы уңай белән Язучылар союзына җибәрелгән котлау телеграммасында мондый сүзләр бар иде:

«ВЦСПС һәм СССР Культура министрлыгы Татарстан АССР язучылар коллективын авылларда культура-шефлык эшләрен бик яхшы алып барганы өчен ВЦСПС һәм СССР Культура министрлыгының Күчмә кызыл байрагы һәм акчалата бүләк бирелү уңае белән чын күңелдән котлый. Авыл хуҗалыгы эшчәннәре белән дуслыкны алга таба да үстерүдә иҗади уңышлар тели.

ВЦСПСның секретаре Землянникова, СССР Культура министры Фурцева».

## ӘДӘБИ АТНАЛЫКЛАР

Республикабыз районнарында әдәби атналыклар культурабызның зур бәйрәменә әйләнә. Язучылар килүен авылларда көтеп алалар. Кунакларга алар үзләренең эшләре, тормышлары турында сөйлиләр. Колхозлардагы яңалыклар белән таныштыралар. Бу кызыклы әңгәмәләрдә язучылар үзләренең булачак геройлары белән якыннан аралашалар.

Кичләрен клублар, культура йортлары халык белән шыгрым тула. Монда әдәбият, сәнгать турында кызыклы сөйләшүләр бара. Язучылар кичәгә килүчеләрне татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштыралар, үзләренең әсәрләрен укыйлар, күп төрле сорауларга җаваплар бирәләр. Соңгы айларда гына да мондый кызыклы очрашулар Чүпрәле, Апас, Буа, Әгерҗе районнарында булып үтте.

Бу очрашуларда Риза Ишморат, Галимҗан Латыйп, Вакыйф Нуруллин, Радиф Гатауллин, Гөлшат Зәйнашева, Рәйсә Ишморатова, Рәшит Әхмәтҗанов, Диләрә Зөбәерова, Кояш Тимбикова, Кадыйр Сибгатуллин, Рәфкать Кәрамиев һ. б. язучылар катнашты.

## ДУСЛЫК КИЧӘЛӘРЕ

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән Татарстан язучылары күп өлкәләрдә булып, дуслык кичәләре үткәрүгә катнаштылар. Колхозларда һәм совхозларда, промышленность предприятиеләрендә, студентлар һәм укучылар алдында күп санлы чыгышлар ясадылар.

Шундый кичәләрнең берсе Пермь шәһәрендә булды. Пермь язучылар союзы чакыруы буенча анда филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Гази Кашшаф һәм шагыйрә Саҗидә Сөләйманова барды. «Бердәм гаиләдә» дигән бу әдәби кичәгә 1970 елда Пермь китап нәшриятында чыгарылган «Четыре ветра» дигән китапның авторлары — Башкортстан, Удмуртия һәм Коми-пермяк республикалары шагыйрьләре дә чакырылган иде.

* * *

19 ноябрьда Горький өлкәсе телевидениесе аша Идел буе халыклары әдәбиятларына багышланган дуслык кичәсе үткәрелде. Бу тапшыруда мари халык шагыйре Миклай Казаков, чуваш шагыйрьләре Стихван Шавлы һәм Владимир Воровьев, мордва шагыйрьләре Иван Пепляев һәм Максим Бебан, татар шагыйре Гәрәй Рәхим катнашты.

* * *

Ноябрь ахырларында Башкортстан комсомолы халыклар дуслыгына багышлап сәнгать атналыгы үткәрде. Анда Башкортстан, Татарстан, Удмуртия, Чувашия һәм Мари АССРның яшь иҗат көчләре катнашты. Алар Башкортстанның авыл хуҗалыгы районнарында, Уфа шәһәренең югары уку йортларында күп санлы иҗат кичәләре уздырдылар. Радио һәм телевидениедән чыгышлар ясадылар.

Муса Җәлил премиясе лауреаты, шагыйрь Равил Фәйзуллин җитәкчелегендәге Татарстан группасының чыгышларын Башкортстан тамашачылары яратып тыңладылар.

## НЕМЕЦ ДУСЛАР АЛКЫШЛЫЙ

Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте чакыруы буенча, республикабызның үзешчән сәнгать коллективлары Германия Демократик Республикасында булып кайтты. ТАССРның X еллыгы исемендәге культура сараеның «Яшьлек» халык бию ансамбле, «Сюрприз» эстрада халык ансамбле, Куйбышев исемендәге клубның «Саз» хатын-кызлар вокаль ансамбле ГДР башкаласы Берлинда һәм башка шәһәрләрдә, кооперативларда һ. б. урыннарда уннан артык концертлар бирделәр. Бөек Ватан сугышы истәлекләре белән бәйле урыннарда булдылар.

## «УФА МОҢНАРЫ»

Декабрь башларында М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында «Уфа моңнары» дигән әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте.

Программаның үзәгендә тамашачыларыбызның яраткан җырчысы, РСФСРның атказанган, Башкортстан АССРның халык артисткасы Фәридә Кудашева җырлары булып, Башкорт поэзиясенең талантлы вәкилләре Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин, Марат Кәримов, Равил Бикбаевларның чыгышлары кичәнең эчтәлеген баетты, тулыландырды.

Башкортстанның халык артисты, композитор Бәхти Гайсин җитәкчелегендәге инструменталь ансамбльгә кушылып, Фәридә Кудашева башкорт һәм татар халкының борынгы һәм хәзерге заман көйләрен, башкорт һәм татар композиторларының эстрада әсәрләрен зур осталык белән башкарды.

РСФСРның атказанган, Башкортстанның халык артисты, Бөтендөнья фестивале лауреаты Мөхәммәт Идрисов һәм биюче Рафаэль Саматовлар татар, башкорт, мари халыкларының көчен, куәтен, җор күңелен, дәртен күрсәткән биюләрне башкардылар.

Тамашачылар Ә. Атнабаевның тормышның үзе кебек кырыс та, бераз моңлы да, бераз көлкеле дә шигырьләрен, Р. Сафинның лирик-фәлсәфи уйлануларын, М. Кәримовның йомшак күңелле якты юморын, Р. Бикбаевның гражданлык хисләре белән тулы әсәрләрен алкышлап каршы алды.

Халыклар дуслыгына багышланган бу кичәләрне артист Рафаэль Галиев алып барды.

«Уфа моңнары» Казан, Зеленодольск шәһәрләрендә атна буена яңгырап торды.

## ШАГЫЙРЬ БҮЛӘГЕ

Казакъ халкының бөек акыны Җамбул Җабаевка 125 ел тулуга багышлап Мәскәүнең Колонналы залында тантаналы кичә уздырылды. Бу тантанада татар шагыйре Әхмәт Исхак та катнашты. Ул Җамбул әсәрләренең татар әдәбиятына йогынтысы турында сөйләде, казакъ әдәбият музеена тапшыру өчен, Җамбул шигырьләрен үзе тәрҗемә итеп чыгарган китапны бүләк итте.

## ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

Ноябрь аенда Мәскәүдә бөтенсоюз драматурглар семинары эшләде. Анда Казаннан Аяз Гыйләҗев «Өч аршин җир», Туфан Миңнуллин «Ат караклары», Диас Вәлиев «Крушение» дигән пьесалары белән катнаштылар. Ике атна барган бу семинарда драматургларның яңа әсәрләре укып тикшерелде.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Декабрь башында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында Тукай премиясе лауреаты, драматург Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» дигән әсәре тамашачыга күрсәтелә башлады. Яшь буынны тәрбияләү, мораль темаларын үзәккә алып, укытучылар тормышыннан язылган бу әсәрне тамашачылар яратып каршы алды. Пьесаны сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт куйды. Баш рольләрне Татарстанның атказанган артисткасы Гәүһәр Камалова, Татарстанның атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Ринат Таҗетдинов һәм Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисткасы Наилә Гәрәевалар башкарды.

Сәхнә оформлениесен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, художник Әнәс Тумашев эшләде.

* * *

Качалов исемендәге Зур драма театры коллективы яшь драматург Диас Вәлиевнең «Продолжение» әсәрен сәхнәгә куйды. Чорыбызның зур төзелешләреннән берсе булган КамАЗ эшчеләре тормышын чагылдырган бу әсәрне сәхнәгә театрның баш режиссеры Н. Орлов куйды.

# ...ТЛЫ КӨННӘР
# ХАТИРӘСЕ

...ез бу санда Мансур Рәхимовның ил
...рлары темасына багышланган рәсем-
...н бирәбез.



**ЯН ЮДИН.**
«Красная Горкада». ▶



*Тик Туган ил булсын*
*Туган ил*
*Мин илемдә үскән*
*Батыр ир. —*

**РӘХИМ САТТАР.**



## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

*«...Әбелмәнихның шиге зур булса да, Шомаларның гаебен исбат итә алмаган... Бер җилле көнне авылда ут чыгып, авылның шактый өлеше янгач,— Шомаларның да иске өйләре һәм каралтылары янган иде,— алар авылга сүз тараткannар, янәсе, бу Әбелмәних эше... Халыкның ачуы котырган чак булган, шунда ук Әбелмәнихны бөтен гаиләсе белән авылдан сөрүне сорап, приговор җыя башлаганнар».*

Бу юллар **Габдрахман Әпсәләмовның** «Күк күкрәр» романыннан алынды. Журналыбызның дүртенче саны шушы роман белән башланачак. Авылдан куыла язган Әбелмәних — хәзер Мәскәүдә, Исмәт бай өенең аскы катында яши башлый.

**Эдуард Касыймовның** «Һаваларда тургай» романының ахырын укырсыз.

Поэзия яратучыларга **Шәүкәт Галиев, Дифгать Сирай** шигырьләрен, **Ренат Харисовның** «Җитмеш икенче ел икмәге» поэмасын тәкъдим итәбез. Дуслар җырыннан — рус шагыйре **Геннадий Паушкин**, башкорт шагыйре **Максуд Сөндекле**, удмурт шагыйре **Флор Васильев** шигырьләре бирелә.

**Федор Вольный** «Тугандаш Татарстанда» дигән мәкаләсендә Татарстан турында булган күңелле, файдалы очрашуларны тасвирлаган.

СССРның «Белем» җәмгыяте тарафыннан галимнәр өчен Америкага махсус оештырылган сәяхәткә Татарстаннан тарих фәннәре кандидаты **Морзаһит Вәлиев** катнашкан. Аның «Америка буйлап сәяхәт» дигән юл язмалары урнаштырыла. Анда сез Вашингтон, Лос-Анджелос, Сан-Франциско, Чикаго, Нью-Йорк шәһәрләрендәге зиннәтле йортлар, негрлар яши торган җимерек кварталлар, гомумән, Америка капма-каршылыгы белән очрашырсыз.

Татарстан АССР Мәгариф министры, СССР Педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты **Мирза Мәхмүтовның** «Милли мәктәп үсештә» дигән мәкаләсендә татар милли мәктәпләре үсүе фактларда, саннарда күрсәтелә. Рус мәктәбендә укучы татар балаларына татар телен укытуның торышы, андагы алдынгы укытучылар, аларның эш тәҗрибәсе яктыртыла.

Сәнгать сөючеләр өчен **Мөнип Газарның** РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Фатыйма Ильскаяның сәхнә тормышын яктырткан очеркы тәкъдим ителә.

Әдәби тәнкыйть бүлеге **Гали Халитның** «Әдәбиятның төп үзәнен һәм үзенчәлеген күреп» дигән мәкаләсен тәкъдим итә.

Безнең календарь, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210